



# КАЗАН УТЛАРЫ

3
МАРТ
1982



Г. ХАЖИӘХМӘТОВ. Г. Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясенә ясалган рәсем.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**3**

МАРТ
1982

## *Бу санда*

СССРның ТӨЗЕЛҮЕНӘ 60 ЕЛ

Г. АФЗАЛ. Абыйлар үткән юл. Шигырь . . . . 3

Н. ФӘТТАХ. Сызгыра торган уклар. Роман . . 4

8 МАРТ — ХАЛЫКАРА ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕ

Н. ИЗМАЙЛОВА. Әлешемә тигән көмешем. Шигырьләр . . . . . 89
Г. ЗӘЙНАШЕВА. Яшел үзәнлек. Шигырьләр . . . 91
М. ФӘЙЗУЛЛИНА. Авылдан хатлар. Шигырьләр . 93
В. ТУКТАРОВА. Бирелер. Шигырьләр . . . . . 95
Р. ХАФИЗОВА. Сөенечле хәбәр. Хикәя . . . . 97
Ф. ӘҺЛИУЛЛИНА. Гөлбакчада. Ярымәкият . . . 103
К. ШӘФИКОВА. Бүген җилләр талгын исте. Шигырьләр . . . . . 105
Э. ШӘРИФУЛЛИНА. Җиркәем, җирем, җир генәм. Шигырьләр . . . . . 107
Б. РӘХИМОВА. Ишелә, җимерелә дөньясы. Шигырьләр . . . . . 109
Р. БАУБЕКОВА-КОЖЕВНИКОВА. Хәтерлим. Шигырьләр . . . . . 110

Р. КӘРАМИ. Өзелгән чәчәк. Хикәя . . . . . . . 112

ОЧЕРК ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

Х. ЗАРИПОВ. Җиләк өлгереп килә... . . . . . 121
Ә. ГАФФАР. Бакча . . . . . . . . . 127
Т. СӘГЫЙТОВ. Кеше хакына . . . . . . . 135

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Язлар тагын килер... . . . 140
Ф. ГАЛИМУЛЛИН. Юл кешесе . . . . . . . 147

КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. МОСТАФИН. Түбән Каманың бәхетле язмышы . . . . . 156
Р. НИЗАМИЕВ. Тугрылык . . . . . . . . 158

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

Ф. ШӘФИГУЛЛИН. Кешелек тавына күтәрелгәндә . . . . . . . . . . . . . . 160
М. ГОСМАНОВ, Н. ХИСАМОВ. Дәрдмәнд әсәрләренең яңа басмасы . . . . . . . . . . 163

ӘДӘБИ ТЕЛ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

А. ЮСУПОВА. Беренче карлыгачлар . . . . . 167

СӘНГАТЬ

Д. ВӘЛИЕВА, Р. ШАҺИЕВА. Күңел җәүһәрләре . 172

МАНСУР МОЗАФФАРОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

К. ТАҖИЕВА. Ул тормышка гашыйк иде . . . 179
Истәлекләр . . . . . . . . . . . . . . 181

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

М. МӨЛЕКОВ. Ил батыры . . . . . . . . . . 185

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

К. БУЛАТОВА. Хәзерге Дон-Жуанның яңа кыйссасы . . . . . . . . . . . . . . . . 189

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 190

**Редакциянең адресы:** Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63; сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ

Редколлегия: ШАМИЛ БИКЧУРИН, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ *(баш редактор урынбасары)*, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, СИБГАТ ХӘКИМ, ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН, НИЛ ЮЗИЕВ

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Т. Сибгатуллина*

Производствога бирелде 30/XI-1981 ел. Басарга кул куелды 3/II-1982 ел. ПФ 09003. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 65044 экз. Заказ Д-441. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1982 ел.



# СССРның төзелүенә 60 ел

## Гамил Афзал

### Абыйлар үткән юл

Күзем белән ялкын йотып,
Урамга карап торам:
Җилфердәгән байрак тотып
Абыйлар үткән урам...

Зәһәрле, ачы буранда
Кем көлеп яулык болгар?
Сыкылы, салкын томанда
Абыйлар үткән юллар.

Үләннәрнең чугын тарап,
Исәдер назлы җилләр...
Әҗәлнең күзенә карап
Абыйлар менгән үрләр.

Хозурланып барасың да,
Карыйсың бераз туктап:
Таулар-ташлар арасында
Абыйлар үткән сукмак.

Яз җиленә җанын ачып,
Кәккүкле урман шаулар.
Җәһәннәм читенә басып
Абыйлар кичкән таулар...

Тимердәй торган йөрәккә
Тимер кепшәләр төбәп,
Тевтоннар килгән төбәк бу,
Абыйлар җиңгән төбәк.

Гарасат йөргән үрләрдә
Ташка әйләнгән йөзләр...
Үлемне җиңгән үзәндә
Абыйлар үткән эзләр.

Сугышчан бурыч үтәлде,
Офыклар зәңгәр хәзер.
Тере чәчәкләр үтәле —
Абыйлар яткан кабер.

Нурихан Фәттах

# СЫЗГЫРА ТОРГАН УКЛАР

РОМАН

*Беренче китап*

## Сүз башы

*Яшәү өчен җирдә борын-борынгыдан көрәш барган. Ачлык белән дә, табигать китергән бәла-казалар, көтелмәгән афәтләр белән дә көрәшергә туры килгән кешегә. Ләкин төрле ыру-кабиләләр, илләрнең бер-берсенә каршы сугышуы, бер-берсен юк итеп, җиңүче булып калу өчен көрәш алып баруы тарих хәтерендә, мәңге җуелмас җөй сыман, аеруча нык сакланып калган. Каң коюлы рәхимсез яуларда ниләр генә уйлап чыгармаганнар. Әйтик, бер кабиләдә үтерелгән дошман башын җыю белән мавыкканнар. Икенче бер кабиләдә һәр көнне яуда әсир төшкән яшь, таза сугышчының канлы йөрәген кояшка корбан итеп бирә торган булганнар.*

*Комсыз патшалар, ханнар, корольләр боерыгына буйсынып илләр белән илләр, халыклар белән халыклар бәрелешкән. Кешеләр чебен урынына кырылган, авыллар, шәһәрләр җир белән тигезләнгән.*

*Дөрес, сугышлар күп төрле булган. Берәүләр, әйтик, коллыктан котылу өчен көрәшсәләр, икенче берәүләр ярсып илбасарларга каршы ташланганнар.*

*Ни генә булмасын, беркайчан да җирдә оҗмах булмаган.*

*Бер-берсенә карата дошманлык тойгысына караганда шулай да янәшә тыныч яшәргә омтылыш кешедә һәрвакыт көчлерәк булган. Ачлыктан, туфаннан, яулардан исән калган Кеше менә безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Ул Кеше — син һәм мин. Җирдә бүген кемнәр исән, кем сулый, уйлый ала, кем сөя, сөелә белә — барысы да без — кешеләр.*

*Ачлыктан, туфаннан һәм Чыңгыз хан, Аксак Тимер яуларыннан, Освенцим һәм Дахау мичләреннән исән калган безнең токым бәхетле дә, бәхетсез дә. Бәхетле шуның өчен, — чөнки без бар. Без яшибез. Бәхетсез шуның өчен, — чөнки безнең белән бергә дөньяда әле һаман үлем куркынычы, сугыш куркынычы яши.*

*Юкка-барга бер-берсенә яу чапкан борынгы кабилә кешеләре белән чагыштырганда, бүгенге кеше аңлырак та, белемлерәк тә. Бүгенге кешенең академияләре, институтлары, галимнәре, инженерлары бар. Ләкин шул ук вакытта галимнәр, инженерлар уйлап тапкан үтерү, җимерү кораллары да бар. Хәзерге «уклар», ясалма «ми» куелган бүгенге «ташлар» белән авылларны-шәһәрләрне генә түгел, бөтен ил-дәүләтләрне җир белән тигезләргә була. Бүгенге көндә аерым илләр мәнфәгате генә түгел, бөтен кешелек язмышы кыл өстендә тора. Бер кешенең мәгънәсез боерыгына буйсынып кнопкага басу белән дә бөтен җир шарының көле күккә очарга мөмкин!*

*Шулай булгач, өстән таш яумый дип, бездә сугыш инде күптән бетте дип, тынычланырга әле иртәрәк. 1945 нең май аеннан бирле кырык еллап вакыт узса да, фронт һаман дәвам итә. Фронт бары чигерелгән, фронт бары күчерелгән генә. Ут сызыгы кайчагында Анголадан үтә, кайчагында Вьетнамнан үтә. Ләкин, каян гына үтмәсен, ул һәрвакыт безнең күңелләргә килеп тоташа.*

*Шулай булгач, җирдә иминлек өчен, тынычлык өчен көрәш ул — синең белән минем өчен, безнең бүгенгебез һәм киләчәгебез өчен көрәш дигән сүз.*

*Менә шундый алга киткән, менә шундый куркыныч заманда тарих нигә кирәк тә, тарихи романнар нигә кирәк? Тарих ул — искелек, тарих ул — артталык. Аңлы, белемле кайберәүләрнең шулайрак та фикер йөртүләре ихтимал. Чыннан да шулаймы соң бу? Юк, алай түгел! Тарих — искелек, тарих — артталык. Ләкин тарих — ул гыйбрәт, акыл һәм тәҗрибә! Ашыга торган, ашкына торган хәтәр заманда боларның барысы*

*да кеше өчен иң кирәкле сыйфатлар. Шулай булгач, җирдә иминлекне, тынычлыкны яклап, кара көчләр белән көрәшү ул безнең бүгенгебез һәм киләчәгебез өчен генә түгел, безнең үткәнебез өчен дә көрәш дигән сүз.*

*Һәрбер аңлы, намуслы кеше алдында бүген: дөньялар имин булырмы, мең еллар буена тупланган цивилизацияне, сәнгать җәүһәрләрен, кешелек акылын саклап калып булырмы дигән котылгысыз сорау торганда, мин җавап эзләп, киңәш-гыйбрәт эзләп, тарихка борылып карыйм. Мең мәртәбә үлеп, мең мәртәбә терелгән, мең мәртәбә таркалып, мең мәртәбә яңадан кушылган һәм бернинди җил-давылга, бернинди карбуранга карамыйча, бернинди янау-куркытуларга, ачлык, туфанга карамыйча, һәрбер җан иясе кебек һаман яктыга, һаман кояшка үрләгән тырыш, чыдам халыкның тарихы миндә һәрвакыт ышаныч, ныклык һәм горурлык тойгысы тудыра. Ирексездән Тукайның «халык зур ул, көчле ул» дигән сүзләрен искә төшерәсең. Шушы ук сүзләрне үз халкыңа карата гына түгел, гомумән, барлык халыкларга карата кулланасы килә: әйе, халык зур ул, көчле ул. Гасырлар буена үлемне җиңеп, бүгенгәчә дәвамын саклап килгән халык һәм халыклар моннан соң да вәхшилекне, үзара дошманлыкны һәм мәгънәсез сугышларны җиңә алыр дип әйтәсе килә. Кеше һәм аның акылына булган ышаныч шуңарга ныклы нигез бирә.*

*Төрки халыкларның борынгы тарихын чагылдырган һәм «Сызгыра торган уклар» дип аталган әлеге романымны язганда минем күңелне менә шундыйрак уйлар борчулар биләде.*

*АВТОР.*



## Беренче баб

### I



Барыс елының[1] сигезенче ае, икенче көне иде. Иртән иртүк, кояш чыгар-чыкмас борын, атларын кызу атлатып, Туман каган урдасына, Көнчыгыш капка алдына бер төркем яшьләр килеп туктады. Арадан берсе — алай[2] башы, алгарак чыгып, йокылыуяулы торгакларга[3]:

— Атсыз күлне боз тоткан! — дип кычкырды.

Бүген төнлә шактый суыткан иде. Иртәнгә таба күлне боз тотуы ихтималы турында торгаклар үзләре дә кичтән үк чамалап куйганнар иде. Ләкин алар шул чамалау белән генә тынычландылар — беркемнең дә иртән күл буена барып, үз күзләре белән карап килергә башы җитмәде. Тучи бәк тәгин углан әнә бик күпләрдән өлгеррәк булып чыккан. Кара син аны, нинди кычкыра — яу килгәнмени!

Капка янында сакта торган кораллы ирләр кыймылдашып куйдылар, тәгин угланга якынрак килделәр. Артык сикереп төшмичә, шулай да беркадәр кызыксыну белдереп, сораштыра башладылар: кайчан күрдең, кай төшендә күрдең? — диделәр. Куанычыннан авызы ерылырга гына торган яшь углан күл ягына төртеп күрсәтә-күрсәтә сөйләде.

Атсыз күлдә беренче тапкыр боз күренүне сөннәр изгегә юрыйлар иде. Күлне боз тоту ул көз бетеп кыш башлануны белдерә. Кыш башлану белән исә бер үк төрле көндәлек тормышта күптән көтелгән үзгәрешләр, күңелле һәм тынгысыз мәшәкатьләр башланачак. Урдадан бер-ике чакрым чамасы ераклыкта урнашкан Атсыз күлне боз тоту

---

[1] Барыс елы — унике еллык төрки календарьда өченче ел. Унике елның һәр елы берәр хайван исеме белән аталган һәм ел санын исәпләгәндә: барыс елы, куян елы... дип санаганнар.
[2] Алай — гаскәри берләшмә, төркем.
[3] Торгак — кораллы сакчы.

белән, барыннан да элек, Сөн иленең башы Туман каган[1] беренче ауга чыгачак иде. Аннан соң корбан, җыен, ярышлар китә, күршеләргә яу чабулар башлана. Кыш буена эш житәрлек сөн иренә! Шуңа күрә дә беренче боз тоту турында хәбәр алып килгән беренче кешегә каган үз кулы белән бүләк бирә. Шуңа күрә дә ике як бите уттай янып торган яшь тәгин углан шулай таң тишегеннән капка төбенә килеп җиткән, куанычыннан нишләргә белми елмая иде.

Тәгин углан[2] алып килгән яңалыкны торгаклар иң элек каравыл агасы Туңгак алыпка әйтергә булдылар. Туңгак алып капка янындагы каравыл өендә йоклап ята иде — аны шундук уяттылар. Яңа бозны карау өчен Туңгак алып күл буена үзе китте. Тиз арада ул аннан әйләнеп тә кайтты. Әйе, күлне чыннан да боз тоткан иде. Каравыл агасы, көнчыгыш офык ягына каранглап, беравык уйланып торды, шуннан соң ул тәгин угланның үзен генә ияртеп капка аша үтте. Угланның унике егете — җан сакчылары тышта капка янында торып калдылар.

Җир өстендәге караңгылык инде таралган иде, көнчыгыштан ачыкланып таң яралып килә — шулай булгач, озакламый каган да йокыдан торырга тиеш иде. Ак урданы[3] әйләндереп алган тышкы бөжраның эченә кергәч, үзәккә таба сузылган туры юлдан алар юри салмак кына, ашыкмыйча гына бардылар.

— Син соң нишләп әле болай, олуг тучи бәк... Атсыз күлне боз тотканын карарга дип кайттыңмени? — диде Туңгак алып.

Аның тавышында яшь угланга карата хөрмәт һәм шулай ук аталарча кырыслык сизелде.

— Шатлыктан онытып җибәргәнмен — йөзбашы[4] Күчәр мине синең янга җибәрде, Туңгак алып, — диде углан ашыгып.

— Минем янга килгән өчен иң элек каганны күрергә булдыңмы? — диде каравыл агасы.

— Аның өчен түгел, Туңгак алып, — диде яшь углан. — Төнне без Атсыз күл буенда кундык, шуңа күрә менә...

— Йөзбашы Күчәр ник җибәрде минем янга?

— Теге яктан ниндидер шикле кешеләр чыкты.

— Бик шиклемени? — дигән булды Туңгак алып.

— Кем белә инде аларны... Йөзбашы Күчәр сиңа әйтергә кушты. Мин аларны Таштугайга кадәр озатып куйдым да, әни янына кереп чыктым.

— Таштугайда Исәнтәйне күрдеңме соң?

— Күрмәдем. Алар аны сорадылар. Банхуа диделәр. Хатыны авырлы.

— Хатыннары да бармени? — диде Туңгак алып.

— Бар. Бер хатын, өч ир кеше, — диде углан.

Туңгак алып тынып калды. «Шикле кешеләр» турында сораштыру аңа күңелсез була башлады, ахрысы. Ул тынгач углан да беренче булып сүз башларга кыймады.

---

[1] Каган — борынгы һәм урта гасырларда төрки халыкларда ил-дәүләт башы. Патша, хан.

[2] Тәгин углан — каганның тәхеткә хокукы булган углы.

[3] Урда — каганның, бәкләрнең ныгытылган һәм кораллы ирләр тарафыннан саклана торган торагы. Шулай ук «башкала» мәгънәсендә дә кулланылырга мөмкин.

[4] Йөзбашы — борынгы төркиләрдә, шул исәптән сөннәрдә, гаскәр унлы берәмлекләргә (төркемнәргә, алайларга) бүленгән булган. Иң кечкенә берәмлек — ун кешелек төркем (алай) булган һәм аның башы (командиры) унбашы дип аталган. Йөзкешелек төркемнең командиры — йөзбашы, меңкешелек төркеменең командиры — меңбашы дип аталган. Ун мең кешелек берәмлек төмән булган һәм аның башлыгы төмәнбәк дип аталган. Барлык гаскәр сү, су яисә чиру дип аталган. Гаскәр, чиру башлыгы — сүбашы, субашы булган.

Бераз шулай тын гына баргач Туңгак алып угланның өй хәлләрен сораштыра башлады. Әниең тазамы, мал-туарыгыз исәнме, илегез тынычмы, диде.

Әкрен генә сөйләнгәләп алар һаман үзәккә таба баруларында булдылар. Тапталган киң юлның ике ягында да, билгеле бер тәртиптә һәм бер-берсеннән билгеле ара калдырып утырган бай киез өйләр торып калды. Бу өйләрдә каганның күп санлы туган-тумачалары, якын кешеләре яши иде. Тын гына йокымсырап утырган ак киез өйләр арасында кыршылып беткән иске тун кигән берән-сәрән картлар, карчыклар күренде. Болар — иртүк торып казан асарга, учак ягарга тотынган коллар-каралар иде.

Юл буендагы өйләр беткәч, ачык җир башланды. Ачык җир бер ук[1] чамасы сузылды. Шуннан соң икенче божра башланды. Тышкы божрага караганда бу икенче божра кечерәк иде. Шул ук вакытта монда сак та көчлерәк иде — сөңге башакларын югары каратып тоткан төнге торгакларның атлары бер-берсенә терәлеп диярлек торалар.

Туңгак алып белән тәгин угланны монда да капка аша берсүзсез үткәреп җибәрделәр. Тышкы божраның Көнчыгыш капкасыннан килә торган туры юл, эчке божра аша үтеп, үзәккә таба сузылды. Монда да юлдан читтә биек ак өйләр торып калды. Бу өйләрдә каганның дәрәҗәлерәк туган-тумачалары, имчеләре, күрәзәчеләре, ашчылары һәм башка якын кешеләре яши иде.

Икенче божра капкасыннан үтеп, бер ярты чакрым чамасы җир килгәч, каравыл агасы Туңгак алып белән тәгин углан өченче божра каршында туктап калдылар. Алар каршысында җәяүле ирләрдән торган җанлы койма калкып чыкты. Җанлы койма артында очлы такталардан җыйналган биек текмә күренде. Арырак, иң уртада, түбәсе күккә тиярдәй булып, Туман каганның Ак өе калкып утыра иде.

Каравыл агасы Туңгак алып белән яшь угланны өченче божра аша үткәреп җибәрергә беркем ашыкмады. Шулай ук алар үзләре дә берничнди ашыгу билгесе күрсәтмәделәр — төнге торгаклардан бер читтәрәк туктап калган көе, тавыш-тынсыз гына көтә башладылар. Кояш әле чыкмаган. Шулай булгач, Кояшның җирдәге улы — Сөн иленең патшасы бөек каган да әле күзләрен ачмаган булырга тиеш...

## II

Еракта, дулкын-дулкын булып яткан караңгы калкулыклар артында, күптән көткән кояш күренде. Таусыз, урмансыз шәрә җир астыннан югары таба бөркелеп иң элек аксыл-тонык яктылык таралды. Аксыл яктылык бераздан ялкынланып янган ут төсенә керә башлады. Төнне уяу уздырган торгак ирләр, изге бер тынлык саклап, чыгып килгән кояш ягына борылдылар.

Кояшның чыгып килүе турында бөек каганга хәбәр бирелде: тышкы ишек сакчысы эчке ишек сакчысына пышылдады, эчке ишек сакчысы каган белән бер өйдә төн куна торган карчыкка пышылдады. Карчык кол кызны уятты. Кол кыз биек өйнең түрендә, ефәк чатыр эчендәге түшәктә төн уздырган ахирәте Табылдыкны уятты. Табылдык каганны уятты. Ул аңа шулай ук киенергә дә булышты. Аннан соң, ярым йокылы күзләрен көчкә ачып, идәндәге озын киез өстеннән абына-сөртенә атлаган авыр таза ир кешене ул җитәкләп ишек янына алып килде. Алып килде дә, эчке ишек сакчысына тапшырды. Ишек төбендә төн уздырган кортка ашыгып киез ишекне күтәрде.

---

[1] Бер ук — атылган ук ераклыгына тигез ара.

Эчке ишектән чыккач, каган бераз җир караңгы аралыктан барды. Тышкы ишек сакчысы — шулай ук кортка кеше — каган ишеккә килеп җитәр-җитмәс борын, ике кат киез япманы күтәреп куйды.

Тышкы ишектән чыгу белән, Туман каганның җылы битенә коры салкын килеп бәрелде. Шул ук мәлдә ул, күнегелгән бер гадәт белән башын калкытып, күк читенә күз ташлап алды.

Корткалар җиргә ак киез җәйделәр. Бөек каган ялан аяклары белән йомшак, салкын киезгә басып, берничә адым алга атлады, җиргә тезләнде.

— Кояш әтекәем, кояш әнекәем! — диде ул, югары үрләп килгән изге яктылыкка эндәшеп. — Илемә-көнемә, малыма-туарыма тереклек биргән, җирдәге киекләрне, судагы балыкларны яраткан олуг Тәңрем! Бүген дә, иртәгә дә — мәңге мине изгелегеңнән ташлама!

Ул, шулай дип әйтү белән, тун чабуларын тотыштырып, аягына басты.

— Аман булсын туар көн! — дип кычкырдылар текмә артындагы кораллы ирләр.

— Аман булсын! — диде каган.

Шулай итеп, изге Сөн илендә изге көн туды. Биек текмә — койманың Көнчыгыш капкасы янында байраклар күтәрелде, капка ачылды. Беренче булып капкадан уң кул карачы[1] Бүзбала керде. Башка көннәрдә ул алай капка ачылу белән үк кереп җитми иде, каган үз йомышларын үтәп, урын-җир җыештырылганчы, өйдәге кыз-кыркын таранганчы, киенгәнче беравык көтеп тора иде. Бүген ул әнә иртәләгән. Бер-бер ашыгыч эш килеп чыкты микәнни?

Туман каган җылы өйгә кереп китәргә дигән уеннан кире кайтып, ишек төбендә тоткарланып калды һәм уң кул карачы Бүзбаланы көтеп тора башлады.

Бүзбала килде, бик кыенлык белән бөгелә торган авыр, симез билен бөгеп, бөек каганны туган көн белән котлады, аннары, артык сүз озайтып тормыйча, сөенечле хәбәр китергән тәгин углан турында әйтте.

Каганның салкын йөзендә җылыну билгесе күренеп китте. Бүген төнлә кулне боз тоту ихтималы турында ул да исеннән чыгарган иде. Куңелле хәбәр бу! Әнә нинди изге көнгә туры килгән! Беренче боз көне кайбер елларда иске ай азагына туры килә, шунлыктан кышы да игелекле булмый. Кайбер елларда иске ай белән яңа ай алышынган төндә катырып җибәрә — алай булганда да ел бик уңай килми. Быел менә ичмасам изге дисәң дә ярый. Иртәгә яңа айның өченче көне, аның инде ныгыган, яшь, көчле чагы. Беренче ау өчен моннан да кулай көннең булуы да мөмкин түгел.

— Хәбәр китерүче керсен,— диде каган Бүзбалага.

Аз сүзле Бүзбала, аны-моны әйтеп тормыйча, кире борылды. Борынборыннан килгән йола шундый иде: каганның йоклый торган чагы булмаса, ашыгыч я сөенечле хәбәр китергән кеше, кем булуына да карамастан, аның янына керә ала иде. Күп тә үтмәде, уң кул карачы Бүзбала тәгин углан белән каравыл агасы Туңгак алыпны ияртеп, биек ак өйгә килеп керде.

Түбәдәге төнлек киезе әле ачылмаган иде, учакта шулай ук ялкынланып ут та янмый. Шунлыктан иркен өй эчендә иртәнге җылымса караңгылык саклана иде. Өстен-башын алыштырырга өлгермәгән каган, кымыз салынган алтын кәсә тотып, керүчеләргә каршы атлады. Туңгак алып, ил башын котлап бил бөкте. Яшь углан ашыгып шулай ук иДәнгә егылды, тезләнде һәм ярым шәрә ир кешенең аякларына кулын тидерде. Аның кулы кайнар иде. Каган, нидер сизенеп, күзләрен ныграк ачты, яшь угланга иелебрәк карады.

---

[1] Карачы — каганның идарә итүдә ярдәмчесе.

— Углым! Албуга! Син түгелме соң? — диде ул гаҗәпләнеп.

— Мин бу, эти! — диде Албуга куанып.

Ата кеше углына торырга булышты, яратып аны күкрәгенә кочты. Шуннан соң ул үз кулы белән углына кымыз бирде дә бүлдермичә аның эчкәнен көтеп торды.

— Үзең күрдеңме, берәрсе әйттеме? — диде ул.

— Үзем күрдем, эти! — диде тагин углан сөенеп.— Йөзбашы Күчәр мине урдага җибәрде. Капкадан керергә соңга калдым да, егетләрем белән күл буенда кундым. Синнән мактау сүзләре ишетәсем килде, эти.

— Бүләк аласың да килдеме? — диде күңеле йомшаган каган.

— Килде, эти! — диде Албуга.

— Ни телисең — сора, — диде ата кеше.

Борылып ул түргә, өйнең уртасына таба атлады. Башкалар да аның артыннан иярделәр. Шул чакны тыштагы төнлек киезен кемдер ачып куйды. Югарыдагы түгәрәк ачыклыктан өй эченә иртәнге яктылык бөркелде. Каган туктады, борылып углына карады һәм аның куанычлы йөзендәге үзгәрешне күреп, аптырабрак калды. Шат күңелле яшь углан, киек күргән аучы кебек, тынып, сагаеп калган иде. Бу вакытта ул, әйтерсең, үзенең кемлеген дә, кайдалыгын да оныткан иде. Аның уттай янган тынгысыз күз карашы өй эчендәге ниндидер нәрсәгә — гадәттән тыш кызык, серле нәрсәгә юнәлгән иде.

Ата кеше ирексездән углы караган якка борылды. Аның өлкән бичәдән туган өлкән углы ятак янында урын-җир җыештырып булашкан кол кыз Табылдыкка карап тора иде. Өйгә чит ирләр керүен күрми калган Табылдык исә өстен-башын алыштырып өлгермәгән иде. Иртәнге ярым-караңгыда ярым-йокылы килеш ул кырык яшьлек каганга түгел, унсигез яшьлек угланга да аеруча сылу, күркәм булып күренде.

Тагин углан әллә үзенең кайдалыгын исенә төшерде, әллә янындагы ирләрнең күз карашларын сизенде — куркытылган болан кебек тиз генә карашын читкә борды. Шундук ул яңадан атасы алдына тезләнде, бөтенләй үзгәргән, юашланып калган көчсез бер тавыш белән, тыны бетеп:

— Эти! — диде.

Аның бу ялварулы «эти!» сүзенең ниндидер үтенеч, өмет белдергәнен ата кеше бик яхшы сизенеп алды. Аның йөзе үзгәреп китте. «Юк, булмаячак! Атаңның авызыннан тартып алырга иртәрәк әле сиңа!» — дип уйлады ул кинәт кенә өлкән углына карата көнләшү һәм дошманлык хисе тоеп. Төньяк таулар-урманнар артында яшәүче кыпчаклардан яу белән алып кайткан Табылдыкны ул барлык кызларыннан-кырнакларыннан артыграк ярата иде. Ул аны дөньядагы барлык хатын-кыздан артыграк ярата иде. Ул үзенең ятагы янына килде, күтәрелгән чыбылдык итәген төшерде. Кол кыз чыбылдык артында күренмәс булгач, ул янә углына борылып карады.

— Нәрсә... углым? — диде ул, тынычланырга тырышып.

Яшь углан, корышкан телен әйләндерә алмыйча, шактый озак тынып торды.

— Синең белән ауга барасым килә, эти,— диде ул төшенке генә.

— Барырсың,— диде ата кеше.

## III

Туман [1] каган иң оста, иң дәртле аучылардан санала иде. Ау дигәндә ул ашавын-эчүен дә, йокысын да оныта ала. Шулай да ул бүген алай

[1] Туман — тарихи шәхес. Сөн дәүләтенең баш кешесе, ханы, патшасы. Борынгы язмаларда исеме сакланып калган беренче каган. Туган елы билгеле түгел. Үлгән елы — безнең эрага кадәр 209 ел.

ашавын-эчүен онытып торырга булмады. Туңгак алыпны ул аучыларны юлга әзерләргә дип чыгарып җибәрде, ашчыларга иртәнге ашны тизрәк өлгертергә кушты. Барысын да чыгарып җибәреп, өйдә ул үзенең углы белән генә калды. Киенгән арада Албуганың әнисе, туганнары турында, мал-туар турында сорашты. Тәгин углы белән ул ягымлы, йомшак булырга тырышты. Шулай да, үз гомерендә беренче тапкыр, ахрысы, аның янында читләшү сыман бер сәер тойгы кичерде. Табылдык инде икенче якка чыгып киткән иде. Ләкин ата кеше, әлерәк кенә булган нәрсәне янадан күз алдына китереп, тагын бер мәртәбә ятак ягына карап алды.

Иртәнге йомышларын йомышлап, киемнәрен алыштыргач ул кымыз эчеп куйды, дөрләп янган учак янына килде, углына да кымыз бирде, аны да учак янына чакырды. «Күңеле булсын — бүләк итеп бирергә кирәк сөенчегә»,— дип уйлады ул бераздан йомшый башлап. Ләкин мондый йомшаклыкка үзе үк каршы төште: «Иртәрәк әле»,— диде үз-үзенә. Аннан соң бүген изге ау көне. Ау эшенә хатын-кыз кысылмаска тиеш.

Алар шулай учак янында вакыт уздырдылар. Яшь углан, туңган кеше сыман, кулларын җылытыштырды, ата кеше учактагы утыннарны әвеш-түеш китерде. Ике арада уңайсызлык барлыкка килгәнен икесе дә сизеп утырдылар.

— Син, углым, кайсы якка басарга уйлыйсың? — диде ата кеше, сүз югында сүз булсын дигәндәй.

— Көньякка, эти!

— Басарсың.

— Алайса мин китим, эти? — диде Албуга, урыныннан кузгалып.

— Китмә, минем белән ашарсың,— диде каган, ләкин, нидер уйлап, болай гына әйтеп куйды: — Китәсең килсә, кит,— диде.— Аучы кеше аучылар янында булыр инде ул.

Яшь углан аның ни өчен шулай тиз арада кире уйлавын бик дөрес сизенде — әтисе бит иртән үзенең якын кырнаклары белән генә ашый! Кызарынып, аяк-кулларының авырлыгын тоеп ул ишеккә юнәлде. Әйе, әтисе белән аның арасына нидер, кемдер үтеп керде. Моның кем яисә нәрсә икәнлеген аңлау өчен иң яхшысы үзең генә калырга кирәк иде. Ишектән чыгып китәр алдыннан ул шулай да түзмәде, артына — учак ягына түгел — биек, калын чыбылдык ягына борылып карады. Анда беркем юк иде. Кол кызның чыбылдык ярыгыннан карап калуын ул, билгеле, күрә алмады.

Аучылар тышкы боҗра читендә, киң яланда җыелырга тиешләр иде. Атасы өеннән чыккач та тәгин углан туры шунда — аучылар җыелышырга тиешле урынга ашыкты. Ул килеп җиткәндә инде төрле яктан атлы, коралл ырләр туплана башлаганнар иде.

Иң элек шонкарчылар җыелып бетте. Барлыгы алар утыз кеше иде. Шонкарчылар яшел белән тышланган озын тун, башларына — кара төлке тотылган, ак белән тышланган очлы бүрек кигәннәр иде. Иңбашларына аларның тырнаклары, томшыклары бәйле бөркетләр утыртылган иде.

Шонкарчылардан соң туктаусыз алга ыргылган йөнтәс баракларын[1] көчкә тыеп, үзләренә билгеләнгән урынга этчеләр җыелды. Алар да барлыгы утыз кеше иде, барысының да өс-баш киемнәре бер төсле: кызгылт-сары белән тышланган озын тун, киң кара билбау, башларында — кызыл төлке тотылган, сары белән тышланган колакчынлы бүрек иде.

Шонкарчылар яланның — көнчыгышына, этчеләр көнбатыш ягына тезелделәр. Сөңгечеләр көньякка җыелды. Аларга кушылыр алдыннан

[1] Барак — ау этләренең көчле бер токымы.

Албуга ашады, киемнәрен алыштырды, кулына сөңге алды. Сөңгечеләр йоны тышка каратып тегелгән кыска тун кигәннәр. Алар барысы да диярлек кыскарак буйлылар, киң күкрәкле, нык беләкле кырыс ирләр. Болар яхшы аучылар гына түгел, болар яхшы сугышчылар да иде.

Сөңгечеләр янында тәгин угланны Туңгак алып үзе каршылады.

— Каганның боерыгы шундый — ул сезнең белән барачак, — диде Туңгак алып, аңлатырга кирәк табып.

Сөңгечеләр тәгин угланга — калку буйлы, таза, ләкин бик яшь угланга беренче кат күргән кебек гаҗәпләнеп карадылар. Аларның усал, сынаулы, хәтта мыскыллы күз карашын тоеп, Албуга кызарынгандай итте, сөңгесен кысыбрак тотты.

— Кабан дуңгызы эчен айкасын диде микәнни каган?

— Марал таптап китсен диде микән әллә? — диештеләр ачулы ирләр, ризасызлык белән.

— Карга күтәреп китсен дигәндер! — диде кемдер усал итеп.

Монысы инде яшь угланның янагына китереп суккандай булды.

— Юк! — диде ул кычкырып. — Мин барыбер сезнең белән барам!

Бу бераз гына балаларчарак килеп чыкты. Тавышы да бик көчсез булып, чәрелдәвек булып яңгырады. Шулай да сөңгече ирләр тынып калдылар — тәгин углан белән сүз көрәштерүнең әле беркайчан да изгегә юралганы юк иде.

— Барсын әйдә, барсын... үзе теләгәч, — диделәр икенче яктагы ирләр, аны яклаган булып.

— Тезелегез! — диде Туңгак алып сөңгечеләргә.

Сөңгечеләр, һәркем үз урынын белеп, бер сафка тезелде.

— Кая телисең, шунда бас! — диде Туңгак алып тәгин угланга.

Албуга «карга күтәреп китсен» дигән ирне күрмәсә дә, аның кемлеген чамалап калган иде. Ул әлеге ир турысына борылды һәм күрәләтә бер үртәү, киреләнү белән:

— Мин аның урынына басам! — диде.

Барысы да төртеп күрсәтелгән ир ягына борылып карадылар һәм барысы да диярлек «ах!» итеп җибәрде. Хәтта Туңгак алыпның да йөзенә аптырау билгесе чыкты. Тәгин углан төртеп күрсәткән ир атаклы сөңгече, атаклы сугышчы Салчак алып иде. Тезмәдә аның урыны уңнан санаганда уникенче — шуңа күрә дә ул сөңгечеләр арасында иң бәхетлесе иде.

Салчак алып агарынып китте, нидер әйтмәкче булды, нидер эшләмәкче булды. Ләкин берни әйтә дә, эшли дә алмады. Мыек чылгыен селкеткәләп, авызын кыйшайтып, уйлангандай итеп торды да, кинәт кенә юашланып, килешеп:

— Ярар, — диде. — Мин синә ачуланмыйм... син дә миңа ачуланма, тәгин углан.

Шундук ул тезмәдән алга чыкты, читкә китеп барды.

Сөңгечеләр каршысына — төн ягына укчылар тезелде.

Ул арада аучылар янына каган үзе килеп җитте. Аучылар, каганны котлап, барысы да бер авыздан:

— Алас! Алас![1] — дип кычкырдылар.

— Аман булсын изге көн! — диде аларга каган.

Каган аучыларга якынрак килде, тезмәдәге ирләрне, аларның коралларын, киемнәрен, этләрне, бөркетләрне берәм-берәм күздән кичерде. Сөңгечеләр янында ул озаграк тукталды. Салчак алыпның ятим бала кебек бер читтә торуын ул күрми калмады, билгеле. Уникенче урында үз улын күреп ул гаҗәпләнгәндәй итте. Шул ук мәлдә аның күңе-

---

[1] Алас — борынгы төркиләрдә исәнлек теләүне белдергән эндәш сүз. «Алас» шулай ук күккә, аллага ялваруны да аңлаткан һәм хәзерге «Ура!» мәгънәсендә дә кила алган.

ләндә яңадан ят, теге сәер тойгы калкып чыкты. Өлкән улы Албуга аңа тагын атасының белмәсенә, беркем кулын сузмаска тиешле яшерен белмәсенә сорамыйча аяк баскан шикелле тоелды.

— Сине кем монда куйды, улым? — диде ул тыелып кына.

— Мин, бөек каган! — диде Туңгак алып ашыгып.

— Мин сезнең белән туйга бармыйм, ауга барам,— диде каган. Туңгак алыпның бу эшен тупламыйча.— Салчак алыпны үз урынына куй. Син, улым, минем янда булырсың.

Атасының мондый карарына тәгин угланның хәтере калды. Ирләр арасында атасы аны — үз улын, тәгин улын хур итте, мыскыл итте сыман тоелды. «Әти, син үзең әйттең ич!» дип кычкырасы килде аның. «Мин сиңа сөенечле хәбәр китердем!» — дип тә әйтәсе килде. Ләкин ул берни әйтә алмады. Атасы каган белән телләшергә ул әле бик кечкенә иде.

— Ярар, әти,— диде ул, үпкәсен эченә йотып.

## IV

Аучылар барлыгы йөз егерме кеше булды. Алардан тыш төп-төгәл мең кешелек каралар җыелды. Болары төрле эшчеләр, сугымчылар, ашчылар, өйчеләр иде. Беренче ауга, каган авына шуннан да азрак яисә күбрәк кеше алынмый.

Иң алдан аучылар китте. Алардан бераз калышып каралар кузгалды. Алар көнчыгышка карап бардылар. Арттан бик үк көчле булмаган салкын җил исте. Югарыга күтәрелгән саен кечерәеп күренгән аксылсаргылт кояш яктысында, бер болытсыз чалт аяз күк йөзе астында иксез-чиксез дала җәелеп ятты. Йөзләгән, меңләгән тояклар таптавына җавап итеп каты җир өсте гүләп-дөпелдәп торды.

Кояш төшлеккә җиткәнче алар шактый кызу бардылар. Кояш түбәнәя башлаганда аучылар тирә-ягында тәбәнәк таллар, карама куаклары, камышлар үскән елга буена килеп чыктылар. Аркача дип аталган бу елга моннан ике көн ераклыктагы Кара-тау арасындагы Кылычкыя төбеннән, куе урман арасыннан агып чыга иде. Бу тирәдә ул тигез җирдән җәелеп, тынычланып ага һәм монда инде аның ярлары да текә түгел, агымы да кискен, шау-шулы түгел иде. Елганың чит-читләрен бүген төнлә юка боз элпәсе каплап алган иде.

Аркача буенча Туман каган бераз туктап тын алырга булды. Сөңге сабы белән төрткәләп ул бозның ныклыгын тикшереп карады. Боз әле юка иде. Туман каган Аркачага беренче корбан бирде — юлда килгәндә үзе атып алган киек канын үзе тишкән бәкегә тамызды. Башкалар да юлда очраган беренче суга корбан бирделәр: берәүләр суга берәр кисәк пешкән ит я булмаса берәр чүметем кипкән эремчек ыргыттылар, икенче берәүләр киемнәреннән җеп, йон ише нәрсәләр өзеп ташлады.

Шул эшләрне башкаргач, аучылар яңадан атларына атландылар, уңга борылдылар да, елганың сул як яры буйлап көньякка таба кузгалып киттеләр. Урдадан чыгу белән көньяк-көнчыгышка карап китсәләр, турыдан алар таулар янына тизрәк барып җиткән булырлар иде. Ләкин ул чагында төньяк-көнбатыштан искән җил аларга гел аркан булыр иде һәм Кара-таудагы киекләр дә аучылар килеп җиткәнче качышып беткән булырлар иде. Шуны исәпләп аучылар шулай бормалы юлдан киттеләр дә. Алар көньякка борылу белән, җил дә үзгәрде — ул хәзер арттан түгел, уңнан исә башлады. Әле елга агымына, әле җил юнәлешенә яраклашып, алар бик әкрен бардылар. Ничек кенә барсалар да, Кара-тауның, Кылыч-кыяның алар артына, көнчыгыш ягына барып чыгарга тиешләр иде.

Төнне аучылар елга буенда — тал, карама куаклары арасында үткәрделәр. Ут якмадылар, казан асмадылар — коры-сары белән тамак ялгадылар да, асларына тире, киез кисәкләре җәеп, туп-туры җир өстенә сузылып йокыга талдылар.

Аучыларның эзләренә басып диярлек арттан мең кешелек каралар килде.

Икенче көнне дә алар туктаусыз юлда булдылар. Еракта, каршыда күкселләнеп биек таулар күренде. Моңарчы тип-тигез булган җир өсте әкренләп үзгәрә барды. Әледән-әле түгәрәк калкулыклар, шәрә таш кисәкләре чыгып торган текә ярлар, иске күл урыннары — батынкы үзәнлекләр очрый башлады. Елга ярлары биегәйде, тарайды, кысан ярлар арасында таштан ташка сикереп аккан суның тавышы ерактан ук ишетелеп торды.

Кара-тауга ярты көнлек юл калгач, аучылар елганың уң ягына чыктылар һәм бераз җир көнчыгышка карап бардылар. Көн кичкә авышканда янадан уңга борылдылар. Кичкә таба әкренәя башлаган җил әле уңнан, әле каршыдан исте. Билгеләнгән урынга — текә калкулык итәгендәге урман буена аучылар кич караңгы төшкәндә генә килеп җиттеләр. Монда алар аеруча сак кыландылар: кычкырып сөйләшү, көлү, тояк тавышлары — барысы да тынып калды.

## V

Төптән бер-берсенә кушылып, бер-берсенә берегеп үскән өч биек калкулыкны Өч-тума дип атыйлар иде. Калкулыкларның уртадагысы башкаларына караганда биегрәк тә, зуррак та иде һәм аның түбәсендә җил-яңгырдан ергаланып, шәрәләнеп беткән кара ташлы кыялар тырпаеп утыра. Кылыч-кыя менә шул иде. Төньяк, көнчыгыш итәкләре каен, карагай, карама урманы белән капланган. Көнчыгыштан көнбатышка таба сузылып киткән әлеге тауларның-калкулыкларның төньяк сыртлары арасында үтеп чыга алмаслык тирән чокырлар да, текә кыялар да, аулак урыннар да җитәрлек иде. Елына бер тапкыр — кышның беренче көннәрендә генә ауга килә торган каганнан башка монда беркайчан беркем аяк басмый. Шуңа күрә дә монда барлык төр ерткычлар, киек, кошлар курыкмыйча үзләренә оя ясыйлар, бала чыгаралар, бала үстерәләр иде. Хәер, аларның ирегә бер елдан артыкка сузылмый иде.

Аучылар икенче көнне кояш белән бергә тордылар. Каган, ак киезгә төзләнеп, туып килгән яңа көнне котлады. Ирләр, күзләрен ачу белән, Кылыч-кыя ягына карамаска тырыштылар. Бары тик урман, тау ияләренә атап корбан биргәч кенә, курку катыш кызыксыну белән, серле, караңгы агач араларына, тау башларына күз ташлап алдылар, ул яктан килгән көчсез тавышларга колак салдылар. Үзара сөйләшү, урман, кыя ягына бармак төртеп күрсәтү тыелды.

Аучылар ашаган-эчкән арада көнчыгыш яктан күп санлы каралар килеп җитте. Алар төнне ачык далада, Өч-тумадан шактый еракта уздырганнар иде. Каралар килгәч Туман каган йола буенча, бөтен ау эшен Туңгак алыпка тапшырды. Каравыл агасы Туңгак алып, «ау агасы» дип атала башлады. Ауда һәркем бары аңа гына — ау агасына гына буйсынырга тиеш иде. Каган, башкалар кебек үк, атка атланды, кулына сөңге алды. Ау агасы Туңгак алып атын җитәкләп аны бүген төн кунган калкулык итәгенә алып китте. Шунда ул аны ачыграк, биегрәк урынга куйды да, үзе дә атка атланды һәм ау багаларына кыскакыска боерыклар бирде. Боерык алгач, ау багалары үз кешеләрен тиешле урынга алып китә башладылар.

Иң элек өч йөз кешелек куркытучылар кузгалды. Алар, атка атланган килеш, тавыш-тынсыз, тик шулай да кызу юртып, сулга — Өчтуманың көньяк итәге ягына юнәлделәр. Алар, ачык җирдән барып, калкулыкларны көньяктан әйләндереп алачаклар. Шуннан соң, бербер артлы тезелеп барган килеш, тезмәне өзмичә, буташтырмыйча, уңга борылачаклар һәм шулай итеп Өч-туманың көнбатыш ягына, җилле ягына — далага барып чыгачаклар.

Өч йөз кешелек куркытучыларның иң арттагы кешесе калкулык сырты артында күздән югалгач та, уң яктан алга таба тагын өч йөз кешелек икенче төркем кузгалып китте. Алар, агачлар арасына кермәскә тырышып, дала буйлап шулай ук көнбатышка таба юнәләчәкләр. Алдан билгеләнгән урында — Өч-туманың аргы ягында, ак ташлары күренеп торган тирән чокырлы Коры елга башында — җил сындырган ялгыз тирәк янында ике төркем бергә кушылачак. Алар бергә кушылу белән, Өч-тума боҗра эчендә калачак. Куучылар, атларыннан төшеп, бик каты кычкырып, шау-шу ясап, барлык киекләрне, ерткычларны көнчыгышка — каган басып торган якка куачаклар. Шул чагында...

## VI

Каган янында калган кешеләр шактый озак көттеләр. Беркем берни сөйләшмәде. Бары тик якындагы агач араларын күзәттеләр дә, тирә-яктагы тавышларга колак салдылар.

Шулай түземсезләнеп көтеп торганда, биек агач башына менеп кунаклаган яшь бер углан, ныгып җитмәгән чәрелдек тавыш белән:

— Күренә! — дип кычкырды.

Күп тә үтмәде, алда, кара урман белән капланган калкулыклар артында аяз күккә төтен баганасы күтәрелде. Бу исә ике төркем бергә кушылды дигәнне аңлата иде.

Аучылар урыннарында кузгалышып куйдылар. Шул ук вакытта диярлек сул якта, калкулык артында сузып-сузып ана болан мөгерәгәне ишетелде. Аның тавышы тынарга да өлгермәде, якындарак аңа бога болан җавап бирде. Бу, билгеле, чын болан тавышлары түгел иде. Бу — ике тезмәнең бергә кушылуын белдереп, барлык куркытучыларга, барлык аучыларга җиткерелә торган шартлы хәбәр иде.

Шартлы хәбәр алынгач та әле каган янында калган аучыларга озак кына көтәргә туры килде. Кешеләрнең киеренкелеге соңгы чиккә җитте. Каган үртәлә, тынычсызлана башлады. Ау агасы билгеләгән урынны яратмыйча ул икенче урынга да күчеп карады. Ау агасы куйган урыннан кузгалырга ярамаганлыгын исенә төшереп яңадан элекке урынына барып басты. Урын сайлау анда үзеннән-үзе каушау тойгысы гына уятты.

Урман ягында көчсез генә эт өргән тавышлар ишетелү белән, барысы да сагаеп калдылар. Эт өргән тавышларга тоныкг кына булып агач шакылдаткан, кычкырган, чинаган тавышлар өстәлде. Бу тавышлар әле еракта килә, ләкин шулай да алар әнә киләләр инде!

Ерактагы шау-шуларга колак салып торганда, якында гына, куе урман арасыннан, агач ботакларын сындырып, зур ана болан атылып чыкты. Аның якын-тирәдә генә ашанып йөргән чагы булгандыр ахрысы, — авызына капкан агач сабагын ул чәйнәп тә бетерә алмаган иде. Күзе-башы акаеп, ул туп-туры кешеләргә таба чабып килде. Ләкин тиз арада аларны күреп алды, туктагандай итте һәм, башын бик каты чайкап, уңга борылды да әле генә куркыныч булып тоелган урманга кире кереп китмәкче булды.

«Мин атмыймын — җаям ата, мин үтермим — ук үтерә!» дип пышылдады Туман каган, нык тартылган керешне ычкындырып.

Агулы ук тимере боланның туп-туры күкрәгенә, йөрәк турысына барып тиде. Ук сабы тыгыз ит эченә яртылаш диярлек батып керде. Болан исә аптырап туктагандай итте, алгы аякларын күтәрде һәм, үзенә һөҗүм итүчеләрне таптарга, сөзәргә, изеп китәргә чамалап, ялан-дагы кешеләр ягына бер укталып алды да, үзенең куркыныч кешеләр-дән көчсезлеген исенә төшереп, тагын ышанычлы урман ягына ыргыл-ды. Шулай да ул ерак китә алмады — әллә абыныı., әллә авыртуга тү-зә алмыйча, сөрлегеп китте һәм гөрселдәп җиргә ауды. Куркып, ашы-гып янә алгы аякларына басты һәм, соңгы көчен җыеп, як-якка чай-калып, тагын берничә адым урманга таба — үзен коткарырга тиешле урманга таба йөгерде.

Аңа башка ук атучы булмады — ул барыбер егылачак иде. Кеше-ләр, аның үлеменнән тәм тапкандай, аны бары читтән күзәтеп кенә тордылар. Үзен үлемнән саклап калырга тиешле агачлар арасына ки-леп керү белән, зур гәүдәле ана болан янадан егылды һәм шуннан соң инде аягына баса алмады.

Ауда беренче киекне каган үтерергә һәм үтергәндә дә бер генә ук атып үтерергә тиеш иде. Болай булганда ау яхшыга юрала. Болан җиргә егылгач та Туман каган елмаеп куйды. Якындагы ирләр, кот-лап, хуплап, җиңелчә шаулашып алдылар. Ау агасы каганны шулай ук беренче табыш белән котлады һәм, йолага туры китереп, агач күбә-тә белән аңа кымыз бирде. Туман каган кымызны эчте, күбәтәне җиргә ташлады һәм шуның белән аның беренче авы, беренче атуы төкәнде дә. Моннан соң инде ул турыдан-туры ауда катнаша алмый иде: үз ала-чыгында утырып, я булмаса атка атланган килеш, ул ауны читтән ге-нә күзәтергә тиеш. Ләкин күптән инде каганнар бу борынгы йола бе-лән исәпләшмәскә тырышалар иде. Туман каган да үз алачыгына ке-реп утырырга ашыкмады.

Болан егылган җирдән берничә адым читтәнрәк, агачлар арасын-нан көтмәгәндә аю атылып чыкты. Аның килеп чыгуын кешеләрдән элек атлар сизеп алдылар. Сизеп алдылар да, куркышып як-якка тар-тылып куйдылар. Ау агасы, ау башланганлыгын белдереп, быргы уй-нарга боерды. Быргычы быргысын кычкыртып өлгергәнче Туман каган атын урманга таба борды, кулына сөңгесен алды һәм быргы тавышы яңгырап киткәндә генә, арт аякларына басып, үкереп килгән ерткычка саллы сөңгесен тондырды. Аю гөрселдәп җиргә ауды.

Ау агасы янындагы быргычының тавышын як-яктагы башка быр-гычылар күтәреп алдылар һәм тиз арада урман-таулар арасында, агачтан агачка, таштан ташка бәрелеп, дәртле авазлар яңгырады.

Шулай итеп ау башланды.

## VII

Өч яктан да кысыла барган куркыныч боҗра эченнән бер генә ерт-кыч та, бер генә киек тә үтеп чыга алмады. Алар барысы да, котлары алынып, шау-шу ишетелмәгән якка — каган алачыгы торган үзәнгә ашыктылар. Берәр киек, ерткыч, тезмәне өзеп, ачык җиргә чабып чык-са, аны куып кире боҗрага керттеләр. Инде шулай да берәр усалрагы, башсызрагы еграк чабып китә ала икән, аны барыбер кулдан ычкын-дырмадылар — я ук атып, я бөркет җибәреп алдылар. Бары тик тәңре углы бүрене генә беркем дә тоткарламады. Бүре ул сөннәрнең изге абалары — ерак туганнары, ата-бабалары санала иде.

Киекне шулай ук теләсә кайда да атмадылар. Аларны ничек тә ояларыннан, качкан җирләреннән куалап ачыграк яланнарга алып чы-гарга тырыштылар. Алдан ук билгеләнгән яланнарда, тигезрәк җир-

ләрдә сакта аучылар торды. Сөңгечеләр эре ерткычларны гына үтерделәр, ваграк җәнлекләрне, кошларны укчылар атты.

Аучыларның эзләренә басып диярлек килгән күп санлы эшчеләр, сугымчылар үтерелгән, яраланган киекләрне, кош-кортларны шундук тунарга, йолкырга тотындылар — итен иткә, тиресен тирегә аердылар. Икенче берәүләр — ташучылар, җилкәләренә күтәреп, билгеләнгән урыннарга итләр ташыдылар, тире, эчәк-бавыр ташыдылар. Шул ук вакытта башка каралар суына, туңа башлаган итне, тирене, эчәк-бавырны каган алачыгы янындагы үзәнгә китерә тордылар. Сөңгечеләр, укчылар артыннан килгән теркәүчеләр үтерелгән, туналган, ботарланган киекләрне, ерткычларны санап, исәпкә алып бардылар — бер генә табыш та теркәүчеләр күзенә чалынмый калмады, бер генә тире дә, мөгез дә, эчәк-бавыр да юкка чыкмады.

Каган алачыгы янындагы тигез җирдә туналган итләрдән, тиреләрдән таулар өелде.

Баш өстендә, кара болыт булып, кан исе сизгән каргалар очып йөрде. Тирә-якка, карга-козгын каркылдаулары белән бергә, ерткычларның җан ачысы белән чинаган, кычкырган, үкергән тавышлары яңгырап торды.

Туман каган, дәрте кузгалып, шактый күп киек үтерде. Аның мондый комсызлыгына эче поша башлаган ау агасы аңа алачыкка кереп утырырга боерды. Туман каган карышып тормады. Җылы алачык түрендә кымыз эчә-эчә ул ау күренешен күтәрелгән ишек аша гына күзәтеп утырды.

Ау кызганнан-кыза барды. Киекләр, ерткычлар ачык алан ягына күпләп килә башладылар. Тауның көнчыгыш ягында сакта торган аучылар, аларның барысын да атып бетерә алмыйча, әкренләп кире чигенергә мәҗбүр булдылар. Ерткычлар, киекләр, үкереп, чинап, агачлар арасында ары-бире чаптылар. Аюлар, аучылардан качып, агач башларына үрмәләделәр. Тау тәкәләре, ботак-сатакка эләгеп калдылар. Елгыр төлкеләр, аяк асларында качып калмакчы булып, җиргә, үлән арасына постылар. Үзеннән көчсезрәк, куркаграк ерткычлар арасында калып та, беркемне дә бугазлый алмаган карт юлбарыс, җирне-күкне тетрәндереп, бар көченә үкереп җибәрде.

Юлбарыс тавышы ишетелү белән, көчсез киекләр, ерткычлар гына түгел, куркусыз ирләр дә калтырап төште. Ярсып ашкынган йөрәкләр кысылырга мәҗбүр булды, ычкынырга әзер керешләр тукталып калды. Батыр ирләр бер-берсенә карашып алдылар, пышылдап кына дога сүзләре әйттеләр. Бөҗрада юлбарыс барлыгын белдереп, шундук ау агасына хәбәр бирелде.

Өч-туманы ел буена күзәтеп торган махсус аучылар-сакчылар күптән инде урманда, Кылыч-кыя янындагы чытырманлыкта юлбарыс барлыгы турында хәбәр иткәннәр иде. Шуңа күрә, бөҗрада юлбарыс булса, аучылар аны атмаска, бары тик каган ягына куалап китерергә генә тиешләр иде. Ауда беренче киекне каган гына үтерә алган кебек, ерткычлар патшасы юлбарысны да бары ул гына үтерә ала иде.

Ау агасы быргы кычкыртып барабан кагарга боерды. Шул ук вакытта ул каган янына кеше җибәрде. Ләкин каган үзе дә бөтенесен ишетеп тора иде. Ул алачыктан атылып чыкты. Аңа шундук атын китереп тоттырдылар, коралларын бирделәр. Аның янына дүрт таза сөңгече басты. Сөңгечеләрнең бишенчесе, исәпкә керми торганы, тәгин углан Албуга иде.

## VIII

Каган алачыгы торган үзәннән бер ук чамасы ераклыкта, уң якта, урман бетеп, ачык җир башланган төштә зур гына сазлык бар иде.

Кылыч-кыя төбеннән агып килә торган Аркача суы, шул урынга житкәч, әйтерсең, кайсы якка агып китәргә белмичә, шулай җир өстенә таралып, җәелеп ята иде. Ул бары әлеге сазлыкны үтеп киткәч кенә шаулап аккан чын елгага әйләнә. Сазлык өсте куе камыш урманы белән капланган. Камышлыкта һәр төрле кошлар, киекләр мыжгып тора иде.

Куркытып ояларыннан, аулак урыннарыннан чыгарылган ерткычларның кайберләре, сыену урыны эзләп, әлеге камышлыкка ташландылар. Ау агасы бөҗра эчендәге юлбарысны да шул якка куарга боерды. Каган да туп-туры камышлык ягына ашыкты.

Урман янында гына ачыклык калдырып, аучылар сазлыкны төрле яктан әйләндереп алдылар. Каган килеп житү белән, сазлык янындагы бөҗра сакчылары көчәйтелде. Иң алга сөңгечеләр басты, алардан читкә укчылар урнашты, укчылардан да арырак шонкарчылар куелды. Каган үзенең ирләре белән җилгә каршы — сазлыкның көнчыгыш ягына урнашты. Ау белән, яу белән күзе чыккан Туман каганның әле беркайчан да атып тидерми калганы юк иде. Аның әле кулы нык, күзләре үткер. Шулай да, юлбарыс белән очрашканда шаярырга, саксыз кыланырга ярамаганлыгын аңлап, ау агасы аның янына тагын өч-дүрт таза ирне куйды. Тәгин угланның куркыныч урында булуы гына аның бераз эчен пошырды, ләкин ул аңа берни әйтмәде — яшь угланның күңелен кырасы килмәде.

Урман эчендәге шау-шу көчәйгәннән-көчәя барып, камышлыкка таба юнәлде. Әле сулда, әле уңда ярсып этләр өрде. Куркытучылар шак та шок китереп төрле тавышлар чыгардылар, кемнәрдер ачы итеп бар көчләренә чинап җибәрде.

Менә бер заман сазлык эченә күпләп киекләр керә башлады. Коры камыш сабакларын сындырып алар куерак, куркынычсызрак урыннарга омтылдылар. Шул ук вакытта сазлык уртасыннан пырылдап, канатларын сызгыртып үрдәкләр күтәрелеп чыкты.

Күп тә үтмәде, бөтен камышлык куып кертелгән киекләр белән мыж килеп тора башлады. Сазга, камышка күнекмәгән, бер-берсен якында күреп котлары алынган боланнар, тау-тәкәләр ничек тә моннан таярга тырыштылар һәм, саз кырыена килеп житү белән, туп-туры аучыларга килеп төртелделәр.

Шул чакны аучылар тезмәсе өстеннән көчле җил исеп киткәндәй булды: барысы да, дөньяларын онытып, урман белән сазлык кушылган якка борылып карадылар. Ул яктагы күзәтчеләр, быргы кычкыртып, юлбарысның камышлыкка килеп керүен белдерделәр. Чыннан да, урманга якынрак торган аучылар аның көчле, сиртмәле аякларында җиңел-җиңел сикереп, ала-кола буе белән сузылып, сазлык ягына ыргылуын күреп тордылар. Ерткычлар патшасы алдында тез чүгеп бөтен тирә-як кинәт тынып калгандай булды. Бөҗра эчендәге киекләр, бар кайгыларын, куркуларын онытып, барысы берьюлы шып булдылар.

Камышлыкка юлбарыс кереп күп тә үтмәде, урманнан җәяүле аучылар төркеме килеп чыкты. Куе урман аша, тирән чокырлар, кыялар аша үткән, киек аулап арыган, хәлдән тайган, яраланган, канга баткан аучылар, боерык булганны да көтеп тормастан, сазлык буендагы ирләр янына килеп кушылдылар. Ләкин урманда әле башка аучылар да калган иде.

Анда-монда тоткарланып калган аучылар җыелган арада, ау агасы, атын кызу юырттырып, бөтен сазлыкны әйләнеп чыкты, кемнең кайда, ничек торуын барлады, кайберәүләрне бер урыннан икенче урынга күчереп куйды. Ау агасы яңадан сазлыкның көнчыгыш ягына — каган янына килеп житкәч, тезмә буенча яңа боерык бирелде. Менә бер заман аргы якта югарыга аксыл-зәңгәр төтен күтәрелде — аучылар коры

камышка ут төрттеләр. Төтен баганалары шулай ук сазлыкның уң ягында да, сул ягында да калкып чыкты. Озакламый бөтен камышлыкны ут-ялкын чорнап алды. Кызу искән җил белән төтен сазлыкның көнчыгыш ягына — каган көтеп торган якка үрләде.

Шашынып, юка бозны шатыр-шотыр ватып ерткычлар төтен алдыннан чаптылар. Атларның, кешеләрнең борыннарына, күзләренә ачы төтен керде, әледән-әле күз алларын төтен каплады. Ләкин беркем дә артка чигенмәде, беркемнең дә кулы кылтырамады. Сазлык янындагы ярты чакрым чамасы озынлыкта коры җир өсте атылган, кадалган, чабылган киекләр белән тулды.

Юлбарыс, уттан, төтеннән качып, ике мәртәбә сөңгечеләр каршысына килеп чыкты. Икесендә дә аны кире куып җибәрделәр. Өченчесендә ул туп-туры Туман каган янына килеп чыкты. Килеп чыкты да, үзенең язмышы кем кулында икәнлеген аңлаган сыман, ат өстендә кыя таудай утырган алып иргә карап, бар көченә ырылдап җибәрде һәм, ни булса да булыр дигәндәй, ярсып алга ташланды. Ул шундый зур иде, шундый куркыныч иде — каган атланган Кура-мал куркып кинәт читкә сикермәкче булды. Ләкин каган аны вакытында тыеп калды. Тезген тоткан сул кулы белән атын тыеп, уң кулы белән ул сөңгесен юлбарысның күкрәгенә турылап тондырды. Сөңге сабының ерткыч күкрәгенә яртылаш диярлек батуын ул үз күзләре белән күрде. Шул ук мәлдә, ул сул кулын бушайткандай итте. Шуны гына көткән Кура-мал читкә ыргылды.

Каты яраланган ерткыч ярсып яңадан аякларына басты, яңадан алга ыргылмакчы булды, ләкин күкрәгенә кадалган сөңге сабы, туң җиргә төртелеп, бары аның ярасын гына тирәнәйтте. Ерткычның төтен тулган канлы күзләреннән чишмә булып яшь акты. Авыртуга түзә алмыйча ул үкереп җибәрде.

Боларның барысы да күз ачып йомган арада булды. Сихерләнгән сыман ирләр юлбарыска карап торганда камышлыкны ярып, бик зур кабан дуңгызы килеп чыкты. Килеп чыкты да, сөңге сыман очлы тешләре белән каршыдагы атның корсагына китереп төртте. Кура-мал шашынып чинап җибәрде һәм алгы аякларын күтәреп, каядыр сикермәкче булды. Юлбарыс аркасында уяулыгын югалткан Туман каган мәтәлеп җиргә барып төште. Шул ук мәлдә төтен эченнән ярсып икенче кабан дуңгызы килеп чыкты.

Ирләр аны күреп алдылар, кычкырып җибәрделәр. Ләкин беркемнең дә каганга ярдәмгә килергә җае юк — Туман каган җиргә ауган аты белән кабан дуңгызы арасында калган иде. Моңарчы бер читтәрәк торган Албуга шул чакны, сөңге сабын ике куллап тоткан килеш, төтен арасыннан килеп чыккан икенче кабан дуңгызы өстенә сикерде. Каушаса, туры чамалый алмаса, аның да этисе янына я булмаса кабан дуңгызы алдына барып төшүе ихтимал иде. Ләкин ул дөрес һәм төгәл чамалады — сөңге тимере, кабан дуңгызының таштай корсагы аша чыгып, таштай каты җиргә төртелде. Яшь аучы егылган ат аша, этисе аша, тигез җиргә барып төште.

Якындагы ирләр барысын да күреп тордылар. Колак төбендә генә мактап кычкырган, гаҗәпләнү белдергән тавышлар ишетелеп китте. Ирләрнең берсе ат корсагын тишкән кабан дуңгызына сөңге ыргытты. Берничә ир, атларыннан төшеп, каганга ярдәмгә ташландылар. Төрле яктан күтәреп алып, аны аягына бастырдылар да, тиз-тиз генә читкә, куркынычсызрак урынга алып киттеләр. Ул арада этисе янына агарынган, коты алынган Албуга килеп җитте.

— Углым! — диде ата кеше, яшь егетне күкрәгенә кочып. — Мин күрдем. Беркайчан да онытмам, батыр углым!

## IX

Кояш таулар аша үтеп дала ягына чыккач, ау тәмам булды. Камышлык янды, көлгә әйләнде. Ут шулай ук урман буендагы аерым куакларны да өтеп алды. Шулай да аны ары җибәрмәделәр. Өч-тумадагы барлык киек-җанварлар кырып салынды. Урман-таулар арасы бушап, тып-тын булып калды. Ләкин озакламый анда яңа киекләр, ерткычлар киләчәк. Алар анда үзләренә оя корачаклар, аулак урыннар табып үрчи башлаячаклар. Бит алар монда әле генә кан елгасы акканын белмиләр һәм алар аны беркайчан белә алмаячаклар, чөнки моннан бер генә киек тә, бер генә тычкан, йомран да үтеп чыга алмады. Шулай булгач, мондагы үтереш турында аларга кем җиткерсен?!

Каган алачыгы торган үзәндәге табыш таулары үскәннән үсте. Каралар камышлыктан кәки[1] ташып хәлдән тайдылар.

Иң яхшы итләрне, тиреләрне теркәүчеләр каганга калдырдылар. Кемнең нәрсә, күпме үтерүенә карап, аучыларга шулай ук яхшы иттән, тиредән өлеш чыгарылды. Ау агасына да итнең, тиренең яхшырагы бирелде. Теркәүчеләр, сугымчылар, тунаучылар — ауда катнашкан барлык кешеләр үзләренә тигән өлешне алдылар. Эчәк-бавырны, койрык ише калдык-постыкны коллар бүлеште. Аларга шулай ук нык ертылган, бозылган я булмаса кечерәк, затсызрак тиреләрне дә бирделәр. Монда шулай ук тирә-яктан чин ярлылары да килеп җиттеләр. Аларга аягы сынган, корсагын кабан дуңгызы тишкән үле атларны бирделәр. Сөн колларыннан да фәкыйрьрәк киенгән бу ярлылар ат үләксәләрен шундук ботарлап ташладылар, бүлешеп алдылар.

Ау төкәнү белән, үзән уртасында Туман каганның йөз егерме кеше сыешлы киез өе торгызылды. Батыр аучыларны каган бүген сыйларга, кунак итәргә тиеш иде. Бөек каган, урдадагы сыман, киез өйнең түренә урнашты. Аның уң ягына тәгин углан, сул ягына ау агасы Туңгак алып утырды. Башка аучылар, ярым түгәрәк булып, каршыга һәм ике якка урнаштылар.

Ачыккан, алҗыган ирләр түземсезлек белән аш-су башлануын көттеләр. Пешкән ит китерер алдыннан Туман каган иң зур батырлык күрсәткән ирләргә үз кулы белән буза бирергә тиеш иде. Быелгы ауның беренче батыры кем булыр икән? Ирләр, пешкән иттән бигрәк, шул турыда карар көттеләр.

Беренче сүзне йола буенча, каган түгел, ау агасы әйтте. Ул, билгеле, иң элек каганны мактады. Бер атуда юлбарысны егып салган өчен аны барлык ирләр арасында иң батыры, иң булдыклысы дип атады. Үзен мактаганга каганның күңеле булды. Шулай да ул үзенең аттан егылып төшүен дә, чак-чак кына кабан дуңгызының очлы тешләренә эләкми калуын да оныта алмады. Бу хакта эндәшми калуны ул яхшысынмады. Ау агасыннан соң каган үзе сөйләде.

— Ирләр күреп торды: беренче киекне мин аттым, юлбарысны мин үтердем, — диде ул. — Шулай да ау агасы бер нәрсәне әйтми калдырды. Кабан дуңгызыннан мине кем коткарды?

— Тәгин углан! — диделәр ирләр барысы бер авыздан диярлек.

— Әйе, минем өлкән углым! — диде ата кеше сизелеп торган бер горурлык белән.

— Әйе, Албуга! — диде Туңгак алып та. — Мин әле ул турыда да әйтмәкче идем.

— Менә шул-шул! — диде каган. — Быелгы ауның беренче батыры минем углым Албуга булыр! Беренче бузаны мин аңа бирәм!

Ирләр, яшь алыпны мактап, шау-гөр килеп алдылар. Албуга, кызарынып, шатлыктан ерылган авызын көчкә тыеп, атасы кулыннан ал-

[1] Кәки — ит.

тын кәсә алды. Алды да, елмаеп, горурланып, өй эчендәге ирләргә күз йөртеп чыкты. Аның әле беркайчан да атасы алдында, алып ирләр алдында бу кадәр данга ирешкәне, бу кадәр макталганы юк иде, беркайчан үзен шундый бәхетле итеп тойганы юк иде.

Буза тулы алтын кәсәгә ул бер күз төшереп алды да, каушап, тирән итеп тын алды.

— Әти... бөек каган! Ирләр! Сезнең исәнлеккә эчәм, — диде Албуга.

Бирелгән бузаны ул тамчысын да калдырмый эчеп бетерде. Эчеп бетерде дә, инде тагын нишләргә, дигәндәй, тып-тын калып, ирләргә, әтисенә карап тора башлады. Ашчы тиз генә аның алдына кайнар ит китереп куйды. Төрле яктан өзек-өзек сүзләр ишетелде.

— Егылмады!

— Буыны нык! — диештеләр ирләр.

— Булдырды! — диде ата кеше дә.

Ул аңа яңадан урынына утырырга булышты, ашчы китергән табакны аның алдына җайлабрак куйды. Бәхетле яшь алыпны мактап әйтелгән сүзләр әле уңда, әле сулда ишетелгәләп торды. Ләкин бу инде чынында аны мактау да түгел иде, бу бары ата кеше алдында бер ялагайлану да, аннары бер башланган сүзне дәвам иттерү сыманрак кына иде. Андый мактау сүзләре инде яшь алыпның үзенә дә ишетелми башлады. Аның аяк-куллары хәлсезләнеп калды, башы авырайганнан-авырая барды, күз аллары томаланып, өй эчендәге кешеләр әлҗемөлҗә килә башладылар.

«Егылмаска, егылмаска!» диде ул үз-үзенә күңеленнән.

## X

Ачыккан, алҗыган ирләр туйганчы ит ашадылар, буза, кымыз эчтеләр. Иң батыр аучыларны каган үзе сыйлады. Йөз егерме аучының барысына да бүләкләр бирелде.

Ашап туйгач күңел ачу башланды. Ирләр шаулашып һавага чыкты. Уртада зур түгәрәк калдырып, түгәрәк эченә учак яктылар. Учак яктысында яшь ирләр көч сынаштылар, көрәш уеннары башлап җибәрделәр. Уеннарның, көрәшләрнең барысы да диярлек ау күренешләрен кабатлады. Көрәштән, уеннан соң биюләр башланып китте.

Казаннарда туктаусыз итләр пеште, бурдаклардан[1] туктаусыз эчемлекләр акты. Уен-көлке, күңел ачу төн урталарына чаклы сузылды. Төн уртасы авышкач аучылар, көндезгедән дә ныграк арып-алҗып, татлы йокыга талдылар.

Икенче көнне, таң атып кояш җир астыннан чыккач та, аучылар тәгәрәшеп йоклап яткан үзәнгә Кара-тау ягыннан килүче арба күренде. Дөяләр җигелгән арбаны ян-яктан, арттан, алдан унлап-унбишләп сакчылар урап алганнар иде. Дөягә атланган малай да, атка атланган ирләр дә, кыяфәтләренә караганда, җунгошеннар булырга тиеш иде.

Өч-туманың көнчыгышка таба сузылган сөзәк итәге өстенә — калкулык сыртына килеп менгәч тә, атлар да, дөяләр дә туктап калдылар. Калкулыкның төньяк итәге сирәк урман белән капланган. Сирәк урман артында, киң үзән уртасында ап-ак булып ялгыз өй калкып утыра иде. Өйне күрү белән, атка атланган ирләр үзара сөйләшеп алдылар, арба эчендәге кемгәдер нәрсәдер әйттеләр.

Өсте ябулы арбаның алгы ягындагы кечкенә тәрәзәдән киң битен күрсәтеп, нииндидер ир кеше алга, үзәнгә карады. Сакчы ирләргә ул нидер җавап кайтарды. Ирләр тагын үзара сөйләшеп-киңәшеп алдылар.

[1] Бурдак — сөт, су, кымыз ише сыеклык өчен кулланылган тире савыт (капчык).

Бераз көтеп торгач, арбадагы кеше кузгалырга боерды. Кузгалып киткәнче ирләрнең берсе арба тәгәрмәчләренә арттан юан гына агач кыстырды — тауга түбән төшкәндә дөяләр чабып китеп, арбаны аударулары бар иде.

Юлчылар калкулыктан, сирәк агачлар арасыннан тыелып кына, ашыкмыйча гына төштеләр дә тигез җирдә туктап калдылар. Шул чакны аларның күз алдында искитмәле күренеш ачылды: җир өстендә, сүнгән учак тирәсендә, баш-аяк килеп, төрлесе төрлечә бөгәрләнеп я булмаса аяк-кулларын сузып җибәргән килеш, аучы ирләр йоклап ята иде. Шундый ук аунап-йоклап яткан ирләр арырак та күренә — әйтерсең, әле генә монда бик каты сугыш булган да, җиңүчеләрме, җиңелүчеләрме — үлекләрен җыеп алырга да өлгермичә, каядыр китеп барганнар. Якын-тирәдә бер генә сак та, бер генә уяу кеше дә күренми иде.

Арба эчендәге кеше, тәрәзәдәге пәрдәне күтәрә төшеп, тирә-якны күзәтеп барды. Җирдә яткан кешеләргә бик үк якын килеп җитмичә туктарга кушты. Арба туктагач ул арткы киезне күтәреп җиргә төште. Урта буйлы, бик таза һәм бик ямьсез бер кеше иде ул. Зур башлы, киң маңгайлы һәм тумыштан ук кыешрак авызлы бу ир уртасы кайсыдыр ягы белән түбет кешесен,дә, җунгошенне дә, шулай ук сөн кешесен дә хәтерләтә иде. Ләкин ул чынында түбет кенә түгел, җунгошен генә дә, сөн генә дә дә түгел иде бугай. Күз карашы аның нурсыз, котсыз һәм комсыз иде. Авызының кыеклыгы, иреннәренең калынлыгы аның шөкәтсезлеген тагын да көчәйтә сыман. Аннары аның йодрыклары бик зур иде. Менә шул зур, авыр йодрыклары һәм күрер күзгә ямьсез кыяфәте булмаса, ул алай башкалардан бик үк аерылып та тормас иде, ахрысы.

Арбадан читкәрәк китеп, йодрыкка йомарланган куллары белән биленә таянган килеш ул озак кына каранып торды. Ялгыз ак өйдән арырак ул унда-сулда тагын ашык-пошык корылган кечерәк алачыклар, киез өйләр күреп алды. Тагын да арырак исә, җир өстендә кара тап булып яткан сазлык күренде. Елга буенда еракта бик күп атлар утлап йөри, шунда ук кешеләр дә бар иде. Димәк, барысы да йоклап бетмәгәннәр.

— Менә шундый инде алар — хулар... — диде ул үз янындагы ирләр белән сөйләшкән сыман итеп. — Туярларын белмичә ашыйлар-эчәләр дә, хайван кебек йокыга авалар. Шуннан башка аларны берни кызыксындырмый. Сөңге ал да берәм-берәм када да чык!

— Алар уянмыйча анда бару килешмәс, — диде сакчы ирләрнең берсе.

Алар чин телендә сөйләштеләр.

— Агачлар арасында көтеп торырга туры килер,— диде ямьсез ир.

Дөягә атланган малайга ул борылырга кушты. Үзе, арбага утырып тормастан, җәяү генә китмәкче булды. Атларыннан төшкән ирләрнең берсе тәгәрмәчләргә кыстырылган күсәкне тартып алды һәм зур, тупас тәгәрмәчле арба, тешкә тия торган ачы тавышлар чыгарып, борыла башлады. Бу көтелмәгән шыгырдау тавышы иртәнге тынлыкка чумган тирә-якны сискәндереп җибәрде.

Якында гына зур таш артында йоклап яткан кораллы ир кинәт башын калкытты. Кызыл саплы, тимер башаклы сөңгесен ул ике куллап кочаклап тоткан иде. Ул, ахрысы, төнлә торгак булган. Сөңгесен кулыннан ычкындырмыйча шундук аягына басты һәм якында гына кораллы ирләрне, җитмәсә чин кыяфәтендәге ирләрне күреп бар көченә кычкырып җибәрде.

Йокылы-уяулы килеш аның бик нык коты алынган иде бугай. Кычкыра-кычкыра ул артына чигенде дә, борылып йөгерергә үк тотынды.

Бөтен үзән берьюлы диярлек башын калкытты. Аннан-моннан арба ягына уклар очты.

Атлы, кораллы ирләр тизрәк агачлар арасына кереп яшеренергә тырыштылар. Зур йодрыклы ямьсез ир куркып җиргә егылды.

Аның янына кораллы сөн ирләре йөгереп килде. Бил каешыннан тотып аны җирдән торгыздылар, аягына бастырдылар.

— Исәнтәй ич бу! — диде сөннәрнең берсе шаккатып.

— Исәнтәй, исәнме? — диде икенчесе күләргә чамалап.

— Исән, исән! — диде Исәнтәйне бил каешыннан тотып торган ир.

Исәнтәйнең бөтен тәне дер-дер калтырана иде. Кораллы ирләр алдында ул шулай да елмаймакчы булды. Ләкин елмаю барып чыкмады — ачылган эре тешләре, бер-берсенә тиеп шак-шок килде дә, кыек авыздан «ы-ы...ыгы!..» дигән мәгънәсез авазлар гына ишетелде.

## XI

Кичтән күпме генә эчмәсен, төннең кайсы вакытында гына йокларга ятмасын, Туман каган иртән барыбер кояш белән бергә тора һәм, борын-борыннан килгән ата-баба йоласын бозмыйча, яңа көнне котларга чыга иде. Ләкин бу бары урдада чакта гына — тыныч, көндәлек тормышта гына шулай. Урдадан читтә төн кунарга туры килгәндә ул еш кына үзенең күп төрле йолаларга бәйле икәнлеген онытып җибәргәли иде. Башкалар кебек ул да бии, җырлый, кайчагында хәтта куркыныч уеннарда, ярышларда да катнаша иде.

Кичәгенәк ул алай бернинди уенда, җырда-биюдә катнашмады — көндез бик арыткан иде. Үзенең үлемнән котылу сөенеченнәнме, юлбарыс атып алу куанычыннанмы, үз алдына йомылып, басылып ул берөзлексез буза эчте. Шул ук вакытта ул үзенең тәгин углы турында да уйланды. Элеккегә караганда ныграк ярату белән, якынлык тойгысы белән уйланды. «Урдага кайту белән Табылдыкны бүләк итеп бирәм!» — диде ул үз-үзенә, билгеле бер карарга килеп. Аның өчен шуннан да зур бүләк юк та, булмас та. Үзеңне үлемнән саклап калган углыңа бер кыз җәл булмас. Куансын, күңеле булсын. Инде яше дә җиткән — озакламый болай да өйләнергә тиеш.

Утыра-утыра аның — ата кешенең — хәзер үк батыр углы өчен берәр төрле изгелек эшлисе килә башлады. Ничек итеп күңелен күрим икән дип уйлангалап утырганда ул кинәт Албуганың йоклап киткәнен күреп алды. Каган аны тышка саф һавага алып чыгарга, алай да уянмаса, урынга илтеп салырга кушты. Тәгин угланны ирләр күтәреп тышка алып чыктылар, уятып карадылар — ауда шундый зур батырлык күрсәткән яшь алып берни белми йоклавында булды. Аны яңадан өйгә кертеп урынга яткырдылар.

Каган үзе дә озакламый йоклап китте. Кояш чыккан вакытта да ул йоклап калды. Шулай да төнге торгак соңлап булса да аны кереп уятты, җитәкләп диярлек тышка алып чыкты. Каган, иртәнге кояшны котлагач, яңадан урынына барып ятты. Ләкин бер торгач инде яңадан йокыга китә алмады.

Шул чакны өйгә Туңгак алып килеп керде.

— Исәнтәй килгән, — диде ул.

— Ни калган аңа монда? — диде каган.

— Сине күрмәкче була.

— Күрәсем килми!

Туңгак алып тавыш-тынсыз гына ишеккә юнәлде, ләкин ул чыгып җитәргә дә өлгермәде, аны шундук кире чакырып алдылар.

— Кем килгән дисең? — диде каган.

— Исәнтәй... Банхуа... — диде Туңгак алып.

— Ник аны яхшылап аңлатмыйсың? Бар, чакыр!

Өстенә сөннәрнеке кебек озын итәкле туп кигән, биленә киң каеш буган, сул колагына зур алтын алка таккан Исәнтәй-Банхуа, каган өенә килеп керү белән, идәнгә егылды. Туман каган ярым шәрә килеш үзенең биек ятагында утырып тора иде.

— Тор, — диде ул керүчегә.

Исәнтәй тормады, бары башын гына калкытты һәм каганга, иленә-көненә исәнлек-саулык теләде.

— Сөйлә, — диде каган боерып.

Исәнтәй гадәтенчә елмаеп, читләтеп, уратып үзенең урдага баруы, юлда менә көтмәгәндә каганның үзенә юлыгуы турында сөйләргә кереште.

— Кыскарак тот! — диде каган түземсезләнеп.

Исәнтәй сүзен кыскартмады, бары тик ныграк елмайды да башын гына югарырак калкытты. Каганга ул үзенең нинди дер сүз әйтергә җыенуы турында сөйли башлады.

— Бузаң бармы? — диде каган, артык тыңлап торырга тәкате калмыйча.

Исәнтәй, ясалма елмаюын сүндереп, кинәт тынып калды.

— Арбада бар түгел, — диде ул бик нык кайгырып. — Өйдә бар.

— Кызларың бармы?

— Бар. Күп бар! — диде Исәнтәй куанып.

— Кирәгең ни?

— Кызны, бузаны монда китеримме, бөек каган? — диде Исәнтәй чамадан тыш ягымлы елмаеп.

— Китермә. Үзем барып алырмын, — диде Туман каган.

Аның инде күптән шушы Исәнтәйнең оясын үз күзләре белән күрәсе килә иде.

## XII

Исәнтәй-Банхуаның атасы Чжао ягында туган, Чжао ягында үскән ярым сөн, ярым түбет кешесе иде. Чыгышы белән дала кешесе булса да, ул инде күптән үз халкыннан аерылган, аның телен, йолаларын онытып бетергән. Үзе шулай җиңел генә жунгошеньгә әйләнә алганга, элекке тамырдашлары, тугандашлары сөннәрне дә ул җиңел генә жунгошеньгә әйләнергә тиешләр дип, сөннәр тулысынча Чжао йортына буйсынырга тиешләр дип исәпли иде. Шунлыктан ул, урман-кырлардагы киекләр кебек, бер урыннан икенче урынга күченеп йөргән сөннәрне бөтен җаны-тәне белән яратмый иде.

Ул яшь чакта Чжао йорты бай иде, көчле иде. Чжао ваны[1] әледән-әле сөннәргә каршы яу чаба, аларның җирләрен басып ала, күпләп-күпләп мал-туарын, кешеләрен кулга төшерә иде. Ул чакларда Исәнтәй-Банхуаның әтисе Банлу Чжао гаскәрендә мең башы булып хезмәт итә һәм иң турылыклы сугышчылардан санала иде.

Шулай бер кышны, сөннәр белән сугышта бик кыен хәлдә калгач, бөтенләй көтмәгәндә аңа, башын саклап, сөннәр ягына чыгарга туры килде. Дөресрәге, сөннәр аны камап алдылар һәм корал ташлап кул күтәрергә мәҗбүр иттеләр. Банлу белән бергә биш йөзгә якын Чжао ире, коралларын ташлап, сөннәргә бирелде. Банлуның җиңелүе аркасында ул сугышта Чжао ваны да җиңелде. Туманның атасы — сөннәрнең ул чактагы каганы Банлуның бу «изгелеген» буш итмәде. Ягымлы, булдыклы, батыр Банлуны ул үзенә якынайтты, аңа үзенең түбет кырнагыннан туган ямьсез генә бер кызын бирде. Кызның бирнәсе итеп, бер көтү мал-туар белән бергә, әсир чжаолардан йөзләп ир бирде.

[1] Ван — дәүләт башлыгы, патша.

Шул ук вакытта аңа илнең төньягында, Тула суының түбән агымында көтүлекләр билгеләде, үзенчә кала корып, җәен-кышын, язын-көзен дигәндәй, балчык өйдә яшәргә рөхсәт итте.

Бер көзне, моннан егерме еллар элек, сөннәр көнчыгыштагы урман кешеләренә каршы яу чапканда, Банлу да үзенең ярты меңлек алае белән каган чирүенә кушылды. Урман кыргыйларына каршы яуда аның ирләре батырларча сугыштылар. Сөннәр җиңде, һәм Банлуның бу яхшылыгын карт каган буш итмәде. Банлу үзен көньякка, таулар арасына күчерүне сорады. Мондагы салкын далага күнегә алмыйм, таулар миңа якынрак диде, картлык көнемдә туган җиремә — Чжаога якынрак җирдә яшисем килә, диде. Туманның атасы карт каган моныкына да риза булды. Ул аны Сөн җиренең көньягына — Таштугай үзәненә күчерде һәм шунда аңа балчыктан, агачтан өйләр салып, Чжао йолаларын саклап яшәргә ирек бирде.

Таштугай үзәнендә Банлу бик шәп яшәде. Елына өч-дүрт тапкыр ул урдага барып кайтты, каганга бүләкләр илтте, яу чабарга сөннәргә кирәк булса, бер мең кораллы ирне атка атландырып, каган катына озатты. Еш кына каган аны үзе дә чакыртып ала һәм таулар артындагы Күк асты иленә катнашы булган берәр катлаулы, четрекле эш килеп чыкса, иң элек аның сүзенә колак сала торган иде.

Карт каган үлеп, аның өендәге алтын тәхеткә өлкән углы Туман менеп утыргач, Таштугай үзәне өстендә кояшлы көннәргә караганда болытлы көннәр күбрәк була башлады. Үзенчә кала корып, мал-туар асрап, меңләгән якташларын — җунгошен качакларын коллап, баеп яткан Банлуны Туман каган бик үк яратып җиткермәде. Алтын тәхеткә утыруының беренче көненнән үк ул аңа кырын күз белән карады. Берәр сылтау табып ул аның таш-балчык өйләрен, коймаларын туздыртырга, байлыгын тартып алырга диебрәк уйлаштыра башлады. Ләкин карт Банлу көтмәгәндә үлеп китте. Бар нәрсәгә баш булып аның улы Банхуа-Исәнтәй калды.

Исәнтәй эшне атасыннан остарак башкарды. Иң элек ул яшь каган белән дуслашу, татулашу ягын карады. Моның өчен ул булдыра алганын да, булдыра алмаганын да эшләде. Урдага ул өч-дүрт айга бер түгел, бер айга өч-дүрт тапкыр, кирәк икән — биш-алты тапкыр барды. һәм барган саен каганга, аның бичәләренә, яраткан кол кызларына-кырнакларына бүләкләр алып барды. Бүләкнең дә әле андый-мондыен гына түгел, теге яктан, Иән, Вәй, Чжао якларыннан чикканын, затлырагын табарга тырыша иде. Каган да, башкалар да беркайчан бүләктән баш тартмадылар. Урда белән Таштугай үзәне арасындагы салкынлык, шулай итеп, кул белән сыпырып алгандай юкка чыкты куйды.

Каган белән ике арадагы мөнәсәбәтне җайлагач, Исәнтәй үз биләмәсендәге эшләрне җайга салырга тотынды. Барыннан да элек ул атасының элекке якташларын ныклап торып үз кулына алды. Монда кыргыйлар арасында сезне мин якламасам, башка беркем якламаячак, диде, Таштугайдан китсәгез, сөннәр сезне икенче көнне үк тотып ашаячаклар, үзләре ашамаса, этләренә биреп ашатачаклар, диде. Күптән инде Сөн илендә яшәгән, сөн телен, сөн гадәтләрен-йолаларын яхшы белгән элекке җунгошеннәрнең мондый куркытуларга әллә ни исләре китмәде китүен, шулай да әлерәк кенә Чин ягыннан качып чыккан һәм Сөн илендә үзенә сыену урыны тапкан ярлы-ябагай аның кармагына җиңел генә эләгә торды.

Күп тә үтмәде, Банлу углы Банхуа-Исәнтәй Сөн илендәге Чин качакларының үзенә күрә бер яклаучысына һәм шул ук вакытта алар канын эчүчегә әверелде. Аның барлык эшен «якташлары» эшләде: аның өчен алар көтү көттеләр, җир тырнап иген иктеләр, күлдән, елгадан балык тоттылар. Хатын-кызлар җәен-кышын аның өчен йон эр-

ләп, тула бастылар, тукыдылар, тире-яры иләп кием текteләр. Ирләрнең күбесе балта эше белән шөгыльләнде — төрле йорт кирәк-ярагы, эш, сугыш коралы җитештерделәр, утын ташыдылар. Артык шауламыйча, кирәкле кешеләре белән генә киңәшеп-серләшеп Банхуа таулар арасында тимер, бакыр ташлар эзләтте.

Җае чыгу белән ул үзенең ирләре, хатын-кызлары җиткергән затлы әйберләрне каганга бүләк итеп тә, сатып та җибәргәләде. Урдага барган саен каганның бичәләре, чибәр кызлары аңа үзләренең вак-төяк үтенечләрен белдерделәр: шундый-шундый нәрсә таба алмассыңмы, диделәр, икенче килгәндә фәлән нәрсә алып кил әле, диделәр. Хатынкыз йомышын ул аеруча теләп башкарды.

Дала аксөякләренә кирәк булган барлык нәрсәне ул җиңел генә таба алмый иде, билгеле. Кайбер нәрсәләрне аның ышанычлы кешеләре, чик аша чыгып, тегe яктан алып кайттылар.

Каган үзе дә, аның якыннары да шома, елгыр Исәнтәйнең мондый эшләрен бик яхшы белеп тордылар. Ләкин Исәнтәйгә аркылы төшәргә, аңа аяк чалырга дигән уй беркемнең дә башына килеп карамады. Киресенчә, аның мондый изгелекләрен хуп күрделәр. Ни өчен дигәндә, бар нәрсәгә өлгер, булдыклы Исәнтәй хатын-кызның гына түгел, ирләрнең дә күңелен күрә белде. Ирләрнең, аеруча Туман каганның күңелен күрү өчен тун, бүрек, итек, корал ише нәрсәләрдән тыш тагын ике генә нәрсә кирәк иде. Кадерле икенең берсе — дөгедән кайнатылган утлы буза булса, икенчесе — утлы бузадан да утлырак яшь кызлар иде. Дөге бузасын Исәнтәйгә ярлы чиннәр кайнатты. Шул ук буй җиткән яшь, чибәр кызларны да Исәнтәй үзенә буйсынган, көн-төн үзенә бил бөккән ярлы-ябагайдан сайлап, җыеп алды. Бөтен Күк асты илендә атаклы Чжао гүзәлләрен аңа кайчагында тегe яктан да алып чыктылар: ефәк кебек, алтын савыт-саба, дару, җимеш кебек итеп. Бик кирәк булса, билгеле.

## XIII

Олуг кунакны тиешенчә каршылау өчен Исәнтәй тиз арада Таштугай үзәненә кайтып китте. Өч-тума ягыннан Таштугай үзәненә чаклы күп булса бер көнлек юл иде. Атларны, дөяләрне кызулатыбрак барганда, юлны тагын да кыскартырга була иде. Туман каган, Исәнтәйнең үкчәсенә басып бармас өчен, беразга монда тоткарланырга кирәк тапты. Үзе белән кунакка ул бары аучыларны гына алырга булды. Башка барлык ирләргә, караларга кайтып китәргә боерылды.

Исәнтәйнең биек таулар арасындагы таш-балчык-агач каласына каган икенче көнне кояш баер алдыннан гына барып җитте. Исәнтәй аны үз каласыннан ике-өч чакрым читтә, Таштугай үзәне киңәеп, ачык далага килеп кушыла торган бер яланда каршылады. Өстенә ул кызгылт-җирән ефәк белән тышланган яхшы, яңа тун кигән иде. Түбәсе сары ефәк белән капланган ике тәгәрмәчле арбасы янында аның егерменләп атлы-коралы ире тора иде.

Кунаклар килеп җитәргә бер йөз адым калгач ул, арбасыннан төшеп, җәяүләп, ашыгып, каганга таба атлады. Елмаеп, кырыкка бөгелеп иң элек каганның өзәнгедәге каюлы итек башын үпте, аннары атның тезгеннән тотып алды. Сөнчә киенгән, сөнчә коралланган егерменләп ирнең барысы да, атларыннан төшеп, җәяүләп шулай ук кунаклар каршысына килделәр, ирләр атланган атларның алтын-көмеш тәңкәләр, аеллар белән бизәлгән тезгеннәреннән тотып алдылар.

Исәнтәй арбасы торган җирдә әле тагын кемнәрдер бар иде, ахрысы. Туман каган да, башкалар да кичке эңгер-меңгердә аларның кемнәр икәнлеген тиз генә аера алмады. Арба янына килеп җиткәч барысы да аңлашылды. Болар җиргә чүгәләбрәк утырган кызлар төрке-

ме булып чыкты. Яшь кызлар аллы-гөлле ефәк киемнәр кигәннәр, төзәнгәннәр, бизәнгәннәр. Аларның барысы да кулларына кымыз тулы кәсәләр тоткан иде.

Кунак ирләр якынлашу белән кызлар барысы да бердәм булып аякларына бастылар һәм беравыздан диярлек күңелле җыр башлап җибәрделәр. Җырчы кызларның берсе — буйлырагы, сылурагы җырлый-җырлый алга чыкты. Кымызны иң элек Исәнтәй үзе эчте, аннары каганга бирде. Каганның юлдашларын башка кызлар белән башка ирләр сыйлады.

Исәнтәй, мондый очрашуга чиксез куанганлыгын белдереп, каган алдында, уң кул тучи бәк[1] тәгин углан белән каравыл агасы Туңгак алып алдында бишкә бөгелде, бер алларына, биш артларына чыкты, туктаусыз елмайды һәм каушавыннан әле абынып китте, әле тунының итәгенә басты. Каушамаслык та түгел шул — кунак булып аңа каган үзе килә! Карт Банлу элекке каган белән нинди дус-әшнә булган югыйсә, шулай да беркайчан да каган аңа кунак булып килмәгән. Менә аңа, күктән тәңре үзе төшкән кебек, аның таулар арасында кысылып калган ярлы куышына кунак булып беренче тапкыр бөек каган килә!

Кымыз белән сыйлангач җәяүле ирләр яңадан атларына атландылар. Исәнтәйгә иярләнгән яхшы ат китерделәр.

Алар бераз тигезлектән бардылар да, тар гына елга ярына килеп җиттеләр. Юл яр буйлап китте, аннары, калкулыкка туры килеп, кинәт үргә менә башлады һәм шуннан соң әле түбән төшеп, әле югары күтәрелеп, я булмаса берәр калкулык итәге буенча янтаеп, каядыр көньякка — чүмәлә-чүмәлә калкулыклар арасына таба үрмәләде. Тар юлны бер яктан шаулап-шарлап аккан елга, икенче яктан — таулар кысрыклаган иде.

Тауларның төньяк итәкләре, тау араларындагы чокыр-чакырлар монда да куе урман белән капланган иде. Агачлар арасыннан зур-зур шәрә ташлар чыгып тора. Тау итәкләрендә, тар гына тигезлекләрдә, юл буйларында каяндыр өстән, кыя башларыннан кителеп төшкән өй тәүмәлеге ташлар тәгәрәшеп ята.

Таулар, урманнар белән кысрыкланган тар, караңгы җирләр, ниһаять, артта калды. Шарлап аккан су тавышы да ишетелмәс булды. Үзән киңәйде, ачылды, яктырып китте. Елганың уң ягындагы таулар кинәт кенә бик еракка чигенде, анда — елга аръягындагы таулар, куе үлән үскән киң болыннар, ак болыттай булып утлап йөргән сарык көтүләре һәм киез өйләр күренде.

Исәнтәйнең каласы елганың сул ягына, биек таулар, кыялар белән елга арасында кысылып калган утрау сыман бер шәрә калкулык өстенә салынган иде. Калкулыкны таш-балчык койма әйләндереп алган. Койма эчендә агач, таш өйләр, сырлы чирәп түбәләр. Тау астында, торак турысында елга аша салынган агач күпер. Елганың ике ягында да бер-берсенә сыенып, бергәрәк укмашып утырган балчык катыш камыш алачыклар, ярлы киез өйләр... Болар барысы да еректан ук бик сәер булып, матур да, шул ук вакытта чит һәм ят булып күренде.

---

[1] Тучи — төрки сүз. «Акыл иясе, олуг» дигән мәгънәгә туры килә. Сөннәрдә уң кул тучи бәк һәм сул кул тучи бәк булган. Каганның өлкән улы уң кул тучи бәк итеп билгеләнә торган булган. Уң кул, сул кул — уң як һәм сул як. Борынгы төркиләрдә җир өсте һәм гомумән дәүләт территориясе дүрт якка бүлеп каралган. Шундый бүленеш тәртибе административ һәм хәрби бүленешкә дә күчерелгән. Алгы якның кайда булуына карап, уң кулның һәм сул кулның да яклары төрлечәрәк булган. Борынгы заманда, барлык төркиләрдә көнчыгыш як изге саналган. Өйләрнең ишекләре көнчыгышка караган. Уң кул, уң як бәкләр, гаскәрләр һ. б. дәрәҗәлерәк, көчлерәк саналган.

— Кая салырга белгән торакны! — диде Туңгак алып каганга ярым пышылдап.

— Әйе, теге яктагы кебек... Чиндәге кебек,— диде каган да караңгы чырай белән.

— Беркаян да якын килерлек түгел! — диде Туңгак алып.

— Нидер уйлап, чамалап эшләгән бу моны.

— Туздырырга кирәк бу таш ояны!

— Карап карарбыз,— диде каган.

Хуҗа буларак, Исәнтәй бераз гына алдан барды. Каган белән Туңгак алыпның сүзләрен ул аермачык ишетмәде, шулай да, бик тырышып тыңлаганлыктан, кайбер сүзләрен чалып алды. Аларның нәрсә турында пышылдауларын ул бик яхшы сизенде. Аның йөзе кара янып чыкты. Ләкин андагы үзгәрешне беркем күрмәде дә, сизмәде дә.

## XIV

Таш, балчык коймалар белән әйләндереп алынган калкулык астында, юлның ике ягында да олы кунакларны төркем-төркем ярлылар — ирләр, хатын-кызлар, бала-чагалар каршылады. Чуар киемле шундый ук ярлылар тәбәнәк алачыклар арасыннан чыга тордылар, юл буендагы төркемнәргә кушыла тордылар. Кулларын болгап, елмаеп алар котлау сүзләре кычкырдылар.

Атлылар, шау-шулы халык төркеме арасыннан үтеп, үр менә башлады. Ерактан бик үк биек булып тоелмаган койма, янына баргач, шактый калку булып чыкты. Аннары ул балчыктан, таштан гына да өелмәгән — юан-юан карагай бүрәнәләр белән аралаштырып үстерелгән иде. Төньяктагы капканың тигез итеп юнылган, шомартылган юан баганалары яшелгә буялган, капка башына түбә ясалган, түбә өстендә кораллы сакчы өчен кечкенә куыш бар. Калын карагай такталарыннан җыелган капканың күгәннәре бакырдан иде.

Исәнтәй белән бөек каган якынайгач та авыр капкалар шыгырдап ачылып китте. Беренче капка артында, биш-алты адым ераклыкта, икенче капка күренде. Тау башындагы торакны әйләндереп алган койма ике катлы иде.

Алар ишегалдына керделәр. Ике кат койма эчендәге кысан җирдә балчык өйләр, каралтылар калкып утыра. Иң уртага, бердәнбер буш урында йөз кеше сыешлы киез өй корылган иде.

— Монда синең борылыр җирең дә юк икән,— диде каган Исәнтәйгә.

— Бөек каган өчен урын табылыр! — диде Исәнтәй.

— Капкаларны ачык калдырырга, барлык җиргә үз кешеләребезне куярга туры килер,— диде Туңгак алып, караңгы чырай белән як-ягына каранып.

— Шулай эшләрбез! — диде Исәнтәй, бик тиз килешеп.— Мин үземнең караларны, кораллы ирләрне яланга чыгарам, торакны сезгә тапшырам. Сез барыгыз да — минем кунак!

Янындагы кешеләргә ул тиз арада кирәкле боерыкларны бирде. Койма эчендәге кораллы ирләр, кирәкмәгән каралар чыгып беттеләр. Туңгак алып капкаларны, койма өстендәге каравыл өйләрен, барлык аулак җирләрне үзе карап-тикшереп чыкты, һәр җиргә үзенең ирләрен куйды. Койманың тышкы ягына да аның сакчылары басты.

Туман каган ишегалды уртасындагы киез өйгә юнәлде. Кунаклар килүгә өй эчендә бөтен нәрсә җайлап-әзерләп куелган иде. Идәнгә яңа киезләр җәелгән, уртага учак ягылган, өй әйләнә бай бизәкле сфәкләр эленгән иде. Шулай да өй эчендә дала кешесе өчен ятрак тоелган ниндидер ачы-төче исләр дә сизелгәләде. Күрәсең, шундый ят исләрне бетерү өчен өйдә әрем яндырып хуш исле майлар бөркелгән иде.

Хужа каганны түргә, алтынланган биек урынга утыртты. Аның уң ягына тәгин углан утырды. Башка ирләр каган белән тәгин углан тирәсенә, ак киезгә утырыштылар. Табын янында Туңгак алып юк иде— каганның иминлеген саклап ул сакчылар белән тышта, каравылда калды. Аш-су килгәнче кунакларны ялыктырмас өчен, алар янына хужа шундук үзенең кызларын кертте. Һәр ир янына бер кыз утырды. Кызларның күбесе таныш булып чыкты — баягынак далада алар сөн ирләрен җырлап кымыз белән сыйлаганнар иде. Сый монда да кымыздан башланды. Кызлар елмаеп кымыз агыздылар һәм шул арада җыр башлап җибәрделәр.

Ачыккан ирләргә озакламый ит килә башлады. Итне дә кызлар китерде. Кунакларга алар ит бүлеп бирделәр, тегесен-монсын алырга булыштылар. Иттән соң буза килде.

Батыр ирләр туйганчы күңел ачтылар.

Албуганың әле беркайчан да каган этисе белән, алып ирләр белән менә шулай кунакта, эчке туенда утырганы юк иде. Мондый туйларда каган белән бер табактан ашый торган һәм каган үлгәч, аның белән бергә күмелә торган иң якын ирләр генә катнаша ала иде. Бик сирәк булса да, мондый мәҗлесләргә каган шулай ук үзенең иң яраткан угылларын да ала иде. Менә этисе аны беренче тапкыр шундый эчке мәҗлесенә алды. Мондый бәхет теләсә кемгә тәтеми. Албуганың башка ир туганнары мондый нәрсәне төшләрендә дә күрә алмыйлар.

Монда ул үзен ничек тотарга да белмәде. Башка туйлардагы кебек, тын гына, тыйнак кына утырса, ирләр алдында ул үзен җебегән, булдыксыз итеп күрсәтер сыман тоелды. Инде алар кебек — бер ашаганда бер сарык ашап бетерә торган, бер эчкәндә бер чапчак буза эчеп бетерә торган ирләр кебек — алдына килгән бар нәрсәне авызына бушата торса, шулай ук тиз арада җебеп төшәр сыман тоелды. Атасы каган алдында, алып ирләр алдында аның чын ир дә булып күренәсе килә иде, шулай ук ул теге кичтәге кебек исереп егылудан да курыкты. Бүген аңа һич тә егылырга ярамый. Бүген монда бик күңелле булырга тиеш иде!

Аның янына тәбәнәк буйлы, уймактай кечкенә авызлы яшь бер кызны утырттылар. Албуга уңайсызланып кып-кызыл булды. Кызның йөзенә туры карамас өчен күзләрен түбән иде. Кыз исә, киресенчә, вак кына тешләрен күрсәтеп, әледән-әле елмайган булды, калтыранган нәфис куллары белән эчемлек тулы кәсә сузып, яшь егетне эчәргә кыстаган булды. Тәгин угланга ул никтер беренче караштан ук ошамады. Кыз аның үзеннән дә яшьрәк иде бугай. Ул аңа нишләптер бик кызганыч тоелды.

Өлкән углының оялуын, кыюсызлануын ата кеше бик тиз күреп алды. Бу аңа ошады да, ошамады да. «Яратмады»,— дип уйлады ул углы турында. Шул ук вакытта урдада калган Табылдык исенә төште. «Аны уйлый микәнни?» — диде үз-үзенә. Үзенең углы өчен ул нинди дә булса яхшылык эшләргә тиештер ич! Табылдыкны бирсә дә була. Була, ник булмасын! Туктале, монда Исәнтәйнең берәр гүзәлрәк кызы юк микән? Нигә аңа үзенекен өзеп бирергә? Табылдыкка торырлык берәр кызы юк микәнни бу юлбасар Исәнтәйнең?

Кызмача каган үзенең сул ягына утырган Исәнтәйгә борылды да пышылдыйм дип уйлап:

— Минем углыма кыз кирәк, Исәнтәй,— дип кычкырды.

Исәнтәйнең туктаусыз балкыган йөзе сүрелеп калды.

— Мин санадым — җитә,— диде ул.

— Күрмисеңмени — күңелсезләнеп утыра,— диде каган, тәгин углан ягына ымлап.— Аңа син иң яхшысын китер, иң гүзәлен. Илдә югын! Минем углымның күңеле шат булырга тиеш!

— Аңладым,— диде Исәнтәй бик нык уйланып.

— Аңласаң, китер. Мин аңа бүген барлык ирләр «аһ» итәрлек кыз бүләк итеп бирергә тиешмен.

— Бар бер кыз,— диде Исәнтәй, теләр-теләмәс кенә.— Мин аны, бөек каган, синең үзеңә бирергә дип уйлаган идем. Урдага алып барып. Сиңа әйтәсе сүзем дә бар.

— Сүзеңне урдага баргач әйтерсең. Кызыңны китер! — диде каган тыңларга теләмичә.

Исәнтәй китеп барды. Өйдән чыккач та ул каядыр каралты-куралар ягына юнәлде. Монда аның ат абзарлары, утын сарайлары урнашкан. Шунда ук абзарлар, утын сарайлары арасында зур гына ташерен өе дә бар иде. Өйнең ишек төбендә, тышкы якта аның үз кешесе сакта тора иде.

Яшерен өйгә җитәрәк хуҗа кеше адымын әкренәйтә төште. Үзенең ишек сакчылары, койма, капка торгаклары, эшчеләре янына ул шулай качып-посып, сиздермичә генә барырга һәм аларны берәр ярамаган эштә тотарга ярата. Инде чыннан да тота-нитә калса, гаепләне үтергәнче тукмый иде.

Әле дә ул ишек янына песи кебек кенә атлап килде дә шомарып беткән баганага сөялеп торган кораллы сакчының якасыннан эләктереп алды. Берни сизмәгән сакчы сискәнеп китте, бүре авызына эләккән бәрән сыман, кызганыч бер өн белән шыңшыгандай итте дә шып булды. Хуҗа сакчы ирнең битен үзенә таба борды һәм:

— Йокламыйсыңмы? — дип кычкырды.

— Юк, юк, йокламыйм! — диде сакчы, аклана башлап.

Исәнтәй бәйләнеп тормады — эше кызу иде.

— Килүче-китүче булмадымы? — диде ул усал пышылдап.

— Юк.

— Керүче булмадымы?

— Юк.

— Кара аны, күзеңне ачып тор! — диде хуҗа янап.

Ул әкрен генә ачып ишектән керде һәм шундук кире борылды. Сакчы, сукмакчы була ахрысы дип уйлап, тиз генә кулын бите турысына күтәрде.

— Әйдәле минем белән,— диде хуҗа тыныч кына.

Ишектән кергәч алар тар, караңгы аралыктан бардылар. Ялгыш монда берәр чит кеше килеп керсә, бер-ике адым атлау белән, бәрелеп я маңгаен тишәр, я күзен чыгарыр иде. Үз өендә Исәнтәйгә бернинди ут та, юл күрсәтүче дә кирәкмәде. Башта ул турыга барды, аннан соң сулга борылды, уңга борылды һәм суган-сарымсак, кыздырылган ит-май исе аңкыган, ишеге ныклап ябылмаган аш пешерү бүлмәсе яныннан үтеп китте. Ярым ачык ишек турысыннан узганда ул тар ярыктан эчкә күз ташламый булдыра алмады. Олы яшьләрдәге ир кеше, бил тиңентен чишенеп ташлап, хатынынннан аркасын кашытып тора иде. Исәнтәй, гадәтенчә, аларның сүзләренә дә колак салды.

Аш пешерә торган бүлмәне узып өч-дүрт адым атлагач та, каршы якта алар икенче бер ишек алдында туктап калдылар. Ишектән тар гына тасмадай булып яктылык төшә иде. Исәнтәй, тынын кысып, шактый озак тыңлап торды. Эчтә бернинди тавыш-тын ишетелмәде. Үзе белән килгән кораллы сакчыны хуҗа ишектән читкәрәк бастырды да, пышылдап кына:

— Чакыргач та атылып кер! — диде.

Шуннан соң ул әкрен генә ишек шакыды. Эчтән җавап бирүче булмады. Исәнтәй тагын шакыды, ныграк итеп шакыды. Бераздан кемдер ишек янына килде, үрталеп, тотлыгып:

— Кем бар анда? Ни кирәк? — дип сорады.

— Бу — мин. Ач әле, син кирәк,— диде хуҗа ягымлы итеп.

Эчтәге ир кеше үзалдына мыгырданып алды, көттереп булса да

ишекне яртылаш ачты. Исәнтәй ялт кына бүлмә эченә күз төшереп алды һәм ярым шәрә яшь хатынның ашыгып юрган астына кереп барганын күреп калды. Җир идәндәге түгәрәк табында ашалып-эчелеп бетмәгән ашамлыклар, эчемлекләр, вак-төяк савыт-саба тора иде.

Ишек ачкан яшь ир кеше дә ярым шәрә иде. Кара чәчле, озынча битле, калку гәүдәле бу кеше, алыптай таза булмаса да, киң күкрәкле, тыгыз тәнле иде. Шуның өстәвенә анда яшь көч, дәрт, омтылыш һәм шулай ук ачу-ярсу ташып торганлыгы сизелә. Төн уртасында ишек ачтыручының хуҗа кеше булуына да карамастан, ул аны үз бүлмәсенә кертергә ашыкмады — бер кулы белән ишек яңагына, икенче кулы белән ишек бавына тотынган килеш ул тынгысыз, усал күз карашын Банхуаның ямьсез, җирәнгеч йөзенә текәде.

— Җиде төн уртасында ир белән хатын яткан өй ишеген ачтырып керү бернинди йолага да, әдәпкә дә сыймый,— диде ул ярсуын тыярга тырышып.

— Үз өемдә үз бүлмәмә керергә ярыйдыр ич? — диде Банхуа йомшак, ягымлы, үтергеч бер өстенлек белән.

Яшь ир кеше мондый сүзгә каршы ни әйтергә дә белми аптырабрак калды. Шул ук мәлдә Банхуа аның ишек яңагындагы шәрә кулын читкә этәрде, эчкә керде. Яшь ир кеше, биек ятакта юрганга төренеп яткан хатынын яман күздән сакларга тырышкан сыман, арты белән чигенеп, түргә узды, һәм керүчедән күзен алмыйча, көтә башлады.

Ачык ишеккә арты белән баскан килеш, авыр кулларын артына яшереп, Банхуа да беравык көтеп, уйлангандай итеп торды.

— Басып керүем өчен ачуланма,— диде ул килешүчән бер ягымлылык белән.— Ашыгыч эш чыкты. Каганның... синең сеңеләңне күрәсе килә.

Ярым шәрә ир кеше кинәт билен турайтты, күкрәген киерде, аптырап, ярсып һәм нидер эшләмәкче булып, хуҗага таба тартылып куйды.

— Хәзерүкме?! — диде ул гырылдап.— Каян белгән ул? Син әйткәнсең аны!

Ялт кына иелеп ул түшәк астыннан, яшь хатынның башы турысыннан хәнҗәр тартып чыгарды.

— Син әйткәнсең, син! — дип кычкырды ул, хуҗага ташланып.

Юрган кырыеннан утлы күзләрен елтыратып яткан яшь хатын кинәт чырылдап җибәрде, куркып каядыр почмакка шуышты. Шул чакта аның өстендәге юрганы ачылып китте. Исәнтәйнең бер як күзе алдында үткер хәнҗәр очы ялтырады, икенче күзе алдында, акылын-зиһенен томалап, тере балыктай ап-ак булып, оятсыз шәрә гүзәллек чагылып калды. Бөтен нәрсә кинәт күз алдында чайкалып китте. Шулай да ул җебеп төшмәде — хәнҗәрле кулны тиз генә тотып алды, кысып алды, каерып алды да, чыгырыннан чыккан яшь ирне җиңел генә итеп идәнгә чүктерде. Андагы көч, андагы җитезлек мондый яшь ирләрнең берсенә түгел, уңысына җитәрлек иде.

— Син... кунак... Минем өемдә, минем ашымны ашап, миңа каршы корал күтәрәсеңмени?! — диде ул үтергеч бер нәфрәт белән.

Кунак аның андый сүзләрен генә аңларлык хәлдә түгел иде. Аның күзләре акайган, бөтен тәнен тыелгысыз ярсу һәм өметсезлек калтырата. Банхуа хәнҗәрле кулны ычкындыру белән, ул яңадан хуҗага ташланмакчы булды. Хуҗа сакчыга эндәште. Сакчы бер-ике сикерүдә кунак каршысына килеп тә басты, идәндә яткан хәнҗәрне аягы белән читкә шуыштырды һәм яшь ирнең шәрә тәненә үз хәнҗәрен якын китерде. Яшь ир, каршылык күрсәтеп азаплануның мәгънәсезлеген аңлап, лып итеп идәнгә утырды һәм авызын кыйшайтып, йөзен чытып, тавышсыз гына еларга тотынды.

Почмакка поскан ярым шәрә кызга хуҗа киенергә кушты.

## XV

Олы кунаклары янына кызны Исәнтәй юындырып, өр-яңадан киендереп китерде. Алар ишектән килеп кергәндә туйның кызган чагы иде. Ирләр, кызлар, аягүрә басып, күмәк уеннар, биюләр башлап җибәргәннәр. Шуңа күрә Исәнтәй белән ят кызның килеп керүен күрүче дә булмады. Хуҗа, шаулашкан, биегән ирләргә, кызларга орынмаска тырышып, читтән генә түр янына — каган ягына үтте. Шакгый кызмача каган нәрсәгәдер күңеле булып, тыела алмый көлеп тора иде.

Исәнтәй, үзенең килүен белдереп, кыюсыз гына тамак кырды. Каган борылды, ләкин хуҗа кешегә ни кирәген тиз генә төшенә алмады — Исәнтәйне нинди йомыш белән чыгарып җибәрүен ул инде оныткан иде, ахрысы.

— Мин сиңа илдә юк кыз китердем, бөек каган,— диде Исәнтәй, түбәнчелек белән баш иеп.

— «Илдә юк» кыз юк ул, Исәнтәй! — диде каган никтер тагын көләргә тотынып.— Илдә юк булса, миндә бар — урдага кил, мин сиңа күрсәтермен. Син ялганчы, Исәнтәй! Шуның өчен, беләсеңме, мин сине нишләтермен? Мин сине үзең салган агач күпердән шаулап аккан суга ыргытачакмын! Син — икейөзле, угры, Исәнтәй!

— Син миңа боердың, бөек каган,— диде Исәнтәй, агарынып.

— Мин синең балчык ояңны туздырачакмын, сатлык Исәнтәй! — дип кычкырды каган Исәнтәй ягына борылып та карамыйча.

Исерек каганның холыксызлыгы турында Исәнтәй ишетеп белә иде.

— Тәгин угланга син күркәм кыз китерергә боердың, бөек каган,— диде ул тагын да барлык батырлыгын җыеп.

— Кая соң ул синең күркәм кызың, ялганчы Исәнтәй? — диде каган, як-ягына каранып.

— Менә ул! — диде Исәнтәй, кызны каганның каршысына ук китереп.

Каган кызга өстән генә, читтән генә бер күз карашы ташлап алды. Кызны ул чыннан да беренче мәртәбә күрә иде һәм ул чыннан да сылу иде бугай. Бөтен өй эченә кычкырып ул яшьләр арасыннан үзенең оялчан углын чакыртып алды. Уен-көлке туктады һәм барысы да түр ягына борылдылар.

— Каган сөйли — мине тыңлагыз! — дип кычкырды Туман каган.— Ирләрем-алыпларым. Улларым-егетләрем! Сез минем якыннарым, сез минем сакчыларым. Сездән башка мин уксыз җәя кебек, башаксыз сөңге кебек. Мин булмасам, сез булмас идегез, сез булмагасыз, мин булмас идем. Минем тәгин углым Албуга булмаса, мин инде тәңре катына очкан булыр идем. Сезнең күбегез күреп торды — үзенең кыюлыгы, куркусызлыгы аркасында ул мине үлемнән коткарды. Шулай булгач, ул сезне дә үлемнән коткарды. Албуга минем иң турылыклы углым. Шуның өчен мин аңа «илдә юк» күркәм кыз бүләк итеп бирәм!

— Яшә, Туман каган!

— Яшә, Албуга! — диделәр ирләр шаулашып, алкышлап.

— Каяле, тагын бер күрсәт әле «илдә юк» кызыңны! — диде каган, Исәнтәйгә эндәшеп.

Исәнтәй ымлап кызга якынрак килергә кушты. Кыз яктыгарак чыкты, башын югарырак күтәрде һәм эчке бер өстенлек белән, үзенең тел тидергесез гүзәллегеннән горурлану, масаю һәм чак-чак кына мыскыл белән, шулай да ягымлы күренергә тырышып, башта каганга, аннары бүтән ирләргә тылсымлы күз карашы йөртеп чыкты.

Каган кинәт тынсыз калды. Йөзендәге, бөтен кыяфәтендәге исереклек галәмәте, батырлык, кыюлык, бөеклек һәм шуның ише ялган нәрсәләр юкка чыкты. «Күз күрмәгән», ләкин күзе күргән гүзәллек алдында, чын тормыш һәм табигать алдында ул бик кечкенә бөҗәк булып кал-

гандай тоелды. Тик торганда аны кинәт очкылык тота башлады. Өй эче әкренләп тына барды, кызмача шау-шу, гамьсез күңеллелек күз алдында юк булды.

Каган, сакланып кына диярлек, углының кулыннан алды, икенче кулы белән шулай ук сакланып кына кызның кулыннан тотты да яшьләрне бер-берсенә якын китерде һәм карлыгып калган калтыравык бер тавыш белән:

— Менә, углым, миннән бүләк сиңа,— диде. Шуннан соң ул Исәнтәйгә борылды һәм, әле генә үзе кычкырган тотнаксыз сүзләре өчен уңайсызланган кебек, әйтеп куйды.— Син, Исәнтәй, кайгырма — балчык оянга берни булмас,— диде.

Исәнтәй елмайды, шундук бил бөкте һәм каганның тун чабуын үпте. Болай булгач, исән калдың, Банхуа!

— Бүләгеңне алдым, эти,— диде Албуга куанып.

— Алмыйча! Мондый бүләктән баш тартып кара! — диде каган, никтер үкенгән сыман һәм бер дә юктан кычкырып көләргә тотынды.

— Бай бул, эти. Тәңре сиңа күп яшь бирсен, байлык бирсен,— диде углы, гүзәл чин кызыннан күзен ала алмыйча.

— Әйдәгез әле, эчик бер шушы куанычтан,— дип кычкырды каган өй эчендәгеләргә.

Ирләр эчтеләр, кызлар чыр-чу килгән булды. Ләкин күңел ачу элеккечә җанланып китә алмады. Һәркем үзенең янында гына, янәшәсендә генә утырган бәхетле яшьләр турында уйлады. Үзләренең дә шундый гүзәл, шундый бай кызлары булмаудан көнләшеп, кызыгып, күп ирләрнең эче пошты. Исәнтәй кызлары исә — үзләренең дә әлеге ят кыз сыман була алмаулары өчен әрнеп, сыкранып тешләрен кыстылар. Барлык ирләр, барлык кызлар арасында бары бер генә кеше—яшь һәм тәҗрибәсез углан гына беркемнән көнләшмәде дә, бер нәрсәгә сыкранмады да. Бу вакытта бар дөньяда иң бәхетле, иң өлешле кеше иде ул. Бер кызарды, бер агарды углан, елмайды, кашларын җыерды һәм, берни эндәшмичә, бары үзенең бүләгенә генә карап алды. Бу кыз аңа нишләптер бик таныш тоелды. Ул инде аны кайдадыр күргән иде бугай.

## Икенче баб

### I

Бу якка алар берәмләп тә, икешәрләп-өчәрләп тә чыктылар. Адым саен аларны үлем сагалап торды. Ачлыктан соңгы чиккә җитеп алар агач төпләрендә, юл буйларында ятып калдылар. Кайберләре аларның тирән су чыкканда батып үлделәр, кайберләре озын тарлавыкларда, тау-таш араларында адашып калды. Егылып күзләре йомылдымы, шундук аларны ач бүреләр ботарлап ташлады, ерткыч кошлар чукып бетерде. Чик аша чыгу аларга аеруча кыенга туры килде. Йөрү тыелган төштә күренү белән, бернинди кызганусыз аларга ук аттылар, таш аттылар я булмаса көтмәгәндә китереп сөңге белән тондырдылар.

Ләкин алар бернигә карамыйча, караңгы төннәрдә, коеп яуган яңгырларда, качып-посып, шуышып төн ягына — көн ягындагыга караганда кояш җылырак, ягымлырак балкыган шикелле тоелган серле якка омтылдылар. Көч житмәслек авыр эшләрдән, кансыз хуҗалардан качып киткән коллар, юлбасарлар, качак сугышчылар — ирләр, яшьләр, хатын-кызлар — куркыныч таулардан да куркынычлырак чик сакчыларын үтеп, тигез җиргә — әрем, кылган ише каты үләннәрдән башка берни үсмәгән, балчык өйләре, калалары, сугарулы дөге кырлары булмаган ачык, иркен дала ягына аяк басу белән, шомлану катыш сөенеп, иң

артларына әйләнеп карадылар һәм, күз яшьләрен түгеп, Олуг Күккә рәхмәтләр белдерделәр.

Җил-кояш кискән тупас йөзле, тупас телдә сөйләшүче сөннәр качакларга ачтан үлмәслек кенә ашарга бирделәр. Шуннан соң аларны тентеделәр, белгән бар нәрсәләрен сөйләттеләр дә ары озаттылар. Туган илләре Җунгода күргәннәрен алар елый-елый сөйләделәр, үлгән, үтерелгән, югалган ата-аналарын, балаларын уйлап, андагы тәртипләргә, андагы түрәләргә ләгънәтләр яудырдылар.

Арада, билгеле, бүтәннәргә охшамаган качаклар да булды. Сорашканга алар теләмичә генә җавап бирделәр һәм дала хуҗаларына күрәләтә ят итеп, хәтта дошман итеп карадылар. Андыйларны сөннәр шундук кулга алдылар һәм ныгытып тикшерү өчен янә ары озаттылар.

Бу якка чыгу белән, качаклар ничек тә үз ватандашлары тирәсенә елышырга тырыштылар. Кайберләре, киресенчә, ялгызлыкка омтылдылар — берәр су буенда куыш корып, балык тотып, шуның белән җан асрарга тырышты. Кайберләре, далага таралып, сөннәргә ялчылыкка керде. Шулай да күпчелек утрак авылларда, калаларда торып калды. Таштугай үзәнендәге Банхуа катавы [1] качакларны үзенә тартып торган шундый калаларның берсе иде. Тегe яктан чыккан теләсә нинди качак барыннан да элек Банхуаны белеште. Чик буендагы сөн ирләре моңа инде күнегеп беткәннәр иде.

Барыс елының җиденче ае, егерме сигезенче көнендә, таң алдыннан, Тарлавыкка якын җирдә яшәүче сөн ирләре башкаларга бик үк охшамаган берничә качакны тотып алдылар. Алар барлыгы дүрт кеше иде — өчесе ир, берсе хатын-кыз.

Киемнәренә, коралларына, үз-үзләрен тотышларына караганда, ирләр теге якның чик сакчылары булырга тиешләр иде. Хатын-кызның яшьме, картмы, матурмы, ямьсезме икәнлеген белерлек түгел. Ни өчен дигәндә, ул авырлы иде һәм озын тун итәген алгы яктан ямьсез итеп күтәртеп аның таудай корсагы калкып тора. Шуның өстенә аның битебашы иске чүпрәк белән чорналып беткән, чүпрәк аша кызыл кан саркып чыккан иде. Чин хатынының мондый кыяфәтен күргәч, беркемнең дә күңелендә аның кемлеге, ниндилеге белән кызыксыну теләге тумады. Чыннан да, авырлы чин хатыны белән сөн ирләре бөтенләй кызыксынмадылар. Шулай да сөннәрнең берсе болай гына:

— Бите нишләде? — дип куйды.

— Бу минем хатыным. Төнлә урман аша үткәндә битенә ботак төртелде. Канын көчкә туктаттык,— диде тылмач аша качакларның берсе — яшьрәге, чандыррагы.

Үзләренең бу якка чыгуларын алар бик җиңел аңлаттылар. Яуда үләсебез килмәде, үзебезнең башлыкларны үтердек тә качтык, диделәр. Аларның сүзенә беркем шикләнү белдермәде. Качакларга барлык коралларын салып калдырырга кушылды. Алар, берниндн каршылыксыз, бар булган нәрсәләрен — укларын-җәяләрен, пычак, хәнҗәрләрен шундук чыгарып салдылар. Сөн ирләре аларны баштан аяк капшап чыкты. Берсенең куенындагы чакма ташын, икенчесенең кадак сыман очлы тимерен, энәсен һәм шуныңише вак-төяк нәрсәләрен алдылар.

Авырлы хатын, еш-еш мышнап, бер читтәрәк басып торды. Аны тентеп карарга беркемнең дә башына килмәде. Тентегәннән соң ирләрдән сорау алдылар. Чин качаклары әлләни яңалык әйтмәде — алар әйткәнне бу якта инде беләләр иде.

Качакларның барысы өчен дә авырлы хатынның ире — яшь, чандыр ир сөйләде. Сорау алу беткәч ул бик түбәнчелек белән үзенең үтенечен белдерде:

---

[1] Катау — ныгытылган торак, кала.

— Хатынымның хәле начар. Банхуага кадәр озатып куярга кылавыз[1] бирмәссезме? — диде.

Сорау алучы сөн ире — өлкән яшьләрдәге, хәйләкәр кысык күзле йөзбашы Күчәр «Банхуа» исеме чыгу белән тынып калды. «Корсаклы» хатынның Банхуа-Исәнтәй өчен китертелә торган кыз булырга тиешлеген ул инде болай да чамалап алган иде. Качакларның туры Банхуага барырга җыенуларын белгәч, ул моңа бөтенләй шикләнмәде. Исәнтәй белән яшерен килешү нигезендә, аңа бара торган мондый «авырлы» хатыннарны ул бөтенләй тикшерми иде. Моның өчен Исәнтәй аны буш итми.

Хәйләкәр йөзбашы Күчәр сөн ирләре алдында Банхуа-Исәнтәйне сүгеп, мыгырданып алды. Шуннан соң ул авырлы хатынга озак кына карап торды.

— Вакыты җиткәнмени? — диде ул үзен Чәнси дип атаган яшь иргә.

— Вакыты җиткән,— диде Чәнси тылмач аша.

— Ярар, китсеннәр,— диде йөзбашы Күчәр.

Шуннан соң ул өй эчендәге яшь кенә бер иргә — бай киемле, ачык йөзле, алыптай таза угланга күтәрелеп карады.

— Олуг тучи бәк! — диде ул аңа.— Мин сине кылавыз итеп җибәрәм. Егетләрең белән бергәләп бу качакларны Таштугай үзәненә, Исәнтәйгә кадәр озатып куярсың. Шуннан урдага кайтып Туңгак алыпка әйтерсең. Шикле күренәләр болар, үзе яхшылап тикшерер, сорау алыр.

— Хатын өчен арба җигәрбез! — диде тучи бәк тәгин углан, боерыкны үтәргә әзер икәнлеген белдереп.— Ирләре атта йөри бelә микән?

Йөзбашы Күчәр тылмач аша аның соравын кабатлады. Чин ирләре атта йөри беләләр иде.

Шулай итеп, йөзбашы Күчәр качакларны Туман каганның өлкән углы Албуга карамагында Туштугай үзәненә озатты. Үзенә эш таба алмый интеккән, кая да булса яуга, сугышка омтылган һәм нинди дә булса батырлык эшләү турында хыялланган яшь тәгин угланны чик буена, йөзбашы Күчәр өстеннән күзәтеп торырсың дип, Туңгак алып җибәргән иде. Әледән-әле үзенең эчен пошырып, ирегең кысып торган тыңгысыз тучи бәк тәгин углан йөзбашы Күчәр өчен монда, билгеле, артык кеше иде. Шуңа күрә ул аннан беразга булса да котылып торырга тырышты.

## II

Хатыннары, балалары, мал-туарлары белән таулар арасында яшәүче чик буе сөннәренең ялгыз өе Тарлавык авызында, киң генә бер ачык урында утыра иде. Ләкин бу әле дала түгел. Далага чыгу өчен шактый үр менәргә кирәк иде.

Ташлы юлдан алар бераз вакыт җәяүләп бардылар. Тигезрәк, ачыграк җиргә менеп җиткәндә көн яктыра төште. Еракта, караләжым тау шәүләләре артыннан кысылып кына кояш чыгып килгәне күренде. Юлчылар тигезлеккә килеп менгәч, туктап артларына борылдылар. Түбәндә, аяк астында гына исәпсез-хисапсыз таулар, кыялар диңгезе күреп, ирексездән алар аһылдап куйдылар. Шундый куркыныч, дәһшәтле һәм мәһабәт иде бу артта калган ташлы таулар!

Бу таулар аша бормаланып тар гына ташлы сукмак үтте. Язгы ташу һәм җәйге яңгыр вакытларында ул сукмактан — кыялар арасында кысылып калган тар аралыктан шарлап, дөбердәп сулар ага. Тарлавык буенча түбән таба тагын бер көн чамасы барсаң, аста, таулар артын-

[1] Кылавыз — юл күрсәтүче.

да — батынкы, жылы үзәндә Җунго башлана. Киресенчә, таулар арасыннан үргә үрләсәң, кояш чыгып килгән каралҗым таулардан да, кыялардан да өстәрәк, биектәрәк киң тигезлек — Бөек дала җәйрәп ята. Анда — Сөн иле. Анда салкын, анда бары бозлы җилләр генә исә.

Астан югарыга таба үрмәләүче качаклар да, өстән түбәнгә төшүче сөннәр дә әлеге Тарлавыкны берничек тә читләтеп үтә алмыйлар. Чөнки бу тирәдә ике ил арасында башка юл юк. Тарлавык — ике якны килештерә дә, сугыштыра да торган бердәнбер юл. Үлем һәм тереклек юлы.

Менә ул, ниһаять, артта, аста калды.

Авырлы хатын өскә менеп җиткәч тә җиргә егылды. Аны инде болай да чин ирләре ике яклап җитәкләп-күтәреп диярлек алып менделәр. Авыр юлга чыгар алдыннан качакларны өйгә алып кереп, ашарларына, эчәрләренә бирделәр. Авырлы хатынны атлар җигелгән ике тәгәрмәчле арбага утырттылар. Ирләр атка атланды. Иң алдан сөн ирләре китте, алар артыннан — Чәнси, Чәнси артыннан җигүле арба кузгалды. Арба артыннан ике чин ире барды. Юл иркен булса да, бер-бер артлы тезелеп бардылар. Бераздан тигезлек яңадан үр белән алмашынды. Тик шулай да бу инде артта калган Тарлавык түгел иде — монда юл да сөзәгрәк, тау итәкләре дә яссырак, ягымлырак иде. Ачык, шәрә калкулыкның икенче ягына чыккач, имән, каен, карагай катыш урман башланды. Бер калкулык аша чыгып, тигезлектән бераз җир бардылар да, яңадан икенче калкулык итәгенә менделәр. Һәм таулар-калкулыклардан бер менеп, бер төшеп, тирән чокырлар, киң үзәннәр аша алар көне буе шулай бардылар да бардылар.

Качаклар үзара берни сөйләшмәде, шулай ук сөн ирләре белән дә гәпләшүче булмады, чөнки сөннәрнең телен чиннәр белми иде. Алар шулай эндәшмичә, сөйләшмичә, ярым йокылы килеш дигәндәй шактый озак бардылар. Бер ачыклыкта, тауга-үргә чабып барган ниндидер киекләрне күреп, яшьләр кинәт җанланып киттеләр. Албуга белән берничә егет һай-һулап киекләр артыннан ташландылар. Шактый озак куып барганнан соң алар кыр кәҗәсе атып алдылар.

Тәгин углан белән өч-дүрт егет киекләр артыннан куып киткән арада башкалар, туктап тормыйча, юлларын дәвам иттеләр. Аучылар үзләренең юлдашларын арттан куып җиттеләр. Авырлы хатын утырып барган арба белән тигезләшкәч, Албуга арбага төртеп күрсәтте дә:

— Хатының исәнме? — диде Чәнсигә.

Чин качагы, билгеле, берни аңламады, шуңа күрә ул җавап та кайтармады, «белмим» дигән сыман бары баш кына какты. Арбадагы хатын, якында гына ят тавыш ишетеп, ахрысы, сискәнеп китте һәм тыелып кына кычкырып җибәрде. Албуга Чәнсигә эндәшкәндә ул арбада йокымсырап бара иде бугай. Аның ирексездән ычкынган куркулы тавышы Тәгин угланга бик яшь булып, матур булып ишетелде. Бу аңа бик сәер тоелды. Ләкин ул моңа бөтенләй диярлек игътибар итмәде — атын юырттырып, ары китеп барды. Бары тик соңыннан гына ул, үзе дә сизмәстән, әледән-әле яшь матур тавышны исенә төшерде һәм шундый тавышлы хатынның шундый ямьсез булуы аңа гаҗәп тоелды.

Төштән соң таулар артта калды. Алда, як-якта иксез-чиксез тигезлек башланды. Менә тигезлек тә бетте. Сөннәр, үзләре генә белгән ниндидер комлы калкулыклар янына җиткәч, килгән юлдан уңга — көнчыгышка таба борылдылар һәм качаклар алдында тагын күкселләнеп биек таулар күтәрелде.

Көн кичкә авыша барганда алар әлеге күксел таулар-калкулыклар арасына килеп керделәр. Юл ташлы, урманлы үзән уртасыннан барды. Сөн ирләре туктап калдылар. Чиннәргә дә туктарга кушылды. Сөннәр, җиргә төшеп, атларын утларга җибәрделәр. Качаклар да атларыннан

төштеләр һәм кылавызларның күзләренә карап, нәрсә әйтерләр икән болар, дигән сыман көтеп тора башладылар.

Алай башы тәгин углан, качакларга үз артыннан иярергә кушып, җәяүләп, якындагы сөзәк калкулыкка менеп китте. Ирләр авырлы хатынны ике яктан култыклап, аның артыннан ияրделәр. Кораллы егетләр аста торып калды.

Тау башына менеп җиткәч, тәгин углан калкулыкның икенче ягына карады да каядыр еракка төртеп күрсәтте. Алар басып торган калкулык өстендә бернинди агач та, куак та юк, шунлыктан, кайсы якка борылып карасаң да, бөтен тирә-як монда уч төбендәгедәй ап-ачык булып күренә иде.

Качаклар ул күрсәткән якка җентекләп карый башладылар. Аста, еракта, куе урманнар, калкулыклар артында, киң үзән буендагы тау башында алар дүрткел койма һәм койма эчендә чирәп түбәле таныш сыман өйләр күреп алдылар. Бу нәкъ Җунгодагы кебек иде. Чин ирләренә шундук җан кереп китте, бер-берсен бүлдереп алар шундук ни турындадыр сөйләшергә дә керештеләр.

— Банхуа! — диде Албуга елмаеп, коймалы тау ягына күрсәтеп.

— Банхуа! Банхуа! — диделәр чин ирләре, аңлаганлыкларын белдереп.

Шуннан соң тәгин углан җир өстендәге каты үләннәрне төптән тигезләде дә, шунда яткан бер кечкенә ташны куптарып, икенче урынга алып куйды. Ташны ул «Банхуа» дип атады. Тагын икенче бер таш алып, ул аны «Банхуа» дигән таштан читкәрәк куйды. Икенче ташны ул «Без» диде. Моны чиннәр дә аңласын өчен, бармагын башта үзенә, аннары чиннәрнең күкрәгенә төртеп чыкты. «Банхуа»дан да, «Без»дән дә бик читкә ул өченче таш, өченче таш янына дүртенче таш куйды. Аста утлап йөргән атларны күрсәткәч, атта чабып барган сыман итеп ул «Без» ташыннан ерактагы өченче, дүртенче таш янына таба китте. Ерактагы ташлар янына ул юри әйләнгеч ясап барды һәм шулай бик еракτан «Банхуа» ташы янына килеп җитте. Килеп җиткәч, арып, хәлдән таеп җиргә егылды.

Аның һәрбер хәрәкәтен игътибар белән күзәтеп торган Чәнси дә, башкалар да елмаеп куйдылар. Ләкин алар аның ни әйтергә теләвен аңлап елмайдылармы, аның кыланышыннан гына елмайдылармы — тәгин углан белә алмады. Шунлыктан, ул, ныграк аңлашылсын өчен, «Без» ташыннан «Банхуа» ташына таба җәяүләп «йөреп» китте һәм аягүрә басып, кулы белән яңадан ерактагы дүрткел койма ягына төртеп күрсәтте. Моның белән ул: Банхуа торагына шушыннан җәяүләп турыга гына барыгыз, моннан юл кыскарак, димәкче булды.

Качаклар, чыннан да төшенгәнлекләрен белдереп, баш кактылар һәм сөн иренең хәрәкәтләрен кабатлап, Банхуа торагы ягына төртеп-төртеп күрсәттеләр. Шулай итеп, алар тулысынча аңлаштылар.

Тәгин углан сикереп урыныннан торды, саубуллашып түбән төшеп китте. Китеп барышлый ул тагын бер мәртәбә авырлы хатынга карап алды. Хатын, аңа арты белән торган килеш, битендәге чүпрәген сүтеп азаплана иде. Куе, каты үләннәрне шыштырдатып яныннан гына китеп барган егеткә ул көтмәгәндә борылып карады һәм тагын да ничектер куркып, җиңелчә генә кычкырып җибәрде.

Албуга да кычкырып җибәрә язды. Баягы ямьсез хатын урынына тере күз карашлы яшь чибәр кыз күреп ул шаккатты. «Әллә күземә күренә инде?» дип уйлады ул шомланып һәм абына-сөртенә тизрәк атлады, егетләре янына ашыкты.

Төшеп җиткәч ул, арбага сөялеп, беравык тын алып торды. Нишләптер аның буыннары калтырый, йөрәге ашкынып тибә иде.

— Ни булды?

— Синең төсең качкан! — диделәр егетләр.

— Берни булмады,— диде ул.— Ашыйсы килә, арытты. Шуңадыр.

Алар килгән юллары белән кире киттеләр, аулак, тыныч бер үзәндә учак яктылар да, баягынак көндез атып алган кыр кәҗәсен пешерергә әзерләнә башладылар. Төнне алар шул үзәндә үткәрделәр. Икенче көнне тәгин углан үзенең юлдашлары белән әнисенең урдасына юнәлде.



## III

Үзләрен озатып килгән яшь сөн ирләре күздән югалгач та качаклар, эчке бер куаныч белән, өмет һәм ышаныч белән, яңадан, җентекләп «Банхуа» ягын күзәтергә тотындылар.

Дүрт качакның башлыгы Чәнси иде. Теге якта ук килешенгәнчә, ирләрнең икесе дә берсүзсез аңа буйсынырга тиешләр. Буйсынырга тиешле ирләрнең берсе — урта яшьтәгесе, ни әйтсәң шуны тыңлый торган, басынкы һәм күндәм кеше. Икенчесе аннан яшьрәк тә, калкурак та һәм, күндәм ирнең капма-каршысы буларак, шактый кире һәм үзсүзле иде.

Ирләр, тулы ректә калгач, өчесе дә бер тирәгәрәк утырыштылар да, үзара киңәшә башладылар. Көн инде караңгыланып килә. Караңгы төшкәнче алар «Банхуа»га барып җитә алырлармы, әллә таныш булмаган урман-таулар арасында адашып йөрерләрме? «Банхуа» моннан карaганда әллә ни ерак та түгел кебек, ләкин шулай гына тоелмый микән ул? Аннан соң, «Банхуа»га исән-имин барып җиткән очракта да, төн уртасында капкадан кем кертер икән аларны! Урта яшьләрдәге басынкы кыяфәтле ир төнне шунда гына уздырырга киңәш итте. Арыган килеш урманда адашып йөргәнче, ачык җирдә төн уздыру яхшырак булыр, диде ул. Яшьрәк ир дә аны яклады. Әйе шул, шушында гына куныйк, диде.

Алар шулай сөйләшкәндә-киңәшкәндә Чәнси, ни турындадыр уйланып, газапланып утырды. Алҗыган тынгысыз күзләрен кыскалап ул ирләрнең әле берсенә, әле икенчесенә карап алды, аннары, кинәт исенә төшеп, читтәрәк, ирләргә катышмыйча гына утырган авырлы хатын ягына караштырды. Соңгы сүзне, билгеле, ул әйтергә тиеш иде.

— Ярар, шушында кунарбыз,— диде ул килешеп.

Төн куну өчен иң элек җайлы урын табып, җылы куыш әмәлләргә һәм коры-сары җыештырырга кирәк иде. Аннан соң тамак ялгап алганда да начар булмас.

— Ашап алырга кирәк,— диде озын буйлы яшь ир.

Башкалар риза булдылар. Сөн ире калдырган итләрне, эремчекләрне бүлешеп ашап бетерделәр, аннан соң тире капчык авызыннан түгәтүгә әйрән эчтеләр. Авырлы хатын да ирләр белән бергә ашады. Аңа беркем сүз кушмады. Өч ир янында үзенең четрекле хәлен аңлап, күрәсең, ул үзе дә бернигә катышмаска, берни эндәшмәскә тырышты.

Ничек уздырырлар алар мондый төнне? Йоклый алырлармы, әллә бер-берсеннән куркып, бер-берсен сагалап, я булмаса суыкка чыдый алмыйча, төне буе аяк өсте чыгарлармы? Һәркемнең күңеленә шундыйрак уйлар килде һәм караңгылык куера барган саен, мондый сорау котылгысыз булып тоела башлады.

Ашап туйгач, урта яшьләрдәге күндәм ир беренче булып аягына басты.

— Танышыйк әле — ниләр бар икән монда? — дип сөйләнде ул үзалдына һәм түбәнгә, калкулыкның урманлы ягына төшеп китте.

Бераздан Чәнси дә аягына басты.

— Тизрәк кыймылдарга кирәк,— диде ул янындагы озын буйлы яшь ирга эндәшкән сыман итеп.— Үлән йолкырга, корыган ботак-сатак җыярга кирәк.

Озын буйлы, таза яшь ир бер әйтү белән генә урыныннан сикереп тормады. Кузгалып китүдән аны нидер тотып, тоткарлап тора иде сыман. Зур кулларын тез өстенә куйган килеш ул хәрәкәтсез калып, «Банхуа» ягына карап тик утырды. Ул, ахрысы, урман буена төшеп житкән теге ирнең күздән югалуын көтә иде.

Ул шулай җиргә береккәндәй кузгала алмый утырганда коры үлән җыеп булашкан Чәнси авырлы хатын янына килде. Күз иярмәс житез бер хәрәкәт белән ул хатынның кабарынкы бил турысыннан, тун чабуы астыннан кыска хәнҗәр тартып чыгарды. Шул ук мәлдә, коточкыч бер омтылыш белән, ул барыс кебек ыргылып, әлеге яшь ир өстенә ташланды. Озын буйлы ир, үз артында шикле кыштырдау ишетеп, артына борылып карамакчы булды, ләкин карый алмады — киң аркасын авырттырып, бар нәрсәне оныттырып очлы тимер килеп кадалды. Озын буйлы яшь таза ир, ыһ та итә алмады — кискән агач кебек шундук җиргә ауды.

Барысын да үз күзләре белән күреп торган хатын, куркып, кычкырып җибәрде һәм шулай ук һушы китеп җиргә ауды.

Яшь таза ир белән эшен бетергәч, Чәнси ашыгып урман ягына төшеп китте. Урманда сынган коры ботак тавышлары буенча ул теге ирнең кайдалыгын бик тиз чамалап алды. Коры-сары күтәреп, ашыкмыйча гына агачлар арасыннан чыгып килгән ирне дә ул сиздермичә артыннан килеп кадады.

Шуннан соң ул кабаланып өскә, калкулык сыртына ашыкты. Һушы китеп егылган хатын ул менгәндә инде исенә килгән иде. Ырылдауга охшаш бер өн чыгарып, куанып, тилереп ул хатынны аягына бастырды, билен юан күрсәтү өчен мендәр кыстырып тегелгән тунын салдырды да, шашынып аны кочагына алды.

— Ник?! Ник?! — диде яшь сылу кыз күз яшьләрен тыя алмыйча.

— Без икәү! Бар дөньяда без икәү генә! — диде Чәнси.

## IV

Туман каган Исәнтәйдә бер генә көн кунак булды да, урдага кайтып китте. Икенче көнне аның артыннан ук Исәнтәй кузгалды. Чин качагы Чәнсине ул тагын урдага алып китте. Чәнсинең, имеш, каганга гына әйтәсе ниндидер бик кирәкле сүзе бар иде.

Теге кичне калкулык башында яшь сылу кыз белән икәүдән-икәү генә калгач Чәнси, бөтенесен онытып, бөтенесенә кул селтәп, яңа тормыш башлап җибәрергә дә уйлаган иде. Яңа тормыш дигәне аның әлеге кызга өйләнеп, берәр җирдә үзенә куыш корып, беркемгә буйсынмыйча яшәп яту булыр иде. Башка качаклар ничектер яшиләр, җайлашалар — ул да шулай җайлашыр, күнегер иде. Баштарак аңа шулай тоелды да. Янында яшь, сылу хатыны булгач, аңа инде дөньяда башка берни дә кирәкмәс кебек иде.

Икенче көнне таң алдыннан туңып уянгач ул башкачарак уй йөртә башлады: Күк җибәргән салкыннан сөекле хатын янында гына җылынып булмый. Җылыну өчен, җаныңны асрау өчен бу дөньяда сөекле хатын кочагыннан тыш тагын өй дә, учак та кирәк иде. Шуның өстәвенә аларның бер кабымлык ризыклары калмаган иде.

Тегендә Банхуаны бик мактап телгә алдылар, аның белән киңәшмичә бер адым ясама — юкса шундук абынырсың, диделәр. Һәм ул үзенең абынмаска тиешлеген, еракта калган карт әнисен, туганнарын уйлап, башын иеп, кызын җитәкләп Банхуаның капка төбенә килде. Килүен килде, тик менә шулай да бик каты ялгышты бугай...

Банхуа аңа беренче караштан ук ошамады. Аның өендә, үз-үзен тотышында, телендә — бөтен нәрсәдә кыргыйлык, далалык, кансызлык сизелә иде. Банхуаның аңа — шундый кыенлыклар күреп килгән ерак ватандашына бөтенләй исе китмәде. Бары тик юлдаш кызының гүзәллеген күргәч кенә аның котсыз кыяфәтендә җирәнгеч бер җанлану биллгесе чагылып китте. Беренче караштан ук Банхуа Чәнсигә астыртын, хәйләкәр һәм куркыныч кеше булып тоелды.

Урдага барганда ул юл буена үзенең язмышы турында, Банхуа һәм гүзәл кыз турында уйланып барды.

Атсыз күл буена алар кичтән килеп җиттеләр. Өй корып төнне шунда күл буенда уздырдылар. Иртән таң атып ашагач-эчкәч урдага таба юнәлделәр.

Каган урдасының биек ак өе, аның тирәсендә бөжра-бөжра булып урнашкан кечерәк өйләр ерактан ук серле һәм ягымлы булып күренде. Күл буенда, шулай ук урдага таба юл өстендә бернинди көтүчесез утлап йөргән атлар, дөяләр очрады. Урдага якыная барган саен, каядыр ашыгучы я булмаса туктап, үзара гәпләшеп торучы, җил кискән каракучкыл йөзле кешеләр күренеп калды.

Урдага алар йола саклап, Көнчыгыш капка ягыннан килделәр. Тышкы бөжрага бер ук ераклыгы калгач, аларны атлы сакчылар туктатты. Банхуа-Исәнтәй үзенең ят кунагы белән арбада утырып килә иде. Сакчы аларга арбадан төшәргә боерды. Ат өстеннән генә иелеп ул арба эченә күз салды, шуннан соң аларның кем янына ни йомыш белән баруларын сорады. Исәнтәй үзенең туп-туры каган янына баруын әйтте. Исәнтәйне яхшы белгәнлектән, аларны тиз арада үткәреп җибәрделәр. Ләкин дөяләр җигелгән арба артыннан килүче кораллы ирләргә ары бармаска кушылды. Мондагы тәртип буенча, үзенең кораллы ирләрен Исәнтәй Атсыз күл буенда ук калдырып килергә тиеш иде. Исәнтәй аларны юри ияртеп килде. Кораллы сөн ире ачулана башлагач, ул ягымлы елмаеп:

— Оныткан. Кичер,— диде.

Куенынннан чыгарып ул сөн иренә чигелгән чакма таш янчыгы чыгарып бирде. Ачулы сөн ире бүләкне зур, тупас учына алып йомды да тынып калды. «Тагын бер дус артты»,— дип уйлады Исәнтәй үзалдына.

— Күрдеңме? Менә шундый инде алар... — диде ул үзенең юлдашына.

Капкага җитәрәк аларны тагын туктаттылар. Монысында инде аларны озата килүче сөн ире дә атыннан төште. Өчәүләп алар якындагы ялгыз өйгә юнәлделәр.

Өйнең түбә өстендәге япмасы ачылган, шунлыктан өй эче якты гына иде. Ишектән кергәч тә сулда, учак каршысында зур ак киез җәелгән, җир идәннең калган өлешендә тапталып, шомарып беткән үгез тиресе ята иде. Киезнең як-ягында кораллы ике сөн ире утырып тора, уртадагы калку урын буш иде.

Өйгә килеп керү белән Исәнтәй исәнлек-саулык алышты, шуннан соң учак янынарак кыю гына узды, янып торган учакка куенынннан алып берничә бөртек дөге ташлады — Ут-анага йолык[1] бирде. Чәнсине дә үз янына чакырып ул киезнең түргә каршы ягына чүгәләгәндәй итте. Аларны озата килгән сөн ире ишек төбендә туктап калды. Ирләр, берни сөйләшмичә, беравык тын гына утырып тордылар.

Шул чакны ишек ачылып китте һәм өйгә ашыгып, җилләнеп бай киемле, таза, тыгыз тәнле сөн ире килеп керде. Мондагы барлык ирләрдән озынрак буйлы, эрерәк сөякле бу сөн ире бераз гына шадра битле иде. Аның сул колагында, барлык сөн ирләренеке кебек, зур алтын алка ялт-йолт килә. Бу — Туңгак алып иде. Озын аяклары белән бер-ике

[1] Йолык — корбан.

гена атлап ул туп-туры түргә узды да, ак киез өстендәге йомшак урынга утырды. Ул утыргач башкалар аягүрә бастылар.

— Коралларын алдыгызмы? — диде Туңгак алып өйдәге сөн ирләренә эндәшеп.

— Юк,— диделәр киез янындагы ирләр бер-берсенә карашып.

— Алыгыз,— диде Туңгак алып.

Исәнтәй белән Чәнсигә булган барлык коралларын, очлы нәрсәләрен чыгарып идәнгә куярга кушылды. Исәнтәй дә, Чәнси дә үзләрендә булган нәрсәләрен киез өстенә тезеп куйдылар. Сөн ирләре, ышанып җитмичә, иң ахырда аларны берәм-берәм капшап, тентеп чыктылар. Шуннан соң каравыл агасы Туңгак алып ярым йокылы тыныч бер тавыш белән Чәнсигә тезләнергә, баш орырга боерды. Моның өчен аңа ак киез янындагы үгез тиресенә басарга кушылды. Ул шунда басты, тезләнде дә Туңгак алып алдына баш орды. Бу баш ору ант бирү белән бер иде — үгез тиресенә баскан килеш баш орган кеше ялган сөйләсә, аңа тәңренең каргышы төшәчәк, аның җиде буыны корыячак иде[1]. Исәнтәй барысын да аңлатып барды.

Туңгак алып качакка сөйләргә кушты. Чәнси чәрелдек нечкә тавыш белән сөйләргә кереште. Ул үзенең кем булуын, бу якка ничек, ни өчен чыгуын гына әйтте. Кыска гына итеп шул турыда белдергәч, тылмач аша:

— Каганга сөйлисе сүзләрне дә әйтергәме? — диде.

— Юк,— диде Туңгак алып.

Карар күзгә таудай булып, кырыс, усал булып күренсә дә Туңгак алып качакка бөтенләй каты орынмады. Ул аның белән бик тыныч, ягымлы сөйләште. Чәнсинең баштагы куркуы, шомлануы — барысы да тиз арада юкка чыкты.

Беренче танышлыктан соң Туңгак алып Исәнтәйгә күтәрелеп карады да ымлап аңа сорау алырга кушты. Мондый чакта нинди сораулар бирелгәнен белгәнгә күрә, Исәнтәй, Туңгак алыпның әйткәнен дә көтмәстән, качактан сорау ала башлады.

— Син, качак, Чәнси, Сөн иленә үзең теләп чыктыңмы?

— Үзем теләп чыктым.

— Чин качагы Чәнси, Сөн илендә үзең теләп каласыңмы?

— Үз теләгем белән калам.

— Мәңгегәме?

— Мәңгегә.

— Каганны изге дип, Тәңрене алла дип таныйсыңмы?

— Таныйм,— диде Чәнси, маңгаендагы салкын тирләрен сөртеп.

## V

Сорау алу беткәч аңа аягына басарга кушылды. Баскач сөн ирләренең берсе аны үз артыннан ияртеп китте.

Ишектән кергәч тә уң яктарак өйне икегә бүлеп киез пәрдә эленеп тора иде. Чәнсине ияртксән сөн ире, пәрдәне ике якка аерып, шунда кереп китте. Исәнтәй дә алар артыннан атлады.

Бу кысан, тар бүлмәдә шактый караңгы иде. Алдан барган сөн ире, качакның уен сизенгән сыман, өйнең тышкы яктагы икенче ишеген ачып җибәрде һәм киезне өскә кайтарып куйды. Караңгы бүлмә яктырып китте. Шул ук мәлдә бүлмә эченә бөркелеп коры суык тулды.

— Чишен,— диде качакка сөн ире чин телендә.

Чәнси аптырап калды. Ләкин сөн иренең чин телендә әйткән сүзен-

[1] Үгез тиресенә басу — борынгы төркиләрдә үгез изге саналган, шунлыктан аның мөгезе дә, тиресе дә изге исәпләнелгән һәм, ышану буенча, сихри көчкә ия булган.

нән бигрәк, аның шушы салкында чишенергә кушуы гаҗәпкә калдырды. «Бу нәрсә бу?» дигән сыман, яклау эзләп ул үзенең «якташына» күтәрелеп карады. Таштай җансыз Банхуа аңа берни эндәшмәде.

— Чишенергә! Анадан тума,— диде сөн ире кабатлап.

Чәнси, әле һаман ышанырга теләмичә, сөн иренә карады. Сөн ире дә, Банхуа кебек үк, тыныч, гамьсез бер кыяфәттә көтеп торуында булды.

Чин качагы, монда беркем берни аңлатмаячагын, беркем ярдәм итмәячәген аңлап, барлык батырлыгын җыеп, әкрен генә чишенә башлады. Тегендә, туган җирендә, әле җылы, кояшлы, чәчәкле көз иде. Монда да көз. Кояшлы, бозлы көз. Бүген иртән күлдәге бозны күреп ул шулай иртә суытуына шаккаткан иде. Тегендә, аның туган җирендә әле яланөс йөриләрдер!

«Нишләтмәкче булалар икән соң болар мине?» дип уйлады ул, читкә ят, салкын тышка күз ташлап. Шулай да аңа уйланып, җылы күннәрне искә төшереп күп юанырга туры килмәде. Аның артык әкрен кылануын күреп, сөн ире ашыктыра башлады. Чәнси өс киемнәрен салып аяк астына куйды да, «Менә булды да!» дигән сыман елмайгандай итеп, янындагы ирләргә күтәрелеп карады. Никтер аңа бөтен куркыту, чиркәнчек алдыру шуның белән бетәр һәм хәзер менә аңа киенергә кушарлар сыман тоелды.

Ләкин аңа беркем дә киенергә кушмады. Киресенчә, үзләренә ияртеп аны тышка алып чыгып киттеләр. Каты җиргә басу белән, аның аяк табаннарына очлы, вак ташлар кадалды, бөтен тәнен чыдап булмаслык суык өтеп алды. Ирексездән ул ыңгырашып куйды. «Сатлык!» дип уйлады ул Банхуа турында. «Якташы» аңа мондый нәрсәләрнең берсе турында да алдан әйтеп куймаган иде.

Ачык ишек аша аңа баядан бирле якында гына ниндидер тавышлар ишетелеп торгандай тоелган иде. Шул өзек-өзек тавышлар ишетелгән яктан төтен дә күтәрелә сыман иде. Шәрә килеш берничә адым атлагач та ул бөтенесен үз күзләре белән күреп шаккатты. Өйдән якында гына бик зур учак янып тора. Өстенә җылы тун, аягына итек, башына бүрек кигән сөн ире белән Банхуа аны шулай анадан тума килеш туп-туры учак янына алып килделәр. Чәнсинең йөрәге жу итеп китте. Күз алдына шундук гүзәл юлдашы килде, теге көнне ук кадап үтергән ирләр килде. «Белделәр микәнни? Шуның өчен яндырып үтермәкче булалар, ахры?» дип уйлады ул коты алынып. Туңу тойгысы шундук юкка чыкты, бөтен тәнен кайнар дулкын өтеп алды. Тыела алмыйча, ул бар көченә кычкырып җибәрде.

Шул ук вакытта ул учак тирәсендә кайнашкан ниндидер бүре сыман ирләр, ир сыман бүреләр күреп алды. Курку тойгысы беразга кызыксыну тойгысы белән томаланды. Үзенең учакта куырылып үләчәген дә онытып, ул, нәрсә уйларга да белмичә, бүре-кешеләргә текәлеп калды. Ныклабрак карагач, ул аларның баштанаяк бүре тиресенә төренгән чын кешеләр — камнар [1] икәнлеген аңлап алды.

Ул арада бүре-кешеләрнең берсе, ырылдап, үз телендә нидер сөйләнеп, Чәнси янынарак килде. Башкалар, ырҗайган тешле бүре авызларын ачып, аның ягына борылып карадылар. Шунда ук ике бүре-кеше колак тондыргыч итеп дөңгер [2] кагарга тотынды.

— Ут аша сикер! — дип кычкырды Банхуа Чәнсинең колак төбендә генә.

Чәнси барысын да аңлап алды. Юк, аны әле яндырып үтермиләр икән! Ул шулай дип уйларга да өлгермәде, каршысына килеп баскан бер дәү бүре-кеше, аның кулыннан эләктереп алды да, утка таба өсте-

---

[1] Кам — борынгы төркиләрдә дин-йола башлыгы

[2] Дөңгер — барабан

ри башлады. Учак зур иде, коры агачлар дөрләп, ялкынланып яна иде. Шуңа күрә аны читтән йөгереп килеп сикергәндә яхшырак булачак. Чәнси, йөгереп килмәкче булып, артына чигенде, ләкин, шуны гына көтеп торган сыман, ырылдап, кулларындагы артыш таякларын селтәп, шундук аны камнар уратып алды.

Чин качагы, ары-бире каранды, тирән итеп бер тын алды да, башка бернинди чара юклыгын аңлап, утка ыргылды. Бүре-кешеләр бар көчләренә: «Алас! Алас!» дип кычкырдылар. Шул ук вакытта каты итеп тагын дөңгерләр дөпелдәде.

Чәнси утның икенче ягына сикереп чыкты да каты җиргә килеп төште, егылып китте. Вак ташлы җир өстеннән бер-ике мәртәбә тәгәрәп киткәч, бөтен тәненең авыртып сызлавына, пешүенә түзә алмыйча, ул аягына басты һәм, тагын көчлү күрмәсеннәр дигән сыман, учак яныннан кача башлады.

Аны бүлеп китерделәр, тынычланырга куштылар. Уттан ул исән-сау чыкты, димәк, арыкланды. Шулай итеп, ут алласы аның күңелендә ниләр яшеренеп ятканын белә алмады. Ул белмәгәч, сөннәр дә берни белми булырга тиеш. Юк, берни белмиләр алар! Юкка гына куркытып азапланалар. Күрәсең, аны хәзер каган янына алып барырлар.

Ул шулай дип уйларга да өлгермәде, төрткәләп диярлек аны яңадан өйгә алып керделәр. Керү белән ул тизрәк киемнәренә тотынмакчы булды. Ләкин киемнәр куйган урынында юк иде. Ачык ишектән ул тышка күз ташлап алды һәм шул чакта үз киемнәрен дөрләп янган утка ташлауларын күреп алды. Аның ике күзе дүрт булды.

— Ы-ы! — диде ул Банхуага карап, тешләрен шыкылдатып.

— Әйдә киенергә!— диде аңа Банхуа.

— Ник әйтмәдең?! — диде Чәнси ярсып.

— Тиз бул, туңасың! — диде аңа Банхуа чин телендә. Шуннан соң ул, сөн иренә карады да, сөн телендә: — Менә шундый йомшак буынлы инде алар чиннәр! — диде күрәләтә мыскыл белән.

## VI

Төркемләшеп алар өйнең җылы ягына керделәр. Ишектән керү белән Чәнсине шундук ике яктан ике ир тотып алды. Берсе ике куллап арттан аның башын кысып тотты, үткер энә белән аның сул колагын тишә. «Алка кидерәләр»,— дип уйлады Чәнси тыныч кына. Аның инде кычкырасы да, карышасы да килмәде. Ут аша сикереп тә исән калгач, инде нишләтсәләр дә аның өчен барыбер сыман иде.

Чыннан да, аның сул колагына бакыр алка кидерделәр. Шуннан соң икешәр кат өс киеме бирделәр. Ул тупас йон тукымадан, тиредән, күннән тегелгән озын, җылы киемнәр киде, билен буды. Киенгәч аңа агач табак белән күп итеп кымыз бирделәр. Җылынып, тынычланып ул җиңел сулап куйды һәм Банхуага:

— Инде беттеме? — диде елмаеп.

Банхуа җавап кайтармады.

— Син, чин качагы, изге ут аша чыктың — арыкландың, сөн киемнәре кидең — ир булдың,— диде сөн ире тылмач аша.— Хәзер син үз кулың белән битеңне карага буяп каганга буйсыну белдер.

Шул чакны киез чаршау артыннан кулына зур гына кара савыты тоткан картрак бер сөн килеп чыкты. Кара савытын ул Чәнсигә тоттырды һәм кулы белән ымлап, битне ничек буярга кирәклеген аңлатты. Чәнси сорашып, ы-мы итеп тормады — уң кулының бармакларын корым катыштырып ясалган кара сыекчага манды да башта уң як битен буяды, аннары сул як битен, маңгайларын, ияклэрен буяды.

— Бүгеннән башлап — ятканда-торганда, ашаганда-эчкәндә... төнлә дә, көндез дә... ялгыз да, бергә дә... өч көн буена син кара йөз! — диде түрдә тын гына күзәтеп утырган Туңгак алып телгә килеп, тантана белән.

Банхуа аның сүзләрен чин теленә әйләндерде.

«Кара йөзгә» табак белән тагын кымыз, пешкән ит кисәге бирделәр. «Болай булгач яшәргә була!» дип уйлады ул күңеленнән. Соң ирләре аның ашаганын, эчкәнен көтеп тордылар да бер-бер артлы өйдән чыга башладылар. «Кара йөз»гә дә чыгарга кушылды. Өйдән чыккач алар өчәүләшеп капка ягына юнәлделәр.

Каган өенә кергәндә «кара йөз»гә берниндн тоткарлык булмады. Банхуа өйрәткәнне исендә тотып, ул бары тик ишектән кергәндә генә аеруча сак-уяу булырга тырышты. Ләкин ул сак-уяу булмаса да, ишек башына орынырга я булмаса бусагага басарга аңа, күрәсең, ирек бирмәсләр иде. Таудай биек өй ишегенең ике ягында да — эчтә дә, тыштә да икешәр-икешәр коралл ирләр тора. Йөзе кара кеше күренү белән, аның теләсә нинди ялгышын төзәтергә, кирәк булса, үзен урталай чабып ташларга әзер булып, алар аның һәр адымын күзәтәләр. Банхуа да аның колак төбендә генә бертөзлексез:

— Аягыңны күтәреп атла! Башыңны иеп атла! — дип тукып килде.

Туман каганның Ак өе, тыштан зур булган кебек, эчтән дә бик зур иде, иркен иде. Балчык өйдә туган, балчык өйдә яшәгән һәм таш, балчык өйләрдән, сарайлардан яхшырак берни була алмый дип инанган чин кешесе, каганның югарыдагы түгәрәк төннек аша турыдан-туры күк белән тоташкан якты сараена килеп кергәч чын-чынлап таң калды. Мондый иркенлекне, мондый байлыкны аның беркайчан да, беркайда да күргәне юк иде.

Биек түшәмне-түбәне өч багана тоттырып тора иде. Тигез итеп шомартылган, югарыга таба нечкәрә барган карагай баганаларның өчесе дә астан өскә чаклы саф алтын белән тышланган. Алтын калайга чүкеп төрле ерткыч сурәтләре, ау күренешләре, үсемлекләр төшерелгән. Югарыда, түшәмгә җитәрәк, баганалардан тармакланып як-якка ботаклар таралган. Ысылдап торгаң җылан рәвешендә ясалган алтын ботаклар үзара аралашып, кисешеп киң ябалдаш барлыкка килгән. Ботак-җылан башлары барысы да киез өйнең зур гәүдәсен тотып тора торган күп санлы кабыргаларга тоташкан. Уртадагы өч төп баганадан читтәрәк, өй әйләнә, түгәрәк буенча, кечерәк, тәбәнәгрәк баганалар тезелеп киткән. Кечерәк баганалар аралаштырып ал, яшел, ак, сары төсләргә буялган. Баганалар арасыннан, идәнгә чаклы төшереп, чигүле ефәк чаршаулар, япмалар эленгән. Биек баганаларның җылан-ботаклары кабырга башларына тоташкан турыдан тәбәнәк багана башларына кадәр күк төстәге ефәкләр тотылган. Шунлыктан анда түшәм дә, түбә дә тышкы күк белән бергә кушылган кебек булып тоела иде. Аяк астында, идәндә бик зур ак киез сузылып ята. Ак киезнең сул ягына бизәкле ал келәм җәелгән. Келәм өстендә — фил сөягеннән кырып ясалган, алтын болан, тәкә, барыс сурәтләре белән бизәлгән биек тәхет тора. Кая карама, күз карашы алтынга, ефәккә — байлыкка, гүзәллеккә барып төртелә иде.

Шуны күреп «кара йөз» кинәт телсез-өнсез калды. Өйнең аргы башындагы кешеләр аңа бик кечкенә булып күренделәр, аларның аяк тавышлары да, сөйләшкән сүзләре дә бөтенләй ишетелмәде — Чәнси кергән ишектән алар шундый еракта тоелдылар.

«Кара йөз» өй эченә аяк басу белән, кемдер аның кулыннан тотып алды, үз артыннан ияртеп аны каядыр читкә алып китте. Арттанрак атлаган икенче бер кеше аның аркасына төртеп алды — иелергә кушты. Аның кулына кымыз тулы агач савыт тоттырдылар.

— Эч! — диде Банхуа пышылдап.

«Кара йөз» башын калкыткандай итте, ләкин шундук кемдер тагын аның аркасына төртеп алды.

— Миңа кара — менә болай! — диде Банхуа усал пышылдап.

«Кара йөз» карады һәм аныңча тезләнеп, башын иеп агач савытны авызына якын китерде. Эчеп бетергәч, алар икесе дә берьюлы диярлек бер-берсенә күтәрелеп карадылар һәм өйнең түренә — каган утырган алтын тәхет ягына борылдылар.

## VII

Алар янына ашыгып уң кул карачы Бүзбала килеп җитте. Күз карашы белән генә ымлап ул аларны үз артыннан алып китте. Алар, кечерәк баганалар янында басып торган бай киемле ирләр турысыннан үтеп, түргә якынлаштылар. Ак киез белән учак арасындагы үгез тиресенә җиткәч Банхуа-Исәнтәй «кара йөз»гә тирегә ике аяклап басарга кушты. Шуннан соң аңа баш киемен салырга, тезләнергә, тиренең икенче башына кадәр түше белән шуып барырга һәм ак киезгә йөзен орырга диелде.

Биек тәхеттә утырган каганны «кара йөз» баштарак күрә дә алмады. Ул бары аның кайдадыр якында, ләкин шулай да күз күреме җитмәслек югарыда булуын гына тойды.

— Миңа буйсынган «кара йөз» мондамы? — диде каган бөтен өй эченә кычкырып.

Чыннан да аның тавышы Чәнсинең нәкъ түбәсе өстендә ишетелде.

— Монда, бөек каган,— диде Бүзбала.— Аның сиңа сүзе бар — сөйләсенме?

— Сөйләсен!

Сары ефәк белән тышланган озын тун кигән, билен алтынлы киң каеш белән буган, зур гәүдәле, зур башлы, зур йодрыклы Бүзбала, артына борылып, Исәнтәйгә ым какты. Шул ук мәлдә читтәге бер төркем ирләр арасында басып торган олы яшьтәге чандыр бер карт, алгарак чыгып, Исәнтәйгә каршы якта — үгез тиресенең икенче ягында туктап калды. Бу каган тылмачы иде, «кара йөз» сөйләгәндә ул Исәнтәй әйләндереп барган сүзләрнең дөреслеген тикшереп торачак.

Чин качагы чыпчык чыркылдагандай көчсез тавышлар чыгарып сөйләргә кереште. Исәнтәй аның сүзләрен Бүзбалага әйтте, Бүзбала каганга җиткерде: «кара йөз», турыдан-туры каганга сөйләү түгел, сөйләгәндә хәтта аңа күтәрелеп тә карый алмый иде.

— Мин Чжао йортының меңбашы Чәнинең кече углы Чәнси торырмын,— диде качак сүз башлап.— Син инде беләсең булыр, бөек каган, моннан унөч ел элек синең көньяктагы күршең Чжао йортын комсыз Чин ерткычы кабып йотты. Шуннан ике ел элек ул Хань йортын басып алды. Шулай итеп алты йортны бер-бер артлы үз биләмәләренә кушты. Җиренең-суының киңлеге, көченең, байлыгының күплеге буенча Чин йорты барлык борынгы йортларны узып китте. Күршеләренә салган талау, кайгы, кыран буенча да ул җир йөзендәге барлык йортларны уздырып җибәрде. Чиннәрнең явызлыгын, ерткычлыгын берни белән тиңләп, чагыштырып булмый, бөек каган. Күршеләрен басып алып, Шихуанди бар нәрсәнең астын өскә китерде. Җиңелгән йортларның коллары ирләрен ун меңләп, йөз меңләп терелэй җиргә күмдерде. Күпме хатыннар тол калды, күпме балалар атасыз калды, күпме кызлар кияүсез калды! Башка биләмәләрдәге барлык коралны җыеп алып, бер дә кирәкмәгәнгә ул өй тәүмәлеге кыңгыраулар, сыннар койдырды. Чыгышы буенча Чин йортыннан булмаган бик күп аксөякләрнең, олуг нәселләре-

нең тамырын корытты. Аксөякләр чебен урынына кырылдылар, бөек каган! Исән калганнары, туган җирләреннән, мал-мөлкәтләреннән аерылып, көчләп Сйанйәнгә — Чин йортының башкаласына күчерелде. Бөтен җирне яңадан кискәләп-бүлгәләп, утыз алты өлкә ясадылар. Барлык өлкәләргә баш итеп Инчжэн үз кешеләрен куйды. Алты йортның язулары, акчалары, үлчәүләре чүплеккә чыгарып ташланды. Җирдәге, судагы барлык нәрсә, бөтен тереклек комсызлыкның, ерткычлыкның соңгы чигенә җиткән бер кеше сүзенә буйсындырылды. Күк асты илендә хәзер, бөек каган, алай итсәң дә ярамый, болай итсәң дә ярамый. Уңга карасаң да, сулга карасаң да — гаеп, кычкырып сөйләшсәң дә, пышылдап сөйләшсәң дә — гаеп. Минем борынгы китаплардан укыганым бар, шулай ук галим кешеләрдән дә ишеткәнем бар: җирдә кеше үзенчә уйлау, үзенчә яшәү, үзенчә сөйләү өчен туган. Чиннәр иген игеп, шуның белән тамак туйдыра, җитен тукымадан кием тегеп, салкыннан саклана. Сөннәр мал-туар асрап, шуның ите-сөте белән тамак туйдыралар, киемнәрен тиредән тегәләр. Чиннәр үзләренчә, сөннәр үзләренчә сөйләшә. Олуг Күк... Тәңре каршында моның бернинди языгы юк. Ләкин Чин йолалары, Чин тәртипләре буенча бу — яманлык санала. Чиннәр карашы буенча, җирдәге барлык халыклар бер төрле тукланырга, бер төрле киенергә, бер телдә сөйләшергә тиешләр. Үзенчә киенгән, үзенчә тукланган, үз телендә сөйләшкән барлык халыкларны чиннәр угры дип беләләр, бернинди кызганусыз коллыкка саталар — таулар арасына тимер, бакыр ташы казырга я булмаса тоз чыгарырга сөрәләр. Борынгы галимнәрнең акыллы сүзләре язылган бамбук такталарын арбаларга төяп, урамнарга алып чыгалар, утын кебек итеп, ут төртеп яндыралар. Укымышлы кешеләрне тереләй җиргә күмәләр, бөек каган! Бер гаепсез кешеләрне асу-кисү чиннәрнең көндәлек эшенә әйләнде. Урамда, кырда-басуда үлеп яткан, череп яткан кешеләр, кеше сөякләре күреп инде беркемнең дә исе китми. Шул ук вакытта Инчжэн бөтен Җунгоның бер почмагыннан икенче почмагына киң, туры юллар салдыра, үзе өчен илнең теләсә кайсы төшендә күз күрмәгән, колак ишетмәгән бай сарайлар салдыра...

## VIII

— Мин боларны беләм. Мин белмәгәнне сөйлә,— диде каган «кара йөз»нең сүзен бүлдереп.

Чәнси туктап калды. Каганга сөйлисе сүзен ул алдан ук өйрәнеп, ятлап килгән иде. Шуңа күрә аңа каян да булса икенче төштән башлап китүе кыенрак хәзер. Ул, беравык уйланып торгандай итте дә, өзелгән сүзен шул ук төштән ялгап алып китте.

— Шихуанди, Күк асты илендә басып алырдай җирләр беткәч көньяк халыкларын яулау эшенә кереште,— диде ул.— Бүгенге көндә көньякның сазлы, дымлы урманнарында биш йөз меңлек Чин көчләре Аулак дип аталган ил белән канлы сугыш алып баралар. Шул турыда белә микән бөек каган?

Чәнси кыюланып башын калкытты һәм каганның йөзенә карап алды. Ул аның йөзендә кызыксыну билгесе күрде. Аңа бары шул гына кирәк тә иде. Шул ук мәлдә Исәнтәй-Банхуа усал гына итеп аның җилкәсенә төртеп алды, башын түбән идерде, ләкин «якташы»ның мондый кыланышына Чәнсинең әз генә дә хәтере калмады.

— Сөйлә,— диде каган, боерып.

— Сазлар, урманнар арасында яшәүче кабиләләр чиннәргә бик нык каршылык күрсәтәләр,— диде «кара йөз».— Менә икенче ел инде Чин көчләре, бер урында таптанып, бер ли[1] дә алга китә алмыйлар. Юл юк

[1] Ли — озынлык үлчәү берәмлеге. Ярты чакрым чамасына туры килә.

арттан азык-төлек китереп булмый. Чиннең көче көннән-көн кими бара. Ачлык, таркаулык... Инчжэннең тәхете, бөек каган, сөңге очына гына эләгеп тора. Көньяктагы сугыш та, салына торган юллар, сарайлар да караларга бернигә кирәкми. Алар шулай ук безгә дә — җиңелгән биләмәләрнең аксөякләренә дә кирәкми.

Чәнси, барлык кыюлыгын җыеп, тагын бер мәртәбә каганга карап алды. Туман каган танымаслык булып үзгәргән иде!

— Сөйлә! — дип кычкырды ул, түземсезләнеп.

— Зур көч белән Җунгога басып керсәң, элекке йортларның аксөякләре баш күтәрәчәкләр, бөек каган! — диде «кара йөз», чыпчыктан кинәт бөркеткә әйләнеп.— Син кабызган беренче ялкын бөтен үзәнгә таралачак, чиңнәрнең көлен күккә очырачак. Инчжэннәр, Лисылар, Чжангаолар тычкан урынына чыркылдап үләчәкләр. Сине, бөек каган, бөтен киләчәк буыннар ун мең ел буена мактап телгә алачак.

«Кара йөз» сөйләп бетерде. Туман каган озак кына тынып утырды. Өй эчендәге башка ирләр дә, иреннәрен кысып, киеренке тынлык сакладылар.

— Шулай да булсын — мин басып керермен,— диде каган бераздан.— Чин юкка чыгар. Чжао, Хань, Йән... ирек алыр. Мин нәрсә алырмын икән соң?

— Анысын син миннән яхшырак беләсең, бөек каган,— диде Чәнси.

— Беләм,— диде каган.— Шулай да синең туган йортың Чжаоны коткару өчен генә сөннәр кан коярга тиеш микән?

— Минем ишеткәнем бар, шулай ук борынгы китаплардан да укыганым бар: ил агасы үз күзе алдында торганны гына күрмәскә, күз алдында тормаганны да, ерактагыны да күрә белергә тиеш,— диде Чәнси, кыюланып.— Чинне аяк астына салып таптый алсаң, син Чжаоны, Ханьны, Йәнне генә коткармассың. Син үзеңне дә коткарырсың, бөек каган!

Туман каганның күз карашында усал очкыннар елтырап китте.

— Син мине коткарырга килдеңме, кара йөз?! — диде ул, урыныннан кузгалгандай итеп.

— Мине синең янга Чжао йортының аксөякләре җибәрде, бөек каган,— диде Чәнси түбәнчелек белән.— Алар әйттеләр, каганга безнең теләкне җиткер диделәр.

— Әйтеп бетер!

— Көньякта чиннәр Сйәншуй белән Лушуй суларын ялгау өчен арык казый башлаганнар,— диде Чәнси.— Арык казылып ике елга бергә ялганса, ачыккан Чин көчләренә үзәктән азык китерү җиңеләячәк. Ул чагында Инчжэн көньяк маньнарны җиңел генә тез чүктерәчәк. Көньякны басып алу белән Чин йортының көче бермә-бер артачак. Ул чагында Шихуандинең ике кулы да бушап калачак. Менә шул чагында инде ул биш йөз меңлек көчне төньякка таба борачак. Ни өчен дигәндә, Чин ваны күршеләре белән сугышмый тора алмый. Яңадан-яңа җирләр яулап алу теләге аның канына сеңгән. Чиннең төньягында аңа буйсынмаган, аңа бил бөкмәгән бер генә күрше бар: ул да булса — Сөн иле, бөек каган!

Туман каган бөтен өй эчен яңгыратып шаркылдап көләргә тотынды.

— Якын килеп карасын! — диде ул.— Сөннәрне әле беркемнең дә беркайчан да җиңә алганы юк. Булмас та!

Өй эчендә ирләр, мактау-хуплау белдереп, җиңелчә гөрелдәп алдылар.

Шулай да йорт башының мактанып әйтелгән, кычкырып әйтелгән бу сүзләрендә эчке бер каушау сизелде.

«Кара йөз»не чыгарып җибәргәч, каган үзенең якыннарын, киңәшчеләрен түргәрәк чакырды. Моңарчы читтә басып торган ирләр, барысы берьюлы диярлек дәррәү кубып, шулай да бераз гына тыелып, тыйнаграк булырга тырышып, ак киезгә ябырылдылар. Киез өстенә һәркем үз урынын белеп кенә, җайлап кына утырды. Уң кул карачы Бүзбала Исәнтәйгә дә киезгә утырырга кушты. Чингә кагылышлы сөйләшүләрдә аның да сүзенә колак салгалыйлар иде.

Сөйләшү-киңәшү башланганчы каган ашарга китерергә кушты. Киез өстендәге ирләр алдына ашчылар табак-табак кайнар ит китереп куйды. Ачыккан ирләр, беркемгә карамыйча; шундук ашарга керештеләр. Иттән соң кымыз килде. Ашаганда-эчкәндә, йола саклап, беркем берни сөйләшмәде. Тамак туйдырып, күңелләр күтәрелеп киткәч, барысы да җиңелчә генә шаулашып, гөрләшеп алдылар һәм Чин качагы алып килгән хәбәрләр турында сүз башлап җибәрделәр.

«Кара йөз» сөйләгән сүзләрнең бик күбесе мондагылар өчен билгеле иде. Ләкин шул ук вакытта аның сүзләре арасында таныш булмаган яңалыклар да бар иде. Һәркем иң элек менә шул яңалык турында баш ватты. Дөресме, түгелме? Чин качагы ялган сөйләми микән? Ялган сөйләсә, ник сөйли? Дөрес сөйләсә, каганга нинди киңәш бирергә?

Ак киездә иркенләп утырган ирләр, теш арасына кысылган итләрен казыштырып, майлы мыек очларын сыпыргалап, шактый озак шаулаштылар. Үзенең ирләре-туганнары, киңәшчеләре үзара шулай фикер алышканда каган, беркемгә, берни гә катышмыйча, чит кеше сыман тыңлап кына утырды. Чабыш алдыннан атларның аягын яздырып алган кебек, олы сөйләшү алдыннан ул да шулай кешеләргә үзара шаулашып алырга ирек куя иде.

Шулай да ул бүген тезгенне бушайтыбрак җибәргән сыман тоелды. Кызып үзара бәхәсләшергә тотынган ирләр ничектер моны абайламыйчарак калдылар. Абайлап алдылар да, тыела төштеләр. Башта ярым пышылдауга, аннан соң пышылдауга күчтеләр һәм, тәхет ягына текәлеп, барысы да тынып калды. Каганның йөзе бүген аларга бик сәер күренде. Ул инде Чин качагын да, аның сөйләгән сүзләрен дә, хәтта өй эчендәге ирләрне дә бөтенләй исеннән чыгарып ташлаган иде бугай. Аны, әйтерсең, монда беркем дә, берни дә кызыксындырмый иде — күңеле белән ул кайдадыр икенче җирдә утыра кебек. Аның шулай онытылып утыруы исә туган-тумачалар, киңәшчеләре өчен бик үк куанычлы нәрсә түгел. Мондый чакта аның нәрсә уйлавын берничек тә чамалап булмый. Нәрсә уйлавын чамалап булмагач, аңа киңәш бирүе дә бик хәтәр, куркыныч нәрсә иде.

Уң кул карачы Бүзбала беренче булып тамак кырды, каганга күтәрелеп карады да:

— Тыңлар булсагыз, бөек каган...— дип сүз башлады.

Каган мәрттән кире кайтты, курмәс күзләре белән Бүзбалага бер күтәрелеп карады һәм, берниңди кызыксынусыз, тыныч кына:

— Сөйләсеннәр,— диде.

Беренче булып Баргынтай баба сөйләде. Каганның холкын ул башкаларга караганда яхшырак белә һәм аңа кайчан нинди киңәш бирергә кирәклеген дә башкаларга караганда дөресрәк чамалый иде. Баргынтай бабаның киңәше шуңа кайтып калды: Чин ягыннан чыккан теләсә нинди качак сүзенә колак салу, шуңа таянып Чингә каршы олы күсәк күтәрү акылсызлык булачак, диде ул. Чин ваны Инчжэн усал, холыксыз, шулай да ул көчле, нык куллы, диде.

НУРИХАН ФӘТТАХ ◆ СЫЗГЫРА ТОРГАН УКЛАР

Башкалар да, Быргынтай баба ягына авышып, шундыйрак фикерне куәтләделәр: «кара йөз»нең сүзләренә колак салмаска, чиннәр белән бозылышмаска, диделәр.

Каган ирләрне һаман бүлдермичә тыңлап утырды һәм берниндн күз карашы белән дә, берниндн ымлау-ишарәләү белән дә яклау да, каршы фикер дә сиздермәде. Озакка сузылган мондый билгесезлек кайберәүләрнең эченә әле боз булып, әле утлы ялкын булып йөгерде.

Каган, ниһаять, җанлану әсәре күрсәтте. Киңәшчеләр барысы да инде сөйләп бетергәч ул кинәт, яртылаш борылып, ак киезнең сул ягында, кырыенда гына утырган Исәнтәйгә карады да, туп-туры атап:

— Син, Исәнтәй, ни диярсең? — диде.

Исәнтәй сискәнеп китте. Ул монда бик кечкенә кеше иде, һәм беркайчан да каганның менә монда, биек өйдә — туган-тумачалар, өлкән киңәшчеләр, карачылар янында туп-туры аңа атап эндәшкәне юк иде. Ул ихлас бер сөенеч белән елмаеп алды. Аның ясалма елмаюын күреп күнеккән кешеләр шулай да аның бу ихласлыгына ышанып җитә алмадылар. Исәнтәй, тәхет алдында бер-ике тапкыр баш иде дә, мүкәләп каганга таба бераз якынайды.

— Син, бөек каган, миннән киңәш сора, мин әйтә,— диде ул, бик нык каушап һәм шуңа күрә сөн сүзләре тәртибен буташтырып.— Бер качак сүзгә ышанып, Чин иленә яу чаба кирәк имәс. Сөн — батыр, кыю, куркусыз. Шулай да сөннәр Чжао ире Лимуны оныта имәс. Лиму сөннәрне күп үтер, сөннәрне күп куды. Арьякны тартып алды. Синен кыюлыгың, батырлыгың белән сөннәр Арьякны Чжаодан кире тартып алды, бөек каган! Шуның өчен сине сөннәр мең ел макта. Тәңре сиңа күктән байлык, көч бирә. Чингә каршы яу чаба кирәкми. Нигә яу чаба? Чжаоны коткару өченме? Безгә андый яу кирәк имәс. Безгә башка төрле яу кирәк. Сөн бөтен Жунгоны яулап ала кирәк!

— Ә?! — диде каган үзе дә сизмәстән.

— Ә?! — диделәр башкалар да аңлап җитмәгәндәй.

— Төшендереп бир,— диде каган.

— Мин төшендереп әйтә,— диде Исәнтәй каганның йөзенә туры карап.— Чиннең хәле яман. Күк асты иләндә үзара ызгыш-талаш кубарга тора. Син, бөек каган, Чингә басып кер күп көч белән, Чинне тапта, юлбарысны кадаган кебек. Инчжәнгә сөңге када!

Исәнтәй шулай диде. Соңгы сүзләрен ул, яуга ташланырга җыенган сугышчыдай, йодрыкларын йомарлап, омтылыш белән, тантана белән әйтте.

Ягымлы, тыйнак тылмачтан мондый нәрсә көтмәгән ирләр, кинәт йокыдан уянып киткән кебек, күзләрен ныграк ачып карадылар, колакларын ныграк торгызып тыңладылар. Курку-өркү, шомлану һәм ничек тә башкалар артына посып калырга тырышу сыман тойгылар аяк астына төште. Һәркемнең күңеленә бер генә уй: әләксә нык әләгә инде моңа, дигән бер генә уй килде. Кайберәүләр мондый «әләгү» өчен күңелләреннән сөенеп тә куйдылар. Балчык өйдә, балчык коймалар эчендә йомран сыман яшәп ятучы бу ямьсез, шома кешене сөн ирләре шулай да яратып житкермиләр иде.

Шул чакны каган урыныннан торды.

— Бу турыда кич тагын бер мәртәбә сөйләшербез,— диде ул ак киез өстендәге ирләргә карап.— Кичке ашка миңа килерсез.

Ирләр, киңәшнең шуның белән беткәнен аңлап, урыннарыннан тордылар да ишеккә юнәлделәр. Каган, Бүзбалага эндәшеп, Туңгак алып белән Исәнтәйне өйдә калдырырга кушты.

Юк, болай булгач, «әләкмәде» Исәнтәйгә!

## X

Тәхет янында өч ир кешедән башка беркем дә калмагач, Туман каган авыр итеп бер көрсенде дә, әкрен генә сүз башлады.

— Бу арада минем тынычлыгым качты,— диде ул.— Чин дә, Чжао да, качаклар да — беркем мине кызыксындырмый. Синдә кунак булган теге төннән соң минем күземә берни күренми, Исәнтәй, колагыма берни ишетелми. Күз алдымда, зиһенемне томалап, теге гүзәл чин кызы тора. Мин анда бер хата ясадым. Ничек төзәтергә шул хатаны — менә нәрсә борчый мине!

Ул тагын бер көрсенеп куйды һәм беркемгә дә төбәп кенә карамыйча, һәркемгә күз йөртеп чыкты. Тәхет янындагы ирләрнең берсе дә каган авызыннан мондый сүз ишетербез дип уйламаганнар иде. Бу бөтенләй көтелмәгән нәрсә булып чыкты һәм шуңа күрә алар барысы да баягыча авыз ачарга да куркып, тын гына утыра бирделәр. Каган аларга икенче тапкыр күз йөртеп чыкты. Бузбала түзмәде, тизрәк акланырга кирәк тапты.

— Мин Исәнтәйдә кунакта булмадым, шуңа күрә мин берни әйтә алмыйм, бөек каган,— диде.

— Мин Исәнтәйдә кунакта булдым, шулай да синең анда хата ясавыңны хәтерли алмыйм,— диде Туңгак алып.

Туман каган өченче тапкыр көрсенеп куйды. Үзенең хатасы турында сүз башлавы аңа бик авыр иде, күрәсең.

— Мин синең хата беләм, бөек каган,— диде Исәнтәй телгә килеп.

— Белсәң, әйтеп бир: ничек төзәтергә шуны?! — диде каган.

— Мин әйттем: кызны сиңа бирергә кирәк, дидем. Мин әйттем: сиңа сүзем бар, дидем. Син әйттең: кызыңны китер, сүзеңне урдада әйтерсең, дидең.

— Әйе, исемдә. Шулайрак булды,— диде каган килешеп.— Менә хәзер әйтәсе сүзеңне дә әйт, киңәшеңне дә әйт.

Исәнтәйнең каган белән шундый кыю, иркен сөйләшүе, җитмәсә, аларның икесенең генә ниндидер уртак серләре булуы, гомумән, бу әрсез бәндәнең монда ак киез өстендә иркенләп, җәелеп утыруы Туңгак алыпның чиктән тыш эчен пошырды.

— Барысы да аңлашылды, бөек каган! — диде ул Исәнтәйгә аркылы төшеп.— Син теге тәгин угланга бүләк итеп бирелгән чин кызын әйтәсең бугай.

— Шул, шул! — диде каган ашыгып.

— Ул көнне синең тәгин улың сиңа сөенечле хәбәр китерде — бер! Ауда сине үлемнән коткарды — ике! Син үзең, үз кулың белән кызны аңа бүләк итеп бирдең — менә булды өч! — диде Туңгак алып.— Кайда монда синең хатаң? Исәнтәйдә булган төнне син берниндә хата ясамадың, бөек каган.

— Белмим, белмим,— диде каган чын күңелдән, аптырап.— Барысы да исемдә. Мин аны үзем бирдем, үз кулым белән. Шулай да мин аны оныта алмыйм. Ятсам да, торсам да ул минем күз алдымда.

— Син аны ярата, бөек каган! — диде Исәнтәй кабаланып.

— Әйе, яратам бугай,— диде каган.

— Ярату хата була алмый! — диде Туңгак алып шактый тупас итеп.

Ул моны каганны яклаудан бигрәк, Исәнтәйгә каршы төшү өчен генә әйтте. Үз кайгысына чумып утырган каган Туңгак алып белән Исәнтәйнең үзара әйтешә башлавын бөтенләй сизмәде. Исәнтәй исә барысын да сизеп-тоеп утырды. Шуңа күрә дә ул каравыл агасы Туңгак алыптан ничек тә алгарак чыгарга тырышып, кыюланып, яңадан һөҗүмгә ташланды.

— Туңгак алып дөрес әйтә,— диде ул елмаеп.— Каган ярата — хата имәс. Каган илдәге барлык кызларны яратса да, хата имәс. Тәгин угланга биргән кызны каган кире алса, шулай ук хата имәс!

— Нишләп ул алай? — диде Туңгак алып.

— Биргән бүләкне кире алу йоласы юк,— диде Бузбала да, Исәнтәйне усал күз карашы белән өтеп.

— Әйтеп бетер, Исәнтәй,— диде каган тылмачны яклап.

— Ул кызны чин качагы... «кара йөз» алып килде...— сиңа бүләккә, бөек каган!

— Миңа?! — диде каган шаккатып.— Нишләп аны башта ук әйтмәдең?

— Син мине тыңламадың, бөек каган,— диде Исәнтәй үз-үзен шактый тыныч тотып.

— Әйе, тыңламадым.

— Аны сиңа Чжао аксөякләре җибәргән. Ул кыз әлеге кара йөзнең сеңелесе, бөек каган.

— Шулай ук мени әле ул?! — диде каган чын күңелдән гаҗәпләнеп.

— Аңлашылды! — диде тагын Туңгак алып нидер әйтергә җыенып. Ләкин бу юлы Исәнтәй аңа үзен бүлдерергә ирек бирмәде.

— Мин киңәш итәм, бөек каган: бүләк — сиңа, кыз синеке. Кызны кире ал! — диде ул.

— Ничек? — диде каган.

— Болай булгач, мин болай уйлыйм,— диде Туңгак алып та яуга ташланып.— Үзеңә дигән бүләкне... аңламыйча, ялгыш тәгин угланга биргәнсең икән, аны үзеңә кире ала аласың. Сине ялгыш юлга этәргән өчен, кызның сиңа дип китерелгән булуын белеп тә, башта ук аны сиңа бирдермәгән өчен... тылмач Исәнтәйнең башын чаптырырга кирәк.

Мондый сүз ишетеп Исәнтәй кинәт күз алдында бөрешеп калды, кызгану, ярлыкау өмет итеп, шундук каганның аяк астына егылды.

— Син моңа ни әйтерсең, Бүзбала? — диде каган, уң кул карачыга борылып.

— Кызны болай гына тартып алсаң, уң кул тучи бәк белән арагыз бозылыр,— диде Бүзбала.— Тәгин углан белән бозылышу ул өлкән бичә белән, атаклы Котлуг бәк белән, Куян ыруы белән бозылышу дигән сүз. Ак өйдән тынычлык китсә, бөтен илдән тынычлык китәр, үзара ызгыш-талаш китәр. Сөннең көче үзара талашта түгел — бердәмлектә. Өч таган таймас, тайса берсе дә калмас, дип белми әйтмәгәннәр. Куян, Алан, Сөйбү ул өч таган дигән сүз. Синең туган ыруың, бөек каган, Сөнәнкәләр менә шул таган астында, ышыкта, түрдә утыручылар. Үзеңне җил-яңгырдан, кар-бураннан саклый торган таганны кисеп аударуны берничек тә аклап булмый. Шулай да синең ул чин кызын үзеңә аласың килә икән, моны бик уйлап эшләргә кирәк, өч таган таймаслык итеп... Бер чин кызы аркасында илдән тынычлык, татулык китәргә тиеш түгел. Кызны кире алсаң, бар гаепне Исәнтәйгә аударып, аның башын чаптырырга кирәк булачак. Ул чагында инде беркемнең сине яманларга теле бармаячак.

— Кичер, бөек каган! — диде Исәнтәй.

Туман каган озак кына уйланып утырды.

— Үз кулым белән бирмәгән булсам, мин Исәнтәйнең башын чаптырган да булыр идем,— диде ул Бүзбала белән Туңгак алыпка җавап итеп.— Юк, монда баш чаптырып кына котылып булмый. Бүре дә тук булсын, сарык та исән калсын — менә нәрсә кирәк монда! Кем эшли ала шуны?

— Мин! — диде Исәнтәй аны-моны уйлап тормыйча.

— Эшлә,— диде каган киң күңеллелек күрсәтеп.— Эшли алсаң, түремдә утырырсың, баш тылмачым булырсың. Эшли алмасаң...

— Эшлим! — диде Исәнтәй, дөрләп янган утка ташланган кеше кебек, барлык батырлыгын җыеп.— Син, бөек каган, Табылдыкны тучи бәк тәгин угланга бирә, чин кызын үзеңә ала! Бүләк урынына бүләк. Бүре дә тук, сарык та исән!

Каганның йөзе ачылып китте. «Ишеттегезме?» дигән сыман, ул Бүзбала белән Туңгак алыпка карап алды.

— Башың үзеңдә калыр, ахрысы, эттән туган Исәнтәй! — диде ул карачы белән каравыл агасының нәрсә дә булса әйткәнен көтмичә.

— Уйлап карарга була,— диде Бүзбала килешкәндәй итеп.

Туңгак алып берни эндәшмәде.

## XI

Кичке аш вакытында Исәнтәй ак киезнең уң ягында, тәхеткә бишалты кеше кала гына утырды. Мондый яңалыкны туган-тумача, агайэне бик тиз күреп алды. Исәнтәйнең шулай кисәк кенә түргә үрләвен күпчелек бер төрлерәк юрады: алып килгән теге «кара йөз»е, күрәсең, бик кирәкле кешедер, диделәр, озакламый илдә, урдада үзгәрешләр булмагае, диделәр. «Нинди үзгәреш булыр икән соң ул?» дигән сорауга шундук җавабы да табылды: «Чингә каршы каган олы яу күтәрер — башка тагын ни булсын?!» диделәр. Иртәнге күлемдә каганның биек Ак өйдә өч кеше белән генә калып ни турында сөйләшкәнен беркем дә белә алмады.

Каган үзе дә иртәнге сөйләшү турында уйланды, ләкин ул бөтенләй икенче төрле уй-теләкләр белән уйланды, Исәнтәйнең киңәше анда ышаныч тойгысы уятты һәм аның борчулы күңеленә берөзлексез җылы өстәп торды. Шулай да бу әле бәхет түгел иде. Шунлыктан әлегә ул сөенә алмады. Әлегә ул бары нининдер өмет барлыгын гына шәйләде.

Йорт башының уйчанлыгын барысы да күреп, тоеп утырдылар. Кичке аш басынкы гына, шау-шусыз гына үтте. Туман каган, эчен тырнаган нәрсәләрне томаламакчы булып, бузаны күбрәк эчеп ташлады.

Төнне ул бик начар йоклады. Таңга таба каган төш күрде.

Төш бик куркыныч иде. Эсселәп, шыбыр тиргә батып ул кинәт уянып китте. Уянып китте дә, йөрәгенең дөп-дөп тибүен тыңлаган килеш, өй эчендәге сыекланган җылы караңгылыкка текәлеп, кымшанмыйча ята бирде.

Көн яктысы төшкән нининдер тау итәгендә, нининдер тирән су буенда яшь җирән бога белән карт юлбарыс сугышты. Иң әлек су буенда, яшел болында утлап йөргән сыер көтүе күренде. Яшь җирән бога әлеге көтүнең башлыгы имеш. Мөгезләре очлы, муены кыска, аяклары нык. Күзләре уттай яна. Үзе шундый зур, таза!

Каяндыр шул чакны камышлар арасыннан сак кына атлап, як ягына каранып, юлбарыс килеп чыкты. Килеп чыкты да бу, искәрмәстән көтү өстенә ташланды һәм бер-бер артлы сыерларны ботарларга да тотынды! Бер сыерның канын гына суыра да, икенчесенә ташлана. Сыерлар тузына, качыша башладылар. Бары яшь җирән бога гына, баскан җиреннән әз генә дә кузгалмыйча, урынында торып калды. Авызы-борыны канга буялган карт юлбарыс ырылдап кинәт моңа таба ыргылды. Ләкин яшь бога әз генә дә курку сиздермәде — башын түбән иеп, күзләрен уттай яндырып, көтеп тора бу моның килеп җиткәнен. Юлбарыс шүрләгәндәй итте, туктап калды һәм якындагы тауларны калтыратып, бар көченә үкереп җибәрде.

Шулай кара-каршы килделәр дә болар, җирне-күкне дер селкетеп, ямьсез тавышлар белән кычкырып, сугышырга да керешеп киттеләр. Бик озак сугыштылар болар. Яшь җирән бога көтмәгәндә тегенең корсагына очлы мөгезләрен китереп батырды да, бар көченә ярсып

тегене баш өстенә күтәрде дә сырты аша жиргә орды. Шундый иттереп орды — еракта дөбердәп кыялар ишелеп төште, гөрселдәп жиргә мең яшәр карагайлар ауды. Яшь бога куанычыннан үкереп жибәрде.

Яралы юлбарыс, канлы эчәкләрен өстерәп, кыялы таулар ягына элдерде. Үзе чаба, үзе артына борылып карый да, яшь жирән богага яный имеш: бер сыерыңны калдырмый бугазлап бетерәм, үзеңне тере килеш кабып йотам, дип әйтә имеш. Моның шулай дигәнен ишетте дә яшь бога, борылып килеп, тегенең артыннан куа китте. Шулай да куып житә алмады бу. Юлбарыс кыялар арасындагы үз оясына кереп качты. Кереп качты да, ояга керә торган юлны бик зур таш белән томалап куйды. Шулай итеп, котылды, исән калды юлбарыс!

...Туман каган, тынын кысып, өй эчендәге жылымса караңгылыкка карап ятты да ятты. Янында гына ефәк тышлы мамык ястыкларга, мендәрләргә күмелеп, берни белми йоклаган Табылдыкның тигез тын алуы ишетелде, кайдадыр тышта, еракта этләр өргәне ишетелде.

...Юлбарыс үз оясына кереп, тар сукмакны таш белән томалап куйгач та, югарыдан, текә кыялар арасыннан, канатлары белән бөтен яктылыкны каплап, каракош очып төште. Очып төште дә бу, очлы тырнаклары белән яралы юлбарысны эләктереп тә алды. Эләктереп алды һәм уктай атылып югары менеп тә китте.

Менә шул чагында Туман каган куркып кычкырып жибәрде. Юк, кычкыра да алмады — кычкырмакчы булып бары көчәнде генә. Яшь бога белән карт юлбарысның сугышын ул каяндыр читтән генә карап торган сыман иде. Юлбарысны каракош күтәреп киткәч ул нишләптер көтмәгәндә үзе юлбарыска әйләнде куйды!

Шулай итеп каракош аны... Туман каганны күтәреп алып китте!

Шулай итеп дөнья кайгылары онытылды.

Бу тегенди-мондый гына төш түгел иде, ахрысы. Бу нииндидер серле һәм хикмәтле төш булырга тиеш иде. Ләкин нәрсә булыр бу? Яшь бога кем дә, карт юлбарыс кем? Юлбарыс чыннан да Туман каган үзе булса, бу ни дигән сүз бу?!

## XII

Төш юрауга, күрәзәгә һәм һәр төрле ырым-шырымнарга чын күңелдән ышана торган Туман каган бер генә зур эшен дә камнар, күрәзәчеләр белән киңәшмичә эшләми иде. Инде шундый куркыныч, буталчык төш күргән икән, иң элек аны, билгеле, төш юраучыларга, күрәзәчеләргә сөйләргә кирәк иде. Баштарак ул шулай дип уйлады да. Ләкин, ныклап торып уйлана торгач, ул бөтенләй капма-каршы фикергә килде. Үзенең карт юлбарыска әйләнүен, юлбарысны каракош күтәреп алып китүен кемгә дә булса сөйләү дөрес булырмы? Бу бит төштә генә түгел, өндә дә үз-үзеңне нииндидер явыз каракошларга тотып бирү белән бер булачак! Синең шундый төш күрүеңне көнчел туганнарың, дошманнарың ишетеп калса, ул чагында алар сине терелэй тотып ашамаслармыни?!

Шулай булгач, нишләргә?

Бу бик авыр, бик катлаулы сорау иде. Моны хәл итмичә торып, моннан соң яшәргәме, яшәмәскәме? Яшәсәң, ничегрәк итеп яшәргә, дигән сорауны хәл итеп булмаячак кебек иде. Төшне беркемгә дә сөйләмичә, мәңге аны күңелеңдә яшереп калырга да булыр иде, билгеле. Ләкин бу инде йөрәк турысына килеп кадалган ук тимерен тартып алмыйча, шул көенчә яшәп ятарга азаплану белән бер булыр иде. Төш аркылы ата-баба, изге ияләр исән калганнарга киңәш бирәләр, аларны кисәтәләр, аларга туры юл күрсәтәләр.

Шулай булгач, теләсәң дә, теләмәсәң дә төшнең серен ачыкларга кирәк булачак. Туман каганның барлык киңәшчеләреннән дә якынрак бер киңәшче-сердәше бар иде. Ул да булса, Баргынтай баба иде. Баргынтай баба — аның үлгән атасының ана ягыннан үги агасы. Сөнәнкә ыруында ул каганнар тамырының иң карт кешесе, бөтен ыруга ата урынына калган кеше.

Торып иртәнге йомышларын йомышлагач, киенгәч, тарангач, Туман каган Баргынтай бабаны алырга кеше җибәрде. Баргынтай баба урданың уртанчы бож̌расында яши иде. Көттермичә ул тиз арада килеп тә җитте. Каганның үзенә генә әйтәсе ниндидер сүзе барлыгын ул, билгеле, сизенми калмады. Шулай да иртәнге аш янында ул-бу турында бернинди сүз булмады. Бары тик ашап-эчкәч һәм өч аяклы түгәрәк өстәлне, табак-савытларны ашчылар Ак өйнең икенче ягына алып чыгып киткәч кенә каган Баргынтай бабага үз янына күчебрәк утырырга кушты.

Күк гөмбәзедәй биек, иркен өйнең ярты ягында Баргынтай баба белән икәүдән-икәү генә калгач, калын чыбылдык артыннан берәрсе тыңлап тормасын дигән сыман, тавышын әкренәйтеп, Туман каган аңа әлеге төшен сөйләде. Ул аңа барысын да түкми-чәчми сөйләде, тик ахырга таба гына аны тагын икеләнү белән алды. Үзенең карт юлбарыска әйләнүен әйтергә аның шулай да кыюлыгы җитмәде.

Каганның нидер яшереп калуын Баргынтай баба сизеп утырды. Ләкин ул берни сорашмады. Бөтен ыруда иң карт кеше булса да, мондый икәүдән-икәү сөйләшүләрдә, киңәш-табышта аеруча сак булырга кирәклеген ул инде беләә иде. Шуңа күрә зур гәүдәле, бай киемле ир уртасы каган алдында тезләнеп, башын иебрәк утырган чандыр карт беренче булып сүз башларга ашыкмады.

— Ник эндәшмисең, Баргынтай баба? — диде каган тынып утыру озакка сузыла башлагач.

— Изге төш бу, углым,— диде Баргынтай баба, башын калкытып.

Каган, җиңеләеп, ат сыман пошкырып куйды. Тезләре өстендә җансыз булып яткан авыр йодрыклары үзеннән-үзе язылып китте.

— Беркайчан да синең мондый изге төш күргәнең булмады,— диде күңеле күтәрелеп киткән карт.— Өндә син үзең карт юлбарыс үтерден. Төштә мена тагын карт юлбарыс! Изге бу, изге төш. Карт юлбарыс ул — карт, явыз Чин иле...

Баргынтай бабаның шулай дип әйтүе булды, Туман каган, әле генә җиңеләеп сулыш алгандагы кебек, янә дә ат пошкырган сыман көрсенеп куйды. Шул ук мәлдә аның ирексездән сул күз кабагы тартыша башлады. Бик нык эче пошса, үртәлсә, ачуланса һәм шул вакытта үзенең күңелсез тойгыларын эченә яшерсә, аның шулай сул күз кабагы тартыша башлый. Моны Баргынтай баба да, башкалар да беләләр һәм мондый чакта ничек тә аннан читтәрәк булырга тырышалар иде. Шулай да Баргынтай баба төш юравын батырларча дәвам итте.

— Берәм-берәм сыерларны бугазлаган сыман, бер-бер артлы алты йортны аяк астына салып таптаган Чин юлбарысы чәнчелер, иншалла! — диде ул.— Аның үзен кем егар, кем сөзеп эчеп айкар яшь җирән бога сыман? Синме? Күрәсең шулайдыр, углым.

— Бирсен тәңрем! — диде каган.

— Бу әле төш юрау түгел,— диде Баргынтай баба.— Бу — минем теләк, синең теләк. Дөньяда эшләр синең теләк, минем теләк буенча гына бармый. Барлык эшләр изге ата-бабаларның теләге буенча, тәңренең боерыгы буенча бара. Без бары тәңренең боерыгын үтәүчеләр генә. Синең төшеңдә аңлашылмаган нәрсәләр бар, изге каган.

Үз уйларына бирелеп утырган каган шундук башын калкытты. Бу юлы да ул шаулатып көрсенүдән үз-үзен тыеп кала алды.

— Карт юлбарысны Чин дип, яшь боганы Сөн дип уйласак, бу дөрес булмаячак,— диде Баргынтай баба, каш астыннан гына каганны күзәтеп.— Сөн иле, яшь богадай көчле булса да, аңа инде күптән мең яшь тулган. Сөннәр күп халыклардан элегрәк барлыкка килгәннәр. Сөннәр — тәңренең иң сөекле балалары. Шуңа күрә дә алар йиксез-чиксез көтүлекләрне, тау-ташларны, урманнарны үз кулларына алганнар. Җунго әнә төрле яктан биек таулар белән, диңгез белән чикләнгән тар, кысан үзәнлектә торып калган. Инде карт юлбарысны бүгенге Чин йорты дип уйласак, монысы бөтенләй хата булачак. Чин әле аягына да баса алмаган сабый бала кебек кенә.

— Сүзләрең изге, Баргынтай баба,— диде каган тыңламыйча.— Яхшы сүзләрең өчен миннән сиңа кеш якалы тун, йөгәнле, иярле кашка бирерләр.

— Бай бул, изге каган!

— Инде турысын әйт: сөйләргәме юраучыларга бу төшне? — диде каган чандыр картның йөзенә туры карап.

— Төшең буталчык, углым,— диде Баргынтай баба,— Анаң Кортка-бикәдән башка беркемнең башы җитмәс бу төшне юрарга.

## XIII

Анасы Кортка-бикә янына Туман каган үзе китте. Бер үзе. Бай киемнәрен дә кимәде, егетләрен дә алмады. Карт алашасына атланды да, күңелендәге каршылыклы уйларын җиңеп, тешен кысып, башын иеп анасы янына китте.

Туман каганның анасы Кортка-бикә урдадан биш-алты чакрым читтә, төн ягында кечерәк бер күл буенда яши иде. Каган урдасы кая гына күченеп китмәсен, кайда гына утырып калмасын, теләсә кайда, теләсә кайчан ул үзенең өлкән углыннан шулай биш-алты, кайчагында сигез-тугыз чакрым чамасы читтә, төньякта булырга тырыша иде. Бары тик су ягы кыенга туры килгәндә генә ул урдага, димәк, суга якынрак җиргә утыра, ләкин беркайчан да каганның биек Ак өен әйләндереп алган божралар эченә керми иде. Каганы өеннән кала аның өе якын-тирәдә иң биек, иң зур өйләрдән санала иде. Каган өен, өч кат тыгыз божра булып, атлы, кораллы торгаклар әйләндереп алган булса, аның өен дә шулай ук өч кат божра булып тыгызланып, кечерәк, ярлырак өйләр әйләндереп алган иде. Тик ул өйләрдә бернинди торгаклар да, кораллы ирләр дә юк. Ул ярлы өйләрдә Кортка-бикәнең үз кешеләре — йөзләгән, меңләгән ырудашлары, коллары, төрле авырулар, ярлылар, аяк-кулсыз карт-корылар яши иде.

Карт атка атланган таза ир кешенең туп-туры үзләренә таба килүен аксак-туксак ирләр — элекке сугышчылар — ерактан ук күреп алдылар. Беравык алар аны танымыйчарак тордылар. Танып алдылар да, барысы берьюлы диярлек куанып кычкырып җибәрделәр. Титаклап бер-икесе шундук өйгә — Кортка-бикә янына йөгерде, калган бер-икесе — тазарак, төзегрәк күренгәннәре каган каршысына ашыкты. Атын үз көенчә генә атлатып килгән Туман каган тышкы божрага барып җиткәнче алар аның каршысына килеп тә җиттеләр, атының йөгәненнән тотып та алдылар. Шунда берсе, олы кунакка иярдән төшәргә булышып, аның аяк табанына зур учын куйды, икенчесе, биектән сикергән баланы тотып алырга җыенган сыман, аны тотып алырга әзерләнеп торды, өченчесе дәрте сүнгән, юаш, карт алашаның сөякчел маңгаеннан, күкрәгеннән сөештергән булды. Каган җиргә баскач, аксак-туксакларның берсе юл күрсәтеп алдан китте, икенчесе, куанычыннан нишләргә белмичә, алаша белән туктаусыз сөйләнеп алдан титаклады.

Ярлы, караңгы өйләр артында каганга сәләмә туннарына төренеп өй буенда утырган ниндидер карчыклар, үзара ыгы-зыгы килеп кузна уйнаган бала-чагалар очрады. Мондагы ярлылык, мондагы күңелсезлек каганның ачуын китерде. Бу аксак-туксак ырларне, авыру кортларны, караеп, тишелеп беткән, кырык җирдән ямаулы өйләре-ниләре белән аның бөтенесен бер өемгә өеп ут төртеп яндырасы, я булмаса тау-ташлар арасындагы берәр упкынга илтеп аударасы килде. Анасы белән, билгеле. Тик менә төшне генә юрасын да...

Каганның анасы Кортка-бикә үзе болай бер дә ярлы түгел иде. Аның үзенә беркетелгән уникә мең өйле иле, көтүләре, көтүлекләре бар. Теләсә ул үз өен дә, үзен әйләндереп алган башка өйләрне дә өр-яңа киездән кордыра алган булыр иде һәм теләсә аның тирәсендә бер генә сәләмә киемле карт-коры да булмас иде. Каганның анасы буларак ул биек Ак өйнең һәрвакыт түрендә, табынның мулында утыра алган булыр иде. Ләкин ул әнә теләми. Аның менә шундый ярлы булып, углы каган тарафыннан кыерсытылган булып күренәсе килә.

Моннан унҗиде-унсигез еллар элек ул бер дә андый түгел иде. Туманның атасы, Кортка-бикәнең ире каган үлгәч, Алан ыруының Бай-Тимер яклылар Сөнәнкәнекеләргә каршы баш күтәрделәр. Бай-Тимернекеләр урда аксөякләренең шактыен үз якларына аударып өлгергәннәр иде инде. Урдада бик каты суеш булыры көн кебек ачык иде. Менә шунда Кортка-бикә, каршы яктагыларның кайберләрен үз ягына аударып, кайберәүләренә иркәләп, кайберәүләрен куркытып, тиз арада дилбегәне үз кулына алып өлгерде һәм өлкән углы Туманны биек Ак өйнең түреңә утыртуга иреште. Бай-Тимер җиңелде. Аның яклы бик күпләрнең башлары аяклары астына тәгәрәп төште.

Каган булгач, Туман ни теләсәм шуны эшләрмен дип уйлаган иде. Ләкин чынлыкта эшләр бик үк алай булып чыкмады. Әледән-әле аның эшенә, тормышына Кортка-бикә кысыла башлады. Ире каган исән чакта аны уч төбендә биеткән усал, үзсүзле, холыксыз хатын үзенең өлкән углын да уч төбендә биетмәкче булды. Һәм, чыннан да, тәхеткә утыруның беренче елларында каган ничек тә анасы теләгәнчә эшләргә, ул теләгәнчә яшәргә тырышты. Шулай да тора-бара аның вак-төяк киңәшләре, еш кабатланган холыксызлыклары ачуын китерә башлады.

Көннәрдән бер көнне алар бозылышып киттеләр. Бик каты бозылыштылар! Туман каган әйтте: алтын тәхеткә мин синең итәгеңә ябышып яшәү өчен утырмадым, диде. Анасы әйтте: мин утырттым анда сине, мин! диде. Мин булмаган булсам, син инде күптән атаң янында җир куенында яткан булыр идең, диде. Атаң исән чакта мин бөтен Сөн илен үз кулымда тоттым, син каган булгач, мина сигез мең өй бирдең дә, коры таякка калдырдың, диде. Дүрт мең өйлек Сөйбүләр аның бирнә буларак артыннан килгән үз байлыгы иде.

Шушы ызгышудан соң Кортка-бикә шулай да углының эшенә, тормышына кысылмый башлады. Ләкин шул ук вакытта ул урдадан аерылып, «башкаланып» чыгып китте. Урдадан аерым яшәсә дә ул углы янынннан бик үк читкә дә китмәде. Болай яшәү аның өчен бик тә җайлы иде. Әкренләп ул урданың барлык камнарын, күрәзәчеләрен, имче-томчыларын үз тирәсенә туплады һәм алар аша итәк астыннан ут йөртә башлады. Озакламый ул үзен Ана-кам дип белдерде һәм барлык дин-йола эшен үз кулына алды. Шулай итеп, ул барыбер җиңелмәде!

Хәер, Туман каган беркайчан да аны җиңәргә уйламады да. Нинди генә булмасын, ана — изге, үз анасына каршы кул күтәргән кешене яшен сугачак иде. Шулай ук Кортка-бикә дә үз углына каршы бер-

НУРИХАН ФӘТТАХ ◆ СЫЗГЫРА ТОРГАН УКЛАР ◆

кайчан да бернинди яманлык эшләмәде бугай. Итәк астыннан ут йөрткәндә дә ул турыдан-туры каганга зыян ясамаска тырышты.

Анасы башкаланып яши башлаганнан бирле Туман каганның менә шулай аның белмәсенә беренче мәртәбә аяк басуы иде.

## XIV

Кортка-бикәнең тыштан караганда каганныкы кебек биек, иркен өе, янына килгәч, якын тирәдәге ярлы өйләрдән әлләни аерылып тормый иде. Кайчандыр кардай ак булган киезләр караеп, ямалып беткән. Өйнең итәкләре тетелгән, теләсә ничек ямап, тарттырып куелган. Өй янындагы казыкларда изге ата-бабаларның — Бүре, Аю, Куян кебек абаларның[1] җилдә-яңгырда шомарып, агарып беткән баш сөякләре ыржаеп тора; казыктан казыкка сузылган кыл арканнарда очлы тешләр, усал тырнаклар тирбәлә, йомшак койрыклар җилферди. Ишек катындагы иң биек казык башында, канатларын киң җәеп, кара тугбөркет чайкала.

Өйнең үгез тиресе белән тышланган ишеген билсез карт ачты. Беренче ишектән кергәч, эчтә, бусага төбендә каганны икенче бер гарип каршылады. Кулыннан тотып ул аны бусага янындагы агач-ат[2] янына алып килде, утыртты. Икенче бер аксак карт, олы кунак килүен әйтергә дип, өйнең түр ягына таба атлады. «Ничек кылана!»— дип уйлады каган анасы турында, яратмыйча.

Каган улының үз янына килерен Кортка-бикә бөтенләй көтмәгән иде ахрысы. Әлерәк кенә ниндидер тире кисәкләре, канатлар, койрыклар белән булышкан җиреннән ул бар эшен ташлап, шулай да өстендәге сәләмә киемнәрен алыштырмыйча, илтотмыш бикә сыман, өенең уң ягында, биек ятагында аякларын бөкләп утыра иде. Шунда ук, Кортка-бикәнең аягы астында, сәләмә киемле, корышкан йөзле берничә карчык тынып калган. Башына Кортка-бикә куян тиресе тотылган мескен бүрек, өстенә — җирән йон күлмәк, күлмәк өстеннән тире күртәнә[3], аякларына — кыршылып беткән болан итекләр кигән иде.

Ябыклыктан ияк очлары, яңак сөякләре күзгә төртелердәй булып торган чандыр карчык үзенең чак-чак кына каушап калган игелексез улына сынап, исе китеп һәм шактый ягымлы итеп карады. Туман каган исә, мышнап, кызарынып, авырлык белән генә анасы алдында билен бөкте, баш киемен салып, башын иде.

— Кичер, анам,— диде ул таштай авыр, кытыршы сүзләрен каяндыр төптән тартып чыгарып.

Анасының ни өчен үзен кичерергә тиешлеген ул үзе дә аңлап җитмәде, ләкин бу очрашуда, мондый очрашуда ул аңа бары тик шундый гына сүз әйтергә тиеш иде сыман.

— Анаңның ничек яшәгәнен күрергә килдеңмени, балам? — диде Кортка-бикә җиңелчә мыскыл белән.— Менә, күр: мине ачлар туендыра, тунсызлар киендерә. Аксак-туксаклар минем көтүләремне көтә, тишек-тошык өемне җылыта. Мин инде күптән атаң янына киткән булыр идем — изгеләр җибәрми. Миннән алда алар сине көтәләр, улым!

Еллар буена җыелып килгән сүзләрен, ачуын-үпкәсен тизрәк әйтеп бетерергә тырышкан сыман, Кортка-бикә ашыгып, кабаланып сөйләде. Аның чатнап торган чәрелдек-яңгыравык тавышы каганга куркыныч һәм шомлы булып ишетелде. Анасының соңгы сүзләре аның йөрәгенә агулы ук булып кадалды. Ул, үзенең тирли башлавын тоеп, авыр кулын битенә якынайтты.

---

[1] Аба — мифик ата-ана, баба. Ыруның-кабиләнең нәсел башы. Абалар гадәттә берәр ерткыч кыяфәтендә булганнар.

[2] Агач-ат — агач утыргыч.

[3] Күртәнә — кыска тун, куртка.

— Мин сине чакырып кеше җибәрәм, син килмисең,— диде мышнап.
— Куалап җибәргәнеңне оныттыңмыни? — диде Кортка-бикә тыңламыйча.
— Мин сине куаламадым, анам. Син үзең киттең,— диде каган.
— Син мине чүплек башына чыгарып ташладың! — дип кычкырды Кортка-бикә кинәт ярсып китеп.— Син мине үлсен дидең. Мин әле үлмәдем. Мине изгеләр яклый. Кул күтәреп бер дога кылсам, менә шунда сине җир йотачак, игелексез! Биек ак өйгә баш булу өчен син күпме туганнарыңның, күпме ырудашларыңның канын койдың?! Тәмугта сиңа барысы өчен дә җавап бирергә туры киләчәк.
— Анам! — диде каган түземлеген җуя башлап.
— Әйе, мин — синең анаң. Изге анаң! — дип кычкырды биек ятакта аякларын бөкләп утырган Кортка-бикә, нурсыз күзләреннән усал очкыннар чәчрәтеп.— Нишләп аны әле генә исеңә төшердең?
— Мин сине гел исемдә тотам, изге анам,— диде каган ялганлап.— Менә синең шундый көнгә төшүеңне ишеттем дә, үз күзләрем белән күрмәкче булып, янына килдем. Мин сиңа, изге анам, туену өчен... өч мең өйлек ил-көн, көтүләр, көтүлекләр бирмәкче булдым.
Ул моны әле генә уйлап тапты. Күрешми торган арада Кортка-бикә бик нык үзгәргән иде һәм берәр майлы калҗа ташламыйча торып күрәсең, аның күңелен җиңел генә яулап алып булмаячак иде. «Майлы калҗа» чыннан да үзенекен итте. Тиле кортка, углының соңгы сүзләрен ишетеп, кисәк кенә тынып, юашланып калды һәм тыела алмыйча җылап җибәрде.
— Атаң исән булса, мин дә монда аксак-туксак белән бер табактан ашап, каткан киез өстендә йокламас идем,— диде ул, борынын тарткалап.
— Урдага кайт — янымда гына булырсың, изге анам,— диде каган.— Алдыңда алтын табаклар, баш астыңда мамык түшәкләр булыр.
— Юк, юк! — диде карчык йокыдан уянган сыман.— Мин инде бу өемне ташласам да ташлап китә алмыйм. Әнә, күрәсеңме, алар мине дүрт күз белән күзәтеп торалар! Мине алар җибәрми.
Ул очлы тешләрен ырҗайткан баш сөякләренә ымлап күрсәтте. Туман каган ирексездән изге абаларга карап алды. Аңа чыннан да өйнең барлык төшеннән — астан, өстән, ян-яклардан кемнәрдер күзәтеп, сагалап торалардыр сыман тоелды. Аның тизрәк төп сүзгә күчәсе килде.
Углының уйларын сизенгән кебек, Кортка-бикә шундук кымыз китерергә кушты. Кымызны бары үзе генә эчә торган савытка — юка алтын калай белән тышланган, эчке ягы исә көмеш калай белән капланган баш сөягенә агызды. Кымызны Кортка-бикә, йола буенча, иң элек Ут-анага бирде, аннары үзе авыз итте дә углына тоттырды. Каган эчеп бетергәч ул, кулын селтәп, өй эчендәгеләрнең барысына да чыгып китәргә боерды. Шуннан соң, бөтенләй тынычланып, юашланып калган изге бер кыяфәттә:
— Төшеңне сөйлә, углым,— диде.
— Төшне?! — диде Туман каган шаккатып.
— Куркыныч төшеңне сөйлә, балам,— диде Кортка-бикә.
— Син... изге анам, каян беләсең аны? — диде каган.
— Мин барысын да беләм,— диде Кортка-бикә тыныч, серле бер өстенлек белән.— Миңа изге абалар җиткереп тора. Кара аны, бер нәрсәңне дә яшереп калдырма.
«Баргынтай баба җиткерде микәнни?» дип уйлады каган, әле булса исенә килә алмыйча. Ләкин, алай дисәң, Кортка-бикә беләч алар — дошманнар.
Углының икеләнүен Ана-кам шундук чамалап алды.

— Миңа ышанмагач, ник килдең монда? — диде ул усал гына итеп.

«Ул чыннан да изге!» дип уйлады Туман каган исе китеп.

## XV

Төшне каган анасына түкми-чәчми сөйләде.

Тыңлап бетерү белән, Кортка-бикә сикереп урыныннан торды, шомарып беткән баганадагы шомарып беткән дөңгерен кулына алды һәм шундук бөтенләй икенче кыяфәткә керде. Күзләрен акайтып, бөтен тәне, өстендәге сәләмәләре белән калтыранып, дөңгердәге шөлдерләрен, тимер, сөяк кисәкләрен шакылдатып-шалтыратып, бар көченә: «Алас! Алас!» дип кычкырып җибәрде. Атка атланган килеш якъякка тирбәлеп, чайкалып баргандагы сыман, кызу-кызу атлап ул өй эчен өч мәртәбә әйләнеп чыкты. Шуннан соң, кемнәр беләндер бик каты сугышкан шикелле, кемнәрнедер куа-куа, арып-алҗып, хәлдән таеп, яңадан үз урынына килеп ауды. Килеп ауды да, күзләрен йомып, кул-аякларын хәлсез салындырып, беравык мәрткә китеп ятты.

Ниһаять, ул башын калкытты: Берни эндәшмичә, беркемне күрмичә шактый тынып утырды. Каяндыр җир астыннанмы, калын киез артыннанмы сөйләшкән сыман, тавышын үзгәртеп, серле һәм шомлы итеп:

— Кем син, и адәми зат? — диде.

Анасының күз алдында шулай үзгәрә алуы игелексез угланны янә тетрәндереп җибәрде.

— Синең өлкән углың каган бу, изге Ана-кам,— диде ул, дер-дер калтыранып.

— Син Кара-тау иясен... изге абаны атkансың,— диде Кортка-бикә бераз көттереп.— Кара-тау иясенә атап корбан бир.

— Бирермен, изге анам,— диде Туман каган.

— Ул төнне ятагыңда үзеңнән башка кем бар иде?

— Ы-ы,— диде каган төртелеп.— Яшь кыз. Табылдык атлы.

— Аны абаларга бирерсең,— диде Ана-кам боздай салкын, дәртсез бер тавыш белән.

— Бирермен...— диде каган әкрен генә һәм шул ук мәлдә сөекле Табылдыгын, аннан да бигрәк, гүзәл чин кызын уйлап, кинәт тирләп чыкты.

Болай булгач Куяннар белән чынлап та бозылышырга туры килер микәнни? Әллә соң киңәш сорап карарга мы? Ярамас. Ул чин кызы турында авыз ачсаң, аны да үзенә тартып алырга күп сорамас бу изге анаң! Юк, аны әлегә бирмибез абаларга!

Кортка-бикә, углын сынаган сыман, озак кына эндәшми утырды.

— Яшь җирән богадан саклан,— диде ул аннары каганның тынычланганын күреп.

Яшь җирән бога турында ишетү белән Туман каган икенче мәртәбә уянып киткәндәй булды.

— Кем ул, кем яшь җирән бога?

— Ул синең баш балаң уң кул тучи бәк тәгин углан Алдбуга булыр,— диде Ана-кам ап-ачык итеп.— Аны ничек тә үзеңнән ераграк тот.

— Ничек аңларга моны, изге анам? — диде каган коты алынып.— Ул минем сөекле углым! Ул мине үлемнән коткарды.

— Син кем өчен яшисең, Туман каган? — диде Ана-кам, корыган агач шыгырдаган сыман дәртсез, салкын бер гамьсезлек белән.

— Мин... ни... синең өчен, изге анам, Илем-көнем өчен, балаларым өчен!

— Ялган сөйлисең! — диде Ана-кам усал итеп.— Син үзең өчен генә яшисең. Сиңа тәңре көч бирде, ил-көн бирде, тәхет бирде. Көчең киткәнче тәхетеңне кулыңнан ычкындырма. Көчең киткәч, тәңре барысын да үзе тартып алыр.

— Нишләргә соң, изге анам? — диде каган, яшь җирән боганы күз алдында тотып.

— Барысы да тәңре ирегендә,— диде Ана-кам аның тел төбен аңлап.— Үзең бармак белән дә чиртәсе булма. Чин карасыннан дүрт курчагын ясат, дүрт якка күмдер. Курчак ясаучыны Кара-тау иясенә корбан итеп бир.

— Бирермен, изге анам! — диде каган төштәге сыман.

— Хы-хы!— диде Ана-кам явыз көлемсерәп.— Бүре дә тук булсын, сарык та исән калсынмы?!. Булмый ул алай!

— Син анысын да беләсеңмени?! — диде каган яңадан гаҗәпкә калып.

— Беләм, барысын да беләм! — диде серле карчык.— Син генә белмисең минем ниләр белгәнемне. Мин барын да күреп, ишетеп торам. Миңа изгеләр житкерә!

Туман каган, исерек кебек тынып, басылып утырып торды да, авыраеп калган аякларын көчкә кузгатып, алпан-тилпән атлап ишеккә таба юнәлде. Аның тизрәк моннан — изге, куркыныч анасы янынннан чыгып китәсе килде. Ул нәрсә уйларга да белмәде, аның күңелендәге бөтен нәрсә бергә буталып, баш-аяк килде. Баргынтай баба белән сөйләшер алдыннан да, монда килер алдыннан да ул үзе ничектер башкачарак фикер йөрткән иде. Үзе яралы юлбарыс булган очракта да, яшь җирән бога, аныңча, өлкән углы Албуга түгел, бөтенләй икенче берәү — үзенә баш бирмәскә тырышкан берәр башбаштак булырга тиеш сыман тоелган иде. Баксаң, әнә ул ничек икән эшләр!

Кортка-бикә беркайчан да Куяннарны яратмады. Элек-электән ул аларны яманларга җай табып кына торды. Ире каган исән чагында ул Куяннарга каршы этлек эшләүдән дә тартынып тормады. Куяннан килен булып төшкән Күрекле бикәне дә, аның балаларын да ул бик үк өнәп бетермәде. Аларга карата нишләп шулай дошманлык саклагандыр ул — чынын гына беркем дә белми иде. Яшь чагында Котлуг бәк белән аның арасында ниндидер серле, күңелсез нәрсә булган ахрысы,— имеш-мимеш шулай сөйли иде.

Менә хәзер бөек углы каганның төшен юраганда да ул Куяннарга карата әүвәлге шул дошманлыгын исендә тотмады микән? Анасының Куян ыруынныкыларга карата мөнәсәбәтен яхшы белгән Туман каган шулай дип уйлый ала иде, билгеле. Ләкин алай дип уйларга аның хәзер нишләптер башы житмәде. Анасы камның изгелеге, серлелеге алдында аның тәмам зиһене томаланды. Ул бары шаккатты, аптырап, каушап калды һәм үзен өермәдәй бөтереп алган каршылыклы уйларына, тойгыларына баш була алмыйча, куркыныч язмыш алдында — күзгә күренмәгән, ләкин әледән-әле үзен сиздереп торган яшерен көчләр алдында ихтыярсыз сыгылып төште.

## XVI

Урдага ул бик төшенке күңел белән кайтты. Аның ниндидер кайгысы барлыгын өйдәгеләр барысы да күреп алдылар, тынып калдылар һәм, йорт башының күзенә күренүдән куркып, су сипкәндәй кайдыр юкка чыктылар.

— Бүзбала кая? — дип кычкырды каган, түргә узып.

— Бүзбала! Бүзбала! — дип пышылдадылар анда-монда өйдәгеләр, карачыны эзләп.

Бүзбала ниндидер эш белән Атсыз күл аръягына, көтүчеләр янына киткән иде. Аны тиз генә алып кайтырга дип йомышчыны җибәрделәр. Йомышчы Бүзбаланы тиз арада эзләп тапты һәм серле пышылдап: «Атабыз ачулы!» диде. Бүзбала барысын да аңлап алды. Урдага кайткач ул каган янына үзеннән алда Табылдыкны кертеп җибәрде.

Каган янында үзенең нинди зур көчкә ия булуын белгән яшь, сылу кырнак, көлеп-елмаеп, тәхет янына кыю гына килде:

— Син арыгансың, хуҗам! Сине чишендермәгәннәр дә! — дип сөйләнде ул, кайгылы-ачулы ир кешенең өстен-башын чишендермәкче булып.

Каган аның сүзләрен, әйтерсең, ишетмәде дә — кыз килеп кергәндә ничек утырган булса, ул килеп үзенә орынгач та шул килеш кымшанмыйча утыруында булды.

— Абау, синең түшең качкан! — диде Табылдык куркып.

Ул йомшак кайнар кулы белән ир кешенең тез өстендә яткан җансыз кулын сыйпады, шаяртып, кытыклап, аның салынып төшкән мыек чылгыйларына кагылгалап алды. Ләкин яшь, сөекле кырнагы күпме генә тырышмасын, таш кыядай калкып утырган куркыныч ирнең таштай йөзе барыбер ачылмады. Яшь кыз курка калды, хуҗасының тезләренә утырды да, ике куллап аның юан муеныннан кочып, тирәнгә яшеренгән төпсез күзләренә карады. Кирәк чакта утлы очкыннар чәчрәтеп яна торган, кирәк чакта җылы нур таратып елмая торган тере күзләрдә Табылдык тетрәндергеч моң-сагыш һәм кайгы күрде.

— Чирләдеңме әллә, хуҗам? — диде яшь кыз, чын-чынлап куркуга төшеп.

— Юк,— диде каган авыр гына.

— Алайса ни булды?

— Берни булмады.

— Син мине яратмый башладың! — диде Табылдык һәм үпкәләп еларга да керешеп китте.

Каганның нindидер гүзәл чин кызы турында уйлап кайгыруы турында ул инде белеп өлгергән иде. Хәзер дә каган, күрәсең, шул кыз өчен бетеренәдер, дип уйлады һәм аның яшь күңелен көнчелек ялкыны өтеп алды. Аның кайнар яшьләре таш кыяның таш йөрәген урыныннан кузгатты. Авыр кулын көчкә күтәреп, ул сирәк була торган бер ярату белән, иркәләү һәм саклык белән кызны күкрәгенә кысты.

— Мин сине генә яратам... беләсең ич,— диде ул сүзләрен бик авырлык белән сайлап.

Яшь кызга шуннан артыгы кирәкми дә иде — ул шундук елмаеп куйды, битеннән агып төшкән күз яшьләрен теле белән ялый-ялый йомшак чәчләре, кайнар яңаклары белән кырыс ирнең киң күкрәгенә сыенды.

Бик нык ашыккан булып шул чагында өйгә Бүзбала килеп керде. Ярыктан ул барысын да күзәтеп торган иде. Сөекле кырнагын иркәләп утырган каганны ул инде тынычланды дип уйлады һәм, түргә үк килеп җитмичә тезләнеп баш иде дә, тамак кырып:

— Мин монда, бөек каган,— диде.

Каган аны күрде, ишетте, шулай да, Бүзбала көткәнчә, Табылдыкны тез өстеннән төшерергә ашыкмады. Карачыга бу бик сәер тоелды — каганның әле беркайчан да тезенә гүзәл кызлар утырткан килеш үзенең карачысы белән сөйләшкәне юк иде. Яшь кырнак та, ике ир янында үзенең артык икәнлеген аңлап, аягына басмакчы булды. Каган аны ычкындырмады.

— Мин монда! — диде Бүзбала кабатлап.

— Күрәм,— диде каган тонык кына.— Бире кил, Бүзбала.

Бүзбала якынрак килде.

— Мин үтереп алып кайткан теге юлбарыс тиресен анам Кортка-бикәгә илтеп бирсеннәр,— диде каган, каядыр читкә карап.
— Ник? — диде Бүзбала гаҗәпләнеп.
Үзе кадап алган юлбарыс тиресе каганның иң зур куанычы иде.
— Кара-тау иясе булган ул.
— Ярар. Илтеп бирерләр.
— Аннан соң...— диде каган көчәнеп,— менә... Табылдык кырнакны да... Ана-камга... Кортка-бикәгә...
— Аһ! — диде Табылдык сискәнеп, күзләрен зур ачып.
Йомшак, кайнар билдән кысып тоткан тимер куллар да, таштай каты муеннан кочып алган яшь куллар да — дүртесе дә берьюлы бушап калды. Беркем беркемне тотмады, тоткарламады. Яшь кыз, кылыч белән чабылган дошман башы сыман, балта белән чабылган агач сыман, сынсыз калып идәнгә шуышып төште.
Каган да, Бүзбала да, бер-берсенә күзләрен күтәреп карарга кыймыйча, ачуланышкан кешеләр кебек, икесе ике якка төбәлеп тик тордылар. Яшь кыз кинәт исенә килде, сикереп урыныннан торды һәм алтын тәхетендә кымшанмыйча утырган ир кешенең алдына килеп капланды.
— Кызган мине, хуҗам! Ана-кам мине абаларга бирәчәк, ул мине утлы табада кыздырачак, ул мине тереләй җиргә күмәчәк! — диде ул такмаклап, өзгәләнеп.— Бөек хуҗам, коткар мине. Яратмасаң ярат-ма — мин тамчы да көнләшмим. Гүзәл чин кызының ялчысы булырмын, көн дә аның аягын юармын — яныңнан гына җибәрмә!
Туман каган Бүзбалага ым какты. Бүзбала, шуны гына көтеп торган кебек, тиз арада урыныннан купты, яшь, сылу кырнакны ике куллап күтәреп алды да каядыр китеп тә барды.
— Кызганыгыз, кызганыгыз! Бирмәгез Ана-камга, бирмәгез! — дип кычкырды Табылдык, Бүзбаланың каты кулларыннан ычкынмакчы булып.

## XVII

Биек Ак өйдә мәет чыккандагы кебек күңелсез булып калды. Бу күңелсезлек кичке аш вакытында да сакланды. Башка көннәрдә үзе белән бер табактан ашаган туган-тумачаларын, якын ирләрен каган аерым сыйларга кушты. Үзе ул бушап, котсызланып калган өендә ашады. Аның янында бары өч кенә кеше бар иде: аларның берсе Бүзбала булса, икенчесе Туңгак алып, өченчесе Исәнтәй.
Ашаганда-эчкәндә каган «табын яме» өчен гадәттә берәр яшь кырнагын алып утыра иде. Соңгы бер ел буена диярлек аның «табын яме» Табылдык булды. Бүген кич ул күренмәде. Аш-суны да элеккечә кызлар түгел, олы яшьтәге хатыннар кертте. Бүзбала белән Туңгак алып моның серен белсәләр дә, Исәнтәй әле берни белми иде. Табылдыкның юклыгын ул үзенчә юрады. Күрәсең, каган аны, мин әйткәнчә, чин кызына алыштырып җибәргәндер, дип уйлады ул. Тик менә каганның күңелсез булуы гына бик үк аңлашылып җитми иде. Шулай да ул түзмәде, беренче булып шул хакта сүз башлады.
— Нишләп бүген гүзәл Табылдык күренми? — дип куйды ул үзалдына сөйләнеп.
Бүзбала белән Туңгак алып икесе берьюлы диярлек әрсез, әдәпсез тылмачка күтәрелеп карадылар. Туман каган, тамагына сөяк утыргандай, ашавыннан туктап калды, ләкин Исәнтәйгә берниндн шелтә белдермәде. Шулай ук ул аңа берниндн җавап та кайтармады.
Бары тик ашап туйгач кына ул Исәнтәйгә... өтеләнгән бер тылмачка үзенең кайгыларын сөйләп бирде. Бүзбала белән Туңгак алып каган-

ның Исәнтәйгә сөйләгән сүзләрен яратмыйча тын гына тыңлап утырдылар. Исәнтәйнең тәхет тирәсенә якынайганнан-якыная баруы аларның ачуын китерде.

— Менә шулай, син әйткәнчә барып чыкмады, Исәнтәй,— диде каган.— Табылдыктан да колак кактым, чин кызын да ала алмадым. Җитмәсә, менә тагын бу төш... яшь бога... курчак... Берсе өстенә икенчесе өстәлеп кенә тора!

Бүзбала белән Туңгак алыпны бөтенләй күрмәгәндәй, каган туры Исәнтәйгә карап сөйләде. Мондый катлаулы, четрекле мәсьәләдә аның Исәнтәйдән нинди дә булса төпле, акыллы сүз ишетергә теләве әллә каян күренеп тора иде. Бүген ул, бик сирәк очракларда гына булганча, чамадан тыш басынкы, юаш һәм аталарча ягымлы иде. Сабый бала кебек, ул ни әйтсәң дә каршы килмәс, нәрсә әйтсәң дә берсүзсез ышаныр төсле иде. Исәнтәйгә ул нәкъ шундый булып күренде дә. Үзенең көтмәгәндә югарыга үрли баруын аңлаудан кыюлыгы бермә-бер арткан Исәнтәй бу юлы да беренче булып яуга ташланды.

— Мин болай уйлыйм, бөек каган,— диде ул сораганны да көтмәстән сүз башлап.— Ана-кам изге абалар белән аралаша. Ул белеп әйтә. Курчак ясый торган ирләр монда бар. Таштугайда. Тучи бәк тәгин угланның курчагын ясатуны, күрсәтелгән урынга күмүне мин үзем эшлим. Ана-кам белеп әйтә: син үзең аңа бармак белән дә чиртмәссең. Синнән боерык булса, тәңре катына да... мин үзем озатырмын, бөек каган!

Туңгак алып түзмәде, ярсып башын калкытты һәм оятсыз тылмачка карата чиксез бер нәфрәт белән:

— Исәнтәйнең кулы да озын, теле дә озын, ахрысы,— диде.— Синнән боерык булса, бөек каган, мин аның телен дә, кулын да кыскартыр идем!

Исәнтәй, йөзенә китереп суккандай, кызарынып китте. Ярдәм сораган сыман, ул каган ягынарак күченеп утырды.

— Киңәшеңне әйт, Туңгак алып,— диде каган ызгышучы ике якның берсенә дә катышмыйча, юаш кына.

— Турысын әйтимме, сиңа яраклы итеп әйтимме, бөек каган? — диде Туңгак алып тынычлана алмыйча.

— Ни уйласаң, шуны әйт.

— Мин турысын әйтәм! — диде Туңгак алып.— Ана-камның: үзеңнән читтә тот, дигәнен Исәнтәй сиңа ялгыш аңлатмакчы була, бөек каган. Үзеңнән читтә тотуны Ана-кам тәңре катына озатырга кирәк дип түгел, урдадан читтә тотарга кирәк дип уйлап әйткән. Уң кул тучи бәк тәгин угланны үзеңнән читтә тоту ул — аны урдадан читкә сөрү дигән сүз. Дүрт мөгезнең[1] берсе — уң кул тучи бәк тәгин углан ул синең углың гына түгел, ул бөтен Сөн иленең углы, аның киләчәге, аның ышанычы. Бер языгы булмаган килеш, бары күңелсез төш күргәнең өчен генә, ялгыш киңәш бирүчеләр коткысына бирелеп, син аны тәңре катына озата алмыйсың, бөек каган!

— Киңәшеңне әйт,— диде каган бүлдереп.

---

[1] Дүрт мөгез — сөннәрдә иң атаклы бәкләр шулай «дүрт мөгез» дип аталган. «Дүрт мөгез»дән башка тагын «алты мөгез» дә булган. «Алты мөгез»ләр «дүрт мөгез»ләргә караганда түбәнрәк дәрәҗәдә исәпләнгәннәр. Терлек мөгезе (башлыча үгез мөгезе) борынгы төркиләрдә изге саналган һәм көч-куәт, хакимлек символы булган. Борынгы патшалар, фиргавеннәр, каганнар чын үгез мөгезе беркетелгән яисә ясалма мөгезе булган махсус баш киемнәре — бүрекләр, таҗлар кигәннәр. Татар телендә сакланып калган «мөгезле», «мөгезсез» сүзләре шул борынгы заман карашларын чагылдыра.

— Киңәшем шул: син аны өйләндереп, ил-көн, җир-су биреп, анасы белән бергә ил читенә җибәр. Ул шунда яшәр. Кирәк вакыты җиткәч, кире чакыртып алырсың.

— Син аңлатып сөйләдең,— диде каган Туңгак алыпка.— Минем үземнең дә аңа... яманлык эшлисем килми. Ана-камгә каршы килмәс өчен генә булса да мин аны... өлкән углымны читләштерергә тиешмен.

— Мин әйтеп бетермәдем, бөек каган! — диде Исәнтәй.

Ләкин Бүзбала шундук аңа каршы төште.

— Син, Исәнтәй, бөек каганга чин кызын кире алып бирергә сүз биргән идең түгелме соң? — диде ул күрәләтә мыскыл белән.

— Минем әле баш тартканым юк!— диде Исәнтәй аптырап тормыйча.

— Син баш тарта алмыйсың, Исәнтәй,— диде каган йомшак кына итеп.

Аның бу йомшаклыгында бу юлы боеру сизелде. Ул инде үзенең төп кайгысыннан — яман төш тәэсиреннән айныган һәм аны инде башка төрле кайгылар борчый башлаган иде бугай.

Исәнтәй каушап калды.

— Болай булгач... Табылдык булмагач...— диде ул нидер әйтергә җыенып.

— Сиңа — өч көн вакыт, Исәнтәй,— диде каган таләп итеп.

## XVIII

Каган яныннан Исәнтәй каравыл агасыннан калышыбрак чыкты. Текмәгә чаклы аңа теләсә дә, теләмәсә дә каравыл агасы белән янәшә атлап барырга туры килер иде. Аның хәзер аны күрәсе дә, ишетәсе дә килмәде. Юл буенча ул уйланып барды. Туңгак алып аңа иң куркыныч, иң көчле, хәтта каганның үзеннән дә көчлерәк һәм куркынычрак дошман булып тоелды. Шуңа күрә дә аның бөтен ачуы, бөтен нәфрәте каравыл агасына каршы юнәлде. Ул аны ничек тә баш аркылы чөяргә, аяк астына салып таптарга тиеш! Туктале, каганның күңелен генә күрсен әле, Ак өйдәге ак киездә аяк терәп утыра гына башласын әле, күрсәтер әле сиңа Исәнтәй күрмәгәнеңне! Җиңел генә баш чапмакчы була! Иң элек кемнең башын чабарлар — анысын әлегә әйтеп булмый. Туктале, тукта!..

Текмә капкасына җиткәнче ул шулай дөнья җимерердәй булып үз-алдына тузынып барды. Текмә тышында аны җигүле арбасы, хезмәтче ирләре көтеп тора иде. Ул үзенең түбәсе ябулы арбасына кереп утырды да, уртанчы бөҗра ягына кузгалып китте. Аның каган бүләк итеп биргән яңа өе шунда — Көнчыгыш капкага таба барганда сул якта иде.

Арбага кереп утыргач, ул төлке тунының биек якасын күтәреп куйды. Йомшак, җылы йонлы яка аның битен, колакларын иркәләде, шул ук вакытта туң җирдән тирбәлеп, җиңелчә шакылдап тәгәрәгән көпчәкләр тавышы аны тынычландыра төште. Ямьсез, күңелсез уйлар әкренләп онытыла барды.

Аның мәрхүм атасы да менә шулай якасын күтәреп ике көпчәкле арбага утырдыммы, тынычланып калам дип сөйләр иде. Җунго осталары эшләгән, җунгоча бизәлгән арбаның тынычландыра торган, юата торган ниндидер сихри көче бар бугай.

Гомере буена атасы аның үз туган иленә кайту турында, анда кайтып күңелле, бай, иркен тормыш башлап җибәрү турында хыялланды. Үзенең түбәт хатыныннан туган бердәнбер углына ул җае чыккан саен тегендә, күксел таулар артында торып калган туган җире турында сөйләде, үзенең бала чакларын, сөекле этисен, ягымлы әни-

сен исенә төшерде. Яшь Хуа ап-ак чәчәккә күмелеп утырган чия бакчаларын, күлдә яшел таллар арасында суга чумып уйнаган үрдәкләрне, җиңел күлмәк кигән, күбәләктәй җиңел, алсу таңдай гүзәл Җунго кызларын төшләрендә күрде. Әтисенең туган җире аның аңына мәңге җәй, мәңге кояш, яшеллек һәм тынычлык хакимлек иткән сихри ил булып сеңеп калды. Инде зур үсеп, яшьлек хыяллары челпәрәмә килә башлагач та ул әлеге сихри-гүзәл күренешләргә чын күңелдән табынып яшәде. Ак чәчәккә күмелеп утырган бакчалар артында, кояш яктысын чагылдырган тирән күл уртасында, түгәрәк утрау эчендә еш кына аның күңел күзенә алтын түбәле ак сарайлар күренде. Хәзер инде ул чия куаклары арасындагы күбәләктәй кызлар турында түгел, әнә шул алтын түбәле ак сарайлар турында хыялланды.

Теге яктан качып чыккан каралар, коллар, юлбасарлар аңа Күк асты илендәге коточкыч хәлләр турында сөйләделәр. Ләкин ул коточкыч нәрсәләр: ачлык, үлем, җәбер-золым, туктаусыз яулар-сугышлар — берсе дә аңа ныклап торып тәэсир итмәде. Андый сүзләргә ул чынында ышанмады да, ышанырга туры килгән очракта да, аларны үзенчә аңлады. «Анда ничек — мондагыдан җылыракмы, чияләр чәчәк атамы, күл уртасындагы алтын түбәле ван сарайлары исәнме?» — дип сорады ул коточкыч хәбәр сөйләүчеләрдән. «Җылы! Чияләр чәчәк ата. Алтын түбәле сарайлар да бар. Күп, бик күп алар. Тик алар барысы да биек коймалар белән әйләндереп алынган»,— дип җавап бирделәр аңа. «Сарайлар исән булгач, Җунго да исән»,— дип уйлады Исәнтәй-Банхуа, үз күңелен үзе тынычландырып.

Күксел таулар артындагы җылы, серле илдә аның күңел күзенә алтын сарайлардан, ак чәчәккә күмелеп утырган бакчалардан башка нәрсә күренмәсә дә, шулай да ул андагы барлык яңалыкны, барлык үзгәрешне биш бармагы кебек белеп торды. Күпчелек хәбәрне аңа качаклар алып килде. Ләкин аңа шулай ук качаклар белмәгән, белә алмаган хәбәрләр дә килеп җитте. Чжао аксөякләре каганга бүләк итеп җибәрәчәк кыз белән ышанычлы ирнең киләчәген ул моннан өч ай элек белгән иде инде.

Әйе, белгән иде. Тик ул гүзәл чин кызы белән әлеге ышанычлы ир килеп төшкәч ниләр буласын гына белә алмаган иде. Тегендәгеләр алдан уйлаганча, каган урдасына Банхуа түгел, Чәнси үтеп керергә тиеш иде. Банхуа аңа кулыннан килгәнчә булышырга гына тиеш. Эшләр әнә бөтенләй киресенчә килеп чыкты. Төптән уйлап караганда, урдага үтеп керүнең, бөҗра эчендә киез өйдә яшәүнең аңа бөтенләй кирәге юк иде. Тегендә, таулар арасында, ни әйтсәң дә, тынычрак. Чияләр чәчәк атып утырган бакчаларың, түгәрәк күл уртасында алтын сарайларың булмаса да яхшырак иде анда! Дөрес, каган аның андагы энәсенә дә тимәде. Анда бар нәрсәгә баш булып өлкән углы калды. Аннан соң гүзәл чин кызының «абыйсы»... Чәнси анда.

Шулай итеп, «ышанычлы» Чәнси каган өенә түгел, Банхуа өенә үтеп керде. Исәнтәй моңа сөенергә дә, сөенмәскә дә белмәде. Шулай ук Чәнси үзе дә мондый хәлгә әллә ни куаныч белдермәде. Бөтен нәрсәдә гаепне ул бары аннан — Банхуадан күрде һәм, үзенең кайдалыгын, кемлеген онытып, аңа инде янап алырга да өлгерде. Исәнтәй аның янавына көлеп кенә куйды. Теләсә ул аны җиңел генә юкка да чыгара алган булыр иде. Ләкин аның артында күзгә күренмәгән көч, байлык барлыгын һәм андагылар — көч, байлык ияләре белән исәпләшергә кирәклеген белгәнгә күрә ул тешен кысып түзәргә булды. Ул мондагыларга да, андагыларга да ярарга тиеш иде. Анда аның яман аты чыкса, иң элек качаклар аннан читләшә башлаячаклар, аннары аңа инде беркем дә бушлай ефәк, дөге, корал һәм гүзәл кызлар озатып тормаячак.

Менә шуңа күрә дә ул «кара йөз»нең үз өенә үтеп керүенә, аның янауларына бармак аша карарга, ничек тә аның белән ныклап торып бозылышмаска булды. Ләкин шулай да чын-чынлап бозылышмас өчен, иң элек бозылган, чуалган эшне төзәтергә кирәк иде. Туңгак алып турында онытып, ул әлегә шул турыда уйлый башлады.

## XIX

Икенче көнне Исәнтәй дүрт тәгәрмәчле чуман арбага дөяләр җигәргә кушты. Монда киез өйдә булган барлык байлыгын диярлек ул арбага төятте, арбаның өстен чыбылдык белән яптырды. Шуннан соң ул үзенең ике тәгәрмәчле яхшы арбасына утырды да, Кортка-бикә авылына карап юлга чыкты.

Элеп киптергәндәй корышып беткән, тешсез, холыксыз, тиле-миле Кортка-бикәне Исәнтәй җаны-тәне белән яратмады. Аның җыерчыклы йөзен күрү белән, аның күңелендә даладан, даладагы барлык үләнтередән җирәнү тойгысы уянды. Ләкин, шулай булса да, барлык сөннәр арасында менә шул корышып беткән кортка аның өчен иң кирәкле кеше иде. Каганның, бәкләрнең сылурак, яшьрәк бичәләреннән, хатыннарыннан ул Кортка-бикәне артыграк күрде һәм аның ямалып беткән, аксак-туксак белән тулы өендә ешрак булды. Ни өчен дигәндә, урдадагы, илдәге бик күпләрнең язмышы менә шул тишек-тошык кара өйгә, тиле-миле карчыкка килеп тоташа. Күпчелек каралар тәңредән, явыз иядәрдән килә дип уйлаган төрле үзгәрешләр дә кайчагында менә шул көч-куәт иясе Ана-камнан башлана иде. Сөн ияләренә, сөн йолаларына ныклап ышанмаган, җунго ияләрен, җунго йолаларын ныклап белмәгән һәм шуңа күрә күктәге аллалар көченнән бигрәк үз көченә, үз акылына ышанган динсез Банхуа-Исәнтәй йола һәм язмыш мәсьәләсендәге күп нәрсәләрнең серен күптән инде аңлап өлгергән иде.

Шулай да ул, сөн диненә ышанмаса да, барлык йолаларны бик тырышып үтәде. Төрле җыеннар, йола туйлары алдыннан ул үзенең ата-бабасына атап Кортка-бикәгә хәер китерде. Аннан ул бик теләп борынгы сөн гадәтләрен, йолаларын белеште, күрәзәчелек, багу, төш юрау серләренә төшенергә тырышты. Менә шулай чөке-чөке килеп сөйләнгәләгән арада ул Кортка-бикә авызыннан күп кенә яңа хәбәрләр һәм урдага, каганга, бәкләргә кагылышлы серләр дә ишеткәләде. Менә шундый файдалы дуслыкны югалтмау өчен ул бернидән дә кызганмады.

Бу юлы да ул бүләккә дип ефәкнең Кортка-бикә яраткан төсләрен генә алды. Ефәккә өстәп дөге, киндер тукыма, аю тиресе, яхшы итеп эшкәртелгән, алтынлап төрле сурәтләр төшерелгән болан мөгезе алды. Ләкин иң кирәге ефәк тә, дөге дә, болан мөгезе дә түгел иде. Кортка-бикә өчен иң кирәге — чин качаклары кайнаткан куәтле буза иде.

Кортка-бикәнең аксак-туксак ирләре Исәнтәйне каганны каршылаганнан ким каршыламадылар. Аның таныш арбасы күренү белән, ерактан ук аңа каршы йөгереп килделәр. Өйләр янына барып житкәнче алар аның аты, дөяләре, арбалары яныннан титаклап бардылар. Өйләр янына килеп җиткәч аңа арбадан төшәргә булыштылар.

Ана-камның үзәктәге өенә Исәнтәй җәяүләп китте. Дөяләргә җигелгән, бүләкләр төялгән авыр арбаны аксак-туксак ирләр әкрен генә арттан алып килделәр. Биек өй янында тышкы ишек сакчысы Исәнтәйгә бераз көтеп торырга кушты. Кайчан гына, ничек кенә килмәсен, Кортка-бикә аны шулай бераз көттермичә кертми иде. Исәнтәй үзен чакырганны башын түбән иеп, тыйнак кына, буйсынучан гына көтеп торды.

Ниһаять, аңа керергә куштылар. Бусагадан атлау белән, Кортка-бикәнең ятак өстендәге таныш йөзен күрү белән, Исәнтәй тезләнде, баш орды һәм мүкәләп диярлек түргә якынлашты.

— Изге анам! Атама, анама багышлап мин сиңа хәер алып килдем. Барлыгы бер чуман әйбер: ефәк, дөге, тире, мөгез... Алырсыңмы шуларны? — диде ул, Ана-камга күтәрелеп карарга кыймыйча.

— Тагын ниләрең бар? — диде Кортка-бикә, бүләкләргә исе китмичә.

— Барысы да бар, изге анам,— диде Исәнтәй серле итеп.

— Алырмын, кертсеннәр.

Исәнтәй ялт кына артына борылды. Ишек сакчысы кортка, аның күз карашын аңлап, шундук тышкы якка башын тыкты, кемгәдер нидер әйтте һәм шул ук мәлдә диярлек ике таза ир — Исәнтәйнең ирләре хәергә китерелгән әйберләрне өйгә ташый башладылар. Аларга ишек төбеннән ары узарга ярамый иде. Авыр-авыр төргәкләрне, капчыкларны түргә чаклы Исәнтәй үзе ташыды. Барысын да ул учак янындагы, уртадагы ак киезгә өеп куйды да, яңадан артка, элекке урынына барып тезләнде.

Кортка-бикә, биек ятагыннан төшеп, төргәкләрне, капчыкларны берәм-берәм тоткалап карады.

— Хәерне күп китергәнсең, Исәнтәй! Баегансың ахрысы,— диде ул кеткелдәп.

Мондый мактау сүзләреннән Исәнтәйнең түбәсе күккә тиде. Гадәтенчә ул елмаеп алды һәм, үз-үзен белешмәстән, түргә таба омтылыш ясады.

— Изге анам! Баедым — бөек каган мине үз янына алды,— диде ул чиксез сөенеп.— Куанычым зур булганга, саранланып тормадым — кичер мине, изге анам!

— Синең урдага күченеп килүеңне беләм.

— Нинди теләкләрең бар — кулдан килгәннең барысын да үтәрмен, изге анам,— диде Исәнтәй ялагайланып.

— Ачы суыңны авыз итеп карыйсым килә... синең белән бергә,— диде карчык бөтенләй үз итеп, якын итеп.

Исәнтәйгә ул, буза салынган сабаны[1] алып, үзе янынарак күченеп утырырга кушты. Шуннан соң ул өстәл чыгарырга боерды. Исәнтәй әчемлек белән булашкан арада, теге яктан кемдер тавыш-тынсыз гына чыгып, карчыкның биек ятагы янына, буш урынга түгәрәк өстәл китереп куйды. Исәнтәй башын күтәреп караган иде, каршысында мәет кебек агарынган, ябыккан таныш сыман йөзне күреп гаҗәпкә калды. Таныш йөзле кыз да аны таныды һәм, оялыпмы, куркыпмы, йөзен шундук читкә борды.

Исәнтәй бөкесе ачылган буза тулы сабаны карчык янына куйды.

— Үзең агыз,— диде Кортка-бикә, алтынланган баш сөяген саба авызына якын тотып.

Исәнтәй агызды, авыр сабаны җайлап киез өстенә утыртып куйды. Ирексездән ул тагын теге кыз ягына борылып карады. Кыз урынында юк иде.

— Теге чин кызы да аның кебек сылумы? — диде Кортка-бикә көлемсерәп, киез ягына ымлап.

«Белеп тә өлгергән!» — дип уйлап алды Исәнтәй.

— Алай ук сылу димәс идем мин аны, изге анам,— диде ул бераз көттереп.

— Миңа аны бик чибәр диделәр.

Аның тавышында күрәләтә борчылу, пошыну сизелде. Яшь, сылу кызлар турында ул беркайчан да тыныч кына тыңлый алмый иде. Үз

[1] Саба — сыекча саклау өчен кулланылган күн капчык. Бурдакның бер төре.

углы каганның чибәр кырнакларына исә ул аеруча сагаеп, шикләнеп карый иде. Борын-борыннан килгән йола һәм ышану буенча, илдә балалар күп булсын-өчен, терлек-туар туктаусыз үрчесен һәм ишәйсен өчен Сөн иленең каганы бар яктан да көч-куәткә ия булырга тиеш иде. Аеруча аның ирлек куәте булырга тиеш. Каган ул күктәге тәңренең җирдәге углы иде һәм ирлек куәте дә, башка төр көч-куәт тә аңа күктән, тәңредән иңдерелә иде. Каганның балалары күп булса, терлекләре үрчесә, аңа буйсынган ыруларның да — шулай булгач, бөтен Сөн иленең балалары күп булачак, терлек-туарлар ишле булачак иде. Ләкин бөтен илдә тигезлек, муллык булсын өчен, каган үзенең бичәләренә, кырнакларына тигез күз белән карарга тиеш. Ни өчен дигәндә, аның аксөяк ырулардан алынган бичәләре аша, кара сөяклардән алынган кырнаклары аша бөтен илгә-көнгә изге көч тарала иде. Әгәр дә мәгәр ул бер хатынын ныграк яратып, башкаларын читкә тибәрсә, бер ыруга яхшылык, изгелек күбрәк төшәчәк, икенче ыру андый изгелектән мәхрүм калачак. Ил башы каганның алай эшләргә хакы юк.

Менә шуңа күрә дә Ана-кам Тәңре углы каганның көн саен кем белән кунуын белеп тора. Каган өендә аның беркем белми-сизми торган үз шымчылары — яшерен күзләре-колаклары бар иде.

Ләкин эш монда борынгы йолада гына да түгел. Йолага, дин кануннарына монда холыксыз карчыкның үз карашлары, үз теләкләре дә катышкан һәм бергә аралашып, ныклы бер кагыйдәгә әверелгән иде. Яшь, чибәр кырнакларны ул җаны-тәне белән яратмый. Кулыннан килсә ул барлык яшь, сылу кызларны үзе кебек корыган агачка әйләндереп бетерер иде. Шуңа күрә дә ул каганның иң яраткан кырнакларын, төрле сәбәп табып, үзенә чүпләп тора килде. Үзенә алгач ул аларны изге абаларга корбан итеп бирә.

Исәнтәй алып килгән эчемлекне авыз итеп карар алдыннан Ана-кам берничә тамчыны учакта йокымсырап яткан Ут-анага бирде, аннан соң, чак-чак кына чыраен сытып, алтын савытны авызына якын китерде. Исәнтәйгә ул яртылаш тулы савытны бирде. Исәнтәй дә бузаны бөтен йоласына туры китереп, башта Ут-ананы сыйлап ашыкмыйча гына эчте. Ул эчкән арада Ана-кам, күзләрен ярым йомган хәлдә, аяк-кулларына рәхәт җиңеллек таралганын көтеп утырды. Исәнтәй дә эчкәч, берни әйтмичә, шулай ук аның кебек күзләрен ярым йомып, үзендә изге җиңеллек барлыкка килүен көтә башлады.

Шулай озак кына көтеп утыргач, авыр тәненең җиңеләя башлавын тоеп, Исәнтәй:

— Изге анам, минем сиңа сүзем бар,— диде.

— Әйт, Исәнтәй,— диде Ана-кам ярым йомык күзләрен ачып карамыйча гына.

— Син үзеңнең өлкән колыңа олы бәтиенең дүрт курчагын ясап, дүрт җиргә күмәргә кушкансың. Моны ничек аңларга, изге анам?

— Мин аны колыма әйттем. Ул үзе ничек аңласа, шулай эшләр, Исәнтәй.

— Минем тагын бер үтенечем бар, изге анам,— диде Исәнтәй, карчыкка табарак елышып.

— Әйт, Исәнтәй,— диде Ана-кам.

— Әле генә монда булган карабашыңны миңа сатмассыңмы, изге анам?

Карчык кинәт башын калкытты һәм үз каршысында эт кояшыдай балкып, майдай эреп утырган ир кешегә усал, ямьсез итеп карап тора башлады.

— Син... Исәнтәй! — диде ул зәһәр ысылдап.— Изге абаларга

корбан буласы беркемнең дә бу өйдән кире чыкмаганлыгын белмисеңме әллә?!

— Беләм,— диде Исәнтәй пышылдап.— Аның урынына мин сиңа икене... өчне бирермен. Өстәп тагын бүләкләр китерермен, изге анам!

— Күзең төштемени? — диде Ана-кам уйланып утыргандай иткәч.— Килеп йөрерсең, шунда бүләкләреңне дә алып килерсең.

Исәнтәйнең балкыган йөзе сүрелеп калды.

— Турысын әйтим микәнни соң? — диде ул үз-үзе белән киңәшләшкән сыман.

— Миннән сереңне яшерүнең кирәге юк.

— Синең колыныңның аны бик яратты,— диде Исәнтәй әкрен генә, сүзләрен чамалап кына.— Аннан аерылгач ул кайгыга сабышты. Кайгыдан саулыгына, куәтенә көч килсә, яман булмагае. Менә ни өчен борчылам мин, изге анам!

— Чин кызын яратмый башлаганмыни минем колыным?

— Чин кызы аныкы имәс, изге анам,— диде Исәнтәй кыюсыз гына.

Ана-кам башын югары күтәрде һәм, Исәнтәйгә салкын, өшеткеч бер караш ташлады да, үтергеч итеп:

— Син, Исәнтәй, мине алдамакчы булып утырасың!— диде.— Мин барысын да беләм — синең кайда нинди сүз әйткәнеңне дә, менә монда нәрсә уйлаганыңны да! Ак өйгә кердем дә, ак киезгә утырдым да, әллә кем булдым дисеңме?! Минем колыныма киңәшләр бирә башладыңмы? Аңа киңәш бирер алдыннан иң элек син минем белән киңәшергә тиеш идең, Исәнтәй!

— Гаеп миндә, изге анам!— диде Исәнтәй ашыгып.— Моннан соң синең белән киңәшмичә берни эшләмәм.

— Синең, Исәнтәй, ак өйнең ак киезендә утырырга бернинди хакың юк,— диде карчык усал итеп.— Ак киездә утырырга хакың булмагач, киңәш бирергә дә хакың юк! Моннан соң синең бер генә киңәшең дә үтәлмәячәк, Исәнтәй!

— Кичер, изге анам!— диде тәмам каушап калган Исәнтәй.

— Мин барысын да белеп, ишетеп тордым, шуңа күрә аның баласы булмаган яшь кырнагын үз яныма алдырдым да,— диде карчык кызганнан-кыза барып.— Төшендеңме инде? Хәзер син шуны миннән кире алып, колынымның күңелен күрмәкче буласыңмы? Юк, сиңа ничек тә Ак өйнең ак киезендә, түрендә утырып калу кирәк!

— Мин аның боерыгын үтәргә тиешмен, изге анам,— диде Исәнтәй, маңгаендагы салкын тирләрен сөртеп.

— Син, Исәнтәй, аның боерыкларын түгел, минем боерыкларны үтәсәң генә теләкләреңә ирешерсең.

Исәнтәй, ниһаять, аңлап алды: бөтен куркуы, каушавы табан астыннан чыгып каядыр җиргә коелды. Ул үзенең ачышына ышанырга да, ышанмаска да белмәгән сыман, авызын ачып, сокланып, исе китеп корышкан карчыкка карап утырды. Юк, тиле-миле түгел бу карчык, башлы бу, усал бу карчык!

— Мин аңладым, изге анам,— диде Исәнтәй.— Моннан соң синең киңәштән башка бер адым да атламам. Изгелегеңнән ташлама мине!

— Мин сине ташламам!

Беравык алар тагын нидер көткән сыман тып-тын калып утырдылар.

— Чин кызы гүзәлме, Исәнтәй?— диде кинәт Кортка-бикә.

— Гүзәл, искиткеч гүзәл, изге анам!

— Син теләгәнчә булыр, Исәнтәй,— диде карчык, ниһаять, килешеп, ярым йомык күзләрен күтәреп карамыйча гына.

— Изге анам!— диде Исәнтәй ихлас бер омтылыш белән, карчыкның корышкан кулларын учына алып.

— Мин аны... син сораган кырнакны болай гына бирермен сиңа,— диде Ана-кам бөтенләй йомшап.— Тик кара аны, бәтиемнән тартып

алыначак гүзәл чин кызын сорап миңа киләсе булма! Мин аны сиңа да, башка беркемгә дә бирмәячәкмен. Ул минеке булачак, минеке!

«Синеке булырмы ул, башканыкымы — анысын әлегә әйтеп булмый. Хәзергә мин уйлаганча барып чыкса, миңа шул җиткән»,— дип уйлады Исәнтәй үзалдына. Ләкин шундук куркып карчыкның йөзенә игътибар белән карап алды — сизмәде микән аның нәрсә уйлаганын? Сизсә, харап эшләр!



**Өченче баб**

## I

Өлкән бичә Күрекле бикәнең авылы урдадан төньяк-көнчыгыш якта, комлы калкулыклар арасында ялтырап яткан Тозлы күл буена урнашкан иде. Күлнең исеме генә Тозлы, чынында исә ул тозлы түгел иде. Моннан бик күп еллар элек Сөн баба күлнең суын беренче булып эчеп караган да, имеш, су аңа әчкелтем тоелган. «Тозлы күл ич бу!» дигән Сөн баба, төкеренеп. Шуннан, имеш, күлне дә Тозлы дип атаганнар. Ни өчен дигәндә, кояш чыгышы ягына карап барган саен әледән-әле анда вак тозлы күлләр очрый.

Бу якларның күлләрен, чишмәләрен дә, халыкта сөйләнелгән төрле имеш-мимешләрне дә Туңгак алып бик яхшы белә. Аның Аркача суының җир астыннан, кара ташлар арасыннан ургылып чыкканын да, ташлар арасыннан шаулап, сикереп акканын да күп мәртәбәләр күргәне бар. Кайсы елда кемнең бу якларда нинди киек атып алганлыгын, кем белән кем ызгышканын яисә татулашканын — ул барысын да, барысын да хәтерли ала. Хәтерләми мөмкин түгел — тормышы аның шушында, шушы җирдә үтә. Аның гына түгел, суның да, талларның-камышларның да тормышы аның күз алдында — кеше күзе алдында үтә бара.

Аркача суы тегендә җир астыннан бәреп чыга да, тоттырмас шук бала кебек, таулар-урманнар арасыннан чабарга тотына. Пөгерә-йөгерә ул иксез-чиксез иркенлеккә килеп чыга. Камышлы күл, сазлык аша үтеп киткәч, бер-ике төштә аңа кечерәк инешләр килеп кушыла. Шуннан соң ул киңәеп, ишәеп китә, көч җыя һәм, ярларына сыя алмагандай шаулап, һаман каядыр шуышуын белә. Кая бара, кая шуыша ул шулай? Кая булсын, билгеле, Тозлы күлгә!

Күлгә җитәрәк ул салмакланып, тыйнакланып кала. Тегендә, урта агымында ул яшь ирләрне хәтерләтсә, монда инде олы яшьтәге ирләргә охшап кала, аннары картая бара һәм күлгә кушылып юкка да чыга. Нинди кыска гомерле ул шулай да! Күп булса ул өч-дүрт көн яшәп кала. Ләкин аның бу өч-дүрт көнлек гомере туктаусыз алышынып, кабатланып тора, шуңа да ул мәңге хәрәкәттә, мәңге яшь булып тоела.

Камышлар, таллар менә озаграк гомерле. Алар беркая ашыкмыйлар, ашыга алмыйлар. Алар Җир-ана кендегенә береккәннәр.

Кеше кемгә ныграк охшаган соң — сугамы, талларгамы, камышлларгамы? Кеше дә, Аркача су кебек, туып аягына басу белән, каядыр омтыла, нидер эшләмәкче була, нидер җимермәкче була. Иң ахырда сине я сугышта сөңге белән кадыйлар, я булмаса сиңа агулы ук тия. Үлгәч далада сине я ач бүреләр ашап китә, я тилгәннәр чукый. Көз көне саргаеп яфрагын койган таллар, камышлар кебек, күлгә килеп кушылган елгалар-инешләр кебек, син яңадан Җиргә кайтасың.

Ләкин барлык кеше дә шулаймы соң? Берәүләр тумыштан ук биек ак өйләрдә яши, алтын савытлардан ашап, затлы киемнәр кия. Икенче берәүләр тумыштан ук кол булып, кара булып туалар. Тумыштан ук биек ак өйләрдә яшәүчеләр башкалар арасында Кылыч-кыя кебек кал-

кып утыралар, бер ярыннан икенче яры күренмәгән Тозлы күл кебек, Диңгез-күл кебек, бөтен җирне иңләп-биләп яталар. Тумыштан ук кол булып, кара булып туган кешеләр, Кылыч-кыя итәгендә аунап яткан ташлар кебек, күлгә кушылып юкка чыккан инешләр, елгалар кебек, гомергә күренексез һәм кечкенә булып кала бирәләр.

Ул үзе — Туңгак алып — нәкъ менә шундый хәлдә түгелмени? Аның барлык көче, барлык күңел дәрте, йокысыз төннәре төпсез күлгә — биек Ак өйдәге аксөякләр бүксәсенә төшеп, мәңге юкка чыга түгелмени? Бик теләсә дә инде ул беркайчан да кыя булып калка алмаячак, бөтен җирне биләп яткан мәгърур күл дә була алмаячак.

Атын җиңелчә юрттырып ул көне буена барды да барды. Әле тигез җирдән теркелдәде, әле сөзәк калкулык өстенә килеп менде, әле көтмәгәндә киң үзәнгә килеп чыкты. Уңда-сулда көтүләр, ялгыз өйләр күренгәләп калды. Менә шулай далада, иркендә үзе генә калгач аның күңеленә төрле уйлар килде. Еш кына ул үзенең күңелсез, авыр үткән яшьлеген исенә төшерде. Мондый чакта ул үз-үзенә бик кызганыч булып тоелды. Шул чагында аның күңелендә моңарчы кайдадыр яшеренеп яткан горурлык тойгылары баш калкытты. Ул үзенең бөтен Сөн илендә атаклы алып булуын, каганның уң кулы, ышанычлы сакчысы булуын беркайчан да исеннән чыгармады, ләкин шул ук вакытта ул үзенең һаман да барыбер кол булып калуын да оныта алмады.

Әйе, кол булмаса, хәтәр юлга менә шулай җиңел генә чыгар идеме соң ул? Юк, күрәсең, чыкмас иде. Хәер, бу эшкә турыдан-туры Исәнтәйнең катнашы булмаса, бу хәтәр юлга ул сөенеп чыккан булыр иде. Бары каган боерыгын үтим дип уйласа, аның моңа алай ук эче дә пошмас иде, күрәсең. Бу эшнең Исәнтәй киңәше белән, Исәнтәй тырышлыгы белән эшләнгәнлеген белгәнгә күрә генә, өлкән бичә янына аны менә каган үзе түгел, бәлки Исәнтәй куалап җибәрде сыман тоелганга күрә аның ачуы килә түгелме соң? Әйе, шуңа гына бугай.

Юл буена ул шулай әле Исәнтәйгә үртәлеп, әле үзенең авыр язмышына ачынып барды. Тик шулай да Ак урда ерагаеп, өлкән бичә көтүлекләренә килеп кергәч, туктаусыз борчыган нәрсәләр үзеннән-үзе онытыла барды. Күз алдына икенче күренешләр — якты, татлы күренешләр килде.

Юк, алай ук өлешсезләрдән түгел бугай әле ул бу дөньяда! Аркача су Тозлы күлгә килеп койса да, барыбер бөтенләй үк юкка чыкмый. Аркачаның суы күлне яшәтә. Күп төрле чишмәләр, инешләр килеп кушылмаса, комлы калкулыклар арасындагы Тозлы күл дә, башка күлләр дә инде күптән корып юкка чыккан булырлар иде. Туңгак алыплар, Салчак алыплар, башка йөзләгән, меңләгән ирләр, каралар булмаса, биек Ак өендә Туман каганнар тынычлап йоклый алмас иде. Изге каган Ак өендә тынычлап яши алмаса, Сөн иле дә — йөзләгән, меңләгән ирләр, каралар да, исәпсез-хисапсыз мал-туар да бу дөньяда яши алмас иде. Бит Тозлы күл дә суын үзендә генә саклап яшереп тотмый — ярларында аның таллар, камышлар үсә, суын терлек-туар эчә. Тозлы күлләр, елгалар, инешләр җирдәге барлык тереклекне туйдырып-туендырып торалар. Тереклекнең башы — суда. Менә ул бер-берсенә нинди нык бәйләнгән бу дөньяда барлык нәрсә! Шулай булгач, синең көч-куәтең, синең йокысыз төннәрең, синең кайгыларың, Туңгак алып, алтын тәхеттәге аксөякләргә генә түгел, үзеңә дә, үзең кебек иш башка ирләргә дә, караларга да — барлык илеңә-көнеңә дә сарыф ителә түгелме соң? Әгәр син Туман каганның атаклы алыбы икәнсең, шул ук вакытта син бөтен Сөн иленең дә, барлык ил-көннең дә ышанычлы сакчысы буласың түгелме соң? Әйе, шулай.

Ул үзе дә күптән инде шушы якка килү турында хыяллана иде бит. Йомышын үти алмаган очракта да ул барыбер монда караңгы чырай

очратмаячак. Барыбер аны бай, җыйнак өйдә ягымлы йөз белән каршы алачаклар.

— На, Бахбай, тизрәк житик бикә урдасына!

## II

Тозлы күл буена ул кояш баеганда килеп җитте. Күрекле бикәнең авылы күлнең көнбатыш яр буена, ике калкулык арасындагы үзәнлек уртасына урнашкан иде. Тунгак алып авылга көньяктан — күл буенча бормаланып сузылган арба юлыннан килеп керде. Аның уң ягында өсте юка боз белән капланган, өстәл кебек тип-тигез күл ялтырап ятты, сул ягында биек калкулык кабарып утырды. Күлнең аргы ягында, еракта — дала белән күл чите тоташкан турыда, зур булып, кып-кызыл булып, кичке кояш баеп бара иде. Кызыл кояшның кызгылт нурлары, шома боз өстеннән чагылып, бу яктагы калкулыкка кадәр килеп җиткән. Шунлыктан бөтен тирә-як нурга күмелгән булып күренә һәм бу бераз гына серлелек, тантана тәэсире тудыра иде. Боз өстендә уйнап йөргән балалар, анда-санда утлап йөргән атлар, дөяләр бу серлелеккә, бу тантанага җылылык, якынлык тойгысы өсти сыман иде.

Авылга якыная барган саен Тунгак алып үзендә җиңелчә бер каушау, җилкенү тойды. Үземә йөкләтелгән бурычны үтәп чыга алырмын микән дип түгел, ничек каршыларлар икән, ничек очрашырбыз икән дип уйлаганга каушау һәм җилкенү тойды. Ул алга, калкулык артындагы ак өй түбәләре ягына карап барды. Аңа монда бар нәрсә таныш, якын иде. Ул, әйтерсең, монда каган йомышын үтәү өчен килми, киресенчә, бикә йомышын үтәп каяндыр кайтып килә иде.

Күкне, авылны каплап утырган калкулыклар озакламый артта калды. Алда, бозлы күлнең дәвамы сыман булып, соргылт киң җәймә белән капланган тар үзән сузылды. Үзән уртасында, күлдән бер чакрым ераклыкта, бер тирәгә укмашып, унлап-унбишләп киез өй күпереп утыра иде. Бергә укмашып утырган шул өйләр арасында, уртада, башкаларга караганда берсе биегрәк тә, нурлырак та булып күренде.

Күл буеннан читләшеп, үзәнгә таба борылгач та, калкулык буенда Тунгак алыпны өлкән бичәнең атлы торгаклары туктатты. Алар барлыгы биш-алты кеше иде һәм аларның барысы да күптәнге танышлар иде. Тунгак алыпны алар дусларча елмаеп, үз кеше итеп каршыладылар. Шулай да арадан берсе — унбашы болай гына, йола саклап кына Тунгак алыпның кемлеген, кая, ник баруын белеште.

— Өлкән бичә Күрекле бикә янына каган йомышы белән,— диде Тунгак алып.

Бикәгә хәбәр итү өчен унбашы шундук яшьрәк бер торгакны авылга җибәрде. Ул ерагайганчы Тунгак алып ирләр белән беравык гәп сатып торды. Меңбашы булса да, каганның каравыл агасы булса да, бикә ирләре белән ул масаймыйча, эреләнмичә сөйләште. Сөйләшә торгач сер итеп кенә ирләр мондагы кайбер яңалыкларны әйттеләр. Яңалыкларның иң зурысы чин кызы иде.

— Чибәр!

— Яңа туган ай кебек! Сабый бала кебек!— диделәр ирләр кызны мактап.

— Тагын углан күзгә күренеп үзгәрде,— диде унбашы.

— Үзгәргәнен каян беләсең — аның хәзер күренгәне юк,— диде шунда икенче берсе.

— Үзгәрде! — диде унбашы.— Чин кызын алып кайткач та атын да, коралын да онытты.

— Егетләрен дә онытты. Аларга инде күптән Тарлавыкка китәргә вакыт җиткән — йөриләр теләсә кайда каңгырап,— диде ирләрнең өченче берсе.

Шулай кыска гына очрашу вакытында Туңгак алып төрле хәбәрләр ишетте. Чин кызы, тәгин углан турындагы сүзләрне ул аеруча колак салып тыңлады. Шулай да монда озаклап сүз куертып та торып булмый иде — ул кузгалып китте. Торгакларның бер-икесе аны бикә өенә кадәр озата бардылар.

Өлкән бичәнең авылы, даладагы барлык бай авыллар кебек, бер-берсенә яны белән терәп куелган дүртәр тәгәрмәчле зур-зур арбалар белән әйләндереп алынган иде. Азык-төлек, кием-салым, тире-яры, су-утын төялгән, өсте ябулы бу арбаларның озын тәртәләре югары күтәрелеп, тышкы якка каратылган.

Авылны әйләндереп алган әлеге койманың көнчыгыш капкасы алдында Туңгак алыпны өлкән бичәнең баш багасы Кортага каршылады. Исәнлек-саулык сорашкач алар, капканы үтеп, туп-туры уртадагы биек ак өйгә таба юнәлделәр. Ак өйнең ишеге төбендә, җир өстендә сузылып яткан ак киез өстенә басып, ачык изү белән үзен көтеп торган бикәне күргәч, Туңгак алып бераз гына гаҗәпкә калды. Бу авылга, бу өйгә кем генә булып килмәсен, ул каганның өлкән бичәсе каршы алырдай зур, дәрәҗәле кеше түгел иде. Ул бары каганның йомышчысы гына иде һәм аны тик шундый ук дәрәҗәдәге кеше генә каршы алырга тиеш иде. Нидер булган бикәгә. Ни генә булса да, хәерлегә генә булсын, тәңрем.

## III

Туңгак алып җиңел генә сикереп атыннан төште. Бераз җир ул бикәгә каршы җәяү барды. Өлкән бичәгә биш-алты адым кала тезләнде, баш орды. Шул ук мәлдә Күрекле бикә аягы астыннан аның янына зур ак киез төргәк тәгәрәп килде дә урталыкка сузылып ятты. Киез төргәген ике яктан ике кыз тәгәрәтеп китерде. Алар аны Туңгак алыпның аягы очына ук китереп җәйделәр.

— Түрдән уз, меңбашы Туңгак алып!— диде бикә елмаеп.

Ул уртадан калкурак буйлы, чандыр, чибәр, ягымлы бер хатын иде. Барлык дала хатыннарыныкы кебек аның да битен җил кискән, кояш ашаган, шулай да, үзен-үзе саклаганга, күрәсең, бите аның тупасланмаган, шактый яшь, сылу иде.

Туңгак алып киез өстеннән бер-ике адым гына атлады да тагын бикә алдына тез чүкте. Бикә аңа үзе каршы килде. Зур гәүдәле алып ир аның кечкенә, кайнар, йомшак кулын үпте. Бикә, егылган бала-чаганы торгызган кебек, кулыннан тотып, елмаеп аны аягына бастырды һәм беренче булып үзе өйгә таба кузгалып китте. Туңгак алып аның артыннан атлады.

Ишек янындагы казыкка җиткәч ул икеләнгәндәй итеп туктап калды, сораулы караш белән бикәгә, якындагы кешеләргә карады. Бикәнең һаман ягымлы йөзен күреп ул шундук үзенең коралларын сала башлады. Казыктагы чөйгә ул иң элек, иплэп кенә, җәясен, аннары ук тулы авыр ук савытын элде. Шуннан соң ул бил каешын, аркалык каешын, хәнҗәрен, пычагын, чакма таш янчыгын, сөңгесен, калканын — барлык сугыш коралларын элеп куйды. Авыр, очлы, куркыныч коралларыннан бушанып калгач, җаны-тәне белән, бөтен күңеле белән җиңеләеп ул бикә өенең ябулы ишегенә якынайды. Ул үзенең кораллары белән булашкан арада бикә дә, аның янындагы ирләр дә су сипкәндәй каядыр юк булганнар иде.

Бикәгә йомыш белән килгән ир кунакларны, түрә буенча, иң элек аның — бикәнең багасы янсә берәр ир туганы каршы ала иде. Читтән

килгән ир кешегә, кунакка бикә белән сөйләшергә кирәк булса, шулай ук алар янында бикәнең баш багасы яисә берәр ир туганы булырга тиеш. Мондый чикләүләр, тыюлар һәм һәр төрле саклык чаралары каган бичәсенең исеменә тап төшермәү өчен, төрле имеш-мимешләргә юл куймау өчен кирәк иде.

Ләкин шул ук вакытта түрә белән исәпләшми торган, турыдан-туры түрәгә каршы килә торган борынгы йолалар да үз көчендә иде әле. Борынгы йола буенча бикә үз иреннән бөтенләй диярлек бәйсез иде. Ирләрне ул үз өендә каршы да ала, кунак та итә ала иде. Аксөяк кызларына, бөек каган бичәләренә үз ирләреннән тыш, болай гына, кирәк өчен генә тагын икенче ир тотарга да ярый иде.

Туңгак алыпны Күрекле бикә йола буенча каршылады. Аның алдында изүен ачык калдырып ул аңа үзенең күңеле дә ачык икәнлеген белдерде. Туңгак алып, өйнең тышкы ягындагы казыкта барлык кораллaрын калдырып, шулай ук аңа үзенең бу өй хуҗасына карата бернинди яман уе юклыгын сиздерде.

Шулай итеп алар бик тиз аңлаштылар.

Хәер, алар инде күптән аңлашканнар иде.

Моннан күп еллар элек кыпчакларның Тула суы буенда күченеп йөргән ыруларын җиңеп, илен-көнен туздыргач, яшь Туман каган аны — Туңгак алыпны әсир итеп алып кайтты. Алып кайтты да, берничә кызкыркын белән, үсмер малай белән бергә аны үзенең бичәсенә — ул чакта бердәнбер, яшь, гүзәл бичәсенә бүләк итеп бирде. Туңгак малай баштарак бикәнең көтүләрен көтте, соңыннан үсә төшкәч, яшьтәшләре арасында үзенең көчлелеге, булдыклылыгы белән аерыла башлагач, яшь бикә аны үзенә якынайтты. Ул аның ат караучысы да, кораллы торгагы да булды. Кол торгак, алып торгак су сөлегедәй сылу егет булып җиткәч, өлкән бичә аны тагын да ныграк якынайта төште. Бу вакытта Туман каганның Күрекле бикәсеннән башка инде өч бичәсе, кырыклап кызы-кырнагы бар иде. Шуңа күрә ул үзенең өлкән бичәсенә бик үк мохтаҗ түгел иде.

Кол егетне бикә, ахрысы, чын күңелдән яратты һәм, йолага таянып, икенче ир сайлап тормады. Үзеннән өлешсезрәк, булдыксызрак булган күп санлы яшьтәшләре кар-буранда, эсседә, яңгырда катып-калҗаеп, янып-пешеп көтү көтеп йөргәндә Туңгак кол, шулай итеп, тынычта, рәхәттә яшәде.

Бикә янында ул чыннан да бик күңелле яшәде. Шулай да мондый тормыш аны җиләтә башлады. Ул үзен икеләтә коллыкта, кысынлыкта итеп тойды. Аның каядыр иркенгә, ирекка чыгасы килде, ниндидер зурзур эшләр эшлисе, каядыр югарыга үрлисе килде. Ирекне ул каган коллыгыннан, сөннәрдән котылып, үз туган җиренә, туган ыруына китү дип аңламады. Үз ыруын ул бик аз хәтерләде. Хәтердә калганы да аңа ниндидер төштә күргән, кемдер сөйләгән томанлы истәлекләр генә булып тоелды. Ирекне ул өлкән бичә назыннан котылып, үзе теләгән берәр кол кызга өйләнү һәм үз ояңны кору дип, үзеңчә яшәү дип аңлады. Аның инде күз атып, якын итеп йөргән кызы да бар иде. Ләкин бикәгә аның өйләнү турында сүз башларга кыюлыгы җитмәде. Бикә исә бу хакта башына да китереп карамады.

Шулай да ул аны үзенә бәйләп тә тота алмады. Кол егетнең күркәмлеге, батырлыгы турындагы, өлкән бичәнең аны башка барлык коллaрыннан артыграк күрүе турындагы имеш-мимешләр каганга да килеп иреште. Каган, билгеле, көнләшмәде. Аның бары андый булдыклы, яшь колны үз янына аласы гына килде. Бер кышны, яу чабар алдыннан, каган өлкән бичәсе карамагындагы ирләрне дә сугышка алдырды. Бу вакытта Туңгак алып бикәнең торгак агасы булып исәпләнелә иде. Барлык кораллы ирләр аңа буйсына иде. Шулай итеп бикә үзенең сөекле колын йөз кешелек алайга баш итеп, яуга җибәрергә мәҗбүр булды.

Яуда Туңгак алып үзен тиңсез батыр итеп күрсәтте. Аның батырлыклары турында соңыннан сөн ирләре бик озак сокланып, исләре китеп сөйләделәр. Менә шул яудан соң каган Туңгак алыпны үз урдасына алды. Алып колы белән аерылышу бик күңелсез булса да, өлкән бичә каган теләгенә каршы килә алмады. Ул бары Туман каганның аны — Туңгак алыпны — беркая да читкә җибәрмәвен генә үтенеп сорады.

Өлкән бичәсенең үтенечен каган бик яхшы аңлады. Бикә белән Туңгак алыпның бер-берсен яратуына ул әз генә дә аяк чалырга теләмәде. Каганны, урданы саклауда, каравыллауда менә шундый Туңгак алып кебек кешедән дә ышанычлырак колның булуы мөмкин түгел иде. Ул аны үзенең каравыл агасы итеп билгеләде. Шулай итеп, үз карамагына тапшырылган кораллы дүрт мең ир белән Туңгак алып көнен-төнен аның иминлеген, тынычлыгын саклый башлады.

Күп тә үтмәде, меңбашы Туңгак алыпка каган үзенең бер кырнагын бирде, өй бирде, беркадәр мал-туар бирде. Шул рәвешчә яшь алып үзенең барлык теләкләренә иреште. Кем аркасында? Әлбәттә, бикә аркасында!

Ул моны беркайчан да онытмады, оныта алмады. Каган биргән кызга өйләнеп, үз оясын корып җибәргәч тә ул барыбер аннан читләшмәде. Бикәне ул үзенең яшьлек дусты һәм сөеклесе итеп тә яратты.

## IV

Иркен, бай өйдә, ялкынланып янган учак янәшәсендә алар икәүдәнікәү генә утырдылар. Бикә өйгә балаларын да, туган-тумачаларын да — беркемне дә кертмәскә кушты. Болан тиресеннән тегелгән каюлы йомшак итек кигән аякларын бөкләп, йомшак мендәр өстендә утырган бикә кунагын иң әлек кымыз белән сыйлады. Кымыз эчкәннән соң ак киез уртасындагы тәбәнәк өстәлгә алтын табак белән бер бөтен сарык китереп куйдылар. Таралырга гына торган йомшак, кайнар итне бикә беренче булып үзе авыз итте, шуннан соң кунагын сыйларга тотынды. Көне буе ат өстендә килгән алып ир бик нык ачыккан иде — күз ачып йомганчы ул сарыкның бер як санын ялт иттереп куйды.

Ашаганда беркем берни сорашмады. Аларның очрашмаганына инде бер айдан артык вакыт үткән, шуңа күрә икесенең дә сөйләр сүзләре күп булырга тиеш сыман иде. Кунагы бирелеп ит ашаган арада бикә җайлап әле бер кисәкне, әле икенче кисәкне аның алдынарак этеп куйды. Иң ахырда кайнар шулпа китерделәр. Зур агач табакны ике куллап тоткан килеш, Туңгак алып шулпа эчте. Шуннан соң, тирләгән маңгаен сөрткәләп, ул беравык тынып, рәхәтләнеп утырды.

Сүзне бикә башлады.

— Ау ничегрәк булды соң?

Ул инде күптән сүз башларга җыенып утыра иде бугай — бу аның тавышыннан сизелде.

— Тәгин углан сөйләмәдемени?— диде Туңгак алып көттеребрәк.

— Сөйләде. Аның сөйләве — аныңча, синеке — синеңчә.

— Өйдәме соң әле ул?— диде кунак артык исе китмәгән сыман.

— Өйдә. Аның хәзер үз өе бар. Атасы аңа яшь кыз биреп җибәргән.

— Шулай шул,— дип куйды Туңгак алып гамьсез генә.— Ул кызны бик сылу диләр. Дөресме шул?

— Син әле аны күрмәдеңмени?

— Якыннан күрмәдем.

— Алайса, син Таштугайда булмадыңмыни?

— Мин анда капка сакладым.

Бикә эндәшмәде. Кулына пычак алып ул яңадан ит кискәләргә тотынды, сөягеннән аерылган бер кисәген кунагы алдына куйды да җиңелчә генә кыстап: «Ашале, аша» диештерде. Зур гәүдәле ир кеше алай кыстатып тормады — беркадәр тын алып утырганнан соң ул яңадан эшкә керешә. Озакламый алтын табакта тырпаеп шәрә кабырга сөякләре генә калды. Иттән соң бикә үзенең кунагына янә кымыз салып бирде.

— Яшь... «кияү» ничегрәк соң?— диде Туңгак алып өзелгән сүзне ялгап. Үзе сагаеп тынып калды.

— Ничек булсын — яшьләрчә,— диде бикә көлеп.— Таштугайдан кайтканнан бирле күзгә-башка күренгәне юк. Өеннән чыкмый. Алыштырган кебек — икенче кешегә әйләнде куйды.

— «Килен» ничегрәк соң?— диде Туңгак алып, шул ук җиңелчә шаян бер кызыксыну белән.

— Сиңа аның «килене» кирәгрәк, ахрысы?— диде бикә, хәйләкәр елмаеп.— Ничек булсын — ягымлы, моңсу. Телне белми. Яннарына телне белә торган бер карчык куйдым. Әлегә шуның аша аралашалар. Ул кызның Таштугайда бертуган абыйсы да бар икән.

— Шулаймыни?— дигән булды Туңгак алып.

— Кул эшләрен белә,— диде бикә.— Тавышы матур, җырлый, бии, гөсләдә уйный. Көне буе җырлап-биеп күңел ачалар.

— Тәгин угланны йөзбашы Күчәр урдага йомыш белән генә җибәргән булган. Ул шулай монда чин кызы белән гомер уздырмакчы була микәнни?— диде Туңгак алып.

— Мин дә әйттем: улым, дидем, олы җыен якынлаша — уенга, ярышка катнашырга уйламыйсыңмы? — дидем. Шуннан соң яланга чыга башлады. Ук аталар, атта узышалар. Бүген кызын дөягә атландырып алып чыккан. Ул чыккач атыш та булмаган, чабыш та булмаган. Егетләре гел теге кыз тирәсендә чуалалар икән. Үзара кычкырышып беткәннәр. Егетләрен тыңлата алмый җаны чыккан. Төштән соң Сөенечен... ул аны Сөенеч дип атады... Сөенечен минем янга китереп куйды. Көнли, курка. Менә шундый бездәге хәлләр!

— Башы-күзе әйләнгән икән!— диде Туңгак алып, ризасызлык белән.

— Кемнең башы-күзе әйләнгәндер — әйтеп булмый. Кызы да бик юха, сарылырга гына тора.

— Абыйсының килгәне юк микән?— диде Туңгак алып, иплэп кенә, сүзне янә дә үзе теләгән юнәлешкә борып.

— Юк, килмәде,— диде бикә.— Баштарак үзе янына алдырырга дип караган бугай да, соңыннан тынган. Аннан соң ул әйтә икән: мине монда каганга бирергә дип алып килделәр, дип әйтә икән.

— Алайса, ул инде белә?— диде Туңгак алып, урыныннан кузгала төшеп.

— Кем? Нәрсәне?

— Чин кызының кире каганга кайтарып бирелергә тиешлеген.

— Каган сине шуның өчен җибәрдеме?

— Шуның өчен. Алдан синең белән сөйләшергә, киңәшергә җибәрде.

— Киңәшергә! Күз буяу өчен аңа минем ризалык кирәк. Күптән инде ул минем белән исәпләшми. Минем янга ул яшь кызларыннан арыгач ял итәргә генә килә.

Бикә үртәлеп, ашыгып-кабаланып сөйләде. Аның тавышында әледән-әле күз яшьләре сизелеп калды, тырышса да тыела алмады — күңеленә җыелып килгән барлык үпкәсенә, ихтимал, шулай ук сагыну тойгысына ирек биреп, борынын тарткалап кинәт сулкылдарга керешеп китте. Туңгак алып белән элекке очрашуында да ул шулай искәрмәстән күз яшьләре түгеп алган иде. Ул чагында ул үзенең күңеле йомшавын башкачарак аңлаткан иде: яшь хатынының ныграк яратасың бугай, мине оныттың, дигән иде, элекке колын шелтәләп. Бүген ул әнә бөтен-

ләй икенче төрле сүзләр сөйли. Бүген ул анә үзенең колына түгел, иренә үпкә белдерә. «Бикә дә картая башлады!» дип уйлады Туңгак алып үзалдына.

Авыр гәүдәсен көчкә кузгатып, ул бикә янынарак күчеп утырды, юатып, иркәләп авыр кулын аның чандыр аркасына куйды. Бикә тынычлана төште, күз төпләрен сөрткәләде дә, үзенең йомшаклыгын акларга тырышкан сыман:

— Мин инде ярты картайдым. Ябыктым, ямьсезләндем,— дип куйды.

— Бер дә картайган кебек күренмисең әле!

Әле генә бетеренеп утырган бикә искәрмәстән елмаеп җибәрде. Туңгак алыпка ул чыннан да элеккечә яшь һәм чибәр булып күренде. Ул аның җиңел генә үзенә якынрак китерде, зур, дымлы кулы белән аның битеннән, маңгаеннан сыйпады.

— Каган яратмаган өчен миңа зарланырга җыенмыйсыңдыр ич син, бикә?

— Сиңа да зарланмагач, тагын кемгә зарланырга соң?!

— Мин — каганның колы...

— Иң элек син — минем кόлым!— диде бикә яңадан үртәлә башлап.

— Мин әле дә синең колың, бикә.

— Мин синнән шундый сүз көттем дә!

— Ирләрнең үзеңә кол булуларын гына телисең дә инде син, бикә.

— Юк, барлык ирләрнең дә түгел — синең генә! — диде Күрекле бикә.— Яшьләрнең... үз улымның оялуын-кызаруын, шат йөзен күреп көнләшә башладыммы, яшьлегемне сагындыммы... гел сине уйладым. Бу көннәрдә эчем поша — үземне үзем кая куярга белмим. Урдадан еракта, беркемнең кулы җитмәстәй таулар арасында яшәргә иде икәүдән-икәү генә. Күңелгә шундыйрак уйлар килә. Син дә сирәкләдең.

— Китеп булмый. Эш, хезмәт.

— Шулайдыр,— диде бикә һәм никтер яңадан тынычсызлана башлады.— Киңәшергә сиңа мин кирәк түгел, миңа — син кирәк! Син алып килгән хәбәрләрне мин инде күптән белеп торам.

Туңгак алып кинәт билен турайтты.

— Алаймыни?— диде ул сагаеп.— Шулай да, нәрсәләр беләсең?

Бикә дә башын югары күтәрде, укалы, чигүле бүреге астыннан чыккан маңгай чәчләрен төзәткәләп куйды да, беравык көттергәндәй итеп утырды.

— Бик серле булып чыкты әле ул гүзәл чин кызы,— диде ул.— Алар янындагы теге чин карчыгы колыныма әйткән: каган синең кызыңны кире алачак дигән.

— Ул карчыкка кем әйткән?!— диде Туңгак алып, гаҗәпләнеп.

— Исәнтәй булырга охшый. Аның яныннан ниндидер кеше килгән.

— Исәнтәй! Монда да ул миннән өлгеррәк булып чыкты болай булгач,— диде Туңгак алып, йодрыкларын йомарлап.

— Ник аңа ачуланырга? Ул синең бурычны гына җиңеләйткән,— диде бикә көлемсерәп.

— Ул җиңеләйткәннән соң нишләптер миңа авыр була башлады,— диде Туңгак алып ачу белән.— Аның яхшылыгы да миңа яманлык булып тоела. Мин аннан бары явызлык кына көтәм.

## V

— Миңа шунысы аңлашылмый,— диде бикә, яңадан сүз башлап,— бер кулы белән биргәнне икенче кулы белән тартып алгач, ил-көн алдында, агай-эне, туган-тумача алдында ул ни диячәк? Тиздән олы бәйрәм җитә. Шундый изге бәйрәм алдыннан шундый әшәкелек эшләсә,

аның барлык терәкләре юкка чыгачак бит! Уйлыймы шул турыда каган? Котлуг бәк белән, Куяннар белән бозылышу аның көчен дә, абруен да арттырмаячак. Бер гүзәл чин кызы аңа Котлуг бәккә, Куяннарга, Аланнарга торырлык куәт өстәмәячәк. Уйлыймы шул турыда каган?

Әле генә шундый ягымлы, юмарт күңелле хатын күз алдында илтотмыш бикәгә әверелде. Хәзер инде аның белән гамьсез генә, теләр-теләмәс кенә сөйләшеп булмаячак иде.

— Каган эшне алай зурга җибәрергә уйламый, бикә,— диде Туңгак алып ашыкмыйча гына.

Ул бикәнең яраткан ире булып түгел, каганның илчесе булып сөйләште.

— Эшне зурга җибәрергә теләмәгән өчен дә ул синең янга мине җибәрде. Күп нәрсә синнән тора. Син каршы килмәсәң, тәгин угланны син килештерсәң, үгетләсәң, каган белән Котлуг бәк арасында да, Куяннар арасында да берниндн дошманлык барлыкка килмәячәк.

— Булмаячак андый эш!— диде бикә, никтер кызарынып.— Мин күп түздем. Илгә таркаулык килмәсен дип, Сөнәнкәләр Куяннар белән бозылышмасын дип, каганның читләтүенә дә, санламавына да — барысына да түздем. Бу юлы мин башымны иеп калмаячакмын. Мин — өлкән бичә! Мин — Котлуг бәк кызы! Минем урыным — түрдә, каганның уң ягында!

— Синең урыныңны әлегә беркемнең тартып алганы юк, бикә,— диде Туңгак алып, аның шулай кинәт тузынуын аңлап җитмичә.

— Әйе, әлегә тартып алганнары юк. Шулай да түрдә күбрәк кырнаклар, икенче, өченче бичәләр утыра.

— Кырнаклардан көнләшмисеңдер ич син, бикә?— диде Туңгак алып ясалма бер гамьсезлек белән.

— Беләсеңме, мин кемнән куркам?— диде бикә кинәт тавышын үзгәртеп.— Мин каганның Куяннар белән бозылышуыннан да, үзара тавыш-гауга чыгуыннан да курыкмыйм. Мин әлеге чин кызыннан куркам, Туңгак алып! Каган аны үзенә алса, ул чагында ул мине генә түгел, башка бичәләрне дә читкә тибәрә башлаячак. Күңелем сизенә. Мин ул кызны күргәч тә яратмадым. Ул күз явын ала торган ялтыравык таш кебек. Эчендә — агу, мәкер. Ул теләсә нинди ир кешене акылдан яздырачак. Ул каганның да күзен томалаячак. Ул чагында инде аның тирәсенә елышкан төрле килмешәкләр — Исәнтәйләр, «абыйлар», теләсә нинди чин карчыклары аңа үзләре өчен кирәкле сүзләр пышылдый башлаячаклар.

— Монда мин әллә нинди куркыныч нәрсәләр күрмим,— диде Туңгак алып басынкы гына.

— Ник алайса Исәнтәйдән шикләнәсең?

— Исәнтәй — башка, чин кызы — башка.

— Юк, башка түгел!— диде бикә.— Алар бер-берсенә бәйләнгәннәр. Алар әнә каяндыр гүзәл кызларны китертәләр, каганның Ак өенә үтеп керәләр, астыртын гына үз эшләрен эшли бирәләр.

— Шулай,— диде Туңгак алып килешеп, караңгы чырай белән.

— Шулай булгач, нидер эшләргә кирәк, Туңгак!— диде бикә, усал пышылдап, күзләрен уттай яндырып.— Иң әлек шуны белеп тор: чин кызын ул кире ала алмаячак! Берәр сылтау табып, мин аны барыбер ат койрыгына тактырачакмын![1]

Ул моны нык итеп, үз-үзенә ышанып әйтте. Әле булса тыныч, килешүчән булып күренергә, артык кызмаска тырышып утырган илче үзгәреп китте.

---

[1] Борынгы төркиләрдә үлемгә хөкем ителгән кешене аркан белән ат койрыгына такканнар да атны дала буйлап куып киткәннәр.

— Каган мине монда боерык белән җибәрде. Әгәр мин аның боерыгын үти алмасам, ул минем башымны чаптырачак. Син әле минем үлемемне теләмисеңдер ич, бикә?— диде ул.

Бу билгеле, бикә уйлаган, бикә теләгән сүзләр түгел иде. Бу аны кимсетә торган, аны читләштерә торган, аны үтерә торган сүзләр иде.

— Синең яшисең килгәнне... минем яшисем килмимени, Туңгак кол?! — диде бикә кинәт кызарынып, усал итеп.

Туңгак алып кинәт әсселе-суыклы булып китте. «Менә нинди икәнсең син, бикә... картая башлагач» дип уйлады ул үзалдына тыныч кына. Ләкин тыштан ул тыныч кала алмады. Кызарынып шундук аягына басты, бикәдән, алтын табаклардан, ак киездән читкәрәк тайпылды. Бугазына килеп уралган ярсуыннан арына алмыйча, ул шактый озак бер сүз әйтә алмый торды. Шуннан соң ул кулларын күкрәк турысында кушырып, мыскыллы-күндәм бер кыяфәттә бикә алдына баш иде.

— Минем, бикә, коллыгымнан баш тартканым юк. Баш тартырга теләсәм дә, мин ирекле булмаячакмын,— диде ул.— Кол буларак мин бары каган теләген генә белдердем. Син каганны яхшы беләсең: күңеле төшкәнне ул алмый калмаячак. Яхшылык белән бирмәсәң, ул көч белән алачак. Менә шунда күренер инде кемнең ил тараткановы да, кемнең ил ныгытканы. Хуш, бикә.

Ул ишеккә таба атлады. Ашыгудан, кабаланудан ул аяк астындагы нәрсәгәдер сөрлегеп китте. Аяк астындагы ул нәрсә сөлге булып чыкты. Ләкин ул аны иелеп, аягыннан алып тормады — шул килеш, уралган сөлгесен өстерәп, ишек катына ук килеп җитте. Ул ишек бавы белән булашкан арада аның янына бикә килеп басты.

— Ашыкма!— диде ул, боерып.

Бер дә юктан ул кычкырып көләргә тотынды.

— Ашыкма!

Туңгак алып ярсып кинәт артына борылды.

— Минем боерыктан башка син моннан беркая китә алмаячаксың, колым!— диде бикә, үтергеч бер өстенлек белән.

— Нишләтмәкче буласың мине, бикә?— диде ир кеше, авыр гыжылдап, кулларын йомарлап.

— Чин кызы белән... ат коерыгына, ат коерыгына!.. — диде бикә тотлыгып, тиле сыман никтер көлә-көлә.

Туңгак алып бикәнең кулларыннан тотып алды, тыелгысыз бер көч белән аны җиңел генә үзенә таба якынайтты.

— Кол, мин, кол, бикә! — диде ул, кычкырып.— Үзем үлгәнче мин сине... буып үтерәм, бикә!

Бикә агарынып китте һәм үзен буып алган алып иргә сәер итеп бер карады да, кинәт хәлсезләнеп, җансызланып калды. «Үтердем!» дип уйлады алып ир, коты алынып.

Кызганулы бер өн чыгарып ул ыңгырашып куйды, авыраеп калган хатынны шашып кочагына алды, битенә, күзләренә карады.

Бикә исән иде. Тәне әвәлгечә җылы, йомшак, затлы, нәфис киемнәреннән хуш исләр бөркелеп тора. Алып ир аны коточкыч куаныч һәм котылу-бушану тойгысы белән, тилереп, яратып үбәргә тотынды.

— Күреклем! Сөеклем! Ни булды?

Бикә җанланды. Тирән итеп бер тын алды да, балалар сыман сулкылдап җыларга тотынды.

— Китмә! — диде ул, алып ирнең муенына сарылып.

— Китмим! Кусаң да китмим!

— Кичер. Кызып киттем,— диде бикә, бөтен тәне белән калтыранып.— Мәңге минем якчым-сакчым бул. Синнән башка минем бер ышанычлы кешем дә юк.

Туңгак алып, кием-салым, мендәр күтәргән кебек, аны җиңел генә күтәреп кире табын янына алып килде. Бикә алтын кәсәгә кымыз агыз-

ды. Эчкәч алар икесе дә тынычланып калдылар. Бикә учакка утын өстәде дә янадан ак киезгә алып ир янына килеп утырды һәм әле генә булып узган давылдан соң телгә килеп:

— Ярар, аңлаштык... бозылыштык, хәзер инде ачыктан-ачык сөйләшсәк тә була,— диде.

## VI

Алар шактый озак сөйләштеләр, ләкин шулай да уртак фикергә килә алмадылар. Тышта этләр өрүеннән башка берниндн тавыш-тын ишетелми башлаганда, инде төн уртасы җитеп килгән бер вакытта, эчке яктагы ишек сакчысы биек ятак янына килде дә, калын чаршау астыннан кулын сузып, бикәне йокыдан уятты.

— Ишектә кеше бар.

— Нинди кеше?

— Торгак.

Төннәрен уяу-сак йокларга күнеккән Туңгак алып аларның якында гына пышылдауларын ишетеп, шундук күзләрен ачты. Тиз арада ул барысын да аңлап алды, бикәдән алдарак аягына басты һәм ишек янына килде. Бикә дә аның артыннан килеп җитте.

Бикә авылының тышкы бoҗрасын көндез дә, төнлә дә ир торгаклар каравыллый иде. Арбалар белән әйләндереп алынган кече бoҗра эчендә исә бары хатын-кыз сакчылар гына тора. Ишек янына килгән торгак та хатын кеше иде. Аның белән бикә үзе сөйләште.

— Әрәмә тугаена ниндидер кораллы алай килеп туктады. Шунда төн кунмакчылар,— диде тыштагы хатын-кыз торгак.

— Кемнәр икән?

— Белмим.

— Мин беләм,— диде шул чакны Туңгак алып, бикәгә пышылдап.— Каган кораллы алай җибәргән.

— Таң ату белән алар безне чолгап алачаклар!— диде бикә барысын да төшенеп.

— Таң атканда алар безнең капканы килеп кагачаклар, бикә!— диде Туңгак алып.

— Каган ашыга!

— Каган түгел. Исәнтәй ашыктыра. Аңа да минем баш кирәк, бикә!

— Ярар — нишлибез?— диде бикә, сулуы кабып.

— Миңа синең өеңнән чыгып китәргә туры килә.

— Куркыныч килгәндә алып ирләр иң элек үзләрен генә кайгырталар.

— Иң элек сине кайгыртып, бикә.

— Мин колыным турында, тәгин углан турында әйтәм!

— Мине оныттыгыз! — диде тыштагы торгак.

— Онытмадык,— Туңгак алып бикә өчен җавап бирде.— Андагыларга әйт: барлык ирләр аякларына бассыннар, яхшылап кораллансыннар. Без аларның борын төбендә генә, елганың бу ягында төн уздырачакбыз. Мин хәзер чыгам, мине көтсеннәр.

— Аңлашылды. Мин киттем,— диде ишек артындагы торгак.

Туңгак алып ятак янына килеп киенә башлады.

— Син... алар белән сугышырга җыенасыңмы?— диде бикә, ике куллап аның беләгенә тотынып.

Аның тавышында чиктән тыш каушау-борчылу сизелде.

— Кирәк булса... сугышырбыз да!

— Бөтен эшне харап итәсең! Кирәкми! Җибәрмим!

— Болай булгач, каган боерыгына буйсынырга туры килә.

— Мин риза!— диде бикә, кабаланып.— Мин колынымны күндерер-

мен. Ул мине тыңлар. Ул — акыллы. Туктале, әллә соң син сөйләшеп карыйсыңмы аның белән?

Туңгак алып киенүеннән туктап torгандай итте.

— Өлгермәм,— диде ул уйланып.— Синең сөйләшүең яхшырак булыр. Шулай да аңа әйт: ир булган ир кеше теләсә нинди чибәр кыз алдында җебеп төшәргә тиеш түгел дип әйтте диген; ир булган ир кеше иң элек аты, коралы турында, яу турында уйлый дип әйтте диген.

— Әйтермен!— диде бикә аны тыңламыйча.— Бар инде, бар. Шундый сүзләр сөйләгән ир кешене минем күрәсем килми башлый.

— Үз җаем белән тагын бер килеп чыгармын,— диде Туңгак алып.

— Авыл читендә синең өчен аерым өй корылган булыр,— диде бикә, аны ишеккә кадәр озата барып.— Кызларның берәрсе сине шунда озатып куяр. Озатып куючы синең янда калыр. Мин инде йоклый алмам.

— Мин дә йоклый алмам,— диде Туңгак алып, аны юаткандай итеп.

— Бар инде, бар тизрәк! — диде бикә, аны ашыктырып. Ләкин Туңгак алып ишектән чыгып китмәкче булгач, ул яңадан аның беләгеннән тотып алды.— Тукта, ярат мине!— диде.

Кочаклашып алар беравык тын гына басып тордылар. Тынычлангач, бикә кунагын ишектән үзе чыгарып җибәрде. Туңгак алып казыкта калдырган коралларын яңадан биленә такты, кулына алды һәм бер читтәрәк үзен көтеп торган бер кыз торгак артыннан капкага юнәлде. Башта ул торгак кыз белән авыл читендәге ялгыз өй янына барды. Торгак кызны шунда калдырып яңадан авыл янына кайтты. Күл буенда аны өч йөз-дүрт йөз чамасы коралллы ир көтеп тора иде.

Төннең икенче яртысын ул елга буенда, Әрәмә тугае дигән җирдә үткәрде. Алар йокламадылар. Иртән таң атар-атмас борын ул бикәнең коралллы ирләренә тавыш-тынсыз гына елга ярына таба якынлашырга боерды. Ләкин теге яктагыларның төнге сакчылары аларны күреп алдылар. Каган җибәргән ирләр тиз арада аякка басты. Һәркем үзенә каршы яктагы «дошманның» кемлеген яхшы белгәнгә күрә, теге яктан да, бу яктан да ук атучы булмады. Каган ирләре дә, бикә ирләре дә, коралларын әзер тоткан килеш, өстен боз каплаган елга аша бер-берсенә карашып тордылар.

Туңгак алып бикә ирләренең иң алдында басып торды. Ул теге яктагыларның алай башын танымакчы булды. Ләкин анда аңа таныш бер генә атаклы ир дә күренмәде. Кулларын авыз турысына куеп ул бар көченә:

— Башыгыз кем? Монда чыксын! — дип кычкырды.

Бераз көттереп теге яктагы төркем артыннан ала атка атланган берәү алгарак чыкты, яр буенарак килде. Бу Салчак алып иде. Каганның атаклы батырларыннан берсе Салчак турыдан-туры Туңгак алыпка буйсына иде. Үзе монда киткәндә Туңгак аны вакытлыча үзе урынына каравыл агасы итеп калдырды. Бер-берсен монда, Аркача суы буенда, күреп, алар икесе дә аптырап калдылар. Шулай да, Салчак алыпның йөзендә гаҗәпләнүдән бигрәк, каушау, уңайсызлану өстенлек итсә, Туңгак алыпны күбрәк ачу һәм ярсу биләп алган иде.

— Ни булды, ник килдең, Салчак алып?

— Каган җибәрде, олуг меңбашы,— диде Салчак алып, акланмакчы булып.

— Мин урдага кайтмый торып каган минем арттан беркемне җибәрмәскә тиеш иде!

— Мин берни белмим, олуг меңбашы,— диде Салчак алып, буйсынучан бер төс белән.— Чин кызын бирмәсәләр, миңа бикә авылын камап алырга, кызны көч белән тартып алырга боерылды.

— Кем боерды?— дип кычкырды Туңгак алып ярсып.— Исәнтәйме?

— Исәнтәй боерык бирә алмый, олуг меңбашы,— диде Салчак алып тыныч кына.— Боерыкны каган үзе бирде.

Туңгак алып тынып кал ды. Каганга каршы сүз әйтергә аның батырчылыгы җитмәде. Боерыкны бары каган гына биргәнлеген ул үзе дә бик яхшы белде, ләкин каганның шулай тиз арада үз фикерен, үз боерыкларын үзгәртә алуына аның ышанасы гына килмәде. Билгеле, монда Исәнтәйнең таяк тыкканлыгы көн кебек ачык иде.

— Кырнакны алып килдеңме?— диде ул, шактый озак тынычлана алмый торгач.

— Килдем.

— Аны минем янга чыгар. Үзең урдага кайтып кит,— диде Туңгак алып, боерып.— Барысын да мин үзем җайлармын. Миннән алда кайтып җитсәң, каганга шулай дип әйтерсең.

— Шулай дип әйтермен, олуг меңбашы,— диде Салчак алып, әллә ни куаныч белдермичә.

## VII

Салчак алып Табылдыкны елга аша чыгарып куйгач һәм каган ирләре урда ягына таба кузгалгач, Туңгак алып бикә авылына кайтып китте. Авылга кайтканда ул беркем белән берни сөйләшмәде. Шулай ук үз янынннан гына барган Табылдыкка да берни эндәшмәде. Ул бары аңа бер-ике мәртәбә күтәрелеп кенә карады. Каганның сөеклесе, бөтен урданың күрке булган гүзәл Табылдык элеккегә караганда ябыккан, суырылып калган иде. Аннары, әллә тән йокламаганга, әллә борчылганга, курыкканга, йөзеннән кан качкан. Ләкин шул хәлендә дә ул матур иде!

Бәхетсез кырнакны кызганудан алып ирнең йөрәге сыкрап куйды. Үзе белән Табылдык арасында ул күзгә күренмәгән бер туганлык, якынлык җебе барлыгын тойгандай булды. «Менә нишләтә язмыш!»— дип уйлады ул, тирән бер сагыш һәм әрнү белән. Әле кайчан гына барлык хатын-кызлар арасында йолдыз булып балкыган, яшьлегеn, матурлыгын аңлаудан сөенеп, кая басканын белми йөргән беренче гүзәл әнә суга төшкән тавык кебек бөрешеп калган. Күрәсең, ул әле шуның өчен дә куанадыр. Куанмыйча! Аны әнә Кортка-бикә тырнагыннан тартып алдылар да япь-яшь угланга... тагын угланга алып баралар.

Туңгак алып үзалдына көрсенеп куйды. Үзе ул кол кызның язмышы өчен көрсенәм дип уйлады. Ләкин чынлыкта исә үз язмышын уйлап көрсенде бугай. Былтыр яз көне ул, башкалар арасында йолдыз булып балкыган менә шушы кырнакка күзе төшеп, чак-чак кына харап булмый калды. Ярый әле тойгыларын вакытында тыя алды. Аның белән дә бәйләнеп китсә, бу инде Күрекле бикә белән ике арадагы яратышу гына булмас иде. Аларны бик тиз сизеп алырлар иде. Сизеп алырлар иде дә, шундук койрыкларына да басарлар иде. Үз бичәләренең һәм шулай ук бик үк яратмаган кырнакларының башка ирләр белән чуалуына каган бармак аша караса да, үзе яраткан, бары үзе генә яратырга тиеш булган гүзәлләр янына беркемне дә, хәтта үзенең иң ышанычлы алыпларын да якын җибәрми.

Табылдыкны Туңгак алып туп-туры бикә өенә алып кайтты. Бикә чыннан да төннең яртысын йокысыз уздырган иде, ахрысы — болай да юка ирennәре аның тагын да ныграк кысылып, күзләре кечерәеп калган сыман иде. Туңгак алыпны яңадан исән-имин күргәч ул елмайды.

Өлкән бичә өенә Туңгак алып бу юлы коралларын салмыйча керде, шунлыктан ул бикә алдында да үзен икенче төрлерәк тотты.

Бикә дә аны йомшак мендәрдә, ак киез өстендә утырган килеш каршыламады. Аның ике ягына ике ир кеше — якын туганнары утырган иде.

Каган илчесе Туңгак алыпка бикә кымыз бирергә кушты. Кырнаклар китергән кымызны йола кушканча әз-әзләп кенә, кулдан-кулга йөртеп эчтеләр. Ул арада бикә өлкән углы Албуганы алырга кеше җибәрде.

Албуга килде. Ишектән керү белән, исәнлек-саулык сорашты, түргә узып, уртадагы ак киезгә басты, аннары тезләнде.

— Углым, атаң Туман каганның илчесе килгән,— диде бикә, улының түбән иелгән күз карашын тотарга тырышып.

— Күреп торам, әни,— диде Албуга.— Нәк килгән ул монда каган илчесе Туңгак алып?

— Туңгак алып... атаң бөек каганның боерыгын алып килгән, балам,— диде бикә, йомшак кына итеп.

Яшь углан шундук башын калкытты һәм тынгысыз күзләре белән әле әнисенә, әле Туңгак алыпка каранып алды.

— Нинди боерык, әни?— диде ул тынын кысып, сагаеп.

— Син аны беләсең, углым,— диде бикә, әкрен генә.

— Белмим, беләсем дә килми!— диде кинәт углан, йодрыкларын йомарлап.

Ирләр кымшанмыйча, эндәшмичә, таштай катып утыра бирделәр. Иртәнге өй эчендә дөрләп учак янганы да ишетелерлек тып-тын булып калды.

— Балам, бөек каган сиңа яхшылык тели,— диде бикә, яшь егетне юатмакчы булып.

— Бөек каган миңа яхшылык теләсә, үзе биргәнне кире тартып алмасын!

— Син аңларга тиеш, улым,— диде ана кеше тагын да йомшаграк, үтемлерәк итеп.— Атаң синнән беркемне тартып алмый. Ул сиңа үзенең яраткан кырнагы Табылдыкны бирә.

— Табылдыкны?— диде Албуга беркадәр кызыксыну белдереп.

Ул як-ягына карап алды һәм якында гына башын иеп торган таныш сыман кызны күреп алды.

— Ул Табылдык... түгел, әни!— диде ул.

Үзе турында ачыктан-ачык яратмый әйтелгән сүзләргә хурланып Табылдык кинәт ыңгырашып куйды, кырт кына борылды да, борынын тартып чаршау артына йөгерде.

— Сөенечемне бирмим, әни — теләсә нишләтсеннәр!— диде яшь углан чиктән тыш кирелек, үзсүзлек белән.

Бикә күңелсез генә көлемсерәп куйды, маңгай чәчләрен төзәткәләде дә, башта Туңгак алыпка, аннары үз янындагы туганнарына карап:

— Ирләр чыгып торсыннар,— диде.— Улым, син минем янда кал.

## VIII

Бикә өйдән ирләрне генә түгел, чаршау артындагы хатын-кызларны да чыгарып җибәрде. Улы белән икәүдән-икәү генә калгач, ана аңа үз янынарак күчеп утырырга кушты.

— Синең белән генә сөйләшәсе сүз бар,— диде ул беравык сүз таба алмагандай утыргач.

— Барыбер тыңламыйм!

— Тыңламыйсың?!— диде ана исе китеп.— Инде син кырнакларны гына тыңлый башладыңмыни?

— Юк, алай түгел,— диде яшь углан, буталып.

— Шулай да тыңлыйсыңмы әниеңнең сүзен?

— Тыңлыйм,— диде углан, теләмичә.

— Мин сине, углым, гүзәл чин кызы өчен тапмадым. Мин сине анаңа, ырудашларыңа, илеңә-көнеңә бәхет, куаныч өчен таптым. Шушы көнгә чаклы мин сине җил-яңгыр тидерми карап үстердем. Үстерүен үс-

тердем дә, сиңа әнә хәзер кырнаклардан башка беркем дә кирәкми башлаган!

— Алай түгел! Алай түгел, әни!— диде яшь углан.— Мин ул кызны яратам. Сине дә яратам. Сине — әнием булган өчен. Аны — башкача. Үзең дә беләсең ич. Ник мине газаплыйсың?!

— Беләм,— диде ана кеше тыныч кына.— Синең кызлар яратуыңа минем бер сүзем юк. Ир булган ир кеше хатын-кызны ярату өчен туа, хатын-кыз — ирләр өчен туа. Тәңре безнең шулай яраткан. Тәңренең теләгенә беркем каршы килә алмый.

— Шулай булгач, әни?!— диде Албуга яктырып.

— Шулай булгач, ир булган ир өчен дөньяда кызлардан башка әле бүтән нәрсәләр дә бар,— диде бикә.— Ир булган ир кызлар кочагында гына җылынып ятмый — атын, коралын кайгырта, ил-көн язмышын кайгырта.

— Аңлатма, әни,— диде углан, сүрелеп.

Әнисенең үз теләгенә, үз тойгыларына, үз омтылышларына каршы килә торган теләсә нинди сүзе, теләсә нинди дәлиле аңа ялган булып, ышандыргысыз булып тоелды. Улының холкын биш бармагы кебек белгән ана да моны бик яхшы сизенде. Ләкин ул аны барыбер җиңәргә, күндерергә тиеш иде! Чак-чак кына каушап, дулкынланып бикә углы янынарак күченеп утырды. Кулын аның маңгаена куйды, аның каты, кара чәчләрен яратып сыйпалады, кызарынган, дымланган тере күзләренә карады да ярым пышылдап:

— Тыңла, углым — мин сиңа сүз сөйлим,— диде.

Яшь углан тынып калды.

— Син, улым, адәм баласы түгел. Син — Тәңре углы! — диде ана шомлы һәм дәһшәтле бер тантана белән.— Син минем карында чагында мин әле Туман каган бичәсе түгел идем. Әле дә исемдә, атам Котлуг бәк урдасында, Керүлән буенда, җиде төн уртасында яшен яшьнәп күк күкрәде. Кыш көне! Караңгылык юкка чыкты, төн урынына көн булды. Югарыдан, ябылып бетми калган төннек ярыгыннан өй эченә сөңгедәй сузылып алтын яктылык төште. Якты нур минем битемнән, күкрәгемнән сыйпады, минем канымa-бавырыма үтеп керде. Иртән таң атар алдыннан, җирән чәчле, җирән сакаллы ир булып, сөңгедәй сузылып, әлеге алтын нур югарыдан чыгып китте. Өч төн буе шулай кабатланды. Шул өч төннең берсендә, улым, син яралдың. Бу хакта мин бары үземнең мәрхүм әниемә генә сөйләдем — авыр туфрагы җиңел булсын! «Син үзге бала, өлешле бала табарсың, кызым!» диде әни. Икенче көнне Керүлән буена, Котлуг бәк урдасына Туман углан килде. Мине аңа кияүгә бирделәр. Синең кемнән яралуыңны мин аңа әйтмәдем. Унсигез ел буена бу серне мин күкрәгемдә йөрттем. Аны хәзер син дә беләсең. Кайчан да булса мин аны сиңа барыбер әйткән булыр идем. Хәзер инде уйлап кара, улым: Тәңре углы, кырнаклар сихеренә бирелеп, җебеп төшәргә тиешме, әллә барлык адәм баласыннан өстен булып калырга тиешме?

Албуга, ышанырга да, ышанмаска да белмичә, аптырап, таң калып әнисенә карап тик торды. Бераз гына ерагайган һәм кул җитмәслек биеклеккә күтәрелгән, тик шулай да аңлаешлы, кадерле әнисен ул беренче кат күргән кебек булды.

— Әнием!— диде ул телгә килеп.— Чынмы бу?! Мин — Тәңре улы!

— Чын, балам,— диде ана берникди икеләнүгә урын калдырмыйча.

— Алып китсеннәр, әни! Кирәкми миңа чин кызы!— диде углан үз авызы белән, үз ирке белән.

Тик шулай да аның нурлы йөзе кинәт төсссезләнеп калды.

— Балам! — диде ана ягымлы итеп.— Мин сине аңлыйм: яраткан кешеңнән аерылуы кыен. Шулай да син бирешмә.

— Мин бирешмәм, әни.

Энисе өеннән чыккач ул үзенең Сөенече янына кайтып тормады. Авылдан читтә бүген алар егетләр белән ук атып, сөңге ыргытып, сугыш уеннары уйнарга тиешләр иде. Ул туры шунда юнәлде.

## IX

Барлык Сөн иленең корбан бәйрәме елына өч тапкыр — беренче, бишенче, тугызынчы айларда — һәр өч айның беренче көненнән алып җиденче көненә кадәр уздырыла иде. Бәйрәмнең иң олысы кыш башында — тугызынчы айда, терлек-туар таза, көр чакта була. Олы ил туена төрле яктан: далалардан, чүлләрдән, тау-таш, урман якларыннан — якыннан, ерактан бәкләр, ыру башлары, алып ирләр, аксакаллар килә. Бөтен илнең корбан курасы уңда, Туман каган кышлавында — Сары су буендагы Изге-тау башына урнашкан иде. Изге-тау башындагы корбан курасы эченә исә моннан мең дә биш йөз ел элек, үзара туктаусыз ызгышкан таркау, ярлы терлекчеләрне берләштереп, көчле ил төзегән Сөн баба күмелгән. Шунда ук, җиргә ярым кадалган килеш, Сөн бабаның саплы тимер кылычы саклана иде.

Илнең төрле ягыннан җыелган бәкләр, ыру башлары, ил агалары менә шушы Изге-тауда Сөн бабага, җир-су иясләренә багышлап корбан бирәләр һәм шуның белән Сөн иленә, Сөнәнкә ыруына, ил башы каганга үзләренең тугрылыкларын белдерәләр иде. Шул ук вакытта монда — бөтен илгә кагылышлы зур эшләр тикшерелә, төрле уеннар, ярышлар уздырыла.

Башка еллардагы кебек, быел да алыстагылар иртәрәк кузгалдылар. Алгы яктан — Алтай, Тула буйларыннан, уртадан — иксез-чиксез далалардан, сул якның Ала-тау, Елан-тау итәкләреннән — бөек Сөн иленең барлык төбәкләреннән өчәр-дүртәр мең, бишәр-алтышар мең коралы ирләре белән; үгезләргә җигелгән арбалары, арбаларга утыртылган киез өйләре белән; алдан теркелдәүче көтүләре белән бәкләр, агалар, ирләр, алыплар борынгы юллар, сукмаклар буенча уңга — көнчыгышка, Изге-тау ягына хәрәкәтләнделәр. Ай буена бөтен Сөн иле, бөтен дала туктаусыз кыймылдап, хәрәкәтләнеп торды.

Ерактагылар ашыгып Сары су ягына хәрәкәтләнгәндә якынрактагылар да тик ятмадылар. Чынында алар да башкалар белән бер үк көнне диярлек кузгалдылар, тик алар ерактагыларга караганда ашыкмыйчарак бардылар.

Изге-тау Сөнәнкә җирендә булса да, Куян ыруы тау буена беренче булып килеп җитте һәм, килеп җитү белән, биек өйләр сыман берсе артында икенчесе калкып утырган комлы калкулыклардан ике ук чамасы ераклыкта, Сары суның уң ягында урда корды.

Котлуг бәк урда корып бер төн узуга, төштән соң, Куяннар кебек үк атаклы аксөяк Аланнар килеп туктадылар. Алан ыруы башы Барыс бәк тә үз җирендә — Сары суның сул ягында Котлуг бәккә капма-каршы яр өстендә урда корды. Өченче көнне Сөйбү ыруы килде. Сөйбү ыруы да Сөн илендә аксөяк санала иде. Сөйбүләр Сары суның сул ягына — Аланнардан бераз алгарак, төн яккарак урнаштылар.

Дүртенче көнне Таслар, Адашлар, Сыбуклар килде. Һәркем, Сары су буена килеп җитү белән, берәрсенең әйткәнен, күрсәткәнен көтеп тормыйча, борын-борыннан үзенеке, үзләренеке булган изге урыннарына утыра тордылар. Яр буйларын куе тал, камыш сарып алган, өстен калын боз каплаган Сары суның ике ягында да тигез, ачык далада берничә көн эчендә йөзләгән, меңләгән өйләр калкып чыкты. Бер тирәгә укмашып, түгәрәкләнеп утырган өйләрне кыршау сыман әйләндереп, тышкы якка күп санлы арбалар тезеп куелды.

Иске айның соңгы көнендә, яңа айның беренче көне башланыр алдыннан Туман каганга буйсынган барлык ырулар диярлек килеп бетте. Бу олы туйга бары сул яктагы Алатлар килмәде дә, каганга калан түли торган түбет бәге, аннары дунху бәге килмәде.

Йола буенча, Сөнәнкә ыруының башы Туман каган Изге-тау янына иң соңгы булып килергә тиеш иде. Шуңа күрә Сары су буена кемнәр килүен, кемнәр килмәвен аңа житкереп кенә тордылар. Яңа ай башына ярты тәүлек кала ул да үзенең күчмә урдасыннан кузгалырга булды.

Каган өчен уртада, Сары суның уң ягында, Изге-тауга якынрак бер жирдә буш урын калдырылган иде.

Дөяләр, атлар жигелгән, өй жиһазлары, азык-төлек, утын-су, бала-чага, карт-коры төялгән беренче арбалар тышкы божра янына килеп життеләр дә, капка аша үтеп, киң аралыктан үзәккә таба агылдылар. Барлык буйсынган ыру башлары, бәкләр, алыплар, ирләр, хатын-кызлар иң алдан яхшы атта килгән бай киемле каганны каршыларга чыктылар. Әле анда, әле монда быргылар кычкырды, дөңгерләр дөпелдәде. Юл буйларында, бер-берсенә кушылмыйча, аерым-аерым төркемнәр булып торган атлы кешеләр өстендә, озын саплы колгаларда төрле төстәге туглар, байраклар балкыды.

Каганның меңләгән кораллы ирләре, исәпсез-хисапсыз арбалары уртага таба туктаусыз агылдылар да агылдылар. Койрыкта әле һаман арбалар шыгырдады, атлар кешнәде, үгезләр үкерде. Туман каганның бу тикле атлары, арбалары, дөяләре, үгезләре, билгеле, Сары су буендагы буш урынга сыеп бетмәде. Изге-тау янындагы изге урында тик каганның биек Ак өе дә, бичәләренең, якын туганнарының өйләре генә утыртылды. Аннары иң кирәкле байлыклары төялгән арбалар да, йөзләгән кораллы ирләре генә калды. Башка барлык ирләр, атлар, дөяләр, малтуар икенче юлдан божраның тышкы ягына, буш далага озатылды.

Кортка-бикә гадәтенчә божра эченә кермәде, тышта калды. Ана-кам буларак, ул болай да урдага керә алмый иде, ни өчен дигәндә, Сөн бабага корбан бирүне тулысынча ир затындагы камнар башкаралар иде.

Шулай итеп, аркылысы-буе бернечә чакрымга сузылган киң божраның тышкы ягын ярлырак өйләр, арбалар, исәпсез көтүләр сарып алды. Әйтерсең, монда Сары су буена — Сөн баба мәңге йокыга талган Изге-тау янәшәсенә бер кешесе, бер малы-туары калмыйча, бөтен Сөн иле жыелган иде. Ләкин шулай да бу бөтен ил түгел. Болар бары бәкләр, ыру башлары белән бергә килгән кораллы ирләр-сакчылар да, якын туган-тумачалар гына. Һәм аларның күпчелеге Туман каганның туганнары — энеләре, абыйлары, абзалары иде.

Туман каган божра эченә кичтән, яңа ай башында кереп урнашты. Икенче көнне иртән төньяк-көнчыгыш офыкта Сары су буена якынлашып килүче ниндидер атлылар күренде. Күзәтчеләр килеп, әлеге атлыларның дунху бәге Начин нойон икәнлеген әйттеләр. Изге-тау буена каган өй корганнан соң божра эченә беркем кертелми иде. Соңга калган өчен каган Начин нойонның башын чаптырып, бар байлыгын, иленкөнен басып кала ала иде.

— Начин нойонны нишләтәбез? — диде Туңгак алып каганга.

— Килсен, туктасын. Урда чистенә, — диде каган.

Изге ай башында изге корбан туен аның баш чаптыру белән башлыйсы килмәде. Аның әле Начин нойоннан да зуррак, катлаулырак эшләре бар иде монда.

— Сөн йоласына өйрәтәсе иде үзен! — дип куйды Туңгак алып, каган белән килешмәгән сыман.

— Алатлар белән түбетләрне өйрәткәндә яхшы булыр иде дә... Алар инде икенче мәртәбә соңлыйлар, — диде каган.

— Юк, килмиләр, — диде Туңгак алып. — Алар чик буенда. Аларның койрык кыска.

— Көтеп карыйк,— диде каган, бу турыда сүзне озайтасы килмичә.
Алатлар белән түбетләрне төшкә чаклы көттеләр. Сары су буена башка килүче булмады.

## X

Сары су буендагы изге урдада Туман каганның барлык бичәләре, туган-тумачалары төрле яктан чикләнгән кысан урында бер-берсенә бик якын урнаштылар. Иң уртада, үзәктә, гадәттәгечә каганның үз өе калкып утырды. Унда — көнчыгыш якта, каган өеннән бер илле адым чамасы ераклыкта өлкән бичә Күрекле бикә өе, алда — төньякта икенче бичә Сырга бикә өе, сулда — көнбатышта өченче бичә Тутыя бикә өе, артта — көньякта дүртенче бичә Кәринә бикә өе корылды. Бикә өйләреннән бер йөз адым чамасы читтәрәк, икенче бож̧ра булып, каганның йөзләгән кырнаклары, кол хатыннарының җыйнак, матур, шулай да караларныкыннан аз гына зуррак булган өйләре тезелеп китте. Кызкыркын өйләреннән дә читтәрәк, өченче түгәрәк булып, туган-тумача, карачы, ашчы, бузачы, агычы һәм шуның ише дәрәҗәле багаларның, хезмәтчеләрнең өйләре куелды. Алар артыннан ук кораллы ирләр — алыплар, торгаклар урын алды.

Моңарчы айлар буена бер-берсен бик сирәк күргән, я булмаса бөтенләй күрмәгән кешеләр шулай бер төбәккә җыйналгач, үзләрен бераз гына чикләнгән, кысылган итеп тойдылар. Бичәләр, йола саклап, бер-берсенә кунакка йөрделәр, исәнлек-саулык сораштылар, бер-берсен олы туй белән котладылар. Төрле анадан туган һәм бер атаныкы исәпләнелгән йөзләрчә балалар чыр-чу килеп бозда, яланда, өй араларында уйнап йөрделәр.

Бөтен Сары су буе бертуктаусыз шаулап, чыр-чу килеп торды. Олылар, балалар тавышына мал-туар тавышлары, анда-монда ишетелеп киткән быргы тавышлары кушылды. Коры, салкын һавада борыннарга таныш исләр килеп бәрелде. Һәркайда, һәркемдә бәйрәм шатлыгы, бәйрәм көтәренкелеге сизелде.

Яңа ай башына каршы кичтә Туман каган үзенең өлкән бичәсе өенә күченде. Күрекле бикә өенең тышкы ягына, ишек янындагы озын колгада чабып баручы алтын куян янында каган тугы[1] — тимер сөн кошы канатын җәеп җибәрде.

Бу көннәрдә күңелен борчу, кайгы һәм каршылыклы уйлар биләп алган булса да, Күрекле бикә үзенең изге ирен ягымлы йөз белән каршылады. Алар, ике арада әлерәк кенә берни булмаган кебек, башка вакытлардагыча мал-туар, ил-көн турында сүз алып бардылар. Каган өлкән бичә өенә аяк басып керү белән, бикәнең балалары — Албуганың бер сеңелесе белән ике энесе олуг аталары янына килеп бил бөктеләр, аңа озын гомер, бетмәс байлык, көч-куәт теләделәр. Ата кеше балаларның кайсын тезенә утыртты, кайсының башыннан, аркасыннан сыйпап куйды, һәркемгә үзе алып килгән бүләкләр, күчтәначләр бирде. Барлык аталы-аналы өйләрдәге кебек, өлкән бичә өендә дә үзара якынлык, җылылык урнашты.

Шулай да бу барыбер тулы, бөтен куаныч түгел иде — моны ата да, ана да, балалар да бик яхшы сизделәр. Беренче булып ата кеше тынычсызлык күрсәтте. Өлкән улының менә бу вакытта, атасы каган монда күченеп килгәндә өйдә булмавына ул шундук игътибар итте.

— Нишләптер минем олы колыным күренми,— диде ул Албуга турында.

— Егетләре белән Тарлавыкка китте.

— Олы туй алдыннан китмәсә дә ярар иде.

[1] Туг — байракның бер төре.

— Болай да өйдә күп юанды. Тегендә югалтып яталардыр, китим эле диде. Мин дә каршы килмәдем,— диде бикә аңлатып.— Синең улының кызлар янында түгел, ирләр янында дип Тунгак алып та тукып кына тора.

— Һы, Тунгак алып...— дип куйды Туман каган, мондый кеше турында беренче кат ишеткән кебек.

— Тунгак алыпны ул берсүзсез тыңлый,— диде бикә.— Теге чин кызын бирергә дә ул күндерде. Мин аны җибәрмәгән дә булыр идем, сизмичәрәк калдым. Ни әйтсәң дә, бала бит әле — акылы җитеп бетми. Күңеле дә кырылган чагы. Бер юлга атасы кичерер әле дип тә уйладым.

Күрекле бикә ашыкмыйча гына, тәмләп кенә сөйләде. Каган бик үк теләмичә генә тыңлады. Ике як өчен дә күңелсез булган нәрсәләрне аның хәзер кузгатып торасы килмәде. Шулай да ул, тупаслыгы аркасында, чак-чак кына эшне бозып ташламады.

— Теге кызны... Табылдыкны тапшырдыларммы соң аңа? — диде ул җайлы гына, шома гына сөйләнеп утырганда.

— Китерделәр,— диде бикә көттеребрәк.— Ул аны үзе белән алып китмәде. Күрәсең киләме? Чакыртыйммы?

— Юк, юк!— диде каган, кулын селтәп.

— Минем өемдә шул кызларыңны бераз онытып торсаң да ярамасмы?— диде бикә күрәләтә үртәлеп.

— Бетте. Берсенең дә кирәге юк,— дигән булды каган бик тиз килешеп.

— Углын да кирәкмиме?— диде бикә бер кызудан, усал-мәкерле көлемсерәп.

Туман каган ялт кына өлкән бичәсенә карап алды.

— Кем әйтте аны сиңа?

— Иртәгә — күренмеш. Син берни әйтмәдең,— диде бикә.— Кичерәсеңме берлеккә, әллә артыннан кеше җибәримме?

— Җибәрергә кирәк.

— Ярар, җибәрермен.

Икенче көнне өлкән бичә Күрекле бикә өендә күренмеш[1] башланды. Башка вакытларда күренмеш каганның үз өендә була иде. Бу юлы ул әнә күренмешне өлкән бичәсе өендә ясарга, аңа үзенең хөрмәтен күрсәтеп, бикәнең көндәшләре, туган-тумачалары алдында, бәкләр, бикәләр алдында Котлуг бәк кызының мәртәбәсен арттырырга булды.

Күренмешкә каганның барлык хатыннары, туганнары, якыннары чакырылды. Түшләренә кыйммәтле ташлар, алтын-көмешләр тагып, бүрекләренә кош каурыйлары кадап, бай киемле туган-тумача, ялт-йолт килеп, өй әйләнә аяк өсте басып тордылар. Өй уртасында, бөтен идәнне тутырып, дүрткел ак киез балкып ятты. Ак киезнең көньяк почмагында, төньякка таба караган килеш, каен агачыннан кырып ясалган һәм алтын белән бизәлгән биек ак тәхеттә каган янында өлкән бичә утырды.

Күрекле бикә өстенә иң яхшы, затлы киемнәрен кигән, иң яхшы, затлы бизәнү әйберләрен таккан иде: башында ал ефәк белән тышланган, кара кеш тотылган бүрек, өстендә яшел ефәк тышлы җиңел тун. Туман каган, бикәгә капма-каршы буларак, бөтенләй диярлек киенмәгән — аның таза, итләч тәненең билдән югарыгы өлеше шәп-шәрә иде. Ул бары йонын тышка калдырып ат тиресеннән тегелгән җирән, тупас яргак[2] ыштан кигән иде дә, муенына кыл җеп белән бүре тешләре таккан иде. Ә башында — бик катлаулы, хикмәтле бүрек. Ул бүрекнең ике ягыннан да үгез мөгезләре очлаеп тора, мөгезләр арасына ак бөркет каурыйлары кадалган иде. Шул ук вакытта мөгезләрне, каурыйларны

---

[1] Күренмеш — кабул итү мәҗлесе.
[2] Яргак — тире кием.

бергә тоташтырган һәм башны уратып алган алтын кыршау бер-берсенә уралган өч елан сыман итеп эшләнелгән. Еланнарның өч башы, маңгай турысыннан чыгып, як-якка ысылдап торалар иде.

Кояш һәм ай углы каган бөтен Сөн иленең патшасы гына түгел, ул шулай ук иң беренче дин башлыгы да иде. Ләкин көндәлек тормышта дин-йола эшләрен анасы Кортка-бикә һәм башка күп санлы камнар, күрәзәчеләр башкарганга, чынында ул андый нәрсәләр белән шөгыльләнми иде. Ул бары изге бәйрәм вакытларында, аеруча тантаналы мәҗлесләрдә генә үзенең кемлеген, нинди көч-куәткә ия булуын күрсәтергә ярата иде.

Каганны, өлкән бичәне котлау өчен беренче булып Куян ыруыннан Котлуг бәк керде. Уң аягы белән ак киезгә баскан килеш, тәхет алдында тезләнеп ул үзенең каганга буйсынуын белдерде. Шуннан соң ул йорт башына, аның өлкән бичәсенә бүләкләр тапшырды.

Котлуг бәктән соң Алан ыруы бәге, Алан ыруы бәгеннән соң Сөйбү бәге керде. Алар барысы да Туман каганга буйсыну белдерделәр, бүләкләр бирделәр.

Бүләкләрнең барысын да ак киез өстенә, каган белән өлкән бичәнең аяк астына куйдылар. Өрсәң очып китәрдәй җиңел, йомшак йонлы чибәр бүрекләр янына каен тузыннан, калын күннән бизәкләп ясалган авыр ук савытлары килеп ятты. Аның өстенә дөя йоны тукымасыннан тегелгән тупас дака[1] килеп капланды. Күп тә үтмәде, бер чабуы кайтарылып калган дака итәгенә кырып-йомшартып эшләнгән, эче-тышы кара катыш кызылга буялган зур агач табак килеп утырды. Табак янына гына алтын саплы, кынылы кылыч сузылды. Көтмәгәндә шул ук табак эченә, шапылдап, божра сыман итеп җыйналган, төйнәлгән кыл-аркан килеп төште. Кыл-аркан хатын-кызлар өчен тегелгән чигүле күлмәк астына яшеренергә дә өлгермәде, барысын да киң күкрәге белән каплап, ялт-йолт килеп, алтынлап бизәлгән тимер калкан килеп ятты.

Ишек төбендә кунакларны сул кул карачы Тук-Сыртлан каршы алып, карап тикшереп торды. Тук-Сыртлан карачы яныннан үткән кунакны уң кул карачы Бузбала каршы алды. Ул, каганга, бикәгә, өй эчендәге барлык кунакларга ишетелерлек итеп кычкырып, керүченең кемлеген, бүләккә нәрсәләр алып килүен әйтеп торды. Каганга буйсыну белдергән, бүләк китергән һәркемне үзләренең билгеле урыннарына озатып куя тордылар.

Котлау, бүләкләр тапшыру шактый озакка сузылды. Элегрәк, башка бәйрәм вакытларында каганның бичәләре, балалалары күренмешкә иң алдан кертеләләр иде. Бүген каган Тук-Сыртлан карачыга икенче төрлерәк эшләргә кушты. Ни өчен шулай кирәклеген аңлатып тормады — Тук-Сыртланга да, башкаларга да бу инде аңлашыла иде. Уң кул тучи бәк тәгин угланның изге бәйрәм алдыннан гына Тарлавыкка китеп баруын һәм нилектән китеп баруын урдада инде белмәгән кеше юк. Шулай ук кичәгенәк тәгин угланны кире борырга дип ашыгыч тартык[2] җибәрелүен дә күп кешеләр күреп калганнар иде.

Шулай итеп, барлык бәкләр кереп беткәч, Тук-Сыртлан карачы каган бичәләренең балаларын кертә башлады. Каган да, Күрекле бикә дә, ут йотып, тыннарып кысып, әледән-әле ишек ягына карап алдылар.

Менә соңгы бичә дә керде, соңгы балалар да керде. Бөтен өй эче дүрт күз белән көткән тәгин углан — уң кул тучи бәк Албуга күренмәде. Каган белән бикә бер-берсенә мәгънәле генә карашып алдылар һәм икесе берьюлы диярлек көрсенеп куйдылар.

[1] Дака — йоны тышка калдырып тегелгән тун.

[2] Тартык — каганга, бигә, бәккә буйсынган кешеләрне ашыгыч рәвештә каган (би, бәк) янына чакыртып алу өчен махсус җибәрелгән кеше, йомышчы.

*Дәвамы киләсе санда*

## Нурия Измайлова

### Өлешемә тигән көмешем

Кем икәнен кемнән сорыйсы юк,
Маңгайларга язып эленгән.
Кайберәүләр никтер маңгай каплап,
Башны аска басып йөриләр!
Нинди көннән, кайсы туфраклардан
Яралганын онытып китәләр,
Танымыйча, затлы почмакларда
Аналарын күрми китәләр...

Ә мин ачып йөрим маңгаемны —
Кем икәнне безнең күрсеннәр!
Дөньяның иң гүзәл җирләрендә
Безнең барлыкны да белсеннәр.
Дөньяның иң нурлы җирләрендә
Безнең күз нуры да төшәрлек.
Дөньяның иң җырлы җирләрендә
Җырыбыз бар, җырлап үтәрлек.
Шуңа «Кем?» дигәндә «Без!» дип торам
Һәм акларга торам исемне.
Бар кардәшкә уртак исем өчен
Мин җаваплы тоям үземне.
Аңа сүзләр тисә, җаным көя,
Аңа җилләр тисә, өши җан.
Җанымда да — маңгайдагы мөһер,
Җаным белән бергә тик чыгар.

Туфрак кардәшләрен кан кардәше,
Җан кардәше итеп карыйм мин.
Дөньяның иң шаулы җирләрендә
Үз туганнарымны таныйм мин.
Дөньяның иң затлы җирендә дә
Туганнардан затлы табылмас —
Иман нуры балкый йөзләрендә,
Телләрендә сайрый сандугач.
Ник танымыйм мин шул сандугачны!
Ник яшерим алтын-көмешем!
Өлешемә тигән көмешемне
Бөтен дөнья белән бүлешим!

## Өмет

Кесә тулы акча бетә,
Патша булып патша бетә.
Кайгы килсә, бәхет бетә,
Бетмәс төсле яшьлек бетә.
Кешеләрнең көче бетә,
эше бетә,
Бар да бетсә — кеше бетә...
Кеше һаман дөнья көтә,
Дөньяларга башлык итә,
Дөньяларны дер селкетә!
Бетсә бетә җегәрлеге,
Бетсә бетә түзәрлеге,
Егыла да торып китә —
Нидер аңа ярдәм итә,
Нидер аны алга илтә.

«Бар да бетте» дигәндә дә
Кешеләрдә нидер кала.—
Кемдер бөек — әйткән белеп:
«Өмет бар, дип,— тере җанда».
(«Өметсез шайтан» диләр дә,
Буладыр ул шайтанда да...)
Инде җан да бетә икән,
Димәк өмет кала сүнеп?

Юк! Сүнгән җан өстендә дә
Җем-җем килеп яна өмет.
Кешеләр зиратка бара,
Мәңгелеккә бара өмет.
Кешеләр елашып бара,
Өмет бара уйнап-көлеп.
Көннән-көнгә, күздән-күзгә,
Бездән — сезгә
Күчә-күчә кала өмет.

●

Яз тартамы, нан тартамы,
Бер кайтаммы шул илгә?
Әй тартылам өй артында
Рәнҗеп калган сиреньгә!

Төнлә килеп, «Әйдә!» диеп
Чәчемнән тарта минем.
Ничек шулай тоясың син,
Җаның бар мәллә, сирень?!

... Әллә минем җаным калды
Тамырларыңда синең?

## Күкләрдән торып...

Мин күкләрдән торып сөйдем сине.
Әйтмәс идем сиңа ни генә!
Ләкин аңламадың күкләр телен,
Сүз тапмадым җирләр телендә.

Еллар буйлап син дә килдең миңа:
Бәлки, инде китмәс идең дә,
Мәхәббәтем азсынды җир телен,
Сүз тапмадың күкләр телендә...

Мин талпынып тетрәп карап калдым,
Урын тапмый киттең күгемнән.
...Телләр бит ул — күңел көзгеләре,
Ялгышмаган телләр-күңелләр.

... Күктән торып сине сөймим инде.

## Гөлшат Зәйнашева

### Яшел үзәнләк

Туган якның гүзәл бер почмагы —
Идел буе. Яшел үзәнлек.
Баш очында сайрый тургайлары,
Моңы бәгыреңне өзәрлек.

Чит җирләргә китсәң, сагындырып
Искә төшә шушы үзәннәр.
Безнең бәхет монда дип кайтадыр
Бәхет эзләп дөнья гизгәннәр.

Яшел үзән буйлап икәү бергә
Төшик әле Идел буена.
Акчарлаклар парлап-парлап оча,
Дулкыннарга дулкын сыена.

Җәйләр җитсә, Идел буйларында
Яшел киңлек, яшел гүзәллек.
Сабый чакка алып китәр кебек,
Бигрәк серле яшел үзәнлек.

### Мәхәббәт эше

Парлашып яши, гөрләшеп яши,
Яратып яши бездә һәр кеше.
Бармы гашыйклар сезнең илләрдә?
Ничек куелган мәхәббәт эше?..

Бармы гашыйклар сезнең илләрдә?
Яучылар бармы, туйлар буламы?..
Үтисез икән хезмәт планын,
Үтәләме соң туйлар планы?..

Үтисез икән хезмәт планын,
Димәк, дусларым, уңышлар әйбәт.
Уңыш мул була, яшәсәң җирдә
Мәхәббәт белән хезмәтне бәйләп.

Парлашып яши, гөрләшеп яши,
Яратып яши бездә һәр кеше.
Бармы гашыйклар сезнең илләрдә,
Ничек куелган мәхәббәт эше?..

### Нишләргә?..

Сине сөюем — җүләрлек,
Беләм дә бит, нишләргә?
Акылга сыймаслык эшләр
Сыя кайчак хисләргә!

## Кышкы кичтә уйлану

Җылы өйдә ялгыз гына утыр'ганчы,
Бураннарда синең белән йөрсәм иде.
Кайгы килсә, ялгызым да күтәрермен,
Шатлыгымны синең белән бүлсәм иде.

Күкрәгемдә ярсып яна, каны кайнар —
Йөрәк түгел, йомарланган бер ут бары.
Алда микән, үтте микән бу гомернең
Иң бәхетле сәгатьләре, минутлары.

Бүген таңда уяндым да бер сискәндем,
Тәрәзәмне кемдер килеп какты кебек.
Һич ышанмыйм аерылуга, көтәм сине,
Хыялымның офыклары якты кебек.

Җылы өйдә ялгыз гына утырганчы,
Бураннарда синең белән йөрсәм иде.
Кайгы килсә, ялгызым да күтәрермен,
Шатлыгымны синең белән бүлсәм иде.

## Ике чишмә бергә кушылган

Тау астында йөрим җәйге таңда,
Ике чишмә бергә кушылган.
Бер ялгызым юлга чыгасым бар,
Башлап китим мәллә шушыннан?

Ике гашыйк җаны кушылгандай,
Ике чишмә бергә юл алган.
Уйга калып йөрим тау астында,
Минем барыр юллар чуалган.

Ике чишмә бергә агып бара,
Челтер-челтер көмеш тавышы.
Чишмәләрдән көчсез булырмыни
Газиз башкайлары сау кеше?

Сере бардыр бу ике чишмәнең,
Юккамыни алар кушылган.
Чишмә юлы буйлап үз юлымны
Башлап китим әле шушыннан...

Мәрзия Фәйзуллина

# АВЫЛДАН ХАТЛАР

## Бригадир

Бригадирым Галләм фронтка китте,
Эш ярыйсы аннан башка да.
Бер аяксыз кайткан Фатих абый
Аның эшен хәзер башкара.

Ул, билгеле инде, аксак булгач,
Көннәр буе йөреп алҗый да,
Шуңа күрә, мөмкин булган саен,
Ат өстенә менеп хәл җыя.

Атлануга, ияр баскычына
Иплэп баса сыңар аягын.
Аннан җайлап ияр кырыена
Бәйләп куя култык таягын...

Кирәклеген аның сизгән кебек
Янга бик тиз килеп җитә ул.
Күңелләрне җылы сүзе белән
Куандырып, сыйпап китә ул.

Ул өйрәтә безне сыгылмаска,
Кырыс, чыдам, сабыр булырга —
Сыерларны җигеп җир сөрергә,
Урак белән иген урырга...

Беркөн күрдем тыңлаганын аның
Тургай җырын арыш кырында.
Мин гаҗәпкә калдым, әти, хәтта,
Язып үтәм шуның турында:

Басып тыңлый — сыңар аягында!
Бер аягы югын онытып...
Әйтерсең лә ялгыз имән тора
Тамырларын җиргә ныгытып.

## Әниемнең тапкырлыгы

«Тигр»ларның берсен тончыктырган
Безнең солдатларның батыры...
Хәзер трофей булып безгә кайткач,
Суыртып су куа моторы.

Әни әйтә: — Улым, бу мотор, — ди,
Йөз карасын юа үзенең...
Дусларыңа, эти, укып күрсәт
Тапкырлыгын әни сүзенең.

## Оятыннан кояш кызара

Таң-таң ата, назлы кочаклашып
Тук башаклар салмак тирбәлә.
Шул чагында туган хисләремне
Шушы хатка язып җибәрәм.

Алтын керфек аша кояш карый
Эшкә бара торган кызларга.
Тагын соңга калып торганмын, дип,
Оятыннан үзе кызара.

## Ике зәңгәр чәчәк кабердә

Мин зиратта... Үтим теләгеңне...
Бигрәк авыр йөрәк-бәгырьгә —
Әбкәм кабере... Ике сагышлы күз —
Ике зәңгәр чәчәк кабердә:
Әйтерсең лә алар, бу чәчәкләр —
Әбиемнең зәңгәр күзләре.
Әтиеңә миннән сәлам яз, дип
Карап тора кебек үзләре.

Әти җаным, кочакладым бүген
Син утырткан бөдрә каенны
Һәм тапшырдым газиз әңкәеңә
Сагынуыңны, бетмәс кайгыңны.

Күзләремнән тамган тамчылардан
Чәчәкләр дә бераз чыланды.
Искә төште әбкәм әйтән сүзләр:
— Әй табигать, бирче чыдамны!

## Бал кортлары да калышмый

— Печәнгә төшәсезме? — дип
Сорыйсың син хатыңда...
Төштек. Бу хат шунда күргән
Бер бал корты хакында.

Без таңнан печәнгә киттек,
Арттан барды колын да.
Гаҗәп хәл күрдек, алаша
Алып килгәч болынга:

Бер бал корты кайтмый калган
Бирелә, таңны көтеп.
Кыңгырау чәчәге эчен
Үзенә чатыр итеп.

Аны күргәч барыбыз да
Куйдык бераз елмаеп.
Ул бер чәчәктән бал алгач
Очып китте юл алып.

Бал корты таңнан бал ташый —
Шуңа тырыша, беләм:
Госпитальдәге солдатлар
Чәй эчәр шул бал белән!

*1981*

## Венера Туктарова

### Бөреләр

●

Елга белми ялның нәрсә икәнен,
Белми үзенең нинди исем йөрткәнен;
Көне-төне ашкына ул диңгезгә
Һәм елмая, табышмак, дип, мин сезгә.

●

Җилләр ачып тора, диярсең,
Гомер китабының битләрен,
Шул китапка куяр идем, кешелек,
Синең уйлап тапкан бикләрең.

●

Чакырып тормаса Кешене
биеклек,
Булыр идеме дөньяда
бөеклек?

●

Көлә язмыш — түзәм мин,
Көлә алган чакларымда
Язмыш түгел, җиңәм — мин.

### Язгы этюд

Кояшны бөреләр
Капламый бер-береннән.

●

Тормыш көймәсендә күптән
Чайкалам, йөзәм;
«Көймә ничек чыдый?» — дисең,
Мин дә бит түзәм.

### Эшкә мәдхия

Башкалар сиңа гашыйк, дип,
Яратып йөрдем,
Мәхәббәткә лаеклы син,
Соңрак белдем.

— Ялгышмыйсыңмы соң?— диеп
Көлеп карадың.

Синсез мин чын кеше түгел,
Шуны аңладым.

Синсез ял юк, олы бәхет...
Ә ипидә — тәм.
Син — эштән дә кадерлерәк
Юк җирдә бәйрәм.

●

Куркам шуңа: ишеттем бит,
Синең суың тирән, имеш.
— Тагын ишет: янәшәмдә
Ага әнә тездән инеш.

●

Каенга гашыйк ак кар.
Апрель дәшә: — Алып китәм,
Каеныңа карап кал.

●

Җәй буена бар яшеллек
Сусады, янып көйде.
Сазлык мескен үз гомерендә
Беренче тапкыр көлде.

●

Мин бу чиксез дөньяның
тик Җирен күреп китәм.
Үзем... йолдызларга карап,
хыял йомгагы сүтәм.

●

Берәү Кояштан көләм дип,
Якты көндә ут алды.
Ут аның йөзенә карап:
— Сүндер мине! — дип янды.

●

Эзләмимен кайгы, шатлык:
Алар мине үзе таба;
Кояш та бит Җиргә шулай
Чәчәк түши, я кар яба.

## Белфаст

Анда — төрмә, анда тоткыннар:
— ИРЕК! — дип ачтан үлә.
Анда һәр көн, күктә түгел,
Җирдә бер Йолдыз сүнә.

●

Утларда яныпмы
Җир шулай көл булган,
Суларда калыпмы
Җир шулай ком булган?

Роза Хафизова

# СӨЕНЕЧЛЕ ХӘБӘР

хикәя



Атна буе инде буран котыра. Ишегаллары, урам як коймалары тау-тау булып өелгән көрт астында калган. Буран исә һаман котырына, ак ялын уйнаклатып тәрәзә пыялаларына сарыла, морҗага кереп кемнедер тирги, үзе белән көч алышырга тышка чакыра.

Безнең өйдә җылы, рәхәт. Мич кашагасына утырткан сукыр лампадан бүлмәгә сүрән генә яктылык сирпелә. Әби, чуар яулыгын артка чөеп бәйләгән дә, мич буендагы утыргычка кабасын көйләп, йон эрли. Аның орчыгы, буран белән узышып, зыр-зыр әйләнә. Аш урынын җыеп алгач, кайнар су белән сап-сары итеп юган өстәл артында без дүрт бала рәттән тезелеп дәрес карыйбыз. Мин тырыша-тырыша мәсьәлә чишәм. «Бер шәһәрдән икенче шәһәргә кара-каршы ике поезд чыккан...» Нинди була икән ул шәһәрләр? Сугыш башлангач, күрше Тәгъзимә әбиләргә Радикны кайтардылар. Тәгъзимә әби белән бертуганның оныгы, ди ул. Алар Киевта яшәгәннәр. Әтисе сугышта кызыл командир икән. Әнисе Радикны кайтарды да үзе хәрби заводка эшкә китте. Радик хәзер безнең класста укый. Шәһәрнең нинди икәнен безгә ул сөйләде. Анда катлы-катлы йортлар, ди. Бер Киевка гына безнең авыл хәтле меңләгән авыл сыеп бетәсе, ди. Ә безнең авыл, мактанып әйтүем түгел, кечкенәләрдән саналмый. Читтән килгән бер кеше аның зурлыгына хәйран кала. Колхозда өч бригада. Менә шундый меңләгән авыл сыярлык булгач, чынлап та зурдыр инде ул шәһәр! Нинди соң әле мәсьәләнең шарты. Әйе, «Бер шәһәрдән икенче шәһәргә кара-каршы ике поезд чыккан...»

— Апай, дим, апай, әтәч ясап бир әле!

Кечкенә сеңелем Фәһимә өстәлнең каршы башыннан миңа кәгазь кисәге суза. Ул әле укымаса да, безнең белән утырып, дәрес караган булып кыйлана. Аның гозерен үтәми ярамый. Әби әйтә: «Ул ятим үсә, ата-ана назын күрми, кыерсытмагыз аны»,— ди. Дөрес тә шул, әтиебез икенче ел инде сугышта, әниебезне узган ел урман кисәргә киткән җиреннән агач басып үтерде...

Анысы без аңа җил-яңгыр тидермибез тидерүен. Әнә, хәзер дә Фәһимәнең миңа кәгазь сузуы булды, мин кайчан очрашуларын һич чутлап чыгара алмый азапланган поездларны читкә этәрдем дә Фәһимә сеңелемә бик матур әтәч сурәте ясарга керештем. Кечкенәләргә шул гына кирәк тә: өчесе өч яктан иңемә сарылдылар. Юкса инде, энеләрем алай бик кечкенә дә түгел. Фатихы — өченчедә, Зарифы — беренчедә укый. Юк, рәсем ясау дигәндә өчесе дә бердәй үлеп китәләр. Миңа да

рәхәт. Туйдырып бетерде инде ул мәсьәлә чишүләр. Безнең уен белән мавыгу әбигә генә ошап җитми. Ул орчыгын зырылдатып җибәрә дә кечкенәләрне кисәтә: «Ярый, ярый, тутагызга комачауламагыз, сурәтне иртәгә төшерер ул, бүген хисабын чутласын, иртәгә сабагына барасы бар»,— ди. Дөрес әйтә, билгеле. Әмма бер башлагач, әтәчне ясап бетерми дә булмый. Әнә, кикриген генә буйыйсы калды...

Сукыр лампа «мелт-мелт» итә. Бу аның «керосиным бетә, эшлисе эшләрегезне эшләп калыгыз»,— дип кисәтүе. Минем әле мәсьәлә чишелмәгән.

Шулчак капка шыгырдап ачылды. Ишегалдында Рекс өреп җибәрде. Без тынып калдык. «Мондый буранлы салкын төндә кем йөрер икән? Әллә соң әтидән хат-хәбәр китерделәрме?»

Әби, орчыгын бер читкә куеп, ишек ачарга чыкты. Ишектә башта калын табанлы киез итекләр, сары тун чабуы, аннары аларның иясе — аргы очның Хәсәнә апа күренде. Ул башына саргылт шәл бөркәнгән, билен тун өстеннән юан бау белән буып куйган. Топ итеп килеп керде дә, безгә карап, ишек катында тукталып калды.

Төнге кунак мондый салкын буранда тикмәгә генә килеп йөрмәс, без, сагаеп, Хәсәнә апага карап калдык. Ул башта шәлен чишеп артка чөйде, аннары тунын ычкындырып җибәрде һәм мич буеннан әби этәргән урындыкка килеп утырды.

— Әтиегез яныннан кеше кайткан, балалар, керәшен авылының Микулай. Әтиегезне күрдем, дип әйтеп әйтә, ди. Дон елгасын бергә кичкәннәр. Әтиегезнең бармаклары шешкән булган...— Хәсәнә апа сөйли дә сөйли. Без аның сүзен бүлмәс өчен тын алырга да куркып утырабыз. Минем баштан ялтырап, йөгерек уй узды: «Бармаклары шешкәч, мылтык тота алмый инде ул, бәлки әле кайтарырлар да?» Уемны кунакның дулкынланган тавышы бүлә:— Безнекеләр белән бергә киткәннәр иде бит. Түбән очның Зыятдин да алар белән иде. Зыятдин Сәкинәсе аны, базарда очратып, бәйнә-бәйнә барын да сорашкан...— Хәсәнә апа, шәл астыннан яулык очын чыгарып, борын тирәсен сөртеп алды. Шулчак Фәһимә өтәләнә-кабалана урындыктан төште дә кунакка килеп сарылды.

— Безнең әти кайтам дигәнме? Шикәр дә алып кайтамы?

— Кайтыр, балам, кайтыр.— Хәсәнә апа Фәһимәнең башыннан сыйпады.

Әбием, мичкә аркасы белән сөялеп баскан килеш, озак кына эндәшми торды, аннары офтанып:

— Әниләре исән булса, Микулай янына барып, үзе сорашып кайтыр иде дә бит,— дип әйтеп куйды.

— Әби, Фатих белән икәү барып кайтыйк. Берсекөнгә — ял,— дип кабаланып әйттем. Күкрәк читлегендә йөрәгем кызу-кызу тибә башлады. Әйтерсең лә, әтинең үзен күрергә барасы!

Фатих йөгереп килеп әбигә сарылды:

— Әби, дим, апам белән икәү барыйк...

Хәсәнә апа да безне яклады.

— Барсыннар. Минъямал абыстай, барсыннар. Өч чакрым араны гына узарлык инде алар.

Әби, икеләнеп, алай итте, болай итте, ниһаять, җибәрергә риза булды.

*

* *

...Әбием безне авылны чыкканчы озата барды. Ул таягына таянып әкрен генә атлый. Фатих белән безнең йөрәк түзми, тизрәк чабасы, урманга җитәсе килә. Без барасы керәшен авылы урманның артында ук

Анда барып житсәк, Микулай дәдәйне табабыз да табабыз инде.

Уф, жилкапкага життек. Әби таягына таянып баскан килеш дога кылды да:

— Иә, балалар, аллага тапшырдык, исән-сау йөреп кайтыгыз,— дип, басу капкасы янында басып калды.

Без, Фатих белән кулга-кул тотышып, алга йөгердек. Аякларыбызда жылы йон оекбашлар белән өр-яңа чабаталар. Әби ул чабаталарны урта урамның Шәйхулла бабайдан үрдереп алдырган иде. Болай үзе, олтанлы булса да, киез итекләребез дә бар барын. Тик әби юлга чабата жиңел, ди. Дөрес әйтә: аяклар үзләреннән үзләре атлыйлар.

Әнә, ерак та түгел, урман караеп күренә. Урман артыннан иренеп кенә кояш күтәрелеп килә. Тирә-юньдә ник бер жан иясе булсын. Тыптын, ап-ак кар дәрьясы. Өстән карасаң, Фатих белән без, мөгаен, шул дәрьяга төшкән ком бөртеге кебек кенә күренәбездер. Күңелләр ашкына! Икебез ике чана табаны эзенә төшәбез дә алга ыргылабыз. Кем кемне уза! Жил, безне тыярга теләгәндәй, бишмәт чабуларын кайтара. Аяк астында кар шыгырдый.

Уф! Ардык. Жан-тиргә баттык. Туктап сулыш алабыз. Фатих бүрек колакчыннарын ычкындырып жибәрә. Мин шәлне бушатыбрак бәйлим. Әнә, урманга якын гына калган инде. Кояш та урманның бу ягына чыгып, аксыл күк йөзендә эленеп тора. Нурлары кар бөртекләренә кагылган мәлдә ак юрган өстендә нәни йолдызлар кабына.

Якын гына булып күренсә дә, урман ерак икән. Барабыз, барабыз, һаман барып житеп булмый. Жил дә каршы исә. Башта ул салмак кына, ялмана-ялмана гына исә иде, урманга якынайган саен көчәя барды. Әнә, карны буразна-буразна тәгәрәтеп каядыр куалый. Бөтереп алып, әйләндерә-тулгандыра да, янадан үз урынына кайтарып яткыра.

Бара торгач, урманга да килеп життек. Монда тыныч. Агачларның жилдә гамьнәре юк, кар бүрекләрен кигәннәр дә йокымсырап тик утыралар. Урман эче яп-якты. Игътибарлап карасаң, агач төпләрендә эреле-ваклы эзләр күренә. Жәнлек эзләре. Бүре-фәлән генә очрый күрмәсен. Аучылар сугышка китеп беткәч, урманда бүреләр бик үрчегән, диләр.

Мин, каушавымны сиздермәскә теләп, Фатихка күтәрелеп карыйм. Ул да никтер шомланып калган кебек. Мин булып, мин курыкканны, ул курка да курка инде. Кызганыч, берәр таяк-мазар алырга башка килмәгән.

Мин Фатихны кулыннан житәкләдем, һәм без шыпырт кына алга атладык. Урманны чыкканчы үр менәсе. Ярый әле, юл яхшы. Кар ерып барасы булса, нишләр идек. Алда кинәт нидер шытырдап куйды. Без куркудан бер-беребезгә сыенып туктап калдык. Ичмасам, борын төртер куыш та юк бит. Тын да алмый торабыз. Үр артыннан кеше тавышлары, чана шыгырдавы ишетелгән кебек булды.

— Йөкчеләр ул!— Энем шатланып сикергәләде. Әнә, утынчылар икән! Аргы очның өч-дүрт хатын бәләкәй чаналарга жигелгән, чыбык-чабык алып кайталар. Үрдән түбән төшәсе булгач, аларга рәхәт, утын төялгән чаналарны тартасы да юк, үзләреннән-үзләре түбән төшәләр.

Без, аларга юл биреп, читкәрәк тайпылдык. Урман инде баягыча шомлы булып тоелмады. Бер без генә түгел икән әле монда: бүреләрнең дә жаны бар, кеше тавышларын ишеткәч, койрыкларын кысып яталардыр әле.

Шулай да безгә кызурак атларга кирәк. Әле бит кире кайтасы бар. «Кышкы көн кыска була ул, яктыда урманны чыгып калыгыз»— диде әбием.

Никадәр генә ашыксак та, без авылга көн төшкә авышкач кына килеп кердек.

Бу авылның да, безнеке кебек, кар астыннан моржалары гына калкып утыра. Урамына килеп кергәч, беравык кая барырга, Микулай дә-

дәйнең йортын кемнән сорарга белми аптырап тордык. Урамда беркем дә юк, хәтта этләр өргәне дә ишетелми. Әллә авыллары белән йокыдан да уянмаганнар инде?!

Ихатасыз-капкасыз бер йорт янында озак кына тордык та, тәвәккәлләп, ишеген тарттык. Ишекне ябарга да өлгермәдек, мич башыннан ябык чырайлы, озын буйлы чандыр бер хатын шуып төште.

— Кем бар анда?!

Ул безнең җавапны да көтми, куллары белән кош кугандай селтәнеп, безне кире ишеккә кысрыклады.

— Юк, юк, бирер әйберем юк. Йөрмәгез, барыгыз, бар!— Хатын безне төрткәләп ишектән чыгарып җибәрде.

Гарьлегемнән күземә яшьләр килде: бу түти безне хәерчеләр дип куалап җибәрде ич! Энемнең дә хәтере калды, ул, йөзен җыерып, берни эндәшми тора. Мин бияләй аркасы белән күзләремне сөртеп, җыламаска тырышам. Апа кеше лә мин, үзеңнән ике яшь кече энеңә күз яше күрсәтеп тору ярамас. Тик күз яшьләрен һич тыеп булмый, алар үзләреннән-үзләре ага.

Инде нишләргә белми аптырап торганда, күрше йорттан көянтә-чиләк күтәргән бер апа килеп чыкты. Аның янына барырга да, бармаска да белми, икеләнеп тик торабыз. Ул арада әлеге апа үзе безгә таба атлады.

— Чит авыллар димме?

— Ие. Без Микулай дәдәйне эзләп килгән иек.

— Кайсы Микулай ул? Бездә күбәү бит алар.

— Теге, әле яңа гына сугыштан кайтканы.— Апаның ягымлы йөзенә карап мин тизрәк әйтеп калырга ашыктым.— Ул безнең әти белән бергә сугышкан. Әби авылыннан без. Мирсәгыйть балалары...

Апа көянтә-чиләкләрен кар өстенә куйды.

— Гөргөри Микуласы кирәк инде сезгә. Узган атнада гына кайтты ул. Бер кулын өздереп... Әйдәгез, күрсәтәм өйләрен,— диде. Хатынның өстендә бил тиңентен бөрмәле киң кара бишмәт. Ул кызу-кызу атлап бара, без аның артыннан көчкә җитешәбез.

— Ник әниегез килмәде соң?

— Әниебезне узган ел җирләдек, агач басты... Әбиебез карт, ерак юлга чыга алмый.

Апа, адымын әкренәйтеп, безгә текәлеп карап куйды. Шактый баргач, шундый ук ихатасыз тәбәнәк бер йортның ишеген какты.

— Микулай, Анка, мин сезгә кунаклар алып килдем.

Безгә ияреп тыштан бер кочак салкын керде, һәм керә-керешкә ак пар мендәренә әйләнеп, бүлмәдә таралды. Пар эченнән йөзеп чыккандай, каршыбызда юка гәүдәле бер хатын күренде:

— Әйдүк, түргә узыгыз, Мәтрүнә, кунакларны кемнәр дип белик соң?— диде.

— Күрше авыллар. Микулайдан этиләре турында сорашырга килгәннәр. Этиләре Мирсәгыйть атлы икән.

Хуҗа хатын никтер тынычсызлангандай булды һәм такта белән бүленгән түр якка карап:

— Микулай, синең янга килгәннәр. Мирсәгыйть балалары,— дип эндәште.

Бүлмәдән буш җиңен бил каешына кыстырган аксыл чырайлы, озын буйлы агай чыкты.

— Карыйк, карыйк, нинди кунаклар килгән икән безгә? — дип сөйләнде ул. Тавышы да бик ягымлы икән — безнең әти яныннан кайткан ла ул. Мин, аны-моны абайлаганчы, Фатих атылып барып аның аягыннан кочаклады. Әйтерсең, үз әтиебезне күргән. Мин уңайсызланып Фатихның җилкәсеннән тарттым.

— Безнең әти түгел ич ул!

Фатих аңа ябышкан да тынган.

Микулай дәдәй анын бүреген салдырып мич башына куйды.

— Әйдә, әйдә, егет, түрдән үз. Әтиең бик сагынып сөйли иде синең турыда. Менә нинди дәү булгансың икән.

Хуҗалар безне чишендереп, түр якка алып чыктылар. Мин Микулай дәдәйгә алдан ук әзерләп куйган соравымны бирдем.

— Син, Микула дәдәй, сугышта безнең әтине күргәнсең икән. Шуны белешергә дип килгән идек.

Микула дәдәй бераз уйланып торды.

— Күрдем, балалар, соңгы сугышка әтиегез белән бергә кердек. Мин менә кулны өздереп кайттым. Ә әтиегез...— агай никтер тотлыгып калды, исән кулы белән муенын сыпырып алды.— Әтиегез исән-сау, сезгә сәлам әйтте. Сәлам генә түгел, менә бумажнигын да биреп җибәрде әле,— диде.

Бу шатлыклы хәбәр безне әллә нишләтте. Соң инде, дүртенче ай хәбәре-хәтере юк ич. Болай яныннан кеше кайткач, исән дә исән инде ул!

— Яле, карчык, әтиләренең бумажнигын бирик балаларына. Үзем барырга җыена идем сезгә, менә һаман ныклап аякка баскан юк. Әниегезнең вафат булуын да ишеттек. Ничек көн итәсез соң?

Әнине телгә алу ярамадымы, Микулай дәдәйнең әти кебек иркәләп сөйләшүеме, үзем дә белмим, мин тик торганда үксеп елап җибәрдем. Еламаска итәм — булмый, күземнән чишмә булып яшь коела. Фатих, Микула дәдәй янына баскан да, анын түшендәге медальләрне барлый.

— Я, я, бала, тынычлан,— дип баштан сыйпады хуҗа апа.

Әтинең безгә дип җибәргән әйберләре бер бумажник кына түгел икән — бәләкәй генә төенчек. Мин күз яшьләремне битемнән сөртеп, кулыма төенчекне алдым. Иплап кенә аны чишеп җибәрдем. Төенчектән әтинең әллә кайчаннан безгә бик таныш булган, таушалып беткән күн бумажнигы, өч медале килеп чыкты. Мин абайлаганчы, энем медальләрне элактереп тә алды.

— Ник әти аларны үзе тагып йөрми, безгә җибәргән?

Шундый гади сорау да ир кешене каушатыр икән, Микулай дәдәй ни әйтергә белми, ык-мык итеп, энемнең башыннан сыйпады.

— Сиңа күрсәтәсе килгәндер. Батырлыгы өчен бирелгән медальләр ул. Әтиегез бик кыю кеше,— диде.

Мин әтинең бумажнигын ачтым. Эченнән өч сум акча, сугышка хәтле безнең бөтен гаилә белән төшкән фотокарточкабыз һәм без язган берничә хат килеп чыкты.

— Ә боларны ник җибәрде?— дип аптырап сорадым мин.— Бумажниксыз нишли инде ул үзе?

— Һи, кызым, сугышта бумажник ник кирәк ул?— диде Микулай дәдәй, үзе хатыны белән тиз генә күзгә-күз карашып алды.

— Анысы да бар инде,— дидем мин. Никтер йөрәгем кысып алды. Тик торганда әти бу әйберләрне җибәрмәс иде. Микулай дәдәйнең дә күзләре безгә туры карамый, нидер яшерә кебек иде. Әллә соң?..

Мин, бармакларым белән чытырдатып тотып, әтинең бумажнигын күкрәгемә кыстым. Өзгәләнеп кабат сорадым:

— Әтием чынлап та исәнме?

— Әйттем ич инде! — диде Микулай дәдәй, үзе өзелгән, иңбашын исән кулы белән сыйпап алды. Йөзен җыерды. Ярасы сызлый башлады, ахры.

— Рәхмәт инде, Микулай дәдәй,— дидем мин урынымнан торып.— Без кузгалыйк инде, яктыда урманны чыгарга кирәк.

Микулай дәдәй безне урманны чыкканчы озатып куйды. Фатих анын исән кулына асылынган да туктаусыз сөйләнә:

— Микулай дәдәй, әти кайткач, без аның белән үрдәк атарга барабыз. Бах... бах... бах... бер юлы өч чүрәкәйне әти чөеп кенә төшерә.

— Барасыз, барасыз,— диде Микулай дәдәй, аның сүзен җөпләп. Ә минем күңелемне ниндидер шик кимерә. Мин, Микулай дәдәйнең яшерен серен белергә теләгәндәй, аның йөзенә текәлеп-текәлеп карыйм. Бер дә шикләнер урын юк кебек. Әтинең кайтасын ул бик ышандырып әйтә. Тик әти нигә бумажнигын җибәрде икән?

— Микулай дәдәй, әти кайткач, син безгә килерсеңме?

— Киләм, килмимме соң! Әтиегез белән гел бергә булдык, дуслар идек. Бер-берәңнең гаиләсе турында кайгыртырга дигән сүзебез дә бар.

Урман авызында Микулай дәдәй безнең арттан озак карап калды. Без, энем белән җитәкләнешеп, ялтырап яткан чана юлы буйлап авылга таба йөгердек. Әтинең исән хәбәрен тизрәк әбигә җиткерәсе килә иде.

Әбием безне капка төбенә чыгып каршы алды. Өйгә кергәнне дә көтмичә, энем кесәсеннән әтинең медальләрен чыгарды.

— Менә, әби, әтинең медальләре. Әллә ничә немецны берьюлы бәреп кенә салган ул. Шуңа күрә биргәннәр. Аннары бумажнигын җибәргән әле, өч сум акчасы да бар.

Фатихның сүзләрен ишетүгә, әбием хәлсезләнеп, болдыр баганасына сөялде.

Без атылып өйгә кердек. Мин әбидән бигрәк үз-үземне ышандырырга теләп:

— Әти исән, әби. Микулай дәдәйне озатып калган,— дидем.

— Микулай дәдәгез үзе килермен димәдеме соң?

— Килә, менә җәй генә җитсен, әти кайткач та килә,— дип такылдады Фатих.

Әби яулык чите белән күзләрен сөртте, аннары мич буена утырып, озаклап дога кылды. Әтинең бумажнигын, медальләрен кулына алып карап торды.

— Җыеп куйыйк боларны, оланнар, югалмасын, әтиегез төсе... үскәч, бер алып карарсыз,— диде, һәм бумажник белән медальләрне барын бергә төйнәп, сандык төбенә яшерде.

Әтинең үлеме турындагы кара мөһерле кәгазьнең дә инде өч айдан бирле шул сандык төбендә ятуын без, балалар, белми идек әле.

## Укучының күңел дәфтәренә

**Бенгаль мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Чокыр казыганы юк, ә күлне тиргәп яши.*
*Нинди генә усал эт тә тезгәчә генә тешли.*
*«Бозау чагым булмады» дип карт сыер мөгри икән.*
*Биргән таш та синеке, төшкән теш тә синеке.*
*Юлбарыс урманны саклый, ә юлбарысны — урман.*
*Телсезнең дошманы булмый.*
*Остазы телсез, шәкерте чукрак.*
*Кулдагы алтынчы бармак ул.*
*Язуны өч нәрсә яза: акыл, кара һәм каләм.*
*Начар уллар туса да, начар аналар булмый.*
*Киеменә күрә сыйгы.*
*Күл астында ут пыскый.*
*Йөри белмәсәң — үрмәләп яшә.*
*Кулын күтәреп сәламен бирә, шул ук кул белән бугазны буа.*

## Фирдәвес Әһлиуллина

# ГӨЛБАКЧАДА

ЯРЫМӘКИЯТ

Яшәгән ди дөньяда бер бакчачы.

Кемнәрдер эшче, җырчы яки язучы була, ә ул бары тик гади бакчачы гына булган. Ул төрле-төрле гөлләр үстергән, аларга күңелен салган, бар вакытын, гомерен аларга багышлаган. Иртән торып, гөлләренең төпләрен йомшарткан, су сипкән.

Гөлләре гаҗәп күп булса да, ул аларны, бер иртәдә дә, кисеп, кәрзингә тутырмаган, базарга алып чыгып, үткән-сүткәнгә тәкъдим итеп, кыйммәтрәк бәягә сату турында уйламаган. Мондый уйлар аның башына да килмәгән.

Түтәлләрдән чүп үләннәрен утаганда ул, гөлләренә сокланып, җанына ял, шифа тапкан, үткән гомерен искә алган. Ә үткәннәрне хәтерләү үзе бер шатлык бит ул, чөнки яман хәлләр оныттыла тора, бары тик яхшы, изге мизгелләр генә күңелдә якты утраулар булып озак саклана.

Әмма бакчачы шулай да әле тулысынча бәхетле була алмаган, чөнки аның бер хыялы бар икән. Ул төннәр буе йокламыйча шул турыда уйлана торган булган. Аның җаны ниндидер бер гүзәл чәчәкне эзләгән, көткән. Ниндирәк кыяфәттә ул гөл, ничек ул аны эзләп табар — бакчачы моны үзе дә әле төгәл белмәгән, әмма аның йөрәгендә олы бер өмет хисе яшәгән.

...Бер көнне сукмак буйлап атлаганда ул аулак почмактагы ташлар арасында шытып чыккан бер үсентене күрә. Исеме билгесез үлән булса да, өзмәгән ул аны, калдырган һәм, ниһаять, бернича көннән соң шул урынга яңадан юлыгып, анда гүзәл чәчәк күргән. Ул — Гөлчәчәк булган. Бу чәчәк дөньяда булган бар хисләрне үзенә җыйган. Ул, тирәюньгә нур сибеп, балкып торган. Хуш исе бөтен бакчага таралган.

Гөлләрнең дә үз тормышлары бар икән... Гөлчәчәккә Кычыткан гашыйк булган. Бакчачы моны сизмәгән, белгеле. Кычытканны, бияләй киеп, өзеп ташламакчы булган, ләкин Гөлчәчәк шунда дустына бөтен гәүдәсе белән сарылган. Өзсәләр — икесен бергә харап итсеннәр. Бакчачы Гөлчәчәкне җәлләгән, өзми калдырган.

Белмим, Гөлчәчәк ничек шулай үзенең тормышын Кычытканга багышлап, аның белән кавышырга булгандыр. Бәлки язның иртәләре бигрәк тә гүзәл, күк йөзе зәп-зәңгәр, болытлар ап-ак, яфраклар ямьяшел, ә үзе яшь һәм чибәр булгангадыр, бәлки инде акыллы, нык тамырлы Кычытканга ышыкланмакчы булгандыр. Кем белә...

Гөлчәчәк көннән-көн үрчи бара икән. Хәзер инде ярты бакчаны диярлек биләп алган аның балалары. Бакчачыга күршеләре «файдалы» киңәшләр дә бирә башлаган:

— Сез, беләсезме, череп баеый аласыз бит хәзер, авызыгызны гына ачып калмагыз. Гөлчәчәк мае гаять кыйммәт тора, аңардан затлы хуш-

буй ясыйлар. Сез аларны сатыгыз! Бик сирәк нәрсә бит ул — гөлчәчәк яфрагы.

Ләкин бакчачы бу сүзләргә колак салмаган, үзенчә яшәвен дәвам иткән.

Җир өстендә җәй бәйрәм иткән чак икән. Бакча шау чәчәккә күмелгән. Кычыткан Гөлчәчәкнең нәфислегенә сокланган, җәйгә ямь өстәргә омтылып булса кирәк, үзе дә чәчәк атып караган. Ләкин аның чәчәкләре бик вак, төссез һәм иссез булып чыккан.

Кычытканның күңеле кимсенгән, әрнегән. Шау чәчәккә күмелгән бакчада ул югалып калган. Моны күреп, Гөлчәчәк аңардан йөз чөергән, хурланган.

— Син миңа тиң түгел. Бар, кычытканнарың янына күчеп кит,— дип, ул кайчандыр кадерле булган дустын куа башлаган.

Әмма күләгәдә, караңгы почмакларда яки чокырларда үсеп утырган кычыткан туганнарының хәзер аны үз араларына аласылары килмәгән. «Сиңа Гөлчәчәк кирәк булган иде бит»,— диеп, усал карашлар ташлап, аңардан көлгәннәр генә.

Шулай итеп, Кычыткан япа-ялгызы калган. Тирә-юньдә һәрнәрсә хозур, шат, күңелле булган чакта аңа тагы да ямансурак икән.

Шул чакны Кычытканны Ромашка мәхәббәте коткарган. Бакчага кайдан килеп эләккән булгандыр инде ул. Аны утыртучы, хәстәрләүче дә булмаган. Ә шулай да ул ярыйсы гына матур булып үскән, чәчәк аткан.

Баштарак ул, ялгызлыктан арынырга теләп, Кычытканга тартылган һәм аның турында һаман саен ешрак уйлавын абайлап:

«Чыннан да яратам түгелме соң?» — дип, бер үк вакытта бәхетле һәм көенечле уйларга чумган. Беренче хисләр ташкыны басылгач, Ромашка айнып киткәндәй була, аңына килә.

— Дустым, әллә аерылышыйкмы соң? Нинди генә үзсүзле, горур булмасын, синең Гөлчәчәгең бар бит. Көннән-көн саргая, шиңә дип ишеттем мин аны.

Ләкин Кычыткан Гөлчәчәккә шулкадәр рәнҗегән ки, үпкәсе, әрнүе аңа карата булган бөтен хисләрен онытгырган.

— Юк, юк, мин бары тик сине генә яратам, синсез яши алмыйм. Ташлама мине,— дип Ромашкадан үтенгән ул.

Җәйләр узып, көннәр инде көзгә авыша башлаган. Җир өстенә сары төс иңгән. Бар гөлләр дә шиңеп беткән. Иң элек, билгеле, Гөлчәчәк сулган. Кычытканга бу хәбәр килеп җитсә дә, ул аңа битараф калган. Аның күптән инде Гөлчәчәктән күңеле кайткан, йөрәгендә Ромашка гына булган.

Шул чакны чибәрлеген бер дә җуярга җыенмаган Ромашка янына бер Бал корты көн саен иртән, әле Кычыткан уянмаган чакта ук, очып килеп, үзенең Ромашкага гашыйк булуы турында сөйли икән. Яшь Ромашка озак уйлап тормыйча: «Бу Кычыткан барыбер тиздән корыячак. Мин үзем дә тиздән шиңәрмен, яшәп калырга кирәк»,— дигән.

Бал корты нечкә борыны белән көн саен чәчәктән бал ала икән. Һәм шулай бик озак дәвам иткән.

Бер иртәне ямьсезләнеп, каралып, җыерчыкланып калган Кычыткан күзләрен ачып җибәрә һәм чак кына һуштан язмый кала: аның сөекле Ромашкасы яныннан Бал корты очып китеп бара. Кычыткан бу хыянәткә түзә алмый, үзен-үзе чагып үтерә.

Бушап калган бакча өстенә ак кар ява. Сукмак буйлап бакчачы атлый. Монда булып алган фаҗигане ул сизми дә калды. Тик Гөлчәчәкнең генә орлыкларын саклап калырга тырышты ул. Яз килгәч, орлыклар кабат шытып чыгар һәм барысы да яңадан кабатланыр. Бәлки...

## Кәүсәрия Шәфикова

### Бүген җилләр талгын исте

Ак болытны мендәр итеп,
Җил йоклый төшләр күреп.
Төшендә дә йөридер ул
Каен чукларын үреп.

Үтәдер ул элгән керне
Җилфердәтеп чак кына.
Тирбәтәдер чәчәкләрне,
Кочып алып сак кына.

Су буена йөгереп төшеп
Дулкыннарны куадыр.
Бөгелгән тал бөдрәләрен
Агым суда юадыр.

Кояш батты, Ай калыкты,
Таң белән җил уяныр.
Бүген нинди җил исәр, дип,
Дөнья күргән уйланыр.

### Мәхәббәт

Тик анасы аңлый алган
Үз сөйләме баланың.
Мә, ди бала үз телендә,
Бир, дию бу аның.

Мә, ди күреп уенчыгын,
Мә, ди чәчәк күрсә дә.
Бар да үзгә, сөйләсә дә,
Еласа да, көлсә дә.

Ике кулы — очар канат:
Мә, ди, күрсә бер кошны.
Тәгәрәтеп уйнаргадыр,
Мә, ди, Айны, Кояшны.

Барысы да сиңа, диеп,
Елмаючы анасы.
Ал мине дип, янә, мә, ди,
Кулын сузып баласы.

Кулындагы баласына
Бирә ана барын да.
Йөрәген дә, Кояшын да,
Аен да, Җир шарын да.

### Кабыныйм дөрләп

Авырып ятам. Көннәрем
Әрәмгә үтә.
Әрәмгә үткән һәр көнем
Җанымны өтә.
«Ярамый, бер дә борчылмый
Тыныч ят», имеш.
Яз ае, болай сызланып,
Уфтанып ни эш?!

Гөрләвек тә жырлый-жырлый
Акмас кук минсез.
Сыерчык та үз тавышын
Тапмас кук минсез.
Җибәрмик инде яз ямен,
Торсын ул гөрләп,
Авыру, кит син, кит тизрәк,
Кабыныйм дөрләп.

## Әллә нинди инде кеше җаны

Яз җитте дә инде минем талга,
Яфракларын ярды, и матур.
Бер сандугач килеп кунар да, дим,
Сайрый-сайрый мине юатыр.

И мин тиле, савыттагы талга
Сайрар кошлар килеп куна ди.
Барысы да шулай гади генә,
Син дигәнчә рәхәт була ди.

Әллә нинди инде кеше җаны,
Бернигә дә охшаш, тиң түгел.
Сындырылган ботак яшәрсә дә
Сандугачын көтә бу күңел.

●

Чәчәкләргә бактың сокланып,
Юк, бу — синең мине күрүең.
Минем өчен утлар, давыллар
Кочагына барып керүең.

Челтер-челтер, бу — син тыңлаган
Чишмә түгел, минем тавышым.
Күзләремдә, минем күзләрдә
Югалтуың синең, табышың.

Яз яктысы түгел, бу — сиңа
Елмаюым минем, көлүем.
Мең газабың кичеп, яныма
Бәхетеңне эзләп килүең.

Мин кыз бала, бөдрә талың мин.
Рәхәт җилгә чәчем таралган.
Миннән башка яши алмыйсың,
Шуңа да бит минем йөрәгем
Иң саф сөю белән яралган.

## Эльмира Шәрифуллина

# ҖИРКӘЕМ, ҖИРЕМ, ҖИР ГЕНӘМ...

●

Әткәем узган юллардан
Йөрим, йөрим уйланып.
Кан-яшь тамган җирдә үскән
Кылгандай дулкынланып.

Бу күзләрем ник елмая? —
Елыймын бит эчемнән.
Көйрәп китмәсме даласы
Дөрләгән уй-хисемнән.

Җил әз генә хәбәр бирсә,
Тере җандай кылганнар

Ташланалар уңга-сулга:
«Исәнме?— дип, — туганнар?»

Ары чабып, бире килеп,
Әйтә кебек кылганнар:
«Белегез тыныч тормышның
Кадерләрен, оланнар!»

Әткәм сугышкан җирләргә
Килдем, йөрим уйланып,
Кан, тир тамган җирдә үскән
Кылгандай дулкынланып.

●

Җил тузгыта ап-ак чәчен әткәемнең,
Моң сызлата ап-ак күңелен әткәемнең.
Үткән юлы, яткан кыры, йөргән җире,
Туфрагына сеңеп калган йөрәк җыры —
Сеңеп калган дуслар җыры белән бергә,
Каны тамган Рәсәй дигән изге җиргә.
Таш стена булып баскан, куеп бергә
Ил уллары белән ул да иңне-иңгә.

Иңне иңгә куйган өчен егылмаган,
Рухлары да бергә булган, сыгылмаган.
Иманын ул саклап калган зур утлардан,
Изге антын бер мәлгә дә онытмаган.

Онытмаган! Ничә еллар үткән инде...
Бу урыннар әткәемнең йөргән җире —
Яшьлек эзен эзләп, гүя килде бире...
Чал чәчләрен тузгыта чал дала җиле.

●

Сугыштан соң туган биш бала без,
Туплар тынгач туган биш бала.
Әйтәсең син, әткәй: — Сезнең чорга
Кабат килмәс сугыш, иншалла!..

Туплар тынгач туган биш бала без,
Тыныч көндә безгә җан иңгән.
Тыныч көндә үстек, тыныч төндә,
Тик кан белән күчкән сез күргән.

Сугыштан соң туган биш бала без,
Атылмыйча калган биш ядрә.
Әгәр кирәк булса, бер урынына
Биш вулкан без бүген — биш тәндә.

Кирәк булса, туган илкәй өчен
Биш ташкын без, бишебез биш җирдән.
Күрмәсәк тә күзләребез белән,
Аңга, җанга сеңгән сез күргән.

Сугыштан соң туган биш бала без —
Туплар тынгач туган биш бала.
Һәрчак әзер торган биш ядрә без,
Чакыра калса әгәр Җир-ана!

●

«Ни хәлләрдә», дип сорыйлар,
Хәлләрем әйбәт кенә.
Кайчагында күңелләрне
Җәберли гайбәт кенә.

Була кояшлы көннәрем,
Коела күз яшьләрем.
Сезнең кебек хәл белергә
Киләләр иптәшләрем.

Язгы гөрләвекләр кебек,
Гөлдер-гөлдер агабыз.
Мөлдерәмә күзебездән
Чумырып хисләр алабыз.

Кузгатабыз яшьлек моңын
Кочакларга ташланып.
Узмакчыбыз кайгыларга
Юлыкмыйча, сакланып.

Фәрештә түгел лә кеше,
Гамьнәрем бар, гарьләрем.
«Ни хәлләрдә?» дип сорыйсыз...
Гөлләр кебек хәлләрем!

## Күбәләк

Ак ефәк канатың, күбәләк,
Битемә кагылды.
Очмый тор, күбәләк, карыймчы,
Күримче, җаныңны.

Битемә синең күк сак кына
Кагыла иде ул.
Югалып торсам мин чак кына,
Сагына иде ул.

Учымда җилпенә, әйтерсең,
Әнисен таныды.
Кем соң син, күбәләк, әллә соң
Кызымның җанымы?..

●

Сагынып кына сөйлибез
Ефәктәй балачакны.
Оныттыкмы чишмә булып
Челтерәп аккан чакны?

Пакь хисләрнең яңгыр булып
Күкләрдән сибелгәнен,
Сабый итеп яратылган
Күңелләр бирелгәнен —

Җылы, йомшак җилләр булып
Кочакка сарылганны,
Олыгайдык, оныттыкмы —
Үзебез табынганны?

Әллә артык сабырландык,
Тыйнакланып киттекме?
Әллә инде балачакның
Ялгыш күңелен киттекме?

*1980—1981*

## Бикә Рәхимова

●

Ишелә, җимерелә дөньясы,
Югалган таяну ноктасы.
Башыңа тынгылык эзлисең,
Тик аны, соң, кая куясы?

Тын беткән, хәл беткән, ни чара?
Беләсең, хәзер син бичара.
Куркасың аягың басарга —
Җир купкан, чайкала, айкала.

... Биш ятим үстергән ананың
Айныта яшьле күз карашы.
Чайкалмый, ишелми — җир тигез.
... Шул туфрак, шул тамыр, шул нигез.

●

Гаепләремне син эзләмә,
булганнарын гафу ит.
Бәгырьләремне ник теләргә?
Ярасына шифа ит.

Күңлем төбенә ник төшәргә?
Төшми генә үлчәргә...

### Электә сөйгәнгә хат язу

— Чибәрме син, дип сорыйсың...
Бакча-Сарай тупылларын
күргәнең юкмы синең?

— Дәртлеме син, дип сорыйсың...
Тар җирендә тау елгасын
кичкәнең юкмы синең?

— Күңлең сафмы, дип сорыйсың...
Аяз көнне зәңгәр күккә
бакканың юкмы синең?

— Сөямсең мине, дип сорыйсың...
Айсыз төндә айболдырга
пар аргамак белән килсәң,
очарбыз бу илдән.

●

Бизәнә хатын-кыз һаман:
бизәнә дә ясана,
Бар булган гәүдә-торышын
үзгәртеп азаплана.
Болай булып туган инде,
ә ул алай итмәкче,
Күңлендә туган рәсемне
Җан өреп тергезмәкче.

«Каш ясыйм дип, күз чыгарып»
куйган чаклары була,
үҗәтләнеп, сер бирмичә,
тагын «яңадан туа».

... Сәнгатьнең озын гомере —
ир-ат яулаган данмы?
Ә аның беренче адымы
бәлки хатын-кыз җаны?

# Роза Баубекова-Кожевникова

●

Хәтерлим, без күмер төйи идек
Төяп тулмас машиналарга,
Миңа шаян кызлар болай диде:
«Менә шуны сал син җырларга!»

И ул колонкага килеп көчкә,
Салкын судан рәхәт күрүләр,
Аннан тагын җиң сызганып эшкә! —
Отбойга да отбой бирүләр...

Кояш нурларында янып-пешеп,
Кара күмер төсле ялтырап,
Без шигырьләр укыдык, искә төшереп,
Һәм тирәбез торды яңгырап.

Бабайларның иман, чыдамлыгы
Рухландырды якты уйларга...
Үзләренә шигырь чыгаруны
Көтте бугай кызлар шуңарга.

●

Хатлар язма, кайтма уятырга
Ядкарьләрне, киртә салалмам
Юлларыңа, — буран уйнатырга
Март аенда карлар табалмам.

Кайтма, кайтма! дип ялвара күңел,
Өзелеп-өзелеп әйтәм сүземне:
Син ышансын шуңа димме?.. Түгел,
Ышандырмак булам үземне.

●

Тагын паркка, юеш каруселькә
Килдем, таныш түгел калада...
Бер утырган идек без яшьлектә,
Икәү поезд киткән арада.

Ул планнар йөзләп, өмет йөзләп,
Ышанычта куллар кысылган!
Вакытны гел ашыктырдык, безгә
Балкып калды парк шушыннан...

Салкын каршылады бүген мине! —
Йөз ялгыштан яуды бозлы сил.
Ул — хак, ниләр генә әйтим инде?.. —
Кирегә әйләнми шул карусель...

Күк күкрәде. Томалап яумый иде.
Еракларда, офык буенда
Сызылып торды күкнең якты җире —
Нәни утрау, кояш нурында.

Койма челтәрләре артындагы
Яфракларны җилләр шаулатты.
Кинәт килгән яңгыр коеп яуды,
Утрау калды һаман як-якты...

Нигә эзлибездер утрауларны,
Ник табабыз, карап туймыйбыз,
Күңелләрдә саклап без аларны
Серле бүләк диеп уйлыйбыз.

**Нури АРСЛАН** тәрҗемәләре.

---

## Укучының күңел дәфтәренә

**Вьетнам мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Караңгыда — каралаасың, яктыда — яктырасың.*
*Бер таш — калкулык та түгел, ун таш бергә — кыя була ала.*
*Җирдә таю — аяктан екмый, сүздә сөртенсәң — кинәт аварсың.*
*Бер ялгызың яшәгәнче, күпләр белән бергә үл.*
*Чикерткә канатыннан да югарак язмыш була.*
*Картка — саулык-тазалык, яшь кешегә — акыл җитми.*
*Мәхәббәт һәрвакыт матур, ә усаллык — гел ямьсез.*
*Яратканда күккә чөеп, ачулангач җиргә бәрәләр.*
*Туганнары юк кеше — кылы өзек скрипка.*
*Елак балага ана сөт бирми.*
*Балаларың барында — һәрвакыт эшең булыр.*
*Кыз акыллы ир эзли, егет матур кыз көтә.*
*Шатлыклы көн кыска була.*
*Сорамады — бирделәр, өмет итмәде — булды.*
*Кыен чаклар килмәсә, батырлар булмас иде.*
*Башы сыйган тишеккә колаклары кысылган.*
*Сукыр мәче елгадан кыздырган балык тоткан.*
*Йомырка белән таш чәкештерә.*
*Кипкән агачның бөресе булмый, усал кешенең баласы булмый.*
*Кат-кат әйтелгән шаяру — дөреслеккә әйләнә.*
*Күк йөзе тәбәнәк дисәң, билеңне бөгеп атла.*
*Балыкчылары — унау, ә елгада — бер балык.*
*Чүмәлә эченә кертеп филне яшереп булмый.*
*Урманга агач утырта, урманга утын ташый.*
*Күзе бар, күз карасы юк.*
*Кешене муллык тудырмый, муллыкны кеше булдыра.*

---

## Рәфкать Кәрами

# ӨЗЕЛГӘН ЧӘЧӘК

ХИКӘЯ



Өченче звонок чылтыраганда күптиражлы газета редакторы Закиров буфетта бик тәмләп сыра чөмерә иде. «Ярар, өлгерермен,— диде ул, сәгатенә карап алгач һәм, гаҗәпләнеп, башын чайкап куйды.— Төгәл халык үзләре». Аннары Закиров әкрен генә аска, шахмат бүлмәсенә төште. Монда, шәһәр чемпионатыннан бер дә ким түгел — уенчылар арасында каты бәрелешләр бара. Закиров ишек катындагы өстәл янында бераз юанып, тагын сәгатенә күз төшерде. Залга керер вакыт җиткән иде.

Культура сараеның зур залы тамашачылар белән яртылаш кына тулган. Ләкин, Закиров уенча, бу да бик яхшы, чөнки башка елларны алдагы биш-алты рәт кенә тула торган иде. Закиров салмак, авыр адымнар белән атлап килде дә бер ялгызы буш рәткә утырды. Югыйсә, аңа алдагы рәттән дә урын калдырырга тиешләр иде. Ул моны яхшы белсә дә, сәхнәдәгеләр каршында чекерәеп утырасы килмәде. Беркөн ул соңга калып керде, икенчедән, залдагы халык вак, күпчелеге моннан берничә ел элек кенә авылдан килгән кыз-кыркын. Ә озын буйлы Закиров алардан бер башка калку. Җайлап, аркасын терәп, гәүдәсен төз тотып йомшак креслога утыргач, ул, ниһаять, башын күтәреп, сәхнәгә күз ташлады.

Чәче яртылаш коелган зур башлы бер шагыйрь калын тавыш белән шигырь укый. Нечкә аяклы кечкенә өстәлләр артында тагын алты егет утыра. Арада берсе, өлкәнрәк яшьтәгесе — Закировның сабакташы. Ул залга игътибар белән карап тора иде, карашы Закировка юнәлде. Ләкин Закиров аны күрүен һәм тануын сиздермәде. Ул юри трибунадагы шагыйрьгә текәлде. Чөнки аның элекке курсташы белән бер дә очрашасы килми иде. Әлбәттә, моның кайбер сәбәпләре бар. Ни өчен дигәндә, Закиров студент елларында үзе дә хикәяләр язды, вакытлы матбугатта да басыла килде. Ләкин өйләнеп, дөнья мәшәкатьләренә чумгач, аның яшьлек хыяллары иҗат илһамы һәм укучыларга җиткерәсе уй-фикерләре ашлама шикелле җиргә күмелеп калдылар. Ә аның элекке дусты — хәзер унлап китап авторы, танылган шагыйрь.

Закиров бүгенге әдәби-музыкаль кичәгә дә бик үк теләмичә, хезмәт вазифасы кушканга һәм бу вакыйганы завод газетасында яктыртырга кирәк булганга гына килде. Ул хәтта килмәскә дә уйлаган иде, ләкин котелмәгән бер хәл мәҗбүр итте: әдәби хезмәткәрнең әнисе авырган һәм Закиров егеткә авылына кайтырга рөхсәт бирде. Менә хәзер Закировка редактор башы белән гап-гади информация язарга кирәк. Дөрес, ул моны иртәгә заводның культура сарае директорыннан сорашып та

белә ала иде. Ләкин журналист этикасы, намусы моны кабул итмәде. Үзен дә ниндидер көч шушы залга этәрде, ахры. «Ярар, унбиш минут утырсам, кайтып китәргә дә була,— дип, үз-үзен юаткандай һәм аклагандай, әйтә куйды ул.— Әдәп йөзеннән...»

Ләкин Закировка, уйларына чумып, озак утырырга туры килмәде. Аның игътибары читкә тайпылды. Халык кул чабудан тынгач, янә шигырь агыла башлады. Ә ишек ягыннан әкрен генә килгән аяк тавышы ишетелде һәм кемдер тиз генә Закиров артына, буш рәткә килеп утырды. Әлеге кемдер, шунда ук кайнар сулышы белән Закировның колагына кагылып:

— Күптән башландымы әле? — дип сорады.

— Юк.

— Кемнәр сөйләде?

— Беренчесе.

— И рәхмәт төшкерләре... Соңга калдым дип, котларым очты.

Зур башлысы сүзен тәгәлләгәч, озын буйлы, житү чәчле, күзлеклесе микрофон каршына чыгып басты.

Арттагы хатын-кыз пышылдап кына тагын нидер сорады. Закиров аңламады һәм ярым борылып:

— Минем янга күчегез, бүрәнә аркылы бүре кумыйк,— диде.

Яшь кенә кыз икән. Бик теләп риза булды һәм ялт итеп күчеп тә утырды. Кулындагы чәчәкләрен тезенә куйды.

— Аһ, ничек әйбәт укый! — диде ул әсәрләнеп.

Нәфис кызый, озын муенын сәхнәгә таба сузып, күпереп торган кызыл иренле кечкенә авызын чак кына ачып, бик бирелеп шигырь тыңлый иде. Бөтен игътибарын туплап, күңел биреп тыңлаганга, аның йөзе тагын да яктырып китте, елмаю хасил булды һәм Закиров сәхнәгә түгел, ә янәшәсендәге кызыйга карап утыра башлады. Ә кызый үзәк өзгеч чибәр иде. Сызылып кына киткән кыйгач каш, вакыт-вакыт дерелдәп куючы озын керфекләр, бөдрәләнеп маңгаена төшкән чем кара чәч — бер килмәгән жире юк иде бу кызыйның. Күз кабакларына да чамасын белеп кенә зәңгәр йөгерткән. Шулар өстенә, Закировның болай да иләсләнгән башын миңгерәүләтеп, аңа затлы крем һәм ислемайның хуш исләре дә килеп бәрелде. Ул хәтта күзләрен йома төште. Закировның эчендә нидер өзелеп, йөрәге чәнчешеп алгандай булды. «Их!» — дип, авыр сулап куйды ул үзе дә сизмәстән.

Кыз сизгер дә икән.

— Гафу итегез, нидер әйттегез, ахры.

— Юк, болай гына.

— Әйбәт шигырь, әйеме!?

— Сездәй гүзәлләр янымда булганда мин шигырь тыңламаска да риза.

— Комплиментыгыз өчен рәхмәт,— диде кыз һәм тагын йотылып сәхнәгә карап утыра башлады.

Озын буйлы егет чыгышын тәмамлагач, кызый, йөгереп диярлек сәхнәгә менде дә, яшь шагыйрьгә чәчәк бүләк итте. Тамашачыларның кайнар алкышы кызга рәхмәт хисләре белән сугарылган иде.

Егетләр бер-берен алыштыра тордылар, вакыт та шактый узды шикелле. Ләкин Закиров баягы уеннан арына алмыйча, хәтта сәгатенә карарга да кыймыйча, кымшанырга да куркып, креслога береккәндәй, өнсез оеп утыра бирде. Чыгып китүдән хәзер аны нидер тотып тора иде. Дөрес, Закиров аның нәфис нәрсә һәм нилектән икәнен белә, ләкин үзүзенә икърар итәргә генә теләми, чөнки беркем белмәсә дә, сизмәсә дә бу уй үзе генә дә аның абруена күләгә төшерер шикелле. Ә дәрәжәсен бик белә, нык саклый иде Закиров. Ләкин менә капыл гына чыгып китү уңайсыз һәм, дөресен генә әйткәндә, хәзер аңа бу кызый янында

утыру бик тә рәхәт. «Аһ, без, ир-атның нәфесе! Үзең олыгаясың, ә күңел һаман яшәрә. Без картайган саен кызлары да чибәрләнә генә бит аның, шайтан алгыры!»

Кайчагында ир-ат арасында кем дә булса үзенең берәр кызый яисә яшьрәк тол хатын белән типтереп алуы турында мактанса, Закиров кызарып: «Оят кирәк, егетләр, хәзер безгә килешми, үзебезнең балалар үсеп килә»,— дип, аталарча үгет-нәсихәт бирергә, вәгазь укырга ярата иде. Ә үзе күңеленнән тегеңә кызыга, аннан көнләшә, үзенә дә шундый чибәркәй эләкмәвенә бик уфтана һәм бәхетсез булуыннан гарьләнә. Ләкин нишлисең, теләсә кем артыннан сөйрәлеп йөреп тә булмый. Ресторан тирәсендә буталырга күңеле тартмый. Редакциядәге яшь машинисткалар бар барын, ләкин Закиров элек-электән бер кагыйдәне тота килә: «Яшәгән җиреңдә — йөрмә, йөргән җиреңдә — яшәмә». Ә хәзер бигрәк тә... Шулкадәр авырлык белән тупланган абруең бер мизгелдә, сабантуенда ватылган чүлмәк кебек, чәлпәрәмә киләчәк. «Аһ, үтте яшьлек, шайтан алгыры!» — дип әйткәнен сизми дә калды Закиров һәм, кызый ялт борылуга, кып-кызыл булды. Шулай да үзен тиз кулга алды.

— Сез концертка каласызмы?

— Белмим.

— Артистларны көн саен телевизордан күрәбез, радиодан ишетәбез. Шагыйрьләр чыгышыннан алган тәэсирләр күмелеп калмагае дим.

— Мин дә шулай уйлыйм. Әйдәгез, алайса,— диде кыз, күршесенә карап.

Закиров үзенең кыюлыгына бер аптыраса, кызның бик тиз риза булуына, күндәмлек күрсәтеп урыныннан ук кузгалуына икенче шаккатып, торып ук басты. Чөнки сәхнә ябылып, тәнәфес-фәлән игълан ителмичә, тамашачылар бераз гына вакытка үз урыннарында калганнар иде.

Урамдагы җылы яз сулышы биткә үк килеп бәрелде, кичке шәһәрнең шау-шуы колакка иңде. Караңгы төшкән. Баганаларда тоныкк утлар яна, асфальт юлда һәм тротуарда күлдәвекләр, күк йөзендә йолдызлар җемелдәшә. Кыз күңелендә дә яз, хыялый уйлар иде булса кирәк, ул, беркавым баргач, ак шарф ураган озын муенын суза төшеп, куе чәчләрен артка ташлап, тиктомалдан шигырь укый башлады:

> Нинди яз бу?
> Һәр көнендә шатлык килә,
> кайгы килми.
> Ләкин, гаҗәп:
> бер шатлыгым арткан саен, бер дус кими.
> Сәер яз бу!
> Һәр көнендә бәхетлерәк була барам...

— Кемнеке икәнен беләсезме?

— Әйе. Без ул шагыйрь белән бергә укыдык. Бу аның яшьлегендә язган шигырь.

— Сез әллә үзегез дә язасызмы?

— Әйе,— диде Закиров читенсенеп кенә, ә соңыннан, тавышына горурлык мәгънәсе салып өстәде: — хикәяләр.

— Ой, мин шулкадәр яратам, якын итәм сезнең халыкны! Сез нинди бәхетле!

Закиров кызарды. Чөнки аның ун еллап инде әдәби әсәр бастырганы юк, элек язганнарын карап, тәртипкә китерергә дә вакыты һәм теләге юк иде. Ә шулай да нинди рәхәт, татлы иде үзеңне әнә шул сәхнәдәгеләр белән бер иш итеп тою. Бигрәк тә кемнеңдер сине шулар белән тиң күреп сөйләшүе, ләйсән яңгырыдай тәннәрне оетып җибәрде.

Кара төстәге күн куртка, зәңгәр джинси чалбар кигән бу гүзәл кыз, үзенең кая һәм ни өчен барганын аңламый, абайламый иде. Ә Закиров

бер генә минутка да үзен ничек тотарга икәнен исеннән чыгармады, бу тирәдә аны белүчеләр күп булуын онытмады. Шуңа күрә ул кызны бакча буйлап, кеше йөрми торганрак урыннан алып китте. «Саклаганны саклармын, дигән бит».

Бер урында, асфальт җимерелеп, су шактый җәелгән төштә, Закиров егетләрчә батырлык күрсәтте: туктап, кызны ялт кына күтәреп, әлеге күлдәвек аша чыгарды. Ләкин шул моментта ук моны ник эшләвенә үкенә дә язды. Чөнки кыз, бөтен урамны яңгыратып көлде, чыр-чу килеп, аны муеныннан кочаклап ук алды.

Алар ары киттеләр. Кыз бертуктаусыз сөйләнде. Ул бүген культура сараенда калган шагыйрьләргә дә, күктәге бихисап йолдызларга да, бөре ачарга әзерләнгән агачларга да, юлда очраган йонлач маэмайга да, янәшә атлаучы Закировка да бертигез дәрәҗәдә гашыйк иде, ахры.

— Сез өйгәме?

— Ә?.. Юк әле, мин бүген иректә. Улымны җомга көн генә алам.

Закиров аптырап китте, чак кына туктап калмады. Ышанырга да, ышанмаска да белмичә, текәлеп, сынап, кызга карады. Баганадан төшкән ут яктысында аның буй-сынын күздән кичерде. Үзе чандыр, кечкенә, яшь-яшь, ә үзе — бала анасы. Гаҗәп.

— Ул кайда соң? Әбиләрендәме?

— Юк, атналык бакча-санаторийда.

— Ә этисе?

— Без — аерым. Ул бүтән берәүгә йортка керде. Улыма җиде атна дигәндә ташлап китте.

— Алай икән.

— Сөйләгез әле берәр нәрсә! Сез бит...— Яшь хатын сүз таба алмыйча гаҗизләнде. Ә аннан кисәк кенә сорап куйды.— Сез өйләнгәнме?

— Ул турыда кирәк микән? Бүген...

— Юк, сез дөресен әйтегез.

— Әйе.

— Балаларыгыз бармы?

— Икәү.

— Исемегез?

— Ирнис.

— Минеке Ләйсирә. Сез миңа ни генә сорасам да дөресен әйтегез, яме, Ирнис абый.

— Килештек.

Алар шактый вакыт урам-тыкрыклар гизеп йөрделәр. Ләйсирә тагын шигырьләр укыды, җырлады, малае турында сөйләде. Ул Закировка тиз ияләнде. Таза гәүдә, салмак адымнары Ләйсирәнең житез хәрәкәтләренә капма-каршы булса да, Закиров үзенең төпле фикер йөртүе белән аның күңелендә ихтирам уятты.

Икенче көнне Закиров трамвай тукталышында озак торды. Оялу, таныш-белеш күрер дип читенсенү өстенә, салкын да үзәгенә үтте. Чөнки төнлә җир туңган иде. Ләкин ул, билгеләнгән, сөйләшенгән вакыт үтсә дә, нидер өмет итеп, әле газета киоскасы, әле яшелчә ларегы артларына ышыкланып, Ләйсирәне көтте. Инде бөтен өметләре өзелеп, килешенгән сәгатьтән соң шактый гомер үткәч кенә еракта, аллея уртасында Ләйсирәнең кызыл пальтолы, ак шәлле кечкенә гәүдәсе күренде. Нинди якын һәм кадерле иде әлеге юка гәүдә бу минутларда Закиров өчен! Нинди олы бәхет аңа таба йөгерә-атлый ашыга иде бу минутларда! Ирексездән, очарга әзерләнгән коштай, Закиров талпынып куйды һәм бөтен сабырлыгын җуеп, кызу-кызу Ләйсирәгә каршы китте.

— Гафу итегез, Ирнис абый, соңга калдым.

— Зыян юк.

— Бер апаны пенсиягә озаталар икән. Мин кичә белмәгән дә идем.

Мине гармунда уйнаттылар. Мәҗбүри эчерттеләр... әзрәк.. Ачуланмыйсызмы? Мин — кып-кызылмы?

— Пальтоңнан төшәдер ул. Ярар, борчылма, кызларга кызыл килешә ул. Киттекме?

— Әллә бүген урамда гына йөрибезме? Башка вакытта кайтыр идек.

— Без бит кичә килештек. Озак утырмабыз.

— Минем өй дә җыештырылмаган.

— Гайбәт сөйли торган гадәтем юк.

— Алайса, гафу итәрсез, яме.

— Әлбәттә.

...Ике катлы агач йорт. Текә, биек баскыч. Закировка җиңел гәүдәле Лэйсирә артыннан калышмыйча җәһәт-җәһәт менүе кыен иде. Ләкин аны тау башына үрмәләгәндә була торган дәрт биләп алды. Тау башына менү дә шулай авыр. Әмма түбәгә күтәрелгәч, үзеңне җиңүче итеп тою, горур кыяфәттә тирә-юньгә, биеклектән аска карап тору — никадәр ләззәтле була бит.

Караңгы коридордан бераз баргач, яктырак, кухня сыманрак урынга керделәр. Лэйсирә артыннан бер адым да калмаган Закиров, бүлмә ишеген ачканда яшь хатынның ачкыч тоткан кулы дерелдәп куюын күрде.

— Менә, улым белән шушында яшибез. Узыгыз.

— Рәхмәт.

Закиров ботинкасын ишек төбендә салып калдырды, кесәсендәге коньяк шешәсен өстәлгә куйды да яны белән суыткычка бәрелеп, бүлмә уртасына үтте.

— Диванга утырыгыз.

Лэйсирә тиз генә өс киемен салып ташлады. Закировның пальтосын шифоньерга элде, ә эшләпәсен шифоньер түбәсендәге телевизор каршына куйды. Мондый хикмәтне Закировның беренче күрүе иде. Шулай да сиздермәде. Гомумән, бүлмә аңарда чиркану кебегрәк бер тойгы уятты. Күптәннән бирле бөтен уңайлыклары булган аерым фатирда яшәүче кеше өчен монда барысы да гайре табигый иде. Чөнки Закировның дуслары һәм туганнарыннан берсе дә мондый шартларда яшәми. Ул утырган диван, ишек катындагы суыткыч һәм зур шифоньер ярты бүлмәне биләп торалар. Ә бит әле өстәл, бала караваты һәм берничә артсыз урындык та шушында сыйган. Түшәм үрмәкүч пәрәвезенә охшап калган: аркылы-торкылы баулар эленгән...

Ләкин бераздан Закиров, үзенең кайда икәнен дә онытыр дәрәҗәгә җитеп, сәҗдәгә киткән мәчет карты кебек, талгын бер рәхәтлеккә чумды. Чөнки аның каршында әледән-әле Лэйсирәнең зифа гәүдәсе бөтерелә. Ул я диван башына басып телевизор кабыза, я баулардан бала чүпрәкләрен җыештыра, я Закировка фотоальбом тоттырып, чәй куярга чыгып китә дә, нинди дә булса йомыш табып, тагын аның янына килә. Закиров Лэйсирәне я үз янына диванга, я тез башына утырта һәм таза, дәү кулын аның нечкә, сыгылма биленә сала, иңнәреннән кочаклап ала. Бу минутлар аның өчен әйтеп бетергесез рәхәт...

Менә шундый ләззәтле минутларның берсендә ул суыткыч өстенә күз салды. Анда киптерелгән чәчәкләр куелган бәллүр ваза тора иде. Закиров түзмәде, торып, вазага үрелде, бәрхет кебек кып-кызыл бер чәчәкне кулына алды. Аның сабагы нечкә, сары, үзе йомшак һәм бик шома иде. Закиров хәтта аны сыйпап та карады. Ләкин кире вазага утыртканда әлеге чәчәкнең сабагы чыртлап сынды. Моны күреп торган Лэйсирә кычкырып җибәрде:

— Ай!

— Гафу итегез.

Лэйсирэ өчен бик кадерле, истэлекле, ничэ еллар буе саклап килгэн чэчэк иде бу. Лэкин ул моны Закировка эйтмэде, мөмкин кадэр гамьсез булырга тырышып:

— Ярар инде, хәерле каза булсын,— диде.

— Мин икенчене алып килермен.

— Кирәкми.

Лэйсирэ, яшьле күзлэрен яшерер өчен башын аска иеп, чэйниген карарга дип чыгып китте. Закиров та диванга барып утырды, элеге вакыйганы бик тиз онытты һэм үз уйларына чумды.

Ул бу яшь хатынның ничэдэ икэнен белми иде. Төсе-битенэ карaганда, бик яшь булырга тиеш, дип уйлады һэм эчтэн генэ горурлык хисе кичереп утырды. «Буй-сын эйбэт, үзе чибэр, үзе яшь, безгэ дэ бэхет килер көннэр булган икэн!»

Закиров бая Лэйсирэ диванга куйган альбомны кулына алды. Ачты һэм беренче биттэге истэлекле язуны укыды. Кызга унсигез яшь тулган көнне энисе бүлэк иткэн, көне-ае һэм елы да язылган. Моны күреп Закиров башта гажэпкэ калды, аннан күңелен төшенкелек билэп алды. Моннан унбер ел элек бүлэк ителгэн альбом иде бу. Димэк... миннэн унөч яшькэ генэ кече бит». Закиров бер почмагыннан кителэ башлаган күңелен тынычландырды, бу турыда уйламаска тырышты. Лэкин элеге уй, үкчэгэ төртеп торучы кадак кебек, аны һаман бимазалады. Аның саен Закиров үз-үзен юатты. «Барыбер миннэн унөч яшькэ кече бит. Мондый бэхет тэ бик күплэргэ тэтеми, агай-эне. Безнең яшьтэ унсигездэге кызлар элэкмэс шул инде».

Закиров альбом актарганда аның янына Лэйсирэ килеп утырды. Бер карточкада ул үзе иде.

— Менэ минем яшь чагым,— диде Лэйсирэ, карточканы кулына алып һэм Закировка сузды.— Чибэрме?

— Эйе. Хәзер, сез хэзер дэ бик чибэр һэм бик яшь.

— Э миңа ничэ яшь дип уйлыйсыз?

— Белмим,— дигэн булды Закиров, иңен сикертеп.— Хатын-кызның яшен эйтүе авыр.

— Ни өчен?

— Чөнки хатын-кызның яше өч төрле.

— Беренче ишетүем. Ничек инде ул алай?

— Юк, хатын-кызның, кабатлап эйтэм, яше өч төрле. Беренчесе — таныклык, ягъни паспорт буенча, икенчесе — кешелэр аңа күпме бирэ, өченчесе — ул үзен ничэдэ дип хис итэ.

— Кызык. Э шулай да миңа ничэ яшь дип уйлыйсыз?

Закиров көттереп кенэ:

— Һым, чама белэн... егерме икe-егерме өчне бирергэ мөмкин,— диде.

Лэйсирэ шатлыктан кулларын чэбэклэп алды. Ул, шифоньер ишеген ачып, көзгe каршына басты, үз-үзенэ сокланып бераз төзэтенде дэ янэ Закировка борылды.

— Миңа инде егерме тугыз.

— Кит аннан?!

— Эйе шул.

— Да, Мэрфуга да утызда...

— Юк, утызда түгел, егерме тугызда гына...

Алар көлештелэр. Закиров хатынның коңгырт күзлэренэ текэлеп сокланды. Лэйсирэ дэ нурлы шат күзлэре белэн аңа томырылып карады. Закировның киңчэ яңаклы тулы йөзе, калын кашлары, чокырлы ияге, сабыр-тыныч холкы Лэйсирэ күңелендэ ихтирам, ышаныч уяталар иде. Ул Закировның озын кара чэчлэрен сыпырып куйды, аннан тузгытып җибэрде, башын кочаклап, күкрэгенэ кысты. Бу назлану-иркэлэүгэ түзэ алмыйча, Закиров хатынны күтэреп алды, кочагында эретте...

— Чәй ташыйдыр,— диде Ләйсирә, аңына килеп.

Чәй эчкәндә ул малае, аның шуклыклары турында, үзенең заводта эшләве, ләкин кечкенәдән үк артистка булырга хыяллануы, тик моның тормышка ашмавы хакында сөйләнде.

— Үкенәсеңме?

— Юк. Ләкин мин гомерем буе әдәбият-сәнгать кешеләренә гашыйк булып яшәрмен, ахры.

— Әйдә, күтәрик шул хыялый һәм гашыйк кешеләр өчен!

— Исерсәм?!.

Бераз капкалап алгач, Ләйсирә бала караваты астыннан гармун тартып чыгарды да егетләрчә, бер җиңеллек белән сыздырып та җибәрде, кушылып җыр да сузды.

Җидегән чишмәләрдә җиде улак,
Челтер-челтер ага көмеш су...

Яшь хатын әсәрләнеп җырлады да җырлады. Аның бу җырына яшьлеген сагыну да, хәзерге ялгыз тормышы өчен борчылу-көенү дә, айлар-еллар буе тулып ташыган ачы сагышлары да — барысы да җыелган иде, күрәсең. Ирексездән аның күзләре яшьләнде. Ләкин ул бу юлы дымлы күзләрен Закировтан яшермәде. Чөнки аларда нииндидер өмет, юатуга мохтаҗлык, назга сусаганлык чагыла иде. Бәлки каршында утырган таза, көчле ир аның күңелендә ни кайнаганын аңлар, дип уйлагандыр. Бәлки ул бераздан Закировка тагын бер альбом күрсәтергә уйлагандыр. Анда Ләйсирәнең иң яшерен уй-теләкләре, табигатькә соклanulары һәм кешенең матурлыгына, дөньяда яшәүнең гүзәллегенә мәдхия җырлаган шигырьләр тупланган иде. Ләкин... Закиров рюмкаларга коньяк койды. Хәзер ул үзенең тагын да кыюланып китүен сизде һәм Ләйсирәне кочагына алды. Бераздан ул үз-үзен белештермичә, шашар дәрәҗәгә җитеп, еш-еш сулап хатынны бертуктаусыз иркәли, аңа назлы сүзләр әйтә башлады, кочагы кайнарланганнан кайнарлана бара иде. Ләйсирә, яңгырның һәр тамчысын көтеп алган һәм аның шифасын бөтен күзәнәкләренә сеңдергән үсемлек кебек, Закировның сүзләренә чын ихластан ышана, бөтен йөрәге белән кабул итә иде. Һәм ул, Закировка каршы килә алмыйча, үзе дә аның күзләрен үпте, иреннәренә үрелде.

Закиров Ләйсирәнең төз матур аякларын, йомры тезбашларын сыйпап:

— Бездә килен төшкәндә төкле аягың белән, диләр. Бу — бәхетен белән, дигәнне аңлата. Син әле бәхетеңне табарсың. Син яшь, чибәр...— диде.

— Минем дә берәр кешене шашып-шашып яратасым килә! Сезне яратыймы?

— Тырышып кара.

— Мин чын әйтәм. И... сез өйләнгән шул. Миңа гаилә бәхете кирәк, әболай...

— Мәхәббәткә маңка комачауламый, диләр.

— Бер шигырь укыйммы?

Синдәгедәй кодрәт булса
әгәр минем,
Бу дөньяны сүтәр идем,
Җимерер идем
Һәм адәмнәр мәңге
рәхәт яшәп торган
Бүтән дөнья иҗат итеп
бирер идем!..

— Тагын укы.
— Җитәр. Мин исердем, ахры.
— Тыңла, алайса, мин укыйм. Көнчыгышның бөек акыл иясе менә ни язган:

Небесный свод жесток и скуп на благодать,
Так пей же и на трон веселия воссядь.
Перед господом равны и грех, и послушанье,
Бери же от жизни все, что только можешь взять.

— Монысын ишеткәнем юк иде.
Закиров торып өстәлдән ике рюмка тотып килде.
— Мәле, тагын берне күтәрик!
— Юк, юк...
— Тот инде.
— Сез минем турыда начар фикердәдер инде?
— Заманча яшә, үз чорының үз кызы бул, үги кызы булма!
— Оялма дисезме?
— Бик үк оятсыз да булма!
— Рәхмәт. Киңәшегезне тотармын. Вакыт күпме әле?
— Алтынчы ярты.
— Улымны алырга соңга калмыйк.
Киенгәндә Ләйсирә Закировның каршына басты да кисәк кенә бит очыннан үбеп алды:
— Үзеңә бер малай табып бирсәм...
Пальтосының бер җиңен кигән Закиров тораташтай катып калды. Бу минутта ул үзенең дачасындагы бакча карачкысына охшаган иде. Тел астына тәмәке салган кешедәй, няге дерелдәп куйды, сүз әйтергә теле әйләнмәде.
— Курыктыңмы, акыллым?..
Ләйсирәнең күзендә шаян очкыннар ялтыравын күреп ниһаять, Закиров телгә килде, әвәләп бер сүз чыгарды:
— Юк.
— Ярар, өегезгә китермәм, алимент кына түләрсез.
Ләйсирә ачы елмайды һәм кычкырып көлеп җибәрде.

...Таксидан төшкәч, Ләйсирә, як-ягына каранып, башта аңыша алмыйча торды. Кулларын кесәсенә тыккан Закиров тыныч кына:
— Ярый...— диде.
— Ә... сез китәсездәмени? Улымны күрәсегез килмиме?
— Башка вакытта.
— Хушыгыз.
— Сау бул.
— Кайчан күрешәбез?
— Сөйләштек бит — пәнҗешәмбе, сәгать алтыда.
Ләйсирә бүтән бер сүз дә әйтмичә кырт борылды да ике катлы ак бинага таба йөгерде.
Закиров та үз юлына китте. Ул шактый чуалган уйларын бер җепкә тезәргә, рәткә китерергә теләде, ләкин барып чыкмады. Алда ни буласын, мәсьәләне ничек хәл итәсен ул әле тәгаен генә уйлап җиткермәгән иде. Ләкин ул инде тыныч. Гашыйк Мәҗнүннән ул яңадан дөньяда барысыннан да канәгать ир уртасы кешегә, гаилә башлыгына, кадерле балаларының хөрмәтле атасына әйләнде. Һәм аңа хәзер бик күп елларга үз хатынынан битәр һичкем дә кирәкми иде. Чөнки аның күптәнге хыялы тормышка ашты, теләге кабул булды. Ул яңадан элекке халәтенә кайтты. Мөхтәрәм, абруйлы, олы кыяфәтле, салмак-әкрен адымлы мөхәррир Закировка әйләнде.

Мунча янында туктап, кесәсеннән кипкән балык чыгарды, бик тәмләп сыра эчә башлады. Аны бер танышы күреп алды һәм, ике кружка тотып, янына килде. Алар әүвәл озаклап һава хәлләрен, кичәге хоккей матчын инәсеннән җебенә хәтле тикшереп, анализлап чыктылар. Аннары танышы:

— Бу атнада бакчага барасыңмы? — дип сорады.

— Бармыйча ярамас.

— Анда эш тә юк инде әлегә.

— Булмаса да... Мин кыш көне дә атна саен бардым, күз-колак булып кайттым.

— Тиярләрмени?

— Тимиләр тиюен. Быел бер-ике кешенекен бастылар, минекенә кагылганнары юк. Каравылчыдан да инде ул. Ә каравылчы мине бик хөрмәт итә, мин дә җәй көне аңа виктория биргәлим. Моңа кадәр тыныч иде.

Алар әле тагын шактый вакыт дача хәлләре, балык тотканда һәм ауга йөргәндә була торган маҗаралар турында сөйләштеләр.

...Пәнҗешәмбе. Сәгать җиде тулып килә. Ләйсирә тәрәзәдән карап утыра. Урамда әле якты. Апрель уртасы җитсә дә, бүген иртәдән үк салкын иде, сулар катты, көне буе кар яуды, ә кич белән җил дә чыкты. Кар бөртекләп, сирәкләп кенә яумый, кушучлап йөзгә сибелә, көчле җил аны ачу белән өстән берөзлексез туздырып кына тора. Шәрә агачлар, канаты сынган авыру коштай, талпыналар, өзгәләнеп ярдәм сорагандай, бөгелә-сыгыла ачы җилдә чайкалалар. Ләкин аларга ярдәм кулын сузучы юк. Киресенчә, буран көчәйгәннән-көчәя. Ә агачлар ялангач. Аларның бик тә бөреләнәсе, яфрак ярасы, яшеллеккә күмелеп, бизәнеп-ясанып утырасылары килә. Юк, үзләре өчен генә түгел, үзләреннән бигрәк, кешеләр өчен тырышалар бит ул изге җаннар. Аларга рәхәт, күңелле, ямьле булсын өчен... Ә карлы буран миһырбансыз. Ләкин барыбер яз үзенекен итәчәк, буран туктар, агачлар яшеллеккә күмелер, бөтен тирә-як тагын да хозуррак булыр.

Ләйсирә юлга карады. Машиналар чаба, ашыга-ашыга атлаучы кешеләр күренә. Салмак кына адымнар белән килүче берәүне Ләйсирә Закировка охшатты. Тулы гәүдә, озын буй... Юк, ул түгел икән. «Бәлки ул соңга калгандыр да хәзер мине көтәдер? Тагын унбиш-егерме минут торасым калган икән. Хәер, мин аны ярты сәгать көттем бит. Киләсе булса, килер иде.»

Ләйсирә үзен шулай дип тынычландырды. Аннары капыл гына торды да киенә башлады. «Мин монда җылыда утырам, ә ул туңып беткәндер. Берәр ашыгыч эше килеп чыккандыр да соңга гына калгандыр». Ләкин киенеп беткәч, ул тагын туктады. «И тиле дә соң мин! Бер сәгать үтте бит инде».

Пальтосының бер җиңен салган килеш диванга килеп утырды да тагын тәрәзәгә карады. Моңаеп, авыз эченнән генә җыр көйли башлады.

Ә тышта карлы буран баягыдан да яманрак котыра, улый, сызгыра, юнәлешен үзгәрткән җил юеш карны хәзер тәрәзәгә үк китереп сылый иде.

Ләйсирә чишенә башлады. Кинәт суыткыч өстендәге вазага күзе төште һәм, өзелгән чәчәкне күреп, йөрәге сыкрап куйды. Ләкин ул бар әрнүен эчкә йотты, моңсу йөзендә бу кичереш берничек тә чагылмады.

Ә бу вакытта Закиров — эштән кайтышлый юл уңаенда баҗаларына сугылган хөрмәтле кунак — кухняда, өстәл артында бик тәмләп сыра чөмерә һәм баудан гына алган майлы чехонь балыгының койрыгын кимерә иде.

*1981*

## ОЧЕРК ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

### Хәмзә Зарипов

# ҖИЛӘК ӨЛГЕРЕП КИЛӘ...



Ул гади, табигый, үзе турында аз сүзле, әмма эшкә кагылган кадәресен җентекләп җиткерә торган тыйнак бер ханым булып күңелгә сеңеп кала. Аның турында кем белән сүз башласам да, кешеләрнең йөзләре яктырып китүен күрдем.

Ямьле бу яклар... Басулар аралаш урманнар шаулап утыра, үзенең бик күп кушылдыклары белән иркенләп Ык елгасы ага. Ә мәһабәт таулары?! Каядыр шунда гына Урал таулары ятадыр кебек. Шунда гына түгел-түгелен дә, әмма барыбер монда аның якынлыгы сизелә. «Урал итәге бу» диләр кешеләре һәм горурлык белән әйтәләр. Кешеләр күңеленең биеклеккә, мәһабәтлеккә, гомумән дә аерылып торуга омтылуыннанмы бу?!

Асия Гайнаншина кечкенә, җыйнак, кызларча җиңел гәүдәле ханым булып чыкты. Чәче чалара башлаган. Коңгырт күзле, туры карашлы. Кысылган иреннәре менә-менә елмаеп җибәрер шикелле. Геологны кояш, җил, дала дусты итеБрәк күрергә күнегелгән, ул исә тәрәзәләре бакчага караган өченче каттагы бүлмәсендә, шома өстәл, шкафлар арасында йомшак урындыкта утыра, үзе күбәләктәй киенгән. Таулар сыман тыныч, чишмәләр кебек ачык йөзле. Сөйләшә торгач, мин аның төгәл сүзле булуын да тойдым.

Мин аңардан үзенең яшен түгел,— ә ул 1928 елның башында туган,— бәлки туган җиренең ничә яшьләрдә булуын сорадым. Ул каршындагы савыттан кәгазь, карандаш алды һәм дулкын-дулкын итеп катламнар сыза башлады. Үзе әйтә барды:

—Карбонат нефте, турней ярусы, бобриков горизонты, девон, кристалл катламы... Монда инде нефть юк, тагын да астарак булырга мөмкин дибез...

Әйе, каршымда нефтьче утыра иде.

—Миллиард еллар...— диде аннары, үзе сүзен озайтмады, туган табигатенең тарихы хакында туктаусыз сөйләрлек сүзе барлыгын аның күзләре генә әйтеп тора иде.

Асия ике телдә дә бик матур сөйли. Алтынчы класстан башлап русча укыган. «Укый алмассың» дип алырга теләмәгәннәр, ләкин ул үзенекен иткән, җидееллыкны бик яхшы тәмамлаган. Сугыш вакыты булган бу. Ул шулай үзенә максат куярга һәм җиңәргә өйрәнгән. Язмышын үз кулында тотарга өйрәнү булган бу. Аннан соң кырык ел үткән, Асиянең төрле юллар алдында калган чаклары аз булмаган, ул гадәттә аларның авырын сайлаган... Һәм җиңә килгән. Ул үр артыннан үр яулаган. Урал таулары итәгендә үскән кызның тауга күтәрелүе бу...

Без аның белән мондый купшы сүзләр кулланып сөйләшмәдек. Дөресрәге, ул мине һавалардан бик тиз җиргә төшерде... Ул бит унынчыны 1946 елда бетергән. Техника йортында нефтьчеләрнең Хезмәт даны музеенда булганда мин шуны белдем: 1946 елның 17 сентябрендә 1 нче скважинадан куәтле нефть фонтаны бәреп

чыга, 19 сентябрьдә «Баулынефть» тресты оеша. Баулы нефтьчеләре аны үзләренең туган көннәре итеп саныйлар һәм былтыр 35 еллык бәйрәмнәрен үткәрделәр. Татарстан җирендә девон нефтенең елъязмасы шул көннән башлана.

— Нефть шау-шуы сезнең өйләргә, классларыгызга килеп кергән,— дип, Асия Мотыйгулловнаның тормышын үзем әзерләгән тәртәгә кертә башлаган идем, ул елмаеп башын чайкады.

— Сез сугыш вакыты икәнлеген онытгыгыз,— диде ул.— Җиденчене бетергәч, 43 нче елны, медсестра булып сугышка китү теләге белән, апамнан күреп, мин дә язуларымны медицина училищесына җибәрдем. Чакыру кәгазе дә килгән иде... Әнинең күз яшьләре алып калды кебек...— истәлекләргә бирелгәндә аның тавышына җылы җилләр йомшаклыгы иңә.— Унны бетергәч тә әле я авиация, я текстиль институтына ашкынган идем. Нигә текстиль? Кызык, унынчы класс өчен имтиханнарны Бөгелмәгә барып бирдек, шунда Уфадагы нефть институтының игъланын күрдек. Чүкечләрен тоттырып, бик матур кыз рәсеме ясалган иде. Хәзер дә әле күз алдымда тора. Мәктәпне дүрт малай, биш кыз бетердек, өч кыз Уфага геологлыкка укырга киттек. Икебез бер елдан технология факультетына күчкәч, мин үзем генә калдым. Аннары безнең факультетны Мәскәүгә күчерделәр, ике курстан соң мин академик Губкин исемендәге нефть институтында укыдым.

Әйе, шулай булырга тиеш тә иде. Нефть үзе аяк астында. Бар халык нефть дип тора. Авиация белән текстиль институтлары ерак, ә бусы күршедә генә. Гомерене багышларлык эш бар монда, ил куптарган олы эш. Кушыл гына...

Институтны тәмамлаганда Асия Зиннәтуллина:

— Мине Татарстанга, Баулы нефть идарәсенә җибәрүегезне үтенәм,— ди.

Студентлык елларында ул Башкортстан, Грозный, Урта Азия якларында геофизик экспедицияләрдә йөри: көндәлекләр алып бара, шул эзләнүләр нигезендә өр-яңа җирләрнең геологик карталарын төзи, диплом эше яза. Татарстанга кайтканда ул Девон картның холкын аңларга кодрәтле геолог булып өлгерә. Институтта ук җәмәгать эшләрендә катнашкан, хезмәткә атлыгып торган Асияне яшьләр үзләренең җитәкчесе итеп сайлаганнар. Ул — комсомол оешмасы секретаре, тиздән ВЛКСМның район, өлкә комитетлары члены. Ул елларда Татарстан яшь нефтьчеләренең беренче слеты җыела. Яшь белгечләр советлары оеша. Фәнни-техник җәмгыятьләрнең конференцияләре уза. Барысы да Асия кебекләрнең инициативасы белән башлана, барысы да беренче тапкыр була.

Бораулаучы яшьләр бер-бер артлы рекордлар куялар. Ул Газим Гайфуллин, Мөгаллим Гыймазов, Мотаһар Нургалиев кебек илне шаулаткан бораулаучы осталар белән бер сафта эшли. Һәм 1952 елның башында кайткан яшь белгеч 1954 елның мартында комсомолның XII съездына делегат итеп җибәрелә. Съездда ВЛКСМ Үзәк Комитеты члены итеп сайлана.

Ул еллардагы газеталардан Асиянең рәсемен каравы кызыклы. Ачык маңгай, дулкынланып иңбашына төшкән кара чәч, кыю караш, елмаеп җибәрергә торган кысык иреннәр. Кечкенә генә бизәк төшерелгән якалы гап-гади күлмәктән. Ул каядыр кузгалып китәргә әзер сыман...

Бер елдан соң аны Татарстан Верховный Советына депутат итеп сайлыйлар. Башка кандидатлар белән бергә аның да кечкенә генә рәсеме газеталарда урнаштырылган.

25 яшьлек Асия республика белән ил күләмендә дәүләт һәм комсомол эшлеклесе булып китә. Аны нефтьчеләр үз вәкиле итеп күтәрәләр. Кыз әнә шулай, туган җиреннән дәрман алып, алга бара.

Бу хакта мин кешеләрдән ишеттем. Үзеннән сораган идем, ул гадәтенчә елмаеп:

— Үзәк Комитет члены буларак, комсомолның XIII съездында да катнашырга туры килде әле,— дип өстәде.— Яшь белгечләр идек, без эшләми, кем эшләсен?..

Шул вакытта ул партиягә керә.

«Баулынефть» идарәсенә Асия өлкән геолог итеп җибәрелә. Бүлмәдә эшләүне кызыклы дип тапмаган кыз үзен промыселга күчерүләрен үтенә. Шуннан ун ел буена геолог булып эшли: җир, скважиналар, кешеләр белән эш итә. Гади генә әйткәндә, үзен эштә сыный, тәҗрибә туплый, белгеч булып өлгерә.

Аның ике улы да Губкин исемендәге Мәскәү нефть институтында укый. Шамиле «Елховнефть»тә башта оператор булып эшли, хәзер промыселда технолог. Наиле «Башнефть»кә, Уфага кайткан була. Әнисе аңа төп эшенә якынрак күчәргә куша.

— Ул бит белгеч булудан туктаячак, — ди Асия Мотыйгулловна, хәтта әле хәзер дә ризасызлыгын белдереп.— Башта нефть исен иснәсен, тәненә, канына сеңдерсен, кеше өйрәтергә хокук яуласын... Хезмәте белән, тәҗрибәсе белән.

*

* *

Баулыга килгәч, идарәнең парткомына кергән идем. Йомышымны әйткәч, секретарь урынбасары Октябрят Вәлиәхмәтович Насыйбуллин, кулындагы кәгазьләрен миңа сузды да:

— Менә, буласы тантаналар уңаеннан иң хөрмәтле кешеләребезнең яна исемлекләрен булдырдык,— диде.— Асия Гайнаншина берничә урында искә алына. Менә «Татарстанның атказанган нефтьчесе» исеме алган иптәшләребез. Бишәү алар бездә. Бер хатын-кыз бар — Асия Мотыйгулловна. Ә менә болары — һөнәрләре белән иң яхшы эшчеләребез. Араларында тагын Гайнаншина. «Хезмәт даны» музеена рәсеме куелган. Ул — «Почет билгесе» ордены кавалеры...

Мәскәү институтындагы остазлары Асияне үзләрендә аспирант итеп калдырырга теләгәннәр. Яхшы укыган өченме? Анысы билгеле инде: ул начар укый, начар эшли алмый. Кешесе андый түгел. Аспирантура бит ул гыйльми эшкә әзерли. Монысы өчен өстәмә бер сәләт кирәк. Студент вакытта ук башкарган эзләнүләрен шулай зур бәяләгәннәрме? Бу хакта мин аның үзеннән сорадым:

— Беренче гыйльми тикшеренүләр институтта чакта ук ясалдымы? — дидем.

— Алар минем курс эшләрен, соңыннан диплом эшен тәшкил иттеләр, бары шул гына.— Шулай дип аңлатты, аспирантура, гыйльми эшкә тәкъдим ясауларын исенә төшермәде.

Шундый җайлы урыннан ул баш тарткан, әмма аның күңеле фәндә булган. Аның Баулыга кайтып, гади геолог булып промыселга китүен дә шул омтылышы белән аңлатырга мөмкин. Бу вакытта Баулы бораулау һәм нефтьне җир куеныннан чыгару ягыннан берсеннән-берсе кыюрак яңалыкларны сынап карау, фән-техника тәкъдимнәрен кертү өлкәсенә әверелә. Монда гыйльми, техник фикер кайнап тора. Нефтьчеләр Мәскәү, Казан галимнәре җитәкчелегендә эшлиләр. Асия кебек эзләнүчән, институтта ук фәнни эшкә сәләте, зәвыгы ачылган яшь белгечләр өчен үзе бер зур бәхет була бу. Һәм алар көндәлек эшләренең зур фән ихтыяҗлары белән кушылуын күреп, җиң сызганып эшкә чумалар.

Асия Мотыйгулловна өчен ул еллар инде еракта калды.

Ул вакытта әле Татарстанда нефть проблемаларын өйрәнүче махсус фәнни институт юк иде. 1953 елда Баулыда Бөтенсоюз нефть фәнни һәм инженер-техник җәмгыятенең — ВНИТОның — республика бүлеге үзенең беренче конференциясен уздыра. Баулыда һәм беренче тапкыр! Көн тәртибендә: «Баулы ятмасына тирәли су кудыру тәҗрибәсен өйрәнү». Идарә җитәкчесе Мингәраев, идарәнең баш инженеры Горюнов, Баулы һәм Туймазаның тәҗрибәле белгечләре белән беррәттән, яшь-яшь геолог комсомолка Асия дә чыгыш ясый.

Бөтен нечкәлекләре белән белмәгән кеше өчен нефть, җир куенында мәңге кысылып яшәүдән котылу мөмкинлеге алгач, скважинадан өскә, яктыга ыргылырга, димәк, бары тик фонтан булып кына атылырга тиеш кебек тоела. Бөтенләй үк алай түгел икән бит.

— Нефть чыганакларының фонтан булып атылырлык куәтләләре була. Аңа без дә булышабыз,— дип аңлатты Асия Гайнаншина.— Шул фонтаннарга көчлерәк тибәргә ничек итеп булышырга да сүнгән фонтаннарга җан өрү өчен ниләр эшләргә? Әле фонтаннар чорында ук нефтьчеләр алдына шундый мәсьәләләр килеп басты. Аларны, һичшиксез, хәл итәргә кирәк иде...

Яшь белгеч Асия дә, тәҗрибәле остазлары белән бергә, шул эш белән шө-

гыйльлэнэ. Конференциядэ ул үзенең кыска гына эш дэверендэ ясаган күзэтүлэре белэн уртаклаша.

— Катламнардагы басымны кочэйтү очен бездэ 1950 елдан ук нефтьле ятма тирэсенэ су кудыру скважиналары бораулый башладылар,— дип сойли ул.— Лэкин бу эшкэ чынлап торып 1952 елның июль ае азагында, 509 нчы, 11 нче су куучы скважиналар сафка баскач тотындык...

Эгэр дэ ел башында катламдагы басым кызу темплар белэн кимегэн булса (Асия аны катастрофа чигендэге темплар дип атый, фикерен саннар белэн нигезли), дүртенче кварталда исэ, катламга берничэ ай дэвамында су кудырылгач, басым киму бер атмосферагa кадэр тоште. Су куыла башлап, ике-оч атна үтте дигэндэ, катламда басым күтэрелде һэм аның нефть бирүе артты.

— Моңарчы безнең алда су белэн нефть чыгаруны арттырып буламы?— дигэн сорау тора иде. Бүген без шушы мөһим сорауга уңай җавап бирэ алабыз.

Без Баулы девон ятмасын шушы юллар белэн үзлэштерүне киңэйтэ барабыз. Эгэр елның беренче яртысында нефть чыгаруны арттыру яңа скважиналарны гамэлгэ кертү исэбенэ генэ ирешелсэ, 1952 елның август аеннан бирле хэрэкэттэге скважиналар саны ишэймэгэн хэлдэ дэ нефтьне коннэн-кон күбрэк чыгарабыз.

Хэзер безнең алда бу эшне бик белеп җайга салу һэм ятмаларны нэтиҗэле итеп файдалану бурычы тора...

Шулай сойли Асия. Мин аның чыгышын бик кыскартып кына китердем. Фэнни-техник конференция исэ «Баулы нефтьчелэренең тэҗрибэсен «Татнефть» берлэшмэсенең барлык идарэлэрендэ киң рэвештэ кертергэ» дигэн карар чыгара.

Академик Губкинның талантлы шэкертлэре, Идел-Урал нефть ятмаларының зур белгечлэре Шмарев, Еронин, Мальцев, Горюнов, Мингэрэев кебек остазлар янэшэсендэ һэм Татарстан нефтьчелэре коллективында шулар тудырган иҗади атмосферада Асия шикелле шунда туып үскэн яшьлэрнең тикшерену, эзлэну һэм гомумилэштерү сэлэте үткенлэнэ.

1958 елда яңа тэҗрибэ башлана. Бу вакытта инде «Икенче Баку» регионы илебезнең төп нефть чыганагына эверелеп җитэ. Нефть коннэн-кон күбрэк кирэк. Җидееллык план белэн нефтьчелэр алдына тагын да зуррак бурычлар куела. Баулы ятмасы инде ун елдан артык халык хуҗалыгына эшли. Инде Кама буенда нефть табылган. Капкан саен майлы калҗа булмый дигэндэй, җирне тишкэн саен яңа ятма табылмый. Яңа ятмалар эзлэү юлы белэн генэ нефть чыгару күлэмен тиз арада арттырырга мөмкин булмавы мэгълүм. Ил алдында торган бурычны тиешенчэ үтэү очен табылган кадэресеннэн нэтиҗэле файдаланырга, ягъни булган ятмалардан нефть алуны арттыра һэм тизлэтэ барырга кирэк. Моның очен аны ала белергэ кирэк.

Нефть аста хэрэкэтсез ятмый: урынын, холкын, сыйфатын үзгэртэ тора. Эйтик, нефтьне кысып чыгаручы басымны арттыру очен катламга су кудыру яхшы эш булды. Лэкин, таяк ике башлы дигэндэй, бу нефтьнең сулануына китерэ башлады. Нефть катламында барган үзгэрешлэрне даими белеп торырга һэм аны күбрэк алу ысулларын эзлэргэ кирэк иде.

Э скважиналарның ешлыгы нефть чыгаруга ничек тээсир итэ? Шулай ук мөһим сорау.

Болай гына чамалаганда исэ нефть диңгезе өстенэ никадэр күп скважина утыртсаң, шулкадэр шэп кебек тэ бит, тик тэгаен шулай микэн соң? Һэр скважина фэлэн сумга төшэ, күпме кыйммэтле металл, энергия, хезмэт тотыла, э шул миллионнар барысы да гел файдага китэме? Шушы катламга ничэ скважина бораууларга кирэк? Аларны кая бастырсаң иң зур отыш була? Һэм скважиналар нинди ешлыкта булырга тиеш?

— Моңарчы нэрсэ уйлаганнар?— дисезме.— Моңарчы да шул хакта уйланганнар, лэкин тэҗрибэ туплана барган саен нэтиҗэлерэк эшлэргэ яңа мөмкинлеклэр туа, нефтьчелэр шул яңалыкларны эшкэ җигэ килэлэр дэ.

Асия Зиннэтуллина бу вакытта эле промыселда геолог. Бер промыселга ике йөз иллелэп скважина карый. Ул шуларны эшлэтүдэ барлык геологик мэсьэлэлэрне хэл итэ. Бер баксаң, нефтьтэ службалар аз түгел, берсеннэн-берсе югарырак

урында утырган белгечләр дә байтак. Шулар күләгәсендә тыныч кына эшләргә дә мөмкин. Ике йөз илле скважина икән — булсын, нигә эч пошырырга? — тырышлык белән, пөхтә итеп шуларны карыйсың, тагын нигә дип аларның сафын сирәгәйтү яки ешайту турында баш ватарга?

Шул чакта ул үзе кебек үк тынгысыз яшь инженер Илгизәр Гайнашин белән гаилә корып җибәрә. 1955 һәм 1957 елларда ике уллары дөньяга килә. Бу чакта Асия — яшь белгеч, яшь коммунист, яшь ана. Җиңел булмагандыр, анысын үзләре генә беләдер, әмма шунысы күренеп тора: дөрес, матур бара аның тормышы, бәхетле корыла аның язмышы.

Иң мәшәкатьле шушы елларда Асиянең дә, Илгизәрнең дә калын-калын журналларда мәкаләләре басыла башлый.

— Бер төркем яшьләр аспирантурага кердек,— дип искә алды Асия Мотыйгулловна ул елларны.— Нииндидер бер рухлану, хыялланып йөрүләр, эзләнүләр чоры иде. Имтиханнарны, читтән торып әзерләнеп, Губкин институтында бирдем.

Тиздән ул Бөтенсоюз нефть һәм газ фәнни-тикшеренү институтына үзлегеннән гыйльми эш алып баручы итеп билгеләнә. Ул геология-минералогия фәннәре докторы М. И. Максимов җитәкчелегендә фәнни тикшеренүләр ясый башлый, гыйльми хезмәт язарга утыра. Әлбәттә ирен, ике яшь баласын, үзен карый, төп эшен алып бара. Шул кыенлыкларны исәпләмәгәндә, аның бөтен мөмкинлекләре бар. ВНИИ галимнәре җитәкчелегендә эксперимент үткәрүчеләрнең берсе — ул үзе. Аяк астында Баулы девоны, хуҗалыгында теләсә нинди холыклы йөзләгән скважина, кулында — техника, кораллар, аппаратлар. Тагын әле еллар дәвамында туплана килгән материаллар һәм тәҗрибә.

1962 елда Асия Гайнашинаны, ун елдан соң, яңадан идарәнең үзенә күчерәләр. Ул «Баулынефть»нең геология бүлеге начальнигы булып эшли башлый. Бу вакытка Асия Баулы нефтьчеләре алдында торган һәм киләчәктә дә күтәреләсе зур эшләрнең бер өлешен үз иңнәренә салырлык әзерлекле, тәҗрибәле, арулусыз хезмәткә сәләтле коммунист җитәкче булып өлгерә.

Асия еллар дәвамында йөзләгән скважинаның үз-үзен тотышы, катламда барган үзгәрешләрне язып, анализлап килә. Ул җирнең йөрәк тибешен, сулышын тыңлый, вакыт-вакыт чыгымчылап алуын тоеп тора, диагноз куя һәм төзәтү буенча тәкъдимнәрен бирә. Мәсәлән, катламга су кудыруны дөрес оештыру нәтиҗәсендә, озак еллар дәвамында нефть чыгару һаман арта килә. Баулы ятмасында 1969 елга барлыгы 54 миллион 487 мең тонна нефть чыгарылган булса, шуның 48 миллион 900 мең тоннасы фонтан ысулы белән алынган. Нефтьнең 90 проценты фонтан булып бәреп торган. Моңа ирешә белергә кирәктер...

Фәнни институт программасы буенча үткәрелгән тәҗрибәнең тагын бер максаты — сафтагы скважиналарның чама белән яртысын япканнан соң да нефть алуны киметмәү мөмкинлеген тикшерү була. Асия Гайнашина: «Мөмкин!» дигән җавап бирә.

Ә төп максат — югары нәтиҗәләргә ирешү өчен скважиналарны кайда, ничек һәм нинди ешлыкта урнаштырырга кирәклеген белү. Ул бу билгесезлекне дә чишә һәм скважиналарны урнаштыруның иң нәтиҗәле вариантын тәкъдим итә.

Яшь галим байтак проблемаларга ачыклык кертә, практик файдалы нәтиҗәләргә ирешә. Диссертациясен ул Мәскәүдә, Бөтенсоюз нефть һәм газ фәнни-тикшеренү институтында яклый. 1969 елда аңа геология-минералогия фәннәре кандидаты исеме бирелә.

Нефть ятмаларын рациональ үзләштерү мәсьәләләре елдан-ел актуальләшә бара. Татарстан нефтьчеләре өчен ятмалардан нефть алуның нәтиҗәлелеген арттыру, коэффициентын күтәрү — төп бурычларның берсе. «Баулынефть»тә ятмаларны үзләштерү буенча махсус бүлек оештырыла, бераздан аның начальнигы итеп Асия Гайнашина куела. Мин аның бүгенге хуҗалыгы белән кызыксындым, нинди мәшәкатьләр белән яшәвен аңларга тырыштым.

— Безнең карамакта хәзер җиде эреле-ваклы ятма бар.

Атаклы Ромашкино ятмасының көньяк плацдармы безгә керә.

Татар Кандызында шулай ук девон ятмасы.

Сабанчы, Урустамак ятмалары өстә, әлеге бобриков горизонтында. Әйе, җир астының үзенең офыклары, таулары, диңгезләре бар...

Баулы районының картасын мин җир төзүче инженер Наил Шәрәпов кулында да күрдем. Анда Җирнең өсте: таулары, инеш-сулары, болын-үзәннәре, күпер-юллары, басу-кырлары, сазлык-далалары ясалган. Асия Гайнанишина кулында шул ук карта, анда шул ук җирнең ике чакрымга кадәр тирәнлектәге байлыклары төрле төсләр белән төшерелгән.

Бу хәл турында уйланып, мин ирексездән күтәрелеп күккә карадым. Анда да бит һава юллары, һава агымнары, кош юллары, радио һәм телевидение дулкыннары — тагын әллә нәрсәләр барлыгы искә төште. Аның да картасы бар. Хәтта нигәдер уңайсыз булып китте: барысы да исәпләнгән, сызылган, билгеләнгән...

— Бүгенге көндә безнең хуҗалыкта меңнән артык скважина эшләп тора: кайсы нефть суыра, кайсы катламга су кудыра. Ел саен унбиш-егермесе сүнә, аның каравы илле-алтмыш яңа скважина сафка баса.

— Каян килеп, нәрсә исәбенә?

— Әле һаман яңа ятмалар ача торабыз, без бит озак еллар буена гигант ятмаларны гына санга сугып килдек. Чыганаклар саегая башлагач, кечкенәрәкләрне дә бик куанып эшкәртәбез.

Хәзер менә Алексеевск, Фомин ятмаларын әйләнешкә кертә башлыйбыз. Перспективада тагын да бәләкәй ятмалар күренә...

— Сезнең бүлек бу эшкә ничек катнаша?

—Разведчиклар бораулап карыйлар да, нефть бар, запасы шул хәтле дип тапшыралар да китәләр. Алар бит берничә урында гына бораулыйлар. Без кайда ничә скважина урнаштырырга кирәклеген төгәл күрсәтеп, бораулаучыларга эш бирәбез. Алар инде һәр скважинага махсус технологик схема төзиләр, ятманың чын байлыгын билгелиләр. Без эшкә керешкәч, девон дигәннәре бөтенләй расланмады, аның каравы бобриков горизонтын һаман әле ача барабыз.

Нефть ятмаларының, скважиналарның һәр сулышын белеп торыр өчен, үзебездә махсус лабораторияләрне берләштергән тикшеренү эшләре цехы бар. Анда әйбәт белгечләр эшли.

— Җир астында хәзер сездән яшерен бернәрсә дә юктыр кебек. Нефтькә кагылышлы һәр проблеманы өйрәнеп-белеп торасыз...

— Эшкә кагылышлы күп нәрсәне фәнни нигездә белергә, җайга салырга мөмкинлекләр зур. Без эшне башлап җибәрәбез һәм ахырына җиткерәбез.

— Яңа ятмаларны әйләнешкә кертәсез һәм һәр чыганакны соңгы тонна нефтькә кадәр бушатырга омтыласыз, шулаймы?

— Әйе, максат шундый, тик аңа ирешүе бик җиңел түгел. 1946—1957 елларда, мәсәлән, без әкренләп үсә килдек, елына 3,9 миллион тонна нефть бирүгә ирештек. Безнең кечкенә коллектив өчен бу рекорд иде. Быел исә 4 миллион 200 мең тоннага җиткерәчәкбез. Әйткәнемчә, һаман үсәбез. Без моны идарәбезнең икенче яшьлеге дип атыйбыз.

Без аның белән Баулы жирендәге 1 нче скважина янына да бардык. Машинадан төшүгә, ул урман аланында баһадирдай басып торган скважинага таба ашыкты, аның тимерләрен сыйпап үтте, аннары бер мәлгә тып-тын калды.

— Соңгы арада киләлми йөргән идем,— диде ул.— Миллион тоннага якын нефть бирде ул безгә. Хәлсезләнсә дә, рәте бетмәгән иде әле. Үзебез туктаттык, һәйкәл бул, дидек. Ул моңа лаек...

Моннан киткәннән бирле нинди үзгәрешләр булды икән диепмедер, Асия ханым карашын скважинадан безне тирәләп алган агачларга, аланга күчерде.

— Карале, җиләк өлгереп килә икән бит, нәкъ элеккечә. Килергә кирәк әле...— дип, ул бетон сукмактан келәм булып яткан аланга атлады. Бераздан скважина янына әйләнеп килде, аңа сөялеп, хискә бирелде:

— Моңсу... Күпме хатирә шушы алан белән бәйләнгән. Шаулап тора иде бит... Киләсең, скважина әкрен генә чайкалып тора, менә болай... — Асия апа бу хәрәкәтне кулы белән сурәтләп күрсәтә. — Әйе, скважиналар картаялар... Алар белән үзебез дә...

Кояшлы көн яктысында чәчәкле урман аланында көмештәй ялтыраган скважина фонында бу ханым бирегә яшьлеге белән очрашуга килгән кызны, Асия Зиннатуллинаны хәтерләтә иде.

Әллә аның уйлары Девон бабасына барып тоташкан идеме? Сүнмәс дәртенә яшьлегендәге шикелле аннан дәрман ала идеме ул?

*Баулы — Казан,*
*июнь, 1981 ел.*

# Әхәт Гаффар

# БАКЧА

*Тыныч җирдә алма үсәр.*
Мәкаль.



Ул бу язны айлап-көнләп түгел, сәгатьләп көтепаалды. Күңелләрне әллә кайларга чакырып, берсен-берсе ашыктыра-ашыктыра Кама өстеннән зәңгәрсу бозлар ташкыны ага, бөтен җанны төбе-тамыры белән кузгатып кыр казлары талгын гына очып уза, акчарлаклар көне буе үзәкләрне өзә, былтыргы куе камышлыкларда кыр үрдәкләре туе бара, күкнең ак болытлар белән кабарып торган йомшак күкрәгендә кыңгырау кебек чыңлаучы тургайлар арткан-нан-арта, агач бөреләренең ирен очлары бер-берсенә үрелә.

Язларны ул ялгызы гына каршылый да язмышының җәйге сәхрәләренә ялгызы гына сәфәр чыгып китә. Ялгызы дип... аның да кайбер парлашып яшәүчеләргә биргесез кадерлесе бар иде. Ул инде аңа үзенең гомерлек юлдашы дип бөтен иманы белән табынган, яшәвенең барлык мәгънәсен шуңа багышлаган иде. Табигать!.. Табигать — ул мәхәббәт кебек: кырыкмаса кырык холыклы. Алмагачлар — аның яшәү мәгънәсе, кешеләргә калдырачак бүләге, иң моңлы җыры, бөтен сагышларын оныттыра торган ак чәчәкле куанычы — үзләренең чираттагы язларын тамырларыннан башлап ябалдашларындагы һәммә бөреләренә кадәр корып каршыладылар. Җир яшәрде, алар корыды. Бишәү генә түгел, дистә генә дә түгел, ә җиде йөз гектар җирдә корыды. Җиткән кызларга тиң хозур 315 мең төп алмагач. Җәннәт иледәй бакча май аена кап-кара шәл ябынып килеп керде дә ыңгырашмый-сыкранмый гына мәңгегә күзен йомды. Югыйсә:

**Алмагачлар чәчәк ата**
**Майның уйбишләрендә,**

— иде ләбаса! Табигатьнең, бигрәк тә кеше кулы белән гөлбакча ителгән табигатьнең, кинәт кара кисәүгә әйләнеп калуы кеше үлеме белән бертигез фаҗига икән.

Бакча корыгач, Галина Павловна Васильева бөтен тәне, рухы белән авырып китте, йөзенә көзге яфрак төсендәге хәсрәт сарылды. Аны больницага илтеп салдылар. Сырхауга дару табыла икән. Ә җанга? Башка елларны диңгез шикелле шау чәчәктә утырган алма бакчасыннан кояш баеганда Кама суына кара күләгә сузылып ята торган булып китте. Совхоз кешеләре күңеленә кара корымдай килеп ягылган хәсрәт ул күләгәдән дә хәтәррәк иде.

Киләчәктә табигать һәм кешеләрне ни көтә? Бу тирә елларда табигать берсеннән-берсе афәтлерәк фаҗигалар кичереп алды. Ул фаҗигаләрнең тәэсире кешеләр күңеленә дә, юшкын төсендәрәк, онытылмаска утырып калды. Табигатьнең кайсыбер афәтләре, баскычтан баскычка тәгәрәп төшкән алма сыман, кешеләрнең һәр буыны күз алдыннан сикереп үтә. Корылыклар, яңгырлар, янгыннар, салкыннар... Ябалдаштан ябалдашка сикерешкән тиеннәр көтүе булып, буыннардан буыннарга шуларның авыр хатирәсе күчә, аларның берсен икенчесе белән чагыштырып карыйлар, аларны хәлдән килгәнчә, көч җиткәнчә хәвефсезрәк үтү әмәлләрен, чараларын эзлиләр, юрыйлар, табалар.

Бу гасырның соңгы дистә елга туры килгән 72, 75, 81 нче елларның корылыгы, 80 нче елның яңгыры, 79 нчы елның кышкы суыгы — һәркайсы үзенә генә хас, кабатланмас, үзенчәлекле. Хәер, кешеләр хәзер табигатьтәге бәла-казаларны матди яктан сизмичәрәк, уңышлырак үтә, ә психологик яктан... анысы һәрвакыттагыча, әйтик, мең ел әүвәл ничек булса, хәзер дә шул дәрәҗә авыр кичерелә. Матди як дигәне машина һәм техниканың күплегенә, тормышның хәзерге муллыгына бәйле, болар — кешеләрнең көче, ышанычы, терәге.

Директорлары Галина Павловна Васильева больницага яткач, «Масловка» совхозы кешеләре дә баштарак, аналарын югалткан үрдәк бәпкәләре сыман, нишләргә белмәстән аптырап калды. Җиде йөз гектар алмагачы, бер йөз гектар чия, аннары бихисап кара миләш, карлыган, кура җиләге, җир җиләге... Карлыган белән кура җиләге исән калды әле, ә илле гектар җир җиләген шул язда су басты.

Май беткәнче, ике күзләрен дүрт итеп, бар өметләрен җыеп көттеләр — алмагачлар яңарып китмәде. Бакча нибарысы өч-дүрт ел уңыш биреп өлгерде. Елга дүрт миллион данә банка консерва әзерләү исәбе белән корылган өр-яңа завод эштән туктап калды. Анысы дүрт кенә ел эшләгән иде әле. Бер мең ярым тонна җиләк-җимеш саклагыч шыр буш. Заводның Венгриядән кайтарылган җиһазы гына да 4 миллион сумлык. Зәп-зәңгәр диңгез уртасында гөрләп, яктырып барган дәү бер кораб комга килеп утырдымыни!

Мәскәү һәм Краснодар белгечләреннән торган абруйлы зур комиссия «Бакча яңармаячак» дигән хөкем чыгарып китеп барды. Галина Павловнаның шунда бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте... Больница.

Көтелмәгән хәлдән халык борчуга, хафага төште. Күп кеше: «Безгә монда эш бетте, без китәрбез инде»,— диде.

Ә Идел белән Чулманны маяк итеп, очар кошлар туган-үскән илләренә кайта иде. Язгы су китүгә, Урта Идел кешеләре кышкы суыкларда туңып корыган алмагачларны, чияләрне кисәргә кереште. Сызылып аткан таңнарда сайраган сандугачларның шат җырларын, шәүлегәннәрнең кечке чәлләләрдәге моңаюларын алмагачларны кискән һәм утынга тураган пычкы белән балта тавышлары бүлә иде. Бакчаларга тукраннар ияләште. Агачлар патшасы имәннәр төннәрен котсыз шыгырдый — аларның да кайсылары тәмам корыды, кайсылары җәй уртасына хәтле бары тик кәүсә һәм юан ботакларындагы яфрак бөреләрен генә җәеп җибәрә алдылар. Көзге туй мәҗлесе табыннарына алмалар саран гына куелды, аның каравы кияү егетләренең тешләре ул елны һич нинди зыян күрмәде — әбиләрнең кияү чикләвекләре җыя торган чикләвек куаклары да шәрә көйгә җилдә сызгырып кына утырды.

Галина Павловна өч айдан соң гына савыгып кайтып төште. Савыгып дип... җан сызлаулы килеш калды, бакчага күзе төшүгә үк, күңел яраларына учлап са-

гыш тозы сипкән шикелле итте. Бакча төннәрен аның төшенә керә иде. Элек, май һәм июнь айларында кичләрен бакчага килеп керсәң, сандугачлар сайравына коенган шикелле була идең. Җанның нечкә кылларына моң куна. ...Бакча үлеме игеннәрне тоташлый боз суүгудан да куркынычрак афәт. Игенне көзен чәчеп була. Ә алмагачлар җиденче яшьтә генә чәчәк ата, сигезенче яшьтә генә чынлап торып алма бирә башлый. Бакчаны кайдадыр дистә елның теге ягында гына терелтеп булачак иде инде. Бүтәнчә юрау мәгънәсез юану гына.

Галина Павловна үз күңелендә язгы бөре кебек әкрен генә бүртеп, хыянәт хисе уянуын тоеп йөри башлады. Күңел кабалана-кабалана хуҗалык һәм кешеләрнең тормышын ун елга кире чигереп ташлаган бакча мәшәкатьләреннән котылу юллары эзли иде. Аларның 2 мең ярым гектар җирләре бар, игенчелектә җәелеп китәрлек түгел, терлекчелеккә күчү иң кулае. Совхозда мең баш мөгезле эре терлек исәпләнә, бу җәһәттән тәҗрибә дә юк түгел. Терлекчелеккә күчәргә була. Тик аның намусы бакчага хыянәт кылуны кире какты.

— Бакча, бары тик бакча,— диде Галина Павловна.— Әнә, күрше «Корноухово» совхозының 12 мең гектар җире бар, ике ярым миллион сум доход алалар. Ә без киресенчә: ике мең ярым гектар җирдән 3 миллион сум!

Соңгы елларда совхозда 160 квартир, килеш-килбәте, эчке йөзе, тышкы кыяфәте белән үк чын сәнгать әсәре дип атардай культура йорты, унъеллык белем бирүгә исәпләнгән мәктәп бинасы, ашханә төзелде. Ашханә. Дизайн дигән чибәр, ләкин нурсыз һәм салкын бизәлештән ул акыллы татар хатыннарына хас тыйнак эчке җылылыгы, кунакчыллыгы белән аерылып тора. Галина Павловна — үзе дә татар хатыны һәм йорт-җирдә кунакчыллыкның культура көзгесе, тәрбия мәктәбе икәнен бик яхшы белә. Шул ашханә генә дә Масловка авылы кешеләрен төрле якка сибелмичә, чикләвекләрне бергә тоткан кәшәнкә кебек, бергә туплауда аз эшләмәде. Өч катлы административ үзәк бинасы, аның каршысындагы икешәр катлы торак йортларның күз алдындагы җыйнак күренеше, завод — боларның һәммәсе гүзәл Кама белән, аның буеннан-буена алты чакрымга сузылган алма бакчасы белән бик камил ярашып тора, индустрия нигезендә корылган дизайнның бер үрнәге дияргә ярый, кешеләрне «Мин шушында яшим бит әле!» дип горурландырырлык күренеш иде.

Инде менә шуларның берсе — бакча юк. Кешеләрне җир белән бәйләп торган кендек бавы өзелде һәм алар кимсенеп, ятимнәр сыман сагышланып һәм үзәкләре өзелеп:

— Без моннан китәрбез инде,— диделәр.

Аларның күңелләре бакча белән йортларының гармониясенә күнеккән. Заманында Масловка авылы картаюга, таралуга юл алган иде инде. Дүрт йөз йорт арасында тәрәзәләре кадакланганнары, бакчаларының әрем һәм тигәнәк белән капланганнары елдан-ел арта, яшьләр калмый. Хәзер әүвәлгесе белән янәшә ике йөз йортлы шәһәрчек калкып чыкты. Яшьләр кайта, әллә кайлардан гомерлеккә төпләнү исәбен белдергән теләкләр килә. Галина Павловна бирегә эшкә килгәндә балалар бакчасын ябарга ниятләп яталар иде инде. Хәзер берьюлы 80 бала йөри торган бакча эшли, яңасы, зуррагы салына. Шушы мәлдә яңгыраган:

— Без моннан китәрбез инде,— дигән сүзләр кешеләрнең бакчаны яңартырга өметләре сүнүе турында сөйли иде.

Галина Павловна кешеләргә табигать тартып алган ышанычларын кире кайтарып бирергә булды. Үзенең биредә үткәргән гомерен тагын бер мәртәбә кабатлау бәрабәренә булса да, ул моны эшләргә карар кылды. Үз гомереңнең табигать сызып ташлаган авырлыкларын да, татлы җиңүләрен дә тагын бер тапкыр кабатларга мөмкин булган очрак сирәк эләгәдер әле ул. Һәм ул сирәк күренештән читкә тайпылмыйча, фаҗигане яшәү тантанасы белән алыштырыр өчен кичтән килгәннең барысын да эшләргә кирәк иде...

Дистә ярым-ике дистә еллар әүвәл Татарстандагы һәммә колхоз-совхозда диярлек алма бакчалары гөрләп уңыш биреп утыра иде. Алар азмы-күпме керем китереп кенә калмыйча, хуҗалык кешеләренең күңеленә дә хуш килеп, тормыш-

ларының бизәге генә түгел, яшәүләренең ачык һәм аңлаешлы бер шигыле дә иде. Алмалы авыл нур чәчеп тора кебек бит ул. Әүвәлге авылларның җәйләре яшелрәк, таңнары алсурак иде бугай. Тәрәзә каршысына алмагач утыртып кую элек берни тормаган. Хәзер күп кызлы гаиләдәге бирнә белән шыплап тулган сандыкларга охшаган өйләр тезелешеп утыра, тәрәзәләрендә икешәр катлы кыйммәтле пәрдәләр. Бар да җитеш. Агачлар юк. Шәрә. Буш. Ямансу. Борынгыдан килгән бер йола бар иде — бала тугач, агач утырту. Онытылды. Татар халкының «Якының кеберенә агач утыртмау гөнаһ» дигән язылмаган законы бар. Ул шәригать фасылыннан битәр тормыш асылына карый, яшәүнең мәңгелек икәненә тирәнтен ышануын белдерә. Кешенең үлеме дә агач утыртуга хезмәт итәргә тиеш булгач, тормышы җирне гөлбакчага әйләндерү булырга тиешлеге кычкырып тора! Кеше туса да, үлсә дә, агач арткан. Хәзер зиратларда кабер артса да, авылларда кеше саны ишәйсә дә, агач кими.

Авыл абзые белән сөйләшү:
— Ник алмагач утыртмыйсың?
— Яшелчә бакчасын куләгәли.
— Бәрәңге бакчасының түбән башына ярамыймыни?
— Анда барыбер бала-чага тотмый аны.

Алма бакчалары басарлык бала-чага булу, бала-чаганы җәлеп итәрлек алма бакчаң булу бәхет түгелмени соң? Мин үзем рәссам булсам, чигүле алъяпкычы итәгеннән балаларга алма өләшүче әби янсә яшь үренте янында ике куллап көрәк сабына таянып, оныгы белән басып торган кара бәрхет түбәтәйле бабай рәсемнәрен ясар идем.

Бакчасындагы алмагачлары корыган бер агай белән сөйләшү:
— Ник яңаларын утыртмыйсың?
— Картайдым ич инде. Алмалары миңа тәти мени аның?
— ?

Без китәбез, сез каласыз! — дип җырлармын
Җәсәдемне туфрак берлә күмгәндә дә.

Тукайлар китә — җырлары калган. Җир кешеләре китә — агачлары калсын.

Безнең әти үләсе кышына каршы көзен сигез данә алмагач үсентесе утыртып керде. Әни вафат булгач, инде үсеп, әллә ничә ел алма биргән агачлар шул салкын кышны корып бетте. Йорт-җир дә, бакча да ятим калды. Алмагачлары булмаган җирне тигәнәк белән әрем күмә. Җимеш агачларын бары тик үз гомеренә генә җитәрлек итеп утырткан кешенең күңелен һәм хәтерен ни күмә икән?

Инде менә мин корыган алмагачларыбызга алмашка сигез төп үсенте алып кайтып куйдым, өебездә беркем дә тормый, үзебез югында бөтен бакчаны бетереп күрше-күләннең кош-корты, мал-туары йөри, агачларга тернәкләнеп китү шактый кыенга киләчәк. Ярар, балалар ашар. Тик агачны кадерләү хисе ана сөте белән кермәгәнгә, алар өй артыбызда үскән шомыртларны да ботагы белән генә сындырып алып китә. Ә безне кайчандыр чеме белән генә җыярга өйрәткәннәр иде. Табакка җыеп, бер төнгә кар базына төшереп кундырасың да... Һи-и! Баллы да, авызны да бөрештерми... Хәзер бабаларыбыздан калган янәшә тупылларга балта белән тирән кирт юнып һәм дистәдән артык санда ике йөзле кадаклар белән тимер кагып, турник ясыйлар. Тән сәламәтлеге асыл нәрсә анысы, ә җан, җан?

Керләнә өс-өстенә рух, һич хозур вөҗданга юк.
Ни сәбәптән җир өстендә тәнгә — мунча, җанга юк?

Белмим, белмим, Тукай!

Көзнең песи йоны кебек йомшак бер иртәсендә минем яныма күрше агае килеп басты. Бөтен кеше бәрәңге турында сөйләшә, ел коры килгәнлектән, чыгышы аз, әмма шунысы гаҗәп: авылның яртысында ишелеп уңган, иң кирәк бер мәлендә яңгыр тигән. Без дә бу мәсьәләгә карата үз карашыбыз белән уртаклаштык.

—Чиялегегездән бер сөберкелек кисеп алыйм әле,— диде ул сүзен очлап.

Бакчабызның бер ягында инде күптән кыргыйланган, вак, әче, әмма варенье өчен бик тәмле җимеш китерә торган чиялек бар. Язын ул ун меңнәрчә тапкыр зурайтылган ак бәрхет роза чәчәгенә охшап кала, аның ел да килеп оя кора, сайрый-сайрый балалар үстерә торган пар сандугачы бар. Бу башында безнең иске кара мунчабыз тора, аны ягып керү һични белән тиңләштергесез тән рәхәте һәм рухи канәгатьлек бирә. Мунча ак чәчәкле чия эченә күмелеп утыра, аңа кергәндә җып-җылы томан аша үтәсең шикелле. Аның каравы стеналары төтеннән тән кебек каралып беткән. Хәзерге нарат ак мунчалардан ул калышадыр, бәхәсләшмим, әмма серле бер табышмагы аны барыбер алыштыргысыз итә. Ак мунчаларда тән сихәте, ә кара мунчаларда җан сихәте аласың икән. Кара мунчаны безнең халкыбыз үзен белә башлаганнан бирле ягып кергән һәм уйламый-нитми генә аның бер фәлсәфәсенә ияләшкән. Мунчаның корымлы кара стеналары җирлегендә каймактан яки шикәрдән коеп ясалгандай булып ялтырып торган ак тәнле кешеләрнең сылу, сәламәт сыннарын күз алдыгызга китерегез әле! Кеше үз-үзен, үзе белән бергә юынучы туганнарын, сөеклесен кара мунчада якынрак, кадерлерәк, гомерлерәк итеп күрә.

Чия бакчасы уртасында йомшак үрмә үләннәре, чәчәкләр, люцерна һәм җир җиләге үсеп утырган аланлык сыман бер ачык җир бар, без анда кайвакытны шәрә көе генә чыгып утырып, әйрән, чәй эчә торган идек.

Билгеле, шул чиялектән абзар сөберкесе кисеп алырга сораган күрше агае боларның берсен дә күз алдына китерә алмый, мин башта аны шул суык кышны туңып корыган чияләрне сорый дип уйлаган идем. Юк, чияләрнең үткән ике ел эчендә тамырдан тишелеп чыккан зифа, сыгылмалы, тармаклы яшь үрентеләрен кыеп алырга ниятләгән икән. Әлбәттә, тирес һәм чүп-чар сөберергә аның шулары бик кулай.

Үзәкләрем өзелеп төшәрдәй булсам да, аргы баштан кисәргә рөхсәт иттем, көлтәләп алып төшеп китте, инде менә бу минутта тагын кирмәс микән дип шикләнеп утырам. Нәфсенең кесәсе тирән аның, җайлы ич, якын, ниндидер чыбык-чабык өчен рәхмәт тә әйтеп торасы түгел.

Ә без үзебезгә сөберкегә гел кытлык кичерер идек. Кемгә тән һәм мал кайгысы, кемгә — җан...

Кешеләр язмышы гына түгел, агачлар язмышы да охшаш һәм кабатланучан икән. Мин корыганнарына алмашка дип алып кайткан алмагач үсентеләре дә, әүвәлгеләре кебек үк, тумышлары белән әлеге дә баягы Масловка авылыннан. Анда республикабызда иң беренчеләрдән булып яңарган бакча туган иде инде. Галина Павловна һәм совхоз эшчеләренең табынырдай фидакарьлеге белән, ике ел тулар-тулмас дигәндә, тиздән табигатьнең ак калфагы, ә кешеләрнең горурлыгы төсендә җырларда җырланырга хаклы бакчаның яңа нигезе салынып бетеп килә. «Масловка» совхозы үз бакчасын гына яңартып калмыйча, гомер-гомердән килгән традициясен дәвам итеп, тирә-күрше авыл кешеләренә әлегә бик аз булса да үсентеләр тарата башлады. Бу — гаять игелекле традиция. Совхоз — 1932 нче елдан бирле җиләк-җимеш питомнигы буларак дан алган хуҗалык. Революциягә кадәр авыл мәктәбенә Казан гимназиясен тәмамлаган бер укытучы егет кайта һәм мәктәп укучылары белән алмагач утырта башлый. Ул вакыт үтү белән академик дәрәҗәсенә ирешкән, ә 1953 нче елда биргә кунак сыйфатында кайтып киткән күренекле совет галиме Василий Петрович Мосолов була. Шуннан бирле ничәмә-ничә буын үз оныкларына шушы авыл алмагачларын утыртып калдыра килә.

Ә колхозларның ташландык бакчаларында әле дә булса алмагачларның корыган, сынган, сөяктәй агарып калган шәрә, килбәтсез ботаклары, һәм искән җил саен шыксыз авазлар белән сыкрап, сайрар кошларны куркыта. Аларны ала кар-

галар, козгыннар һәм саесканнар үз итте. Хәтта тилгәннәр дә әйләнми, чөнки тычканнар белән кыр куяннары ул бакчаларны ташлап китте. Кәтү йөри, бозау арканлыйлар, сөреп чәчмиләр, алар яхшы чәчүлек җирләрен беләмиләр иде, ә үр, сырт итәкләренә, ерганаклар белән кискәләнгән кыентыкларга утыртылган булганнар.

Алмагачлар корыганга ике ел. Җиде йөз гектар корыган алмагачларны көнгә бер гектар төпләгән шәттә ике елдан бер генә ай ким вакыт кирәк булыр иде. Бер гектарда 450 төп алмагач, җыенысы 315 мең төп.

Ә бирегә корыган алмагачларны бер ел эчендә төпләп бетерделәр! Хәзер 350 гектары утыртылып та бетте инде. Калган ике йөз гектар җиргә гаҗәеп сихәтле май бирә торган облепиха утыртырга ниятлиләр. Бүгенге көнгә, карап торсаң, сокланырлык 50 гектар чия, 50 гектар карлыган, тагын йөз гектар кара миләш, кура җиләге, җир җиләге. Халык бүген дисә калган җирләрне дә утыртып бетерергә риза, тик үсентеләр җитешми.

Алмагачларны чистарту ягъни төпләү гадәттән тыш авыр шөгыль булып чыкты. Галина Павловна миңа бу хакта елмаеп сөйләде. Әмма бу аның һәлакәткә битараф елмаюы түгел. Бу җиңүдән соңгы елмаю иде. Һәлакәттән соң бары тик җиңгән кешеләр генә елмая ала. Әнисә Ситдыйкова, 30 ел хезмәт стажлы, Почет билгесе орденлы Александр Клементьев, Михаил Никифоров, Екатерина Зайчикова, Геннадий Курочкин, Анна Ботякова һәм алар кебек дистәләрчә механизатор тыныч мәшәкать эчендә кайнадылар. Тыныч дип... Иляшкәч кенә тыныч шикелле ул. Кайчандыр үзең утырткан алмагачларны җир куеныннан төбе-тамыры белән тракторларга сөйрәтеп чыгару сызлаган тешне суырттыру ише генә идеме икән соң? Уйласаң, бәгырьләр өзелердәй күренеш. Әмма дөнья йөзендә яшәүчеләрнең, рухка көч китерә торган, «Үлгән артыннан үлеп булмый» дигән тирән мәгънәле гыйбарәләре бар. Яшәүнең төп мәгънәсе шуңа, бары тик шуңа гына корылган. Хәвефне сылтау итү көчсезләр эше. Авырлык килмәсә, яшәүгә сусауның тәме китә. Сусамаган килеш су эчкәндәге шикелле.

Агачларны төпләү җиңел булмый. Иң әлек 500 метр озынлыктагы корыч трос апкайтып, тракторчыларга өләшәләр. Ул озакка җитми, агачларны бәйләп тарттыра торгач, юкадән ишкән бау кебек тетелеп бетә. Ә корыган алмагачларны төпләү өчен махсус машиналар юк. Мастерскойда хикмәтле сызымнарсыз гына бик җайлы механизмнар ясыйлар. Төпләвен төплиләр, тик корыган агачларны кая куярга?

Галина Павловна Казандагы художество мастерскоена шалтырата.

— Сезнең өчен чималыбыз бар.

— Кыйммәт сорыйсызмы?

— Алмагач арзан түгел.

— Күпмегә сатасыз соң?

— Бушлай бирәбез. Төпләгез генә.

Килеп тә җиткәләр. Төпләгәннәрен бер машинага төяп китәләр дә әзләре суына. Кешеләр җиңел юлны артыграк күрә шул.

Мин уйлап куям: берәүләр булса, меңнәрчә кубометр затлы агачны соң мыскалына хәтле файдаланырлар иде. Алмагач көнкүреш кирәк-яраклары, мебель ясауга китә ала югыйсә.

— Ягарга,— ди чарасы калмаган Галина Павловна.— Бердәнбер юл.

Гаҗәп: коп-коры алмагачы янмый икән ләбаса! Солярка сиптереп карыйлар — юк.

— Иске протекторлар белән аралаштырып карыйк.

Алай иткәч яна икән. Кама ярларында сөремле учаклар кабына. Яшәү өчен көрәш һәрвакыт ут аркылы. Ә ул учакларның иң ялкынлыларыннан да кайнаррак булып Галина Павловнаның йөрәге яна иде.

Бакчачы эше бер караганда тыныч та кебек. Агачны аны утыртып куясың да тора ич инде. Әмма бакчачы йөрәге иң тынгысызлардан ул. Бу җәһәттән ул кайсы һөнәр кешесенә якынрак тора икән. Минем үземә бакчачыны язучы белән якынянәшә кую хаклырак шикелле. Язучы да үз әсәрләрен бүгенге һәм киләчәк кешеләр өчен яза. Җимеш үстерү белән агач утырту да бүгенге һәм киләчәк кешеләре

өчен бит. Әнә ич, халкыбыз үз күңелендә бу хакта бер бәләкәй риваять тә йөртә. Бер абзыйның алмагач утыртканын күргән узгынчы: «Агай, бу агачны ник утыртып торган буласың инде, җимеше сиңа өлгереп җитми ләбаса?» — дип эндәшкән. Абзыйның җавабы гап-гади, әмма якты идеал белән тулы: «Мин аны оныкларым ашасын өчен утыртам». Мин сүз каткан бүгенге заман авыл агаеның нәкъ капма-каршысы!

Авылларда алмагачлар утырту кимегәнен, хәтта бетүен дә сизәсезме? Алмагачы утыртмау, янгын чыккач кыңгырау какмау белән бер үк сыйфаттагы битарафлык.

Язучының чаңы — сүз. Аның фикере кешеләр алмагачлар утыртсын өчен кирәк. Бакчачы да, язучы да киләчәк Ньютоннарының башына атом бомбалары түгел, ә кызарып-алсуланып пешкән тап-таза алма гына өзелеп төшсен өчен тырыша.

Алмагачы, Ньютон һәм бөтендөнья тартылышы законы. Кемдер Ньютон ятып ял итсен өчен алмагач утыртмаган булса?.. Дөньяда бөтен нәрсә үзара бәйле шул. Бәләкәй алмалар белән зур планеталар да. Кешеләр алма үстерүдән йөз чөереп, ясаган бомбаларын берьюлы шартлатса, Җир шары үз орбитасыннан ычкынып, планеталарның үзара тигез тартылышы бозылачак. Менә шундый бәйләнеш. Скептиклар, елмаймагыз! Ә сез еламагыз, оптимистлар! Әйе, мин шартлы, якынча бәйләнеш хакында сүз йөртәм. Ләкин Эйнштейнның һәммә нәрсәнең дә якынча чагыштырма бәйләнеше турындагы теориясен онытмыйк. Җир шарында хәзер һәр кеше башына 10 тонна шартлаткыч матдә эшләнеп куелган. Ә гүзәл планетабызда һәр кешегә йөзәр яки берәр килограмм алма һәм башка җиләк-җимеш туры килә микән? Килсен, килсен иде. Ходайдан ялвармыйк, үзебезнең кулда. Кемнең кулында, шуның авызында. Ишетәсезме: томан ураган Җиребезгә тамчылар сыман тып-тып итеп алмалар коелыша. Коелышсын, шулай тиеш. Аларга алмашка пешәрлек тере бөреләр генә калсын.



1979 елгы кышкы суык, 1980 елгы өзлексез яңгыр, 1981 елгы корылык — иманыңның туры кыйбласы булмаса, буталышып, әллә нишләпләр бетәрсең. Кама буендагы кара сөремле учаклар сүнеп, әле кайчан гына алсуланып утырган сусыл «Әнис», балдай татлы «Башкорт чибәре», зәһәр «Антон»... алмалары биргән агачларның кайнар көлләре җилгә очты... Инде менә бүтән бәла: утыртылган яшь үсентеләрнең корылыктан һәлак булу ихтималы. Шәһәрдән ярдәмгә 4 су сиптергеч машина җибәргән булганнар, әйтерсең лә аларда өч сутый дача җире. Совхозның су сиптереп йөргән 40 тракторы янында нәрсә генә иде? Төпләү, төпләгәннәрен яндыру кебек үк, тоташ су сиптерү дә корылыклы елда гаять четерекле. Иртәнге тугызга кадәр, ә кичен дүрттән соң гына мөмкин. Вакыт аз, ә агачлар

күп. Су сибүгә, төпләренә йомшак туфрак яки торф чәчү шарт. Югыйсә, җир ярыла, тамырлар өзелә, ялангачлана, кибә. 250 гектар җирдәге 112 мең 500 төп алмагачның һәркайсы җәй буена — апрельдән августка кадәр шулай күз уңында торды. Зур хезмәт!

Ә Татарстандагы барча питомникларда үсентеләргә ясалган ялгаулар борынгый алмый калды. Корылык бу яктан да китереп сукты.

Уйланыр өчен факт:

Татарстанда җәмгысе 24 мең гектар алма бакчасы корыды. 14 мең гектары җәмәгать секторында, 10 мең гектар чамасы шәхси хуҗалыкларда. Якынча 10 миллион ярым төп! Моны кабат булдыру өчен Татарстандагы һәрбер кеше 3 төп алмагач утыртырга тиеш. Әлегә исә һәлак булган бакчаларның нибарысы яртысы гына аякка бастырылды». Ә тотрыклы, доход бирә торган уңыш җыеп алыр көннәр җитәргә әле яңадан биш-алты ел вакыт кирәк. Алмага кибетләрдә чират. Базарлардагысы кыйммәт. Җәннәт җимеше диярлеге бар шул. Ә чыклы иртәләрдә үзең сайлап алып тешләгән алмага ни җитә?

Алмаларның иң тәмлесе маңгай тирендә сугарылып, йөрәк утында пешкәне ул. Галина Павловна моны бик яхшы белә. Ул ышана: җирдә кеше яшәгәндә алма бетмәс.

Туп-туп итеп алма коелганда
Дөп-дөп итеп йөрәк... сикерә...

Безнең авылыбызда багъ алмасы дигән сүз бар. Егетләр бездә кызларны «багалмам» дип иркәләгән. Җаннарыңны елата-елата эретерлек татлы сүз ул. Иркәңне табигатьнең иң күркәм җимешенә тиңләүдә халыкның алмагачка нинди зур хөрмәт белән багуы ачык күренә. Ул багъ алмалары шул ук Кама буйларында, шул Масловка җирләрендә, урманнарның иң асыл аланнарында гына үсә иде. Кыргый алма ул — багъ алмасы. Багъ. Мәгәр исеме кызларга яратып дәшәр өчен кулланырлык булгач, авыз суларын китерерлек тәмле икәнлекләре аңлашылса кирәк. Багъ алмалары көзнең иң соңгы мәлләрендә генә, җиләк-җимешкә тансыклый башлаган чакларда гына өлгереп җитәр, һәм, чыннан да, егетләр көндезләрен аларны атларга атланып барып апкайтыр да кичләрен күзләре төшкән, күңелләре яткан кызларына чыгарып бирер иде.

...Ул кышны багъ алмаларының урманнарда үсеп утырганнары да корып бетте... Урманнарның ал күлмәкле, кәүсәләренә сарылып елардай тыйнак кызлары...

Галина Павловна бакчада бик еш була. Иртәләрен дә, кичләрен дә. Бигрәк тә — кичләрен, авылда утлар кабынгач, баш очында Җидегән йолдызының учак күмере дәй җемелдәве көйри башлагач. Татлы ис таратып, аяк астында коелган яфраклар, кипкән үлән сабаклары кыштырдый, кыйгаклашып, ерак көзлекләргә кыр казлары төшеп куна, Кама ягыннан су исе килә, ак күгәрчен шикелле гөрелдәп кенә соңгы су трамвае узып китә. Ямансу әле аңа, бик ямансу. Яшь бакчада аның җанына иң кадерле булган ис — чыклы алма исе юк. Алма исе, салам куышларның коры һавасы, әрҗәләрдәге алмаларны төяүче йөкчеләрнең яңгыравыклы тавышлары, өйләренә таралышыр алдыннан машина көтеп утырган кызларның һәм хатыннарның тыенкы көлешүләре, ялкау этләрнең юри генә өреп куюлары, күңелне әллә кая дәшеп кабынып киткән учак ялкыны — боларның бөтенесе аның хәтерендә генә әле. Хәтерендә генә түгел, бәлки хыялында да. Болар инде артта калган үткән хатирәләр генә түгел, болар инде, торналарның язгы авазлары кебек, яңарачак, киләчәктән дә күренеп, ишетелеп, сизелеп җилкендереп торыр.

# КЕШЕ ХАКЫНА

Ул гомере буена кешеләр белән эшләде. Шулай да бу юлы халык алдына кереп утырырга уңайсызланды. Шул җир уллары, кызлары арасына килеп, авыр йөккә җигелергә шүрләмәгәнсең икән, вакытында алар рәтенә басып, җиң сызганырга батырлыгың җиткән икән, димәк, шушы колхоз халкы бергәләшеп сиңа үзенең җылы сүзен җиткерергә җыенганда гына оялма инде, иптәшкәем.. Югыйсә, дөрес аңламаслар үзеңне...

Культура сараеның олы залы шыгрым тулы. Олысы да, урта яшьтәгеләре дә, кечесе дә җыелган. Үзе бусагада күренүгә үк кул чаптылар. Урыннарыннан торып басып, аны сәхнәгә таба озатып калдылар.

— Бүген бездә зур тантана, — дип башлады сүзен партия оешмасы секретаре Ильяс Тямаев. Шунда гына кул чабулар бераз тына төште. — Радио аша да әйттермәдек, чакырып та йөрмәдек. Язып эленгән гади бер белдерүгә җыелгансыз, иптәшләр. Сәбәбе — Шәриф Сәгыйрович Хафизовка бүген 60 яшь тула. Кайчандыр мондый дәрәү тантанага сәбәп бирермен дип хыяллану түгел, уена да кертә алмагандыр. Кем белә, бәлки бу вакытта биредәге иң беренче җыелышта катнашуын күз алдына китергәндер...

Ә мин кешеләрнең үз председательләре турында чын йөрәктән әйткән кыска, ләкин берәгәйле сүзләреннән тупланган күренешне күз алдына китерәм.

Норлат тирәсендәге иң ярлы, «таушалган» авылларны берләштергән күмәк хуҗалык иде бу.

... 1955 елның июль ае.

Клуб димәсәң хәтере калырлык, шактый гына тормыш күрүдән, җил-буранына, эссе-суыгына, яңгыр-карына каршы торып инде янтая башлаган булса да, бу өй җыелышка килгән халыкның барысын да сыйдырган. Күренеп тора, күбесе битараф кына утыра, чакырылганга күрә генә килгәннәр.

Райком, район башкарма комитеты вәкилләре дә бар. Хәлнең торышына анализ ясалды, җитәкчелекне яхшыртырга кирәге әйтелде. Ил күләмендә ярдәм итү йөзеннән, КПСС Үзәк Комитеты шәһәрләрдән авылларга 30 мең коммунистны җибәрергә булды.

— Менә шундый утызмеңчеләрнең берсе — партия өлкә комитеты җибәргән вәкил — Шәриф Сәгыйрович Хафизов, — диде район җитәкчесе. — Сугыш юлын узган иптәш. Аны бүген председатель урынына тәкъдим итәргә исәплибез. Сезнең фикерләрегез нинди?

Кайсы тәмәке тартып, кайсы сөйләшеп утырган халыкка җан керде.

— Бик яшь түгелме соң?

— Миңа 35 яшь.

— Хатының киләме соң? Безнең колхозда хатыннар янына йөрерлек «Победа»лар юк, булмас та.

— Минем хатыным өчен кайгырмагыз, иптәшләр, ул монда килер. Аксубай районы кызы ул. Авыл, игенче хезмәтен яшьтән татып үскән кеше. Мине партия Казан белән ике арада йөрергә түгел, сезнең янга ипи үстерергә җибәрде. Бергәләп җигелсәк, булдырырбыз.

Сайлаган вакытта каршы килүчеләр булмады. Төпле җитәкчегә сусаганнар... Нык куллы кеше кирәк монда. Кешеләрне бердәм сафка

тезеп, адымнарын бер итә алырсыңмы, Хафизов, минә анысы синнән тора. Әзер рецепт юк. Кешеләр төрле, катлаулы. Әнә җыелышта «халык мәхәббәтен» казанырга тырышып: «Читтән килгән — чит инде ул», — дип, төрле чәнечкеле сүзләр алып утыручы Закир үзе бер атна эшкә чыкмый инде.

Хафизов аны идарәгә чакыртты. Икәүдән икәү генә сөйләшергә исәпләде. Ул әзмәвердәй таза кеше. Нигәдер өнәмәде ул Хафизовны. Әңгәмә вакытында председатель бу серле йомгакны тиз сүтте.

— Соң уйлап кара, Хафизов, син капитан, ә мин — майор. Нишләп мин сиңа буйсынырга тиеш әле? Сугышта алай түгел иде.

— Әгәр бер командир булдыра алмаса, аннан түбәнрәкләрне дә күтәреп, мөһимрәк бурычлар үргән очраклар булды түгелме соң?

— Нинди хәлдә бит, — ди теге хәйләкәр елмаеп.

— Әйдә, шул кан койган юлларны кабат яңартыйк әле.

— Безнең аны онытырга хакыбыз юк.

— Анысы дөрес, алайса ни диеп син онытасың? — диде Хафизов, — һәрбер солдат җиңү хакына арсландай сугышмадымыни? Сугышты! Инде шул елларда яңартып, көчәйтеп тора алмаганга мондый авыр хәлдә калган колхозларны ныгыту, ипи өчен көрәш бүген үзе бер фронт түгелмени ул?! Гади солдатлар, имгәнеп, чәрдәкләнеп кайткан абзыйлар хәлдән килгәннән дә артыгын куеп, көнне-төнгә ялгап эшлиләр, ә майор погонын салган кичәге командир шушы йөкне кирегә өстери. Нигә?.. Алай гына да түгел, артка тарта алмаса, көпчәккә таяк тыга.

— Нишләп алай китереп куясың?! Минем колхозга комачаулыгым юк.

— Ничек юк? Менә син үзеңне командир дисең. Шулай бит. Әйтик, кайсыдыр бер авылны азат итәргә кирәк, ди. Арыган солдатларыңны күтәрдең, ди. Дошманның көче синекеннән күбрәк. Һәрбер кешең исәптә, һәрберсеннән биш-ун солдатныкы кадәр батырлык көтәсең. Ә шул минутларда бер взводың кичә азат ителгән авылга киткән, учак ягып, аш пешереп, кәеф-сафа корып утыра, ди. Нишләр идең? — Хафизов тагын аның күзләренә төбәп карады. Ә тегесе, түзә алмыйча, карашын читкә алды. Җавапсыз кала торган очрак түгел. Нишләргә?

— Ул вакыттагы законны үзең беләсең.

— Ә синең кыланышың? Халык ачлы-туклы күпме эшләде. Беләсеңме? Беләсең. Башта сугыш өчен, Җиңү өчен, Ватан хакына дип түзде. Ә аннан? Сугыш җимергәннәрне торгызабыз, шартлаган заводлар, ишелгән шәһәрләр, көлгә әйләнгән авыллар күпме дә, күпме кеше землянкаларда яши, дидек. Түздек. Ә хәзер? Халык ипигә сусаган. Ансыз акча да юк, завод та эшләми, техника да ясап булмый. Көчне җыеп тагын бер селтәнергә кирәк. Кешесе дә җитми. Шундый вакытта син, бригада оештырып, читтә эшләп йөрисең. Атна буе шулай дәвам итә. Менә бу кыланышны шул качкын солдатлар белән тиңләми ни дисең?

— Арттырасың.

— Үгез сыртын сындырырлык таза кешеләр колхоз эшеннән читтә йөрүгә авыл урынлы гаҗәпләнә. Сөйләшү шул: мин моңа чик куям. Ә председатель итеп сине сайламауларының сәбәбен үзеңнән эзлә. Кайту белән җиң сызганып тыныч хезмәткә алынган булсаң, бәлки минем бу колхозга кирәгем дә чыкмас иде. Майор тикле майорның шундый хәлдә калуы кызганыч, әлбәттә. Эшлә, вакытыңны юкка әрәм итмә, үзеңне хезмәт белән генә аклый аласың син.

Хафизов бүлмәсеннән чыккач, Закир беркем белән сөйләшми генә махорка төрде. Чүмәшкән хәлдә стенага терәлеп, аны озак кына тартты. Кайвакытта, озын гына суырып алгач та, төтенен чыгармый бер

читкә карап торды. Утка тәкереп, тәпчеген чатка атты да китеп барды... Эче кайный, әйтерсең, аның күкрәгендә ике фронт сугыша иде. «Булмады, Закир, оттырдың, үзең баш була алмасаң, инде читтән килгәнгә башыңны иярсең»...

Шул көнне үк балтасын алып, Закир Ганиев ферманы төзәтүчеләргә килеп кушылды.

Эшли башлаганнан бирле Казанга кайтканы һәм гаиләсен күргәне юк иде. Вакыт табарлык түгел. Хафизовның үзен, суктыргыч машина көлтәне суырып алгандай, баш-аягы белән «чорнап батырды».

Кешеләр күңеленә юл төрле сукмаклар буенча эзләнде. Күрше авылда чувашлар яши. Алар янында да еш булды председатель. Алар телен дә өйрәнә башлады. Колхозның исеме «Дружба» икән, җисеменә туры килсен, дуслык нык булсын», — диде ул. Терлекчеләре, игенчеләре, механизаторлары белән дә аерым-аерым иркенләп сөйләшеп утырды. Хафизов бу әңгәмәләрне, кайсы авылда гына булмасын, әчкерсез итәргә омтылды: кеше ышансын, күңел түрендә үзен борчыганын, нидән шулай икәнен һәм аннан чыгу мәсьәләсендә нәрсә уйлаганын да әйтсен иде. Алар шушы җиргә берегеп, ата-бабаларын тыңлап үскәннәр бит. Һәр басуның «холкын» беләләр.

— Җирләр әйбәт, кем әйтмешли, тәртә утыртып куйсаң, тарантас үсеп чыгарлык иш, уңыш түбән... Нидән бу? Карау җитмиме, начар эшкәртеләме ул?

Шәриф Хафизов бу турыда партия җыелышларында коммунистлар арасында да киңәште. Уңыш өчен көрәштә хуҗасызлыкка чик куярга кирәк. Әйтик, чөгендер игү. Бик кирәкле культура, юкка гына «татлы тамыр» димиләр иш. Заводы да рәттән. Нигә шуңа йөз тотмаска? Мәйданны арттырырга кирәк. Звенолар оештырмаска микән? Алар үзләре хәзерләсен, чәчсен, карап үстерсен, җыеп уңышын да тапшырсын. Менә шуннан кешенең хезмәтенә күрә хөрмәте дә үсәр. Үзләрен кыш көннәрендә укытырбыз, агрономнар дәрес бирер.

Терлекчелек, игенчелек, чөгендер игү тармакларындагы хезмәтне тәртипкә салу кешеләрнең эшкә булган мөнәсәбәтләрен бөтенләй үзгәртте. Мәсәлән, чөгендер тишелеп чыккач, аны сирәкләп, рәттә утырган тазарак үсентене генә сайлап калдырырга, чүп үләннәре утарга кирәк. Бу вакытта звено членнары бөтен гаиләләре белән басуга чыга. Аннан механизаторлар эшкә керешә. Көзен, чүлмәк кадәр үскән татлы тамырны алганда да авыл халкы кабат үзләре эшләгән рәтләргә юнәлә.

Хәзер инде бердәм чыгалар дип әйтүе генә җиңел. Ул вакытта бу чара түземлелек, сөйләшү, ышандыруны таләп итте. Ә ул кечкенә генә уңышны да күреп ала, билгеләп үтә иде. Чөгендер игүче Хәсән Яһудин әйтмешли, үзенең мәрхәмәтле зәңгәр күзләре белән бер карап мактарга тотынса, ереп китәрсең, ник тагы да тырышмадым икән, булдыра идем бит дип куясың. «Шәриф Сәгыйрович, борчылмагыз, моннан да ким итмәбез!» дип вәгъдә бирәсең. Аннан ничек үтәмисең инде?

Халык ихтирамы еллар буе яуланды. Ә бу ихтирам, фермаларның яңаруына, терлекләрнең баш саны артуына, озатыла торган сөтләрнең центнерларына, кырдагы чөгендер, арпа, бодайларның уңышына тәэсир итте. «Дружба» колхозын районда, аннан республика күләмендә мактап телгә ала башладылар. Ә чөгендер аларны тагы да ераграк алып китте. Берничә мәртәбә СССР Халык Хуҗалыгы Казанышлары күргәзмәсендә алар тәҗрибә турында сөйләделәр, аны бөтен илгә тараттылар. Еллар буе югары уңыш алган звено җитәкчеләре күргәзмәнең медальләренә лаек булды, ә Хәсән Яһудин мотоцикл белән бүләкләнде. Ярышларда Республика, Россия Федерациясе һәм

СССР күләмендәге күчмә байракларны яулап алдылар. Район, республика чөгендер игүчеләрнең семинарлары берничә мәртәбә биредә узды. Алар һәр гектардан өчәр йөз центнерга кадәр уңыш серләренә өйрәнделәр.

— Рәхим итегез, безнең исемебез дә дуслык ич, — дип, күршеләрне бик теләп өйрәттеләр.

Үзләре беренчелекне ычкындырмас өчен җиңне югарырак сызгандылар, елның елында тотрыклы уңыш алуга ирештеләр. Аларның тырыш хезмәтләре орденнар һәм медальләр белән бәяләнде. Ә председатель Шәриф Сәгыйрович Хафизовка Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде. Утызмеңченең бирегә килеп ун ел эшләү дәверендә ирешкән уңышына ил күләмендә бирелгән иң югары бәя иде бу.

Кешеләр өчен кайгыртуны элеккечә беренче бурыч итеп куйды... Звено җитәкчесе Хәсән Яһудинның йорт-курасы янды. Бер төркем бала-чагасы белән өйләреннән калган көлгә карап тордылар. Хафизов бирегә ут дөрләгәндә үк барып җиткән иде. Кабат килде.

— Борчылмагыз. Тырыш хезмәт, уңган агач кебек, җимешен гел биреп тора ул. Җир улын үги итмәс. Өйнең яңасын салдырырбыз. Әйдәгез әле, әнә тегендә күчеп торыгыз, — диде Хафизов, аларга бер йортны күрсәтеп. Шул вакыт машинадан аш кашыгы, теш щеткалары, паста, сөлге, сабын, чыгардылар. — Менә монда барысы да алтышар данә, һәрберегезгә бирәр диюем. Хәзер алты урын-җир дә китерерләр. Кайгырмагыз, — дип тынычландырды ул тора-тора.

Йортны тиз өлгерттеләр. Миче чыгарылды.

— Башта ипи пешереп карагыз, — диде Хафизов. Аннан, исе борынны кытыклап торган кайнар күмәчне үзе авыз итеп карагач кына: — Күченегез, яшәп була монда, — дип китте.

Бу колхозда кешеләрнең һәм эшнең кадере арта бару, яшьләрнең китәргә омтылмавы, бердәмлекнең сәбәпләре менә кайда икән! Белгечләр дә алышынмый. Хафизов кул астында эшләп, аның «мәктәбен» узган агроном, экономист, инженерлар район күләмендәге идарә эшләренә күтәрелделәр, кайсы совхоз директоры, кайсы колхоз председателе булды инде. Кирам Әхмәтсәгыйров, Хәниф Хәмитов, Виталий Игнатьев... Саный китсәң, исемлек шактый зурга сузылыр иде. Аларның һәрберсе Шәриф Хафизов янында өйрәнүе белән үзен бәхетле саный. Ә Хәлил Морадыймов бигрәк тә...

Әнә бит, колхозчыларның Хафизовны котларга дип Культура сараендагы җыелышына ул да килгән.

— Иптәшләр, Шәриф Сәгыйрович безнең остаз ул,— дип сүз алды Хәлил. Аннары аның үзенә төбәлеп: — Сездән күчеп киткән иптәшләр исеменнән шуны әйтәм: сезнең киңәшләрне тотып эшли башладык. Әле хәзер дә бу мәсьәләдә Шәриф абый ни дияр икән дип эчтән үлчәп йөрибез. Ышанычыгызны акларга тырышырбыз. Рәхмәт...

Шәриф Хафизовка бу сүзләр дә бик кадерле. Хәлил аның күз алдында үсте. Колхоз аны институтта укытты, ул агроном дипломы алып кайтты. Хезмәтне сөючән булып чыкты. Соңгы елларда Хафизов аны председательнең тәзелеш буенча урынбасары итеп билгеләгән иде. Югалып калмады. Бервакыт КПСС райкомының беренче секретаре Габбас Гыйматдинов сүз ара болай дигән иде:

— Шәриф Сәгыйрович, «Рассвет» совхозы шактый бер урында таптанды, ә хәзер артка тәгәри. Җитәкчесенә булышып та карадык, булмады. Алыштырырга дигән карарга килдек әле. Безнең уйда берничә кандидатура бар, син дә киңәш ит әле...

— Бездә бер егет бар. Эшли алыр иде. Карап, ярдәм итеп торырбыз. Хәлил Морадыймов. Яшь, куәте бар.

Шулай итеп, Морадыймовны «Рассвет» совхозына директор итеп билгеләделәр. Хафизов белән көн аралаш диярлек шалтыратышып торырга сүз куештылар. Бергә киңәшләшеп, мәсьәләне хәл итү юлларын таба башладылар.

... Аны тәбрик итүчеләр арасында Хафизовны сайлаганда чәнечкеле сүзләр атып утырган Закир Ганиев кенә юк. Биредә яшәми инде ул. Балалары янына киткәндә кергән иде.

— Хушлашыйк, бәхилләшик дип сугылдым, туган. Картлыкны малайлар янында — Урта Азиядә каршыларга булдым, — диде ул тирән сулап.— Күңелне тырнап йөри торган бер нәрсә бар, аны үзем белән алып китәсем килми. Теге вакытта бәйләнеп йөрүем өчен гафу ит инде! Мин сине башта дөрес аңлый алмаганмын. Әйе, гафу ит инде, туган...

Тормыш диңгез бит ул, дулкыны да булгандыр дип, эчкерсез генә сөйләшеп аерылдылар.

Сүз алып котлаучылар, яхшы теләкләр белдерүчеләр шактый булды. Күбесе колхозчылар үзләре. Хафизов алар хакында үзе менә мондыйрак фикер әйтте:

— Мин аларны җир шарын күтәреп торучы баһадирларга тиңлим. Колхоз алар хезмәте, алар тырышлыгына таяна. Фәйзана Шәйдуллина республика күләмендә иң яхшы чабаныбыз. Чуваш хатыны Антонина Андреевнаның тырышлыгына кем сокланмый?! Хәзер ул колхозның персональ пенсионеры. Ә теге елларны, Хафизов килгәч, ундүрт бозауны үз өенә алып кайтып караган иде. Ферма, салкын, ашатырга азык юк чакта... Утыз биш ел буе сыер савучы булып эшләде. «Өең искергән, әйдә, колхоз салган өйгә күч!» дигән сүзгә каршы да:

— Кадерне белеп әйтүегезгә рәхмәт, акчам бар, үзем салдырам. яшьләргә тәкъдим итегез. Алар — колхозның киләчәге, — дигән иде...

... Мин Шәриф ага Хафизовны Казанда да очраттым. Төзүчеләрнең Культура Сараенда авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре көненә багышланган тантанада. КПСС өлкә комитеты секретаре Ф. Садыйков үзенең докладында Октябрь районының «Дружба» колхозын һәр гектардан утызар центнер арпа, бодай, өчәр йөз центнерга якын шикәр чөгендере үстерүчеләр дип мактап телгә алды.

Аннан соң беренче сүз шушы колхозның председателе Шәриф Хафизовка бирелде. Ул президиумнан трибуна янына килеп басты. Озын буйлы, киң җилкәле. Моннан ун ел элек, Татарстанның илле еллыгы тантанасында да сүзне колхоз председательләренең берсенә — аңа биргәннәр иде. Күкрәгендә СССР Верховный Советы депутаты билгесе, «Урак һәм чүкеч» алтын йолдыз медале, орденнар... Туган ил азатлыгы өчен арысландай батыр сугышкан өчен, тыныч тормыштагы тырыш хезмәтләре өчен бүләкләр... Бүген ул орден, медальләрен такмаган. Күкрәгендә Алтын йолдызы гына.

— Иптәшләр, безнең колхоз унынчы бишьеллыкта уңыш алуны 38 процентка арттыруга ирешә.

Шул ук Хафизов. Бөркет кебек батыр йөрәкле, командир кебек таләпчән, судья кебек гадел, врач кебек кешелекле... Кыскасы, авыл картлары әйтмешли: «Кирәк икәнен ышанса, кара урман аша туры юл салып барыр, һич туктата алмассың». Үзе артыннан башкаларны да ияртер. Гадел кеше ул.

Тәүфикъ СӘГЫЙТОВ.

Ринат Мөхәммәдиев

# ЯЗЛАР ТАГЫН КИЛЕР...

Һәр язны — күңелләрдә генә түгел, табигатьтә дә шигъри рух аеруча күтәренке булган чорда — китап киштәләренә күләме белән алай зур булмаган яңа шигырь җыентыклары өстәлә килә. Татарстан китап нәшрияты моны үз эшендә матур бер гадәт итте дияргә мөмкин. Чынлап та, матур гадәт — елгалар ташып аккан, республика кырларында уҗым яшәреп килгән, бөреләр көнгә тартылган бер мәлдә шигырь сөючеләргә яшь шагыйрьләрнең беренче китаплары тәкъдим ителә. Менә шуңа күрә дә «Яшь шагыйрьнең беренче китабы» сериясендә чыккан һәр җыентык әдәбиятыбыз барышында үзенчәлекле бер сәхифә буларак искә алынуга лаек. 1981 ел бу җәһәттән аеруча нәтиҗәле булды — берьюлы өч яшь шагыйрьнең беренче китаплары укучылар хөкеменә тәкъдим ителде. Нурия Измайлова, Ямаш Игәнәй һәм Роберт Рәкыйповлар быел шигъри бәйгегә чыкты.

Шигъри бәйге дигәннән, менә инде ун-унбиш еллар чамасы шул бәйгедә көч сынашучы шагыйрьләрнең борчу һәм шатлыкларын, иҗаттагы табыш һәм мавыгуларын тоемлый, сизә киләбез. Җитмешенче еллар таңында ук шигъри толпарларын тыя алмаган япь-яшь Зөлфәт һәм М. Әгъләмов атылып чыкканнар иде мәйданга беренче булып. Бу чыгу чын мәгънәсендә җитди вакыйга сыман кабул ителде. Шигырь ялкынында дөрләп янды, тормышчан һәм яңа моңга тулып гөрләп акты һәр икесенең иҗат инешләре. Әмма бу күпкә бармады, мул сулы елгага килеп кушылган ярсу инештәй кинәт алар тынып, сабырланып калдылар. Шагыйрь әйтмешли, «белмим, күпкә, әллә бик озакка...» һәрхәлдә, җитмешенче елларның икенче яртысы һәм сиксәненче еллар башында бу ике шагыйрьнең иҗат пассивлыгы күзгә ташланып торды. Зөлфәтнең төрле жанрларда эзләнүен, балалар өчен әсәрләр язуда эшләп килүен һәм поэма тәмамларга җыенуын да искә алсак, бәлки, аңа мөнәсәбәттә пассив сүзен куллану бик үк дөрес тә булмас. Ә менә М. Әгъләмов дигән шагыйрьнең барлыгын инде күпләр онытып килә булса кирәк. Кызганыч, әмма факт. Гыйбрәтле факт. Әдәбиятта иҗади эзләнү бер генә минутка да тукталмаска тиешлеген күрсәтеп тора ул. Бу хакта — иҗатындагы сүлпәнлекнең сәбәпләре хакында шагыйрьнең, мөгаен, үзенә дә җитди рәвештә уйланырга һәм нәтиҗә ясарга вакыттыр инде...

Күп булса ике-өч ел вакыт үткәндер, яңа шагыйрьләр укучыга беренче шигъри җыентыкларын тәкъдим итте: Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин, Фәннур Сафин. Алар да Зөлфәт һәм М. Әгъләмовның яшьтәшләре, әмма инде иҗат алымнары һәм юнәлешләре белән кабатланмыйлар, үзенчәлеклеләр. Вакыт үтә торды һәм ул бер уңайга әлеге өч яшь шагыйрьне дә аз сынамады. Гаҗәп хәл, беренче әсәрләре кызыклы гына булса да, алай исне китермәгән авторлар шушы еллар эчендә эзләнүдән туктамаганнар, колач җитмәслек иҗат газаплары кичергәннәр, һәм бүгенге әдәби процесста үзләренә генә хас урыннарын тапканнар. Р. Вәлиев прозада, балалар әдә-

биятында һәм лирикада күзгә күренерлек нәтиҗәләргә ирешә. Ул җырлар язуда да актив һәм уңышлы эшләп килгән шагыйрь, киң катлам укучы белән генә түгел, тамашачы белән дә рухи уртаклык һәм аңлашу тапкан бәхетле яшьләрнең берсе.

Беренче китабында ук коеп куйган лирик шагыйрь булган Р. Миңнуллинга, бер карасаң, алай эзләнәсе дә түгел сыман иде югыйсә. Ә шулай да беренче уңышлары белән канәгатьләнеп калмады шагыйрь, лирикадагы ихласлыгын һәм табигыйлеген дәвам иткән тәкъдирдә, балалар шигъриятенә йөз белән борылды. Нәтиҗәдә, үзенең коеп куйган лирик булудан да бигрәк, балалар өчен шигырьләр остасы икәнлеген исбат итте. Тагы шунысы куанычлы, Роберт һәм Разил үз яшьтәшләре арасында иҗтимагый активлыклары белән дә аерылып торалар. Иҗаттагы өзлексез үсеш, нәтиҗәлелек белән моның турыдан-туры бәйләнештә икәнлеге бәхәссез булса кирәк.

Ф. Сафинны да тынычланып, үз-үзеннән канәгать булып, үсеш-хәрәкәттән тукталып калган шагыйрь диеп әйтмәс идем. Тормышта гына түгел, иҗатында да сабыр һәм тыйнак булып калган Фәннур күңелләрне яулап алырга сәләтле җылы шигырьләр язуында дәвам итә. Әмма вакыт-вакыт, үз-үзенә хыянәт иткәндәй, эч пошканнан язылган әсәрләрен дә тәкъдим иткәли укучыга. Мондый шигырьләрнең табигате хакында аңа да утырып бер уйланырга иде.

Һәр яңа яз яңа шагыйрьләрнең беренче китапларын алып килә дигәнне исбатлаган сыман, М. Галиев, З. Мансуров һәм Э. Мостафиннарның да китаплары дөньяга чыга торды (алар шулай ук югарыда искә алынган шагыйрьләрнең яшьтәшләре). Э. Мостафин иҗатын, миңа калса, зуррак кызыксыну белән каршы алганнар иде. Берсүзсез, сәләтле автор. Әмма аның шигъри ялкыны М. Әгъләмовка караганда да тизрәк сүрелә башлады кебек. Ә сәбәбе шул ук — шәхес буларак пассивлык, үз-үзеңдә бикләнеп калу, булган сәләтне үстерү һәм баету турында кайгыртмау.

М. Галиев белән З. Мансуров иҗат алымнары һәм шигъри фикерләүләре белән традицион шагыйрьләр түгел. Шул яктан аларның эзләнүләре, билгеле дәрәҗәдә, Р. Фәйзуллин һәм Р. Харис иҗатларына тартым. Әмма бу — сукырларча иярү һәм кабатлану түгел. Әйтик, М. Галиевны нигездә рациональлеккә йөз тоткан автор дисәк тә, вакыт-вакыт төгәллек һәм кырыслык аның шигырьләренең тышкы формасында, тел-стилендә генә сакланып кала, ә аларның хисси башлангычы һәм чыганагы шигырь калыбының кырыс законнарына сыеша алмый өскә бәреп чыга. М. Галиевка әлеге ихласлык һәр очракта да җитенкерәми, хәтта ул аннан, башкалардан аерылып торуны максаты санап, аңлы рәвештә читләшми дә түгел микән әле.

Ә инде З. Мансуровка килгәндә тагы өстәп шуны әйтәсе килә: ул, башлаган юлыннан тайпылмыйча — фикри һәм мәгънәви тирәнлеккә омтылуын дәвам итә. Киреләнү дип әйтерлек дәрәҗәдә үҗәтләнеп дәвам итә, хәтта вакыт-вакыт нәни генә уйларын да тирән фәлсәфә кабыгына төрергә газаплана — кыскасы, арттырып та җибәргәли. Булсын, дистәләгән яшьтәшләрең арасында, бай традицияле шигъриятта үз-үзеңне табу җиңел эш түгел. Бүтәннәргә охшатмыйча язарга омтылыш, иҗат индивидуальлегеңне табарга, ачыкларга омтылу, һәм шул тапканыңны саклап калу яшь шагыйрь өчен аеруча кирәкле сыйфат. Күпләр өчен дефицит булган сыйфат!

Чираттагы язлар укучыга Б. Сөләйманов, Н. Әхмәдиев, Р. Низамиев һәм Х. Әюповларны китерде. (Шулай ук Зөлфәт һәм М. Әгъләмовтан башланган шагыйрьләрнең яшьтәшләре). Ә уйлап карасаң, инде бер дистә еллар чамасы вакыт узып киткән. Күңелдәге уй конкрет сораулар куя: шул ук бер буын — килә ява, килә ява, нәләнде бер болыт дигән сыман — һаман да әдәбиятыбызны яшь шагыйрьләр белән тәэмин итеп тора түгелме соң? Дөрес, сугыштан соң ук, котеп алынган бәхетле елларда туган бәхетле буын ул! Алай икән, инде яңа сорау туа — бер үк елларда университетта укыган, бергә лекция тыңлаган бу яшьтәшләр нигә соң төрлесе төрле елларда киләләр — шагыйрьләргә булган таләп кими бару, иләкнең елдан-ел эреләнә баруы турында сөйләми микән бу күренеш?.. Болай да үсеп килгән икеләнүләргә тагы шунысы өстәлә: ун ел элек егерме-егерме биш яшьлек шагыйрьләр мәйданга килгән икән, алар яшендәгеләр бүген юкмы икәнни соң? Әллә без аларның яшьлек ялкынына утыз-кырыклардагыларның тәҗрибәсен каршы куя башладыкмы?! Бу күренеш җентекләп өйрәнү һәм нәтиҗәләр ясауны таләп итә торган факт булса кирәк.

Инде югарыда искә алган шагыйрьләргә килсәк, иң элек бу сорау-шөбһәләрнең туууына алар гына сәбәпче түгеллекне искәртеп узу кирәктер. Чөнки һәркайсының иҗат-

та әйтергә теләгән үз сүзе бар. Б. Сөләйманов шигырьләрендә без нефтьчеләре белән данлы Төмән якларының бай рухы, киң һәм көр күңеле белән очрашсак, Н. Әхмәдиев Татарстанның үз нефтьчеләре арасында торып, шуларның бай тормышын җырга-моңга салырга омтылып яши. Р. Низамиев шигырьләрендә бүгенге авылның көр күңелле романтик егетләре киң матур дөньяга сөрән сала. Буразналар, иген кырларыннан зәңгәр күккә, йолдызларга кадәр араны бер талпынуда кочып алырга теләгәндәй, ышаныч һәм оптимизм белән килә Рашат шигърияте безгә. Белмим, аның яшьлек багажы, яшьлек ашкынулары күпкә барырмы, ә поэзиягә һәм тормышка булган мәхәббәте чиксез күренә... Инде Х. Әюповка килгәндә, аңарда бүген, бар нәрсәдән дә бигрәк, салмак һәм җылы лирик башлангычның өстенлек итүен танымый мөмкин түгел. Әмма бу салмак һәм тыныч лирика дигәннең уртакуллыкка авышуыннан да сак булырга кирәктер. Чөнки шагыйрь өчен уртакуллык һәм бертөрлелектән дә куркынычрак нәрсәнең булуы мөмкин түгел.

Ниһаять, югарыда инде искәртелгәнчә, 1981 ел язы тагы өч шагыйрь — шул ук буын вәкиле Н. Измайлованы һәм беразга өлкәнрәк тә булган Я. Игәнәй белән Р. Рәкыйповны алып килде.

Р. Рәкыйпов тормышның күп кенә өлкәләрен үз тәҗрибәсендә өйрәнеп, ерак диңгез һәм океаннарда булып, акчарлаклар тавышы һәм тау-тау дулкыннар шавын шигырь кысаларына сыйдыра алган шагыйрь. Инде моңарчы бер әйтелгәнчә, сабыр һәм тыныч холыклы автор... һәм шундук күңелгә уй килде: без бик еш кына сабыр һәм тыныч холыклы дибез дә, моны зур мәртәбәгә санап, «билгеле бит инде болай да» дигәндәй, җиңел генә уңай нәтиҗә ясап куябыз. Сүз дә юк, сабырлык һәм тыйнаклык һәр кешене бизәгәне кебек үк, шагыйрь өчен дә уңай сыйфатларның берсе булып тора. Әмма еш кына әлеге сабырлык һәм тыйнаклык төп критерийларның берсе итеп тә кабул ителгәли. Һәм кагыйдә буларак, урта куллык, үз сүзең, үз позициянең җитәрлек һәм ныклы булмавы шушы матур сыйфатлар артына елыша, яшеренеп шыпшып барә. Миңа калса, бу — тәнкыйть һәм остазларның вакыт-вакыт итәгатьле генә, шома һәм ыспай гына язгалап килүчеләрне тиешле буразнага кертеп, юнәлтеп җибәрмәүләре бәласе. Сер түгел ич, әлегәчә, «безнеңчә язучылар» һәм «безнеңчә язмаучылар»ны янәшә куеп караганда, кагыйдә буларак, беренчеләренә өстенлек бирелә килә. Нәтиҗәдә, кемгәдер иярүче, әмма үз-үзен таба алмаган, хәтта эзләп тә карамаган тыйнак, сабыр һәм үз-үзеннән канәгать шигырь чыгаручылар ишәйгәннән-ишәя бара. Ә бит иҗат һәм шигърият үз-үзеңне эзләү һәм табудан, заман хакындагы ихлас кичерешләрне кемгә дә булса ияреп түгел, бары тик үзеңчә генә әйтергә, укучыга түкми-чәчми җиткерергә омтылудан башлана. Ә үз-үзеңне табу һәм күңел түрендәге кичерешләрнең челтерәп аккан чишмә суыдай үз юлын табып ага башлавына ирешү җиңел түгел, моңарга бары тик иҗади газаплар һәм үз-үзеңне шәхес буларак раслау аша гына ирешергә мөмкин. Шуңа күрә дә беренче җыентыкларын чыгаручы авторга ярдәм кулы сузу гына аз, аңарга таләпләр куя белергә дә кирәк. Кичәге көн критерийларыннан чыгып кына да түгел, ә киләчәкне күздә тотып. Без исә, кагыйдә буларак, әле моны һәр очракта да искә алып җиткермибез. Беренче китаплары зур канәгатьлек һәм мактауларга юлыккан яшьләрнең тора-бара әдәби процесстан тыныч кына төшеп кала барулары шуның нәтиҗәсе түгелмени?!

1981 ел башларында Хәсән ага Туфан әйткән сүзләр хәтергә уелып калган. «...Шигъриятебезгә Нурия Измайлова һәм Ямаш Игәнәй кебек яшьләр килүенә куанам. Шигырьне нечкә тоемлаучы, өметле шагыйрьләр... Аларны югалтмаска кирәк». Һәм менә бүген, Н. Измайлованың «Яратам», Я. Игәнәйнең «Сәфәр чыгам» исемле китаплары хакында беренчеләрдән булып тәнкыйть сүзе әйтергә җыенганда Х. Туфанның тирән бер дулкынлану һәм киләчәккә олы ышаныч белән әйтелгән һәр сүзе символик бер мәгънәгә ия булып колак төбендә яңгырап тора. «...Аларны югалтмаска кирәк». — Бу сүзләргә аның чыгышында аеруча тирән бер мәгънә салынган иде. Ә бит югалткалаган, мактап яисә кадерсезләп бозган чакларыбыз булмады түгел...

Ямаш Игәнәй Чаллы якларында, Кама автомобиль гигантын төзүче һәм яңа ак кала салучылар арасында, шул гүзәл шәһәрдә яшәүче һәм шул заводларда эшләүче замандашлар арасында торып иҗат итә. Һәм, табигый ки, аның шигырьләрендә дә Чаллы ритмы, Чаллы рухы киң чагылыш таба.

Менә шушы якка таба
Барам мин, барасы бар:
Әнә шул офык ташыннан
Бер кала саласы бар!

Менә шушы якка таба
Барам мин, барасы бар:
Яшен чаткысын яшьлеккә
Өлгегә аласы бар!

Дөрес, КамАЗ һәм Чаллы сүзләренең ил күләмендә зур яңгырашка ия булуын тоемлап, шулар белән кирәкле-кирәксезгә сөрән салып, актуальлеккә омтылучы шагыйрь түгел Я. Игәнәй. Югарыда искә алынганча, «тыйнак һәм сабыр холыклы» автор. Ләкин шул ук вакытта ул шигырьләрендә якташларының олы максатлылыгын, шул максатларга ирешү юлында ныклы характерга ия булуларын түкми-чәчми җиткерергә омтыла. Хезмәт темасы дип, юллар чатына чыгып янсә завод түбәләренә менеп уйлану, чаң кагу түгел бу. Боларның барысын күреп һәм үз җилкәсендә татып караган шәхеснең бераз читкә китеп, табигатьнең тыныч бер почмагында бер ялгызы калып хисләре белән уртаклашуы сыман. Фәлсәфи лирикабызның матур традицияләрен үзенчә баетып, дәвам итәргә омтыла Я. Игәнәй. Ләкин, фәлсәфә дигәннән, монда да нинди дә булса катлаулы, абстракт категорияләр, башваткыч проблемалар күзгатып газапланмый, ә авыл кешесе, тормыш фәлсәфәсен теоретик әдәбияттан бигрәк, аның үзеннән өйрәнгән игенче агай кебегрәк турыдан ярә. Һәм, аерым очракларда, ил агалары әйткәндәй гыйбрәтле, тирән мәгънәле юллар тудыра. Әйтик:

Җирне гөл итәм, дигәннәр әйләнә гөлгә.
Җирне көл итәм, дигәннәр әйләнә көлгә...

Каядыр, кемнәндер ишеткән дә кебек, таныш та кебек тоелган шушы юлларда бүгенге чынбарлыкның төрле яссылыкларына чыгарып фикер йөртерлек, уйланырлык һәм уйландырырлык мәгънә бар. Актуаль һәм сугышчан уй-максат салынган аның асылына. Авыл һәм шәһәрдә яшәүчеләр өчен, иген игүчеләр, урман үстерүчеләр, күп катлы заманча зур яңа йортлар салучылар өчен, котырынып коралланучы, континентларга һәм планетабызга үлем белән янаучылар өчен дә бер дәрәҗәдә гыйбрәтле булырлык шигъри юллар... Һәм шунда ук яшь шагыйрьнең фикри өлгергәнлеге белән мавыгып киткәндә, тукта, ә бу юллар аның өчен очраклы гына түгелме соң дип, китапның яңа сәхифәләрен ачарга ашыгасың.

Кояш бит үзе дә гел мичтән
Алынган икмәккә охшаган...
Табынның мәңгелек кояшы —
Икмәк ул, мин шуңа ышанам.

Бусы да каядыр, кемнәндер ишеткән, таныш сүзләр түгелме соң? «Икмәк табынның кояшы» дигән сүзләрне яшьли әни һәм әбиләрдән ишетеп үстек түгелме соң? Кунак өчен ипи-тоз, якты йөз булса — өйдә кояш чыгар, дип әйткәнне дә ишеткән бар... Шагыйрь шул рәвешле безгә үз һәм таныш та булган җирлектә нигезли үз фәлсәфәсен һәм моның ышанычлы, кагыйдә буларак, озын гомерлеккә илтә торган җирлек булуын да танырга кирәк. Халык тормышына, аның рухына, тел һәм күңел байлыкларына тартылу әдәбият өчен элек-электән характерлы күренеш. Шуңа күрә дә халык телендә булып та каядыр, кемдер тарафыннан әлегәчә теркәлмәгән фразеологик берәмлекләр, образ һәм сынландыруларга иҗатының түреннән урын биргән шагыйрьнең бу юнәлештәге тәҗрибәләрен хупларга кирәктер. Иҗатында шушы юнәлешне кыйбла итеп алу бер үк вакытта шагыйрьнең үз-үзен табу, үз-үзен ачуына да уңай йогынты ясый. Замандашларының күңел кыллары тибрәнеше, халык иҗатына игътибарлы булган авторның лирик кичерешләре бер дә үз мин-минә тирәсендә көпшәк һәм буш фәлсәфә куертуга кайтып калмас.

Инде, Игәнәйнең мәгънәви җегәр һәм фәлсәфи гомумиләштерүгә йөз тотуын хуп-

лау белән бергә, шул юнәлештәге кайбер мавыгу һәм каршылыкларына да күрсәтеп узу файдалы булыр. Әйтик, бер строфа:

**Гомеребезнең орбитасында,**
**Күктәге ике җисем шикелле,**
**Галәм киңлеген урап йөрибез —**
**Без бу дөньяның ике бөрчеге...**

Буш юллар дип әйтеп булмый боларны, шул ук вакытта ялкыны кабынган, сүзләрнең хисләр һәм фикер белән бергә органик үрелүенә ирешелгән шигъри табыш дип тә әйтүе кыен. Гади генә фикер һәм хисне күктәге җисемнәргә, башка орбиталарга күчереп тасвирлауга, маташтыруга караганда, үз сүзләрең белән гади генә, ихлас кына әйтеп бирүгә ни җиткән бит, югыйсә.

Шигъри башваткыч һәм ребуслар кору Я. Игәнәй шөгыле түгел, ул эш белән мавыгучылар болай да җитәрлек. Халыкчан һәм гади генә фикер йөртүгә ни җитә!..

Сүз уңае чыккан икән, тагы бер нәрсә хакында соңга калмый искәртү урынлы булыр кебек. Һәм бу хактагы сүзне уңышлы гына бер мисалдан башлап җибәргә мөмкин.

**Тармаклары күккә баткан имәп,**
**Җирне йомарлаган тамырлары.**
**Атлант кебек титан имәннәрнең**
**Иңнәрендә тора бу Җир шары.**
**...Көчлеләрнең иңендә — Җир шары,**
**Көчсезләр бит аны таптый бары...**

Белмим, кемгә ничек, миңа калса, шушы шигырь өчен генә дә Игәнәйне шагыйрь итеп танырга мөмкин булыр иде. Масштаблы, өлгергән һәм җитди фәлсәфәле шигырь. Уйландыра һәм гыйбрәт алырга чакыра. Күз алдына килеп баскан образ да табигый һәм шагыйранә. Шулай икән, «башка ни кирәк тагы?» дияргә дә мөмкин. Бу шигырьгә инде поэзиябездә ишетелгән, очраштырган образлар нигез итеп алынган, кызганычка каршы. Шигырь Я. Игәнәйкене, ә аһәңе Р. Харис әсәрләреннән килә. Бирәдә сүз авторның вакыт-вакыт шигъриятебез өчен таныш мотивларга ияреп, иҗаттагы мөстәкыйльлегенә хыянәт итеп кую очраклары хакында бара. Һәм моңарга мисаллар «Сәфәр чыгам» җыентыгында сирәк булса да очрый тора: «Күңел күгемдә болытлар...» Дәрдмәндне хәтерләтеп торса, «Ай күктә ялгыз гына...» — Х. Туфан, «Кояш монологы» һәм «Чакматаш монологы» — Р. Фәйзуллин, «Кимерә яшь тай, кимерә...» Г. Рәхим шигырьләренә ияреп язылгандай тәэсир калдыралар.

Шагыйрьнең әлеге кимчелекләре хакында турыдан ярып әйтү урынсыз булмас, чөнки аның мөстәкыйль шигъри фикерләүгә, күңелләрне җилкендерерлек кичерешләрне шигырь юлларына салырга сәләтле булуына тирән ышаныч бар. Бигрәк тә аерым күренешләрне, халәтне тасвирлауда, этюдлар тудыруда Я. Игәнәй, туры мәгънәсендә, сүзләр белән оста рәссамдай эш итә.

**Зәңгәр күктә бер самолет**
**Сызып үтте көмеш эзләр.**
**... Ярга басып шул эзләргә**
**Ак сөлгеләр элә чибәр...**

Соклandыргыч матур һәм киң манзара пәйда була күз алдында, әле яңа чайкап эленгән сөлгеләрдәй чиста һәм саф картина. Шунда ук яшь чибәрнең күңеле пакьлеге һәм самолеттан сызылып калган юллар белән билгесез еракльккка, серле еракльккка китеп югалган хыял һәм өмет күзалланып өлгерә. Һәрхәлдә — бай образ, һәм мондый табышлар беренче китап авторында санаулы гына түгелләр. Шигырьдән шигырьгә яңа романтик сурәтләр тудырып, тормышны тагы да җанлырак һәм тагы да гүзәлрәк итеп тоемларга, күрергә ярдәм иткән шагыйрьнең иҗат уңышларына сокланмый һәм куанмый мөмкин түгел.

«Яшь шагыйрьнең беренче китабы» сериясен чыгару практикасында бер күренеш гадәткә кереп бара иде. Ул — укучыга шагыйрь турында сүз башы бирү. Аларның авторлары — күренекле шагыйрьләр, лауреатлар — мәйданның күләм ягыннан алай ук зур булмавын да исәпкә алмыйча, яшь шагыйрьләрне ныграк мактау буенча үзенә күрә бер ярыш сыман нәрсә дә башлап җибәргәннәр иде кебек. «Талант» һәм «шагыйрь» сүзләре дә кечерәеп калган кебек иде ул сүз башларында, чөнки болары яшьләрнең барысына да рәттән әйтелә... Шушы сүз башларын эзлекле рәвештә укып чыккан берәү булса, ул, мөгаен, мәйданга килгән яшьләребезнең бу дәрәҗәдә дә олы, «җитлеккән», «барлык шигырьләре дә чын сәнгать әсәре» һәм тагы әллә нинди дәрәҗәләргә ирешкәнлегенә ышанып, шатлыгыннан һуштан язар иде. Әлегә андый хәбәрләрнең ишетелгәне юк, шуңа күрә без дә җиргә төшик... Сүз башлары кирәк түгел дию дөрес булмас, аларда кимчелекләр хакында сөйләү дә килешеп бетмәс иде, билгеле. Ләкин чама белергә, сүзләрне, бәяләрне үлчәбрәк әйтергә кирәк. Үз иҗатларына таләпчән була белгән әдипләр яшьләргә мөнәсәбәттә дә моның гаять әһәмиятле икәнлеген онытмасыннар иде. Дәлилсез, ялтыравыклы сүз башлары белән генә укучыны алдый торган заманнар түгел хәзер. Әйтик, Нурия Измайлованың «Яратам» җыентыгы турыдан-туры аның үз шигыре белән башланып китә:

**Ашыгулар ялгышуга була.**
**Юк шул минем сабыр канатым...**
**Ялгышларым — урман, язмышларым —**
**буран.**
**Йөгерә-йөгерә кереп адаштым.**
**Ашкынулар үкенечкә була.**
**Ашкыну — ул минем канатым!**
**Үкенечләр — урман, өметләрем — буран.**
**Кәлә-көлә кереп адаштым.**

Һәм, нәшрият, китапның редакторы Р. Кукушкин бу очракта, безнеңчә, бердәнбер дөрес юлны сайлаганнар. Әлеге шигырьнең беренче строфаларын укыгач та язмышының буранлы урманнарына кереп адашкан яшь шагыйрәнең иҗатын тулырак рәвештә күз алдына китерергә омтылу сине дә үзенә ияртеп алып китә. Башка очраклардагыча, туктале, нәрсә өчен шул тикле үтереп мактыйлар моны, дип түгел, ә ихлас кызыксыну белән мавыгып укый башлыйсың. Яратып, үз итеп укыйсың, бу — шигърият кебек нечкә сәнгать белән очрашуда зуруча әһәмиятле фактор.

Н. Измайлова шигырьләре кайсы яклары белән күңелне җәлеп итә соң? Барыннан да элек, ул гадәттән тыш эчкерсез һәм ихлас шагыйрә. Поэзия өчен, шагыйрьләр өчен шарт булып торган бу сыйфатлар аңарда гаять тирән ачыла, хатын-кызларга гына хас булган тирәнлек белән. Шагыйрәнең кайсы гына шигырен укыма — аларда ул үзе, һәм бары тик үзе генә! Ә бу аның иҗатын тарайтмыймы, чикләмиме соң, шагыйрьләр бөтен дөньяны колачлый алырга тиеш диелә түгелме соң? Урынлы сорау. Шагыйрь үз-үзенә кереп бикләндеме — шундук кызыксызга әйләнә. Әмма бу очракта сүз дөньяга, замандашларына гашыйк романтик шагыйрәнең күңелендә бөреләнгән уй, хыял-омтылышны түкми-чәчми һәм ихлас төстә шигырь юлларына күчерә алу сәләтенә ия булуы хакында бара.

**... Кулым болгап йөгереп чыгам**
**Поезд тавышларына!**
**— Тукта! Тукта!**
**— Китәм! Тотма!**
**Ах, илгизәк, ах, күңел!**
**Тик: «Исәргә — кон узар»,— дип**
**Әйтергә генә җиңел:**
**Туган йортның чирәмнәрен**
**Үксеп эзлим төшемдә...**
**Ә уята поезд тавышы! —**
**Нәрсә җитми кешегә!..**

Н. Измайлова шигырьләрендә әледән-әле, әнә шул рәвешле, кичерешләргә чумган, ашкынган, сагышланган, вакыты белән шул хисләреннән чыгу юлын үзе дә ачык кына тоемлый алмаган образ белән очрашырга туры килә. Һәм ул образ кичерешләрнең табигыйлеге, үзебезгә дә якынлыгы белән күңелне тарта. Күз алдына үзенә һич битараф калдырмаслык җанлы картина килеп баса һәм ул берөзлексез уйландыра, борчый. Бу дөньяда кем генә аерылмаган да, кем генә сагышланмаган, кем генә эзләмәгән икән. Шулай булган, шулай булачак та — тормышның үз кагыйдәләре, үз законнары шул. Йөрәк сызлап алган чаклар кемдә генә булмый икән... Шагыйрә, бер карашка, интим хисләре белән генә уртаклаша сыман, ә шул хисләр башка күңелләрдә, йөрәкләрдә аваздашлык таба, ишен эзли... Йөрәктән чыккан гына йөрәкләргә барып җитә дигәннәре, шул буладыр күрәмсең?!

«Дөнья нигә киң икән?!» шигырендә, чынлап уйлый торсаң, нинди дә булса конкрет проблема куелмый, һәм аны хәл итү, чишү юллары, рецепты да күрсәтелми. «Авылда соңгы кич», «Адашкан» кебек күп кенә башка әсәрләрдә дә шулай ук. Ә кеше һәм аның күңеленең аерым бер мизгелдәге халәте рухиясе каршылыклары чагыла. Драматик ситуацияне хәтерләткән мизгел. Мондый чакта кеше һәм аның хисләре алдаша алмый, дөресрәге, аның бу хакта уйланырга вакыты да булмый. Нәтиҗәдә, чын мәгънәсендәге ихласлык, самимилек һәм эчкерсезлек белән аерылып торган шигъри хисләр туа. Сиңа да, миңа да, аңарга да чит булмаган үз хисләр...

Шулай кайта-кайта шагыйрә иҗатының бары бер үзенчәлеге хакында сөйләшүнең ихтыяҗы зур идеме? Әйе! Чөнки Н. Измайлова әлеге үзенчәлектән башлана һәм аңардан башка гына, белмим, аны күз алдына китерү мөмкинме икән? Хәер, бу — аерым үзенчәлек кенә түгел, шагыйрьнең иҗат йөзен дә билгеләүче төп сыйфат булса кирәк. Шагыйрәнең уңышлы дип саналган кайсы гына шигыренә тукталма, ул иң элек әлеге эчкерсезлеге белән җәлеп итәр. Ә инде шуңарга хыянәт иттеме, шундук аның әсәрләренә ясалмалылык һәм буталчык хис, фикерләрнең килеп керүен көтә тор. Мисал өчен, «Тормыш» һәм «Ах, аңлый алсам...» дип исемләнгән шигырьләрне искә алырга мөмкин. Бәхеткә каршы, шагыйрәнең беренче җыентыгында болары санаулы гына, юк диярлек.

Бай традицияле поэзиябезгә шул рәвешле яңа, үзенчәлекле авторлар килә тора һәм аның киләчәгенә дә ышаныч һәм өмет белән карарга нигез бирәләр. Бер үк вакытта бу процессның үзенә генә хас каршылыклары, уйлануны сорый торган четреклеяклары да бар икән. Гаҗәп түгел, яңарыш һәм үсеш проблемаларсыз гына булмас. Үткәндәге тәҗрибәләр киләчәккә гыйбрәт бирә. Язлар бит әле дәвам итә, язлар тагын килер...

Фоат Галимуллин,
филология фәннәре кандидаты

# ЮЛ КЕШЕСЕ

Кем ничектер, мин үзем кечкенә чакта әдәби әсәрләрне йотлыгып укысам да, бу китапны кем язган икән дип кызыксынып тормый идем. Укылган әйберләрне авторы буенча түгел, ә әсәр исеме, андагы геройлар белән хәтердә калдыра идем. Унбер-унике яшьләр чамасы булдымы икән, «Кечкенә Джон» дигән бер хикәя укыганымны хәтерлим. Хәтерлим генә дип әйтү аз булыр, мин анда сурәтләнгәннәрне бүгенге көнгә кадәр ап-ачык күз алдына китерәм. ...АКШта бер малай яши. Әшсез һәм торыр урынсыз калган шушы малай поездда барганда юлдаш апасының әйберләрен урлап кача. Ә бу апа аның үз әнисе булып чыга. Малайның фаҗигасе минем күз алдында еллар буе сакланды. Ләкин нинди әсәрдән укыганлыгымны хәтерли алмадым...



Әле, шушы мәкаләне язарга әзерләнгәндә, язучы Мәхмүт Хәсәновның барлык әсәрләрен яңабаштан укып чыгарга туры килде һәм кулга аның 1952 елда чыккан «Беренче хикәяләр» исемле юка гына җыентыгы килеп керде. Китаптагы иң соңгы әсәр «Кечкенә Джон» дигән хикәя иде. Шулай итеп, мин үзем дә белмәстән, М. Хәсәнов хикәясендә сурәтләнгән күренешләрне күңелемдә йөрткәнмен икән. Хикәя капиталистик җәмгыятькә карата минем нәни йөрәгемдә нәфрәт уяткан, андагы шартлар чал чәчле аналарга кул күтәрергә җөрьәт итәрдәй яшьләр тәрбияли дигән инануны формалаштырган. Америкада яшәүче Джоннарга контраст итеп совет пионерларының игелекле эшләре сурәтләнгән хикәяләр дә тупланган бу җыентыкта. Димәк, язучы балалар күңеленә мәхәббәт һәм нәфрәт орлыклары чәчкән, җәмгыятебез өчен файдалы эш эшләгән. Шул рәвешле, М. Хәсәнов иҗат эшен аеруча игелекле юнәлештән, сәнгать чаралары белән балаларда кешелекле хисләр тәрбияләүдән башлаган.

Инде алтынчы дистәне ваклаган, баһадирларныкыдай зур гәүдәле, тирә-якка һәрвакыт кызыксынып караучы күзләреннән җылылык бөркегән бу кеше язучы өчен иң кирәкле сыйфатларның берсен — сабыйлыгын саклап калган. Гомумән, шушы сыйфаттан башка әдип була аламы икән? М. Хәсәнов балалар белән аралашудан, алар өчен язудан ялыкмый. Бу өлкә аны даими үзенә җәлеп итә тора. Ул гына да түгел, балалар өчен язганнары аның иң уңышлы әсәрләре көбек тоела миңа. Язучы иҗатындагы казаныш саналырга тиешле «Җирән кашка» повесте үзе генә дә бу турыда ачык сөйли. Кеше белән табигать арасындагы аерылмас бердәмлек бу әсәрдә никадәр дөрес тотып алынган, үзенә бер нәфислек белән сурәтләп бирелгән! Шәйми агайның атларга булган мөнәсәбәте аша кешенең олы җанлы, шәфкатьле булуына сокланасың, хайванның да яратуга тугрылык белән җавап бирүен күреп кинәнәсең. Г. Ибраһимовның «Алмачуар»ыннан килә торган теманың уңышлы дәвам иттерелүенә күңел сөенә. Берничә ел элек язучы Р. Төхфәтуллин да әсәрне югары бәяләгән иде. «Ат язмышы аша халкыбыз тормышының кызыклы һәм гыйбрәтле сәхифәләре ачыла әсәрдә, сюжеты мавыктыргыч һәм җыйнак, теле дә йөгереклегә һәм нәфислегә белән куандыра»[1].

[1] Төхфәтуллин Р. Дулкыннар ярга кага.— «Казан утлары», 1977, 12 сан, 171 бит.

Табигатькә сак мөнәсәбәт дигән иң изге максат куеп язылган әсәр әнә шулай укучылар күңеленә барып ирешә.

Шушы ук тема «Без алтынчы «А»дан» хикәясендә дә үстерелә. Билгеле, бала вакытта үз тирәңдәге кешеләрне аңлап, аерып бетерү шактый кыен. Әгәр иптәшеңнең ямьсез сыйфатлары күзгә күренеп торса, аны тану кыен түгел, әлбәттә. Әмма ул, Илсур Әсәдуллин кебек, отличник булса, эш кыенлаша төшә. Илсурның кемлеген ачыклау аның табигатькә булган мөнәсәбәтен белү аша мөмкин икән. Дөрес, автор биредә дидактика хисабына сәнгатьлелекне бераз йомшарта төшкән. Аның каравы икенче әсәр — «Шайтан малае» хикәясе сюжетының тыгызлыгы, киеренкелеге белән нәни укучыларны тирән дулкынландыру көченә ия. Хикәя кечкенә Бикинең батырлыгы, малай күңелендә утлы өермәдәй бара торган хис-кичерешләр ташкыны, аның үзенә тапшырылган эшкә гаять олы җаваплылык белән каравы, көчле ихтыяры турында сөйли. Яшь укучылар күңеленә әсәр әнә шул ягы белән тәэсир итә дә. Автор Бикинең, комиссар Нурмыйларның эше мәңгелек булуын раслау өчен риторик сүзләр түгел, сәнгатьчә детальләр куллана. Бики үлеп яткан әнисе янына барып комиссарның имчәк баласын алып кайта. Балага әтисенең, ягъни Нурмый исемен кушалар. Хәер сорашып көн күргән, кешеләр сихерче дип атаган Вәсбикамал карчыкның кешелеклелеге дә таң калдыра.

М. Хәсәновның урман эшчеләренә багышлап язган әсәрләре дә бар. Әлеге тема язучының беренче повестьларыннан булган «Урман шаулый» (1953) әсәрендә аеруча уңышлы хәл ителгән. Повестьны кызыклы иткән як, әлбәттә, кешенең урманга, табигатькә булган карашын күрсәтү генә түгел. Биредә шактый гыйбрәтле язмышлар һәм персонажлар арасында катлаулы мөнәсәбәтләр дә бар.

Төп герой Көлемсәр — урман хуҗалыгының алдынгы эшчесе. Шуның өстенә аңа табигать тарафыннан бик матур тавыш та бирелгән. Яшь ягыннан бераз өлкәнрәк булган ире Зариф аңа гаилә бәхете бүләк иткән. Әмма Көлемсәр институттан диплом язу өчен килгән Нияз белән мавыгып китә. Килешле буй-сынлы, матур итеп сөйләшә белүче, төрле манераларга өйрәнгән егеттә ул моңа кадәр татып карамаган мәхәббәт тапкандай була. Нияз дә аның белән очрашу юлларын эзли, үз кыланышларына хисап бирмичә, хатынның башын иләсләндерә бирә. Бу сәер мәхәббәт, ничек кинәт кабынса, шулай тиз сүнә дә. (Кинәтлек, гомумән, М. Хәсәнов персонажларына хас нәрсә). Барысы да үз урынына утыра. Нияз китеп бара. Көлемсәр белән Зарифның гаиләсе тагын да ныгый төшә. Бусы — әсәрдәге мәхәббәт «өчпочмагына» корылган коллизия. Ул әллә ни катлаулана алмый. Чөнки «өчпочмак»тагы иң үткен булырга тиешле образ — Зариф — үз хатынының чит егет белән очрашуларына үтә тыныч карый, тавыш-гауга куптармый, көндәше Ниязны шахмат уенында җиңү белән канәгатьләнә. Ягъни анда җанлы кешеләр өчен табигый булган горурлык юк. Шуңа күрә бу линиягә укучылар битараф карый башлый. Геройлар үзләре өзгәләнмәгәч, укучы да пошынмый.

Безнеңчә, әсәрдә производство җирлегендә барлыкка килгән конфликт уңышлырак кебек. Урман хуҗалыгына продукция җитештерү планын күләм буенча да, ассортимент буенча да арттырыбрак биргәннәр. Директор Бәдри агай шушы бурычны ничек итеп үтәү турында баш вата. Гамәлдәге производство мәйданнары һәм средстволары белән генә яңа планны үтәп булмаячак. Ни эшләргә, яңа резервларны кайдан табарга? Җитмәсә баш инженер Сәйфиев скептиклык күрсәтә, өстәмә планнан баш тарту ягын каера. Ләкин коммунист җитәкчеләр бу тәкъдимне кире кагалар. Үз гаиләсенә янаган куркынычка салкын кан белән караган Зариф исә бу очракта тапкырлык һәм тырышлык күрсәтә. Нәтиҗәдә, җитештерелгән продукцияне эшкәртү өчен өстәмә мәйдан табыла һәм коллектив әлеге бурычны үтәүгә туплана. Иҗади хезмәт нәтиҗәсендә Галләм кебек алдынгы кешеләр эшне нык тизләтердәй кыю тәкъдимнәр белән чыгыш ясыйлар. Сәйфиевләр, Хәмитләр никадәр генә аяк чалырга маташмасыннар, гомуми эш көннән-көн җанлана, эзгә төшә бара. Әсәр план үтәлү тантанасы белән тәгәлләнә.

Күргәнебезчә, яшь язучы әле интим һәм производство конфликтларын оста итеп кисештерә, органик рәвештә үрә алмый, алар бер-берсеннән бәйсез хәлдәрәк үсәләр. Һәр ике линиядәге конфликт йомшаклыгы персонажлар характерларын тулы ачу мөмкинлеген бирми. Нәтиҗәдә Зариф кебек шактый җансыз плакат-образ барлыкка

килә. Әмма шул хәлендә дә тәнкыйть әсәргә карата җылы гына фикерләр әйтте[1]. Язучы илле яшь тулу уңае белән чыккан җыентыгына (1977) әлеге повестьны да кертте. Тәҗрибәле каләме белән аны бераз ипкә китергәндә дә әйбәт булыр иде, әлбәттә. Тик, кызганычка каршы, бу эшләнмәгән.

Мәхмүт Хәсәновны эшчеләр турында язучы әдип дип атау гадәткә кергән. Бу чыннан да шулай. Язучы үзенең эшчәнлеген Зеленодольскидагы һөнәр мәктәбе укучысы һәм эшче булып башлап җибәргән. Аның хезмәт кешеләренә карата гомере буе йөрәгендә мәхәббәт саклавы да әнә шуннан килә булса кирәк. Эшчеләр сыйныфы вәкилләре аның күп кенә әсәрләренең төп геройларын тәшкил итә. Әмма ул ара-тирә үзенең төп темасына «хыянәт» итеп тә алгалый. Алтмышынчы еллар башында ул авыл хезмәтчәннәренә багышланган «Саф җилләр» романын бирде, ә ун елдан соң аның «Хәдичә» дип исемләнгән икенче китабын иҗат итте.

Соңгы әсәрендә автор ил тормышын ныгытуга барлык физик һәм рухи көчен биреп эшләүче Мәдинә, Җәмилә, Хәдичә кебекләрнең колоритлы образларын сурәтли. М. Хәсәнов әсәре кырыс тормыш материалын эстетик үзләштерүгә кертелгән әйбәт кенә өлеш булды. Әдәби җәмәгатьчелек тә аны, нигездә, җылы кабул итте. Язучы Х. Сарьян, мәсәлән, мондый фикер әйтте: «Мәхмүт Хәсәнов... колхоз тормышын, кешеләрен, эш шартларын белеп яза. Ә белеп язылган әйбер һәрвакыт ышандыра. Романдагы конфликт колхоз дип аталган катлаулы бер хуҗалыкта кешеләрнең, берләнгән, эшкә, икенчедән, бер-берсенә булган мөнәсәбәтләре җирлегендә мәйданга килә. Һәм автор шул конфликтларны мавыктыргыч итеп тасвир итә»[2].

Биредә укучыны аеруча дулкынландырганы Мәдинә һәм Хәдичә образлары. Шартлы рәвештә романның беренче кисәген Мәдинә исеме белән, икенчесен «Хәдичә» дип атарга мөмкин. Сугыштан соңгы авыр чорда кыенлыклар алдында бер мәлгә югалып калып та, еллар белән бергә сәламәтләнә, тернәкләнә барган бу хатыннарның язмышы укучы игътибарын тотып тора. Мәдинә — сугыш толы. Намуслы хезмәте белән җиңүебез өчен бөтен барлыгы белән тырышкан кеше. Ул гади колхозчыдан ферма җитәкчесе булып күтәрелгән. Тик киләчәк перспективаны күрмичә, әвеш-тәвеш кенә эшләүче, намуслы колхозчыларга яла ягудан да чирканмаучы Борһан кебекләр утырганда Мәдинәдәй тынгысыз җаннарга авыр килә икән. Борһаннар аларга түзеп тора алмаслык шартлар тудыралар. Мәдинә, Борһанның эзәрлекләүләренә түзә алмыйча, авылдан китеп бара. Менә шушында, райүзәктә, язмыш Мәдинәне Хәдичә белән очраштыра. Хәдичә такта яру заводында эшли, ләкин бик киңәндерми, азып-тузып йөри. Мәдинә дә ул эшли торган заводка урнаша. Алтын җирдә ятмый дигәндәй, ул биредә дә эшнең җаена тиз төшенә, акыллы киңәшләре, уңганлыгы белән алдынгылар сафына чыга, үтә җаваплы эшләрне менә дигән итеп башкара. Мәдинә горур. Борһан үзе килеп авылга кайтырга димләүгә дә карамастан, аның үгет-нәсихәтен дә, мәхәббәтен дә кабул итә алмый Мәдинә. Райкомның яңа секретаре Рәхимова киңәше буенча гына ул яңадан туган колхозына кайта.

Биредә күңелне тырный торган бер як бар. Мәдинәнең иң кыен вакытларда колхозны язмыш ирегенә калдырып йөрүе, аны хатын-кыз буларак аңларга тырышканда акланса да, коммунист буларак гомуми эшкә җитди карамавын күрсәтә. Р. Төхфәтуллинның «Йолдызым» повестеның герое Гөлзифа, мәсәлән, алай итә алмый, бөтен авырлыкны үз җилкәсенә ала һәм әдәби характер буларак та көчлерәк шәхес итеп кабул ителә.

Мәдинә образын автор уңай герой итеп кенә тәкъдим итә. Туры юлдан гына баручы, компромиссларны белмәүче, адашкан кешеләргә тайпылышсыз сукмак күрсәтүче буларак бирелә. Беренче китапның соңгы битләрендә ул аеруча монументальлек ала. Менә ул печән чабучы колхозчылар янында: «ирләр арасында, гәүдәсен төз тотып, ирләрчә киң итеп, Мәдинә дә селтәнә иде». Мәдинә бары тик эштә генә, җитәкче буларак кына гәүдәләнә. Бу хәл авторга героиняны төрле яклап сурәтләүгә комачаулый.

Хәдичә образы, нигездә, шәхси хәл-әхвәлләре аша ачыла. Сафлык, гүзәллек өчен дөньяга туган Хәдичә, эгоист табигатьле Вәлигә тап булып, якты киләчәгенә тап

---

[1] Иделле Г. Язучы һәм аның китабы.— Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1964, 143—144 битләр.
[2] Сарьян Х. Бүгенге авыл һәм аның кешеләре.— «Социалистик Татарстан», 1975, 19 октябрь.

төшерә, хатынга гомер буе күңел газаплары китерә. Үз алдында һичнинди яктылык күрмәгән Хәдичә иң соңгы чиктә поезд астына ташланырга ымсына, әмма Мәдинәнең шул мизгелдә кинәт яңгыраган тавышы аны саклап кала. Автор, шул рәвешле, Хәдичәне укучы күз алдында упкынга төшерә, һәм аның шул баткаклыктан башкаларга үрнәк булыр дәрәҗәдә югары күтәрелүен дә күрсәтә. Безнең карашыбызча, Хәдичәнең әхлакый бозылу процессы психологик яктан да, тормышчан вакыйгалар ягыннан да уңышлы мотивлаштырылган. Ә менә шул хәлдән өскә күтәрелүе, Хәдичәнең күңел каршылыкларыннан азат булуы сәбәпле, сәнгатьчә ныгытылмый кала һәм, әлбәттә, ышандырып җиткерми. Ул гына да түгел, Хәдичә әсәр азагында Социалистик Хезмәт Герое исеменә дә тәкъдим ителә. Бу инде авторның чаманы узып китүе. Беренчедән, әсәрдә Хәдичәнең бу кадәр югары дәрәҗә алырга лаеклы эше юк. Икенчедән, геройны шулкадәр күтәрергә тырышу табигый кабул ителми.

Хәдичәнең яңадан дөрес юлга төшүе кешечә репутация казанып, кызын кире үзенә алуыннан башлана. Әнә шул мотивны үстерү, Хәдичәнең кызы белән кавышу күренешен аның барлык тырышлыклары нәтиҗәсе итеп тәкъдим итү әсәрне тагын да җылырак, кешелеклерәк итәр иде. Әмма шул хәлендә дә Хәдичә образы игътибарны шактый җәлеп итә. «Саф җилләр» дилогиясе, берсүзсез, язучының иҗатта алга китеше иде.

М. Хәсәнов мөмкин кадәр халыкчан, традицион итеп язарга омтыла. Әсәрләрендә еш кына җор телле геройларны — чын-чыннан халык вәкилләрен кертеп сурәтләве дә әнә шуны раслый. «Саф җилләр» романындагы Шапырай карт шундый образ. Һәрвакыт оптимист, үткен акыллы, киеренке шартларны йомшатып җибәрергә сәләтле бу кеше әсәр геройларының гына түгел, укучыларның да яраткан образына әверелә.

Биредә бер парадоксаль фикер әйтергә туры килә. Шапырай — М. Хәсәновның үз иҗат җимеше. Әсәрнең киеренкелеген киметмичә, укучының игътибарын тотып торырлык итеп тасвирлау өчен авторның үзенә дә Шапырай карттан үрнәк алганда начар булмас иде. Китапны укыганда күрәбез: карт бер вакытта да үз тыңлаучыларын күздән ычкындырмый, аларның ничек тыңлавына карап сөйли. Мәсәлән, менә болайрак: «Хикмәтле хәл»нең ничегрәк тәэсир иткәнен чамаларга теләп, кысык күзләрен ялт-йолт йөртеп, каранып алды. Әһә, сүзе үтә, әсәрләнеп тыңлыйлар. Димәк, бераз арттыра төшсә дә ярый. Һәм Шапырай карт кулларын тагы да селтәбрәк дәртләнеп сөйләп китте»[1]. Менә шуның кебек авторга кайчакта үз язганнарына укучы күзе белән карау җитенкерәми. Шул сәбәпле бик отышлы гына чыгарга тиешле урыннар да вакыт-вакыт информациягә кайтып кала. Укучы белән эстетик бәйләнеш бетә, логик элемтә генә кала.

Инде яңадан «Саф җилләр»гә якынрак килсәк, шуны әйтергә мөмкин: язучы әсәрнең икенче кисәген иҗат итеп бик дөрес эшләгән. Ул бигрәк тә Вәли образын аңлау өчен кирәк. Беренче кисәкнең соңгы битләрен ябып куйгач, укучыда Вәлигә карата нәфрәт уяна, ул явыз кеше буларак истә кала. Әмма ул гомере буе Хәдичәне яратып яшәгән икән ич. Пединститутны бетергәч тә, Хәдичәгә якын булу өчен генә аның районына кайткан. Бер көн килеп хатын үзе ишек шакыр дип өметләнгән, ләкин горур Хәдичә моны эшләмәгән. Кызын урлап алып китүе дә бала артыннан әнисе дә килеп җитмәсме дигән теләк белән эшләнгән. Икенче хатынга өйләнсә дә, Хәдичәсе йөрәк түреннән китмәгән. Шулай итеп, яшьлек хатасы, сөйгән кешесенә ышанмау аңа гомере буена барырлык газап китерә. Гомер көзендә япа-ялгыз кала ул. Әсәрнең икенче кисәге белән танышу укучыга Вәлине әнә шулай тирәнтен, кешеләрчә аңларга ярдәм итә.

Җыеп әйткәндә, «Саф җилләр» дилогиясе, андагы геройларның язмышы укучыны уйландыра, дулкынландыра. Бу инде язучы өчен аз түгел. Иң әһәмиятлесе, әсәрдә кайнар йөрәкле, кабатланмас язмышлы, һәм иҗтимагый даирәдә, һәм интим мөнәсәбәтләрдә яхшыга, алга омтылучы образлар бар.

М. Хәсәнов иҗаты тематика ягыннан шактый бай. Татарстан китап нәшриятында 1975 елда басылып чыккан «Саумы, кояш» романы безне бөтенләй икенче тормыш — революциягә кадәрге татар хезмәт ияләренең аянычлы хәле, аларның сыйнфый аңы үсү һәм изелүгә каршы көрәштә актив катнашып китүләре белән таныштыра. Татар

[1] Хәсәнов М. Саф җилләр, 1964, 184 бит.

эшчеләренең социалистик революциягә килүе табигый төзелгән сюжетта хәл ителә, кызыклы язмышларда гәүдәләнеш таба.

Автор бу әсәрен шактый озак — унҗиде ел яза. Роман зур иҗади эзләнүләрнең нәтиҗәсе булып дөньяга килә. Һәм, әйтергә кирәк, татар совет әдәбиятын тарихи-революцион вакыйгалар, халык язмышы фонында сурәтләнгән колоритлы образлар белән баетуга әйбәт өлеш булып тора ул. Романдагы вакыйгалар егерменче йөзнең беренче елларыннан алып 1919 елда Казанны ак чехлардан азат итүгә кадәр булган чорны эченә ала. Әсәрнең төп героинясы Гөлбану гади авыл кызыннан революциянең актив солдатына кадәр юл үтә. Аны да башта, гасырлар буена формалашкан кануннар белән, туктатырга телиләр. «Соң син бит хатын-кыз! Укымаган, томана бер татар хатыны. Политика, сәяси эшләр белән шөгыльләнү синең эш мени соң?» — дип аны бу юлдан йөз чөертергә омтылалар. Әмма кимсетелүне үз язмышында татыган Гөлбануның карары нык. «Томана татар хатыны да кеше лә баса!.. Аның да тураясы, башын калкытасы, кояшны күрәсе килә» дигән нәтиҗә ясый ул. Әмма ирек кояшын күрү өчен бик күп сынаулар, авырлыклар аша үтәргә кирәк була шул әле аңа. Авыл байлары эзәрлекләвеннән качып Казанга килергә, үзләре кебек ук ачлы-туклы яшәүче бер эшче гаиләсенең почмагына сыенырга, Мәрхәмбикә-байбикәгә унбиш ел бил бөгәргә, бик күп ызгыш-талаш күрергә туры килә. Гөлбану революцион көрәшнең корбаннар таләп итүен дә аңлый. Шушы изге көрәш юлында чын революция солдаты булып өверелә. Тик шунысы бар, М. Хәсәнов, әсәрен тизрәк төгәлләргә ашыгып, Гөлбануның җаваплы һәм гаять куркыныч бурычлар башкаруын әйтеп кенә үтә. Башка геройларның язмышын да тиз очлап куярга омтылып, сәнгатьлелеккә зыян китерә. Баштарак бала, соңга таба яшүсмер булган Гөлбану да, нигездә, зурларча күзаллап иҗат ителгән. Гөлбануның балаларча фикерләве, дөньяны шулай кабул итүе сизелми. Бала психологиясен бирүдә әллә ни уңышка ирешә алмаса да, автор зурлар арасындагы, бигрәк тә төрле социаль катлам кешеләре арасындагы мөнәсәбәтләрне җитлеккән каләм белән сурәтли.

Дәрәҗә сөючән, үз дигәнен булдыруда бернәрсәдән дә, хәтта кеше үтерүдән дә кыенсынмаган деспот Мәрхәмбикә образы үзе генә дә ни тора! Чын мәгънәсендә диктатор ул. Ире Асылхан да аннан узып берни эшли алмый. Хезмәтчеләре өстенә кара кискә булып яткан Мәрхәмбикә аша язучы бу катлауның черек әхлагын, бозык кануннарын фаш иткән. Ул ире өстеннән сәркә тота, көндәше Зөһрәнең баласын юк иттерә, соңрак аның үзен дә гариплэтеп калдыра. Һәм, ниһаять, турылыклы хезмәтчесе Хәмитне җибәртеп, ире Асылханны да үтерттерә. Ләкин канга ияләшкән ерткыч бернәрсәгә дә мәрхәмәт күрсәтмәгән шикелле, шул ук Хәмит Мәрхәмбикәнең үзен дә аямый, гомер буе туплаган байлыгын алып, аны караңгы төндә суга батыра. Кеше канын эчеп тупланган байлык Хәмитнең үзенең дә гомерен ала. Хәрәм мал, шул рәвешле, байлык артыннан куучыларның үзләрен берәм-берәм харап итә.

Гөлбануның әтисе булган Сабирҗанның политик аң үсеше укучыда канәгатьләнү уята. Ул да империалистик сугыш эченнән көрәшче булып кайта, «алар (капиталистлар — Ф. Г.) түгел, эшләгән, ил дип кан койган кешеләр хуҗа бу тормышка», дип әйтерлек югарылыкка күтәрелә.

Әсәр турында уйланганда үзеннән-үзе игътибарны җәлеп итә торган тагын бер як бар. Ул социаль-иҗтимагый көрәш аеруча кискенләшкән чорда иҗат интеллигенциясенең урыны, аның политик юнәлеше мәсьәләсе. Бу әсәрдә Сәет образы гыйбрәтле. Ул, яшь кешеләргә хас булганча, үзен бөек шагыйрь дип саный. Моны раслау өчен зур чыгымнар тота, байлар җәмгыятьчелеге белән аралашырга омтыла. Әмма чын шагыйрь булу өчен кыланчык бай кызларының күңел кичерешләрен, гүзәл табигать күренешләрен генә түгел, ә тормыштагы урыныңны дөрес билгеләү, әсәрләреңдә иҗтимагый карашларыңны ачык белдерү дә кирәклеген ул әле аңламый. Әлбәттә, ул поэзияне политик көрәш коралы итеп караудан бик ерак тора. Тик шигырьләре хәтта патша чиновниклары тарафыннан да начар бәя алгач, Сәет уйланырга мәҗбүр була. «Әйтерсең лә, Сәеткә авыр гер белән тондырдылар... Кинәт миңгрәп, аңына килә алмый торды. Аңсыз да кимсетелгән, аңсыз да мыскыл ителгән шагыйрь йөрәге бу кадәресен күтәрә алмас кебек тоелды. Төннәрен йокламыйча, күз нурларын түгеп, «йөрәгенең кайнар каны, нервларының сүле» белән язылган иҗади җимешләренә, хезмәтенә, ниһаять, лаеклы бәяне алды».

Күрәбез, М. Хәсәнов егерменче гасыр башы проблемаларын шактый җентекле өйрәнгән һәм әсәрендә уңышлы гына хәл иткән.

Мәхмүт Хәсәнов иҗатындагы уңышлы һәм кимчелекле якларга моннан егерме еллар элек Газиз Иделле дә игътибар иткән һәм, безнең карашыбызча, объектив бәя биргән: «Өлгерлек, хәрәкәтчәнлек, иҗади тынгысызлык, тормыш эченә керергә омтылучанлык сыйфатлары бар аңарда. Хәзер аның алдындагы төп бурычларның берсе — художество осталыгын күтәрү, әдәби сүз өстендә эшләү булырга тиеш. Чөнки аңа санны сыйфат белән бергә кушу, бергә үстереп алып бару җитми. Ул бик ашыга, кабалана, образларны укучы күңеленә кереп озак сакланырлык җанлы итеп эшләп бирүгә, сүз байлыгын дөрес һәм оста куллануга җитәрлек игътибар итми»[1]. Язучының иҗади үсешен күрү белән бергә, бу фикерләр белән әле бүген дә өлешчә килешергә туры килә.

М. Хәсәнов иҗатында кызыл җеп булып сузылган бер тема бар, ул — Татарстан нефтьчеләренең тормышын һәм фидакарь хезмәтен эстетик үзләштерү. Бу тема 1956 елда язылган «Кыюлар юлы» повесте белән башланып китә. Повесть ике кисәктән — «Яңа горизонт» һәм «Сүнмәс утлар» дип исемләнгән өлешләрдән тора. Бербөтен әсәр дип тәкъдим ителеп, аларда бер үк персонажлар хәрәкәт итсәләр дә, бу өлешләрне мөстәкыйль әсәрләр буларак та кабул итәргә мөмкин. Чөнки аларның үзегенә куелган һәм конфликтлы ситуация китереп чыгарган проблемалар төрле-төрле. Әсәр Татарстан нефтьчеләре тормышын чагылдыруда беренче тәҗрибәләрдән иде. Әле бу вакытта егерме биш кенә яшьтә булган яшь язучының, кыюлык күрсәтеп, шундый җитди темага алынуы үзе үк тәвәккәллек булып тора. Шунысы куанычлы — яшь әдип үзе язарга алынган тормыш материалын, производство процессларын яхшы белә, коллизияне оста тотып ала, тик аларны кеше язмышлары белән үреп бару өчен иҗади тәҗрибәсе генә җитенкерәми.

Повестьта сурәтләнгән чор — Татарстан нефтьчеләренең әле яңа аякка басып килгән чагы. Аларның тәҗрибәле белгечләр киңәшенә мохтаҗлыклары зур. Нефть чыгару буенча элек-электән дан казанган бакулылар биредә ярдәм кулы суздылар. «Кыюлар юлы» повестеның беренче кисәгендә Татарстан җирендә үтә тирән катламнарны бораулап, яңа нефть горизонты ачу төп проблема итеп куела. Бурычның кыенлыгы шунда, әле бу урыннарның геологик-техник наряды төзелмәгән, димәк, һәр метр җирне бораулау көтелмәгән нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Мондый эштә әле безнең нефтьчеләрнең тәҗрибәсе юк. Бакудан Миргали Галиев дигән яшь, энергияле, бораулау эшендә тәҗрибәсе булган мастерны чакырып алалар. Миргали, тиз генә коллектив туплап, бу эшне егетләрчә башкарып чыга, яңа горизонт нефть фонтаны бәрә. Әйтергә кирәк, әсәрдә, бер-ике гадәти генә кытыршылыкларны исәпкә алмаганда, барысы да шома бара. Бригада беренче метрлардан ук алдынгы коллективлар белән ярышта беренчелеккә чыга һәм уңышка юлыга. Әсәр язылган еллар әдәбиятта конфликтсызлык теориясе яшәү белән характерлы иде. М. Хәсәнов та, күрәсең, бу шаукымнан читтә кала алмаган. Бораулау эшенең гаять нечкә серләренә үтеп керә алган язучы, үзәккә конфликт куя алмау сәбәпле, тормышчан персонажлар тудыруда уңышка ирешә алмаган. Миргали, Хаҗи, Минҗан, Галия, Булатов, Шәйхи кебек образлар әле күбрәк схема хәлендә генә калганнар. Мөмкин булган урыннарда да автор персонажларга үз натураларына хас булганча эш итү мөмкинлеге бирми.

Ләкин, ни генә дисәң дә, М. Хәсәновның нефтьчеләр темасына язган әсәрләре татар әдәбиятында бу өлкәне эстетик үзләштерүгә кертелгән саллы гына өлеш дип каралырга тиеш. Ул әле бүген дә бу темадан аерылмый. 1980 елда «Казан утлары» журналында басылган «Шөгеровлар» романы шуны күрсәтә.

Нефтьчеләр династиясенең берничә буын вәкилләренең калку образларын тудыруга багышланган бу әсәр геройларының уртак фамилияләре белән, ягъни «Шөгеровлар» дип атала. Әйтергә кирәк, М. Хәсәнов кызыклы һәм оригиналь коллизияләр төзүдә, яңа идеяләр күтәрүдә кыенлык кичерми. Бу романы да (дөресрәге, романнан өзекләр) күтәргән проблемалары, аларны чишүдәге яңалыгы белән игътибарны җәлеп итми калмый.

---

[1] Иделле Г. Язучы һәм аның китабы.— Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1964, 143 бит.

Әсәрдә, Шәгеровлар династиясе, аның төрле буыннарының гыйбрәтле тарихы турында сүз барса да, авторның үз алдына куйган максаты шактый колачлы. Биредә сүз гомумән татар халкы, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында бара.

Ак-Калада тирә-юньгә данлыклы Шәгеровлар нәселе яши. Рахман карт, заманында Бакуда нефть чыгаруда эшләп, Хезмәт Герое дәрәҗәсенә ирешкән, шәһәрнең күренекле урынында аның бюсты куелган. Улы Корбан исә танылган нефтьче мастер. Оныгы Ногман югары техник белем алган, район инженерлык-технология хезмәте башлыгы. Барысы да үз эшләреннән канәгать, тормышлары түгәрәк. Ләкин җай гына яшәп яткан нәселнең тормыш ритмын кәтмәгәндә үзгәртеп җибәрерлек вакыйга булып ала — аларга АКШтан миллионер Шандор килеп чыга. Бу хәл укучыны кызыксындырып җибәрә. Кем ул Шандор? Ни өчен Шәгеровларга килгән?

Шандорның бабасы узган гасырда, Америкадан килеп, бу урыннарда нефть разведкасы оештырып йөргән икән. Шәгеровлар нәселенә нигез салучыларның берсе Мөхәммәт, океан арты эшкуарына хезмәткә яллпнып, күпмедер вакыт шунда торып та кайткан булган. Ләкин бәхетне читтә түгел, үз илеңнән эзләргә кирәк дигән нәтиҗәгә килеп, туган ягына кайтып егылган. Шандорның бабасы үләр алдыннан язган васыятьнамәсендә Шәгеровларның әнә шул ерак бабасына да хәзинәдән өлеш чыгарган һәм менә аның бер оныгы Шәгеровларны эзләп тапкан.

Иң кызыгы шунда, өлкән Шандор безнең якларда йөргән вакытында татар халкының тормышы, экономик хәле, культурасы, холык-фигыле турында ясаган нәтиҗәләрен дәфтәргә теркәп калдырган. Аннан күренгәнчә, татар халкы бик фәкыйрь яши, алар җиргә иңеп утырган алачыкларда торалар, өйләрендә өреп очырырлык та ризык юк, кичкә керсәләр чыра яндыралар, гомумән, мескен, киләчәге булмаган халык. Бу юлларның моннан йөз еллар элек язылганын искә алсаң, аларның нигездә дөреслеккә туры килүе шөбһәсез. Ә инде бүгенге татар халкы үзен хаклы рәвештә тормышның хуҗасы итеп сизә. Кайсы Алтын Йолдыз, кайсы халык депутаты значогы таккан, күбесе производство житәкчесе булган ирләрне очраткач, Америка конгрессмены социалистик чынбарлыкның халыклар язмышында нинди роль уйнавын аңлый. Ләкин ул безнең өчен гадәти генә булган әйберләрне дә «коммунистик пропаганда» булмасын дип, үз кулы белән тотып, үз күзләре белән күрергә тели. Аңа андый мөмкинлекне тудыралар да. Нәтиҗәдә Шандор татарларның нинди халык булуы турында мөстәкыйль нәтиҗә ясый.

Күрүебезчә, кызыклы ситуация. Татар әдәбиятында әлегәчә сурәтләнмәгән тормыш материалы. Ләкин сәнгать әсәре иҗат иткәндә, Фатих ага Хөсни әйткәндәй, автор ике сорауга төгәл җавап тапкан булырга тиеш: «Ни әйтергә? Ничек әйтергә?» Әлеге очракта М. Хәсәнов бу бурычларның беренчесе турында тәпле генә уйланган булса да, икенчесенә игътибары җитенкерәмәгән диясе килә. Язучы әйтергә теләгән фикернең үтемлелеге бары тик сәнгатьчә югарылык белән генә тәэмин ителә. Менә ни өчен без һәрвакыт идея-эстетик бөтенлек турында сүз алып барабыз.

Әсәр үзәгенә тагы производство конфликты да куелган. Яшь галим Рәхим Галимов нефть чыгаруны камилләштерү максатында яңа химик реагент уйлап таба, шуны практикада кулланырга тели. Корбан Шәгеров һәм күп кенә башка нефтьчеләр яңалыкны хупласалар, РИТС начальнигы Ногман исә моңа теше-тырнагы белән каршы килә. Аңардан экспериментлар уздыру түгел, нефть сорыйлар, янәсе.

Сүз дә юк, мондый конфликт әсәр нигезенә ята һәм характерларны ачуга хезмәт итә ала. Ул чын мәгънәсендә фәнни-техник революция китереп чыгарган конфликт. Тик шунысы бар, автор әлеге техник яңалык серләренә үтеп керми, шул рәвешле, аны укучының да уртак кайгысы итеп әверелдерә алмый.

Хәзер әдәбият белемендә конфликтны позицион һәм психологик төрләргә бүлеп карау күзәтелә. Персонажларның теге яки бу мәсьәләгә төрлечә якын килүләре позицион конфликтны тәшкил итсә, соңгысы үз чиратында кешеләрнең тирән психологик кичерешләрен китереп чыгара. Алар бер-берсенең алшарты булып берләшәләр, еш кына икенчесе беренчесеннән килеп чыга. М. Хәсәнов романы турында сөйләгәндә, без психологик конфликт турында гомумән сүз йөртә алмыйбыз, позицион конфликт та әле ачык билгеләнмәгән, ул геройларның аерым репликаларында гына чагыла.

Нәтиҗәдә Корбанның төпле, фикерле кеше икәнлеге, Ногманның исә кушканны гына үтәүче һәм инициативасыз булуы эш-хәрәкәт аша түгел, автор сөйләве аша гына ачыла. Ә бу сәнгатьлелеккә зыян китерә.

Әсәрнең кайбер урыннары күңелне тырнап уза. Безнеңчә, чит ил кунагы белән сөйләшү мәҗлесе дипломатларча нәзакәтле тонда барырга тиеш иде. Рахман карт исә Шандорның бабасы турында «буржуй булса да адәми тойгысы булган икән мәрхүмнең» дип ычкындыра. Эшен яратучы, шуның нәтиҗәсендә югары дәрәҗәләргә ирешкән Корбан ага исә нефтьчеләр хезмәтен «ходай каргаган» эш дип атый. Чит ил кунагы алдында Ногманның хатыны Гөлгел һәм бабасы Рахман белән ызгыш китереп чыгаруына да бернинди зарурлык юк. Ә яңа задвижка кую эпизодында бу операциянең технологиясен инәсеннән җебенә кадәр язып чыгу техник инструкцияне хәтерләтә башлый. Нәтиҗәдә болар барысы да әсәрнең сәнгатьлелеген киметәләр.

М. Хәсәнов вакыйгаларга сизгер язучы. Ул республикабызда КамАЗ гиганты төзелә башлагач та укучыларга «Кама таңнары» дилогиясен тәкъдим итте. Әсәр үзәгенә электрон-хисаплау машиналары белгече, инженер Имам Котдусов куелган. Котдусов эрудицияле, техник грамоталы инженер гына түгел, бәлки галим-инженер да. Автор аны укучыга әнә шулай дип тәкъдим итә. Коллегалары Даниал Ризванов һәм Николай Соснов турында да шуны ук әйтергә мөмкин. Укучының әсәрдән хәзерге фәнтехника революциясе, төзелештә килеп чыккан фәнни яңалыклар, төрле фикер каршылыклары турында әңгәмәләр, бәхәсләр көтәргә хакы бар.

Котдусов, төзелештә булудан бигрәк, күп вакытын командировкаларда уздыра. КамАЗ проблемаларына үтеп керергә вакыты юк аның. Бәлки, командировкаларга барган урыннарда фәнни-техник яктан бәхәсле мәсьәләләрне хәл итәдер дип тә көтәсең. Юк. Анда да барысы да шома үтә. КамАЗ машинасының соңгы моделе раслану да фикер каршылыкларсыз гына үтмәгәндер, укучы бу турыда да белми кала.

Дилогиянең һәр ике кисәгендә дә кызыклы гына производство коллизияләре бар. Мәсәлән, беренче кисәктә сәгатьлек график кертү турында сүз бара. Баш герой Котдусов, аның ярдәмчеләре Даниал белән Николай, генераль директор Леонид Борисович яңалыкны гамәлгә кертү ягында. Әмма объект җитәкчесе Колун консерваторлык күрсәтә, аны куллануны сузып килә. Тик бу конфликт укучыга барып җитми, аның да кайгы-хәсрәтенә әйләнми. Ник дигәндә, автор төп проблеманы куеп торып, кешеләрнең шәхси тормышларында казына башлый, ә алар исә үзәк коллизия белән бөтенләй бәйләнмәгәннәр. Автор әсәрнең төп тукымасына әллә ни ябышмый торган Вагыйз хатларына зур урын бирә, ә төп проблеманың хәл ителү күренешен бер абзацка сыйдыра.

Дилогиянең «Инженерлар» кисәгендәге конфликт бераз уңышлырак бирелгән. КамАЗда Франциядән алынган компьютер системасы монтажлана. Үткен ситуация туа. Ләкин автор проблеманың чишелешен укучыларга күрсәтеп бара алмый, кискенлек югала.

Автор Имам Котдусовны артык күтәреп сурәтли. Аның алдында бернинди дә киртәләр куркыныч түгел, ул аларның һәммәсен җиңел генә хәл итә. Ул гына да түгел, өч-дүрт телдә сөйләшеп, чит ил кешеләрен шаккатыра. Хатын-кызлар белән мөнәсәбәтләрдә тиз уңышка ирешүен дә китереп өстәсәк, бер кеше өчен бик күп түгел микән дип тә уйлап куясың.

Язучының әсәрләре арасында «Юллар, юллар...» романы (1966) үзенчәлекле урын алып тора. Романның «Современник» нәшриятында басылып, бөтен илебез укучыларына тәкъдим ителүе факты үзе үк күңелле күренеш. Әсәр юл төзүчеләргә багышлана, шул хезмәтне башкаручыларның эчке дөньяларын ачып сала, бай рухы белән таныштыра.

Тормышта һәркемнең үз юлы. Тигез генә барган юл кайчак сикәлтәләргә китереп чыгара, төрле бормаларга алып керә. Шул кыенлыкларны үткәндә кеше характеры ныклыкка сынау үтә, алда тагын да очраячак каршылыкларны җиңәрлек кыюлыкка ия була. Хәйрүш, Тимер образлары әнә шул яклары белән гыйбрәтле. Бу җәһәттән алганда Хәйрүш образы аеруча тулы эшләнгән. Гомеренең күпчелек вакытын колония белән төрмә арасында йөреп үткәргән бу кеше Миләүшә, Минзакир, Варисларның уңай йогынтысы, киң күңеллелеге ярдәмендә дөрес юлга баса. Кешеләр дә аңа якы-

ная төшәләр, бөтен күңелләре белән ачыла баралар. Шунысы әһәмиятле, Хәйрүш образын сурәтләгәндә язучы игътибарны аның психологик халәтен, күңелендә барган каршылыклы уйлар өермәсен сурәтләүгә юнәлдерә. Нәтиҗәдә үтә күңелсез тормыш юлы үткән, әле бүген дә яхшылык белән җинаять арасында буталучы бу кеше образы симпатия уята башлый. Димәк, язучы укучыны үз артыннан иртә, тасвирланганнарга ышандыра.

«Кыргый кыз» Миләүшә, киң күңелле Минзакир абзый образлары да укучыда җылы тәэсир калдыралар. Урман эчендә, кешеләрдән читтәрәк яшәүче бабай белән онык сюжет тукымасына үзләренә бертөрле экзотик буяулар белән килеп керәләр.

Әмма югарыда китерелгән образлар күңелне никадәр генә биләп алмасыннар, язучының төп сурәтләү объектлары әле болар түгел. Әсәрдә партия җитәкчелегендә эшләүче ике кеше — Варис Исламов белән Яруллин бар.

М. Хәсәнов бөтен йөрәге белән Варисларны яклый, Яруллиннарны хөкем итә. Бу мөнәсәбәт укучыга да күчә, ә әсәрнең исеменә чыгарылган «Юллар, юллар...» сүзе вакыйгалар сурәтләнешендә рефрен булып яңгырап бара. Роман күтәренке рухта, оптимистик тәмамлана. Варис, яшьләргә мөрәҗәгать итеп, болай ди: «Сезнең юлларыгыз башлана гына әле. Җир өстен бизәп еракларга, бик еракларга сузылачак сезнең юлларыгыз!»

Бу сүзләр язучының үзенең дә изге теләге булып яңгырый. Үз чиратында укучылар да язучыга изге юл телиләр. Әйе, Мәхмүт Хәсәнов юл кешесе, иҗат юлы кешесе. Без дә аңар барыр юлларында тынгысыз иҗат шатлыклары телик!

## Укучының күңел дәфтәренә

**Вьетнам мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Эшләп тапкан акчасы юк, ә караклардан курка.*
*Хуш исле чәчәк күргәч, бөтен куагын өзгән.*
*Кызган табаның үзеннән май чыгармакчы була.*
*Бер әтәч тавышы өчен ике тавык талашкан.*
*Күк күкрәтүче өенә барабан кагып барма.*
*Балта остасы алдында балтам бар дип мактанма.*
*Бик ашыккан чагыңда елганы акрын кич.*
*Ашаганда — аска кара, су эчкәндә — өскә бак.*
*Берәү бернидән курыкмый агач башына менә,*
*берәү куак төбендә дә дер-дер килеп калтырый.*
*Карбызны карга чукыган, ә җәзасы — чиләнгә.*
*Бер муенга ике бау.*
*Туры кешегә кәкре буразна һич тә куркыныч түгел.*
*Көчле көч белән, көчсез — хәйлә белән.*
*Тәҗрибәле ике кул — йөз киңәштән көчлерәк.*
*Ук атарга маташа, ә җәя тарта белми.*
*Уңсын өчен бер савыт дөге — бер савыт тир түгү кирәк.*
*Тыштан — факел, эчтән — ут корты.*
*Вак балыклар диңгездә зурлар артыннан йөзә.*
*Аз оннан күп пирог пешми.*
*Кайтыр юл һәрвакыт кыскарак күренә.*
*Бу дөньяда ни булмый: хәтта таш тирли икән.*
*Син ашаган җимешне кемнәр үстергәнен бел.*
*Су эчкән һәр чагыңда чишмәне искә төшер.*
*Терелеп җитүе булды, врачларны онытты.*

КИТАП КҮЗӘТҮ

# ТҮБӘН КАМАНЫҢ БӘХЕТЛЕ ЯЗМЫШЫ

Марсель Зарипов китабының исеме тормышта да рас килде. Түбән Кама чыннан да бүген үзенең бәхетле көннәрен кичерә. Партия шәһәр комитетының эш тәҗрибәсе КПСС Үзәк Комитетында тикшерелде, шәһәрнең партия һәм хуҗалык оешмалары эше югары бәя алды. Уңай тәҗрибәне гомумиләштергән, шәһәрнең һәм нефть химиясе производствоның үсеш перспективаларын билгеләгән махсус карар кабул ителде.

«Түбән Каманың бәхетле язмышы[1]» дигән китапның Үзәк Комитет карары белән бер үк вакытта дөнья күрүен гади очраклылык дип санарга да була, чөнки китап булып чыкканчы кульязма бер еллык юл үткән. Аңа кадәр, материал туплауга һәм китап язуга тагын дүрт еллап вакыт сарыф ителгән. Шулай да язучының бу теманы үз итүен очраклы хәл дип әйтеп булмый. Ул гражданлык өлгергәнлеге, сугышчанлык һәм оперативлык нәтиҗәсе.

Тарихи яктан кыска гына вакыт эчендә — егерме елда — Татарстанның төньяк-көнчыгышында тиңдәшсез нефть химиясе комплексы калкып чыкты. Автор бик хаклы рәвештә язганча, Түбән Кама Ватаныбыз экономикасы өчен Днепрогэс, Магнитка, Кузнецклар кебек булды. Хәзер, зур төзелешләр чорында миллионлаган һәм миллиардлаган сум капитал салу белән кемне дә булса шаккатыру кыен, әлбәттә. Түбән Кама комплексы заманыбызның ифрат зур төзелешләре арасында да йомылып калмады, алар арасында күренекле урын биләп тора.

Эш киң колачта гына да түгел. Түбән Кама төзелеше тәҗрибә мәктәбенә, хезмәтне оештыруның алдынгы алымнарын өйрәнү мәйданына әверелде. КПСС Үзәк Комитеты карарында әйтелгәнчә, биредә: «...җитештерүне интенсивлаштыру, резервтагы җиһазлардан аеруча тулы файдалану, хезмәтне һәм идарә итүне оештыруны камилләштерү буенча зур эш алып барыла, ә бу исә бишьеллык чорында нефть химиясе продукциясенең кайбер төрләрен эшләп чыгаруны, 1,5—3 тапкыр арттырырга мөмкинлек бирде. Бу максатларга капитал салулар шундый ук куәттәге яңа объектлар төзүгә таләп ителгәннән биш тапкыр кимрәк тотылды»,— диелә.

Игътибар итегез — биш тапкыр кимрәк! Чыгымнар миллионлап кына түгел, мил-

[1] Марсель Зарипов. Түбән Каманың бәхетле язмышы. Рус телендә. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1981.

лиардлап исәпләнгәндә, бу саннар аеруча кәчле яңгырый һәм гомумдәүләт әһәмияте ала. М. Зарипов китабында Түбәнкамалыларның мондый нәтиҗәләргә ничек итеп ирешү серләре ачыла. Автор әлеге мәсьәләгә экономист, социолог һәм язучы булларак якын килә. Алгы планда һәрвакыт кеше, аның эшләре, мәшәкатьләре, борчулары, уй-теләкләре тора. Әмма кешеләрнең холкын, язмышларын тәшенергә тырышкан автор һәрчак берәр проблемага «юлыга».

Бу җәһәттән кызыклы бер мисал: М. Зарипов танылган ташчылар бригадиры Хәмәтхәсән Хәлиуллин турында сөйли. Бригадирның даны да, бүләкләре дә җитәрлек. Ул — Ленин һәм Хезмәт Кызыл байрагы орденнары кавалеры, бригадирлар Советы председателе, төзелеш парткомы һәм профсоюзның җирле комитеты члены. Мактау язулары һәм рәхмәт кәгазьләренең исәбе-хисабы юк. Ләкин җитәкчеләр аны иске карашларга ябышып ятучы дип саныйлар, бригада подряды ысулына каршы чыгуда гаеплиләр.

Автор да, аңа ияреп укучылар да: «Ничек инде алай була? дип гаҗәпкә калалар. Төзелешнең хөрмәтле кешесе, бригадасы барлык күрсәткечләр буенча беренче урынны тота һәм... мә сиңа — консерватор!»

Шулай итеп язучы документаль хикәясенең икенче өлешенә керешә. Хәлиуллинның һич тә бригада подрядына дошман түгеллеге, ә бәлки бу ысулны җан-фәрман яклап йөрүчеләрнең берсе булуы ачыклана. Бригадир алдынгы ысулның авторы Злобин янына ике мәртәбә барып кайта, бөтенесен сораштыра һәм Түбән Камада беренчеләрдән булып бригада подрядына күчә. Әмма аның дәртләнеп йөрүләре формаль-бюрократлык мөнәсәбәткә килеп тәртелә. Кәгазьдә бригаданы подрядка күчерәләр, ә эшкә килгәндә бөтенесе искечә кала. Төзү материаллары китерү графигы даими рәвештә бозылып тора. Бригаданың күпме материал тотуын, күпмесен янга калдыруын, нихәтлесен, бәлкем, артыграк та тотуын санаган кеше юк. Бригада белән исәп-хисап вакытында ясалмый һәм чынлыкта сарыф ителгән вакыт та, эш көче дә исәпкә алынмый кала.

«Без подрядтан түгел, ә подрядлы уйнаудан баш тартабыз»,— ди бригадир. Ул күпшы отчетларда үз исеме яңгырауга, шуларга карап министрлык рапортларында фәлән хәтле бригада прогрессив подряд ысулына күчерелде дип шапырынуларга каршы икән. Хәлиуллин җитәкчеләр белән кискен бәхәскә керә. Бу конфликт Гельманның «Премия» әсәрендәге конфликтны хәтерләтә. Ниһаять, Хәлиуллин, тырыша торгач, үз дигәненә ирешә: бригада подрядына мөнәсәбәт акрынлап үзгәрә башлый.

Бу мисал М. Зарипов китабының бер матур үзенчәлеген — аның проблемалылыгын күрергә ярдәм итә. Язучы гади сурәтләү белән генә чикләнми: ул уйлана, чагыштыра, сиздерми генә укучыны да үзе белән бергә уйланырга мәҗбүр итә.

М. Зариповның бу китабында ясалма пафос бөтенләй юк. Ул бөтенләе белән киләчәккә, иртәгәге көнгә юнәлтелгән. Нәкъ менә шуңа күрә язучы җитешсезлекләр һәм хәл ителмәгән проблемалар хакында кыю яза, аларны бетерү һәм хәл итү юллары турында фикер йөртә. М. Зарипов китабының бу үзенчәлекләре Үзәк Комитет карары актуальлыгында күзгә бигрәк тә ачык бәрелеп тора.

«Кадрларның күчеп йөрүе һәм эш вакытын югалту очраклары күп. Бишьеллык дәвамында шәһәрдә табыш алу һәм капитал салуларны үзләштерү планы үтәлмәде. Кайбер җитештерү куәтләре билгеләнгән сроклардан соңарып файдалануга тапшырылды»— диелә карарда. Түбән Кама нефть химиясе комплексының мөмкинлекләре гаять зур. Бер кулда зур көч: средстволар, техника, кешеләр тупланган. Ләкин кайда да булса җитештерү объектларын төзүдә тоткарлык яки өзеклек тудымы, шунда ук кешеләрне һәм техниканы торак төзелешеннән алып шунда җибәрәләр. Автор сүзләре белән әйткәндә, производство тишектошыклары шәһәр исәбенә ямала. Нәтиҗәдә торак төзелеше планы яртылаш кына үтәлә.

«Шәһәр исәбенә янга калдыру — кешеләр исәбенә янга калдыру була дигән ачы сабакны инде никадәр төзелеш кабатлады,— дип яза М. Зарипов.— Соңгы исәптә бу экономик яктан да, политик һәм социаль яктан да һәм, бигрәк тә, әхлакый яктан берниндн отыш бирми».

Карарның шәһәрне үстерү перспективалары турындагы пункты язучының Түбән Кама киләчәге турындагы уйланулары белән авазлаш. Заманында Түбән Кама шәһәренең проекты СССР халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә Алтын медаль алган иде. Журналистлар Түбән Каманың иртәгә буласы матурлыгына бик күп мәд-

хия җырладылар. һәм менә егерме ел үтте. Бресттан алып Камчаткага кадәр, Урта Азия чүлләреннән Архангельскигача, һәр шәһәрдә диярлек, Черемушкилар калкып чыкты. Инде ачыкланды: Түбән Каманың иң үзенчәлекле билгесе... шәһәрнең үз йөзе булмау икән! Юк, М. Зарипов шәһәрнең үткәнен сызып ташламый. Ул Түбән Каманың башка яшь шәһәрләрдән бер дә ким булмавын, көнкүреш һәм коммуналь шартлары ягыннан һич кенә дә калышмавын таный. Шулай да шәһәрнең матуррак, кызыклырак, күңелдә уелып калырлыграк булуы кирәк иде, ди. Түбән Кама борынгы Чулман буенда, Болгар дәүләтенең Биләр, Болгар кебек тарихи шәһәрләре күршесендә урнашкан. «Шәһәрне бизәгәндә борынгы татар архитектурасының кайбер элементларын ник файдаланмаска?»— дип уйлана автор. Милли колорит ялыктыргыч бертөрлелектән коткарыр иде. Шәһәрнең архитектур потенциалы кешенең «монда бөтенләйгә калыргамы, әллә бәхетне бүтән урында сынап карарргамы» дигән уйлануларына ачыклык кертә торган нәрсә икәнен дә онытмыйк.

Бу көннәрдә Түбән Кама республикабызның гына түгел, бөтен илебезнең игътибар үзәгендә тора. Бу исә яңа күтәрелеш өчен таяныч булыр дип уйларга нигез бар.

**Рафаэль МОСТАФИН.**

# ТУГРЫЛЫК

„Шагыйрь авылда туа, шәһәрдә үлә...» Кайсыдыр бөек әдипнең шушы хикмәтле сүзләре хәтергә сеңеп калган. Татар шагыйрьләре дә әдәбиятка авылдан килә. Авыл — безнең сабый чагыбыз, «чишмә башы»быз. Чишмәләр исә зуррак елгага, зуррак дәрьяга юл тота. Көннәрнең берендә дөньяның әллә кай төшендәге ерак диңгезгә барып җитә ул, куәтле дулкын булып яңа мохитта яши башлый. Әмма табигатьнең тылсымлы көче аны, җитәкләп дигәндәй, кабат беренчел ноктасына — балчыклы, чирәмле ярларына кайтара. Мәңгелек хәрәкәт, мәңгелек әйләнеш. Кешенең дә туган җиренә булган үлмәс мәхәббәте, рухи бәйләнеше табигатьтәге шушы серле әйләнешкә охшаш түгелме соң?!

Шагыйрь Рәшит Гәрәй «Синдә калам»[1] исемле китабының беренче битләрендә үк:

**Урамнарын сөям, паркларын,**
**Бульварларын сөям каланың.**
**Тик шулай да, авылым, җырларымда**
**Мин синеке булып каламын,**

— дигән юллар белән әлеге охшашлыкның дөреслегенә ишарә ясый, киләчәктә туган туфрагына мең дә бер тапкыр әйләнеп кайтачагын белдерә. Шәһәрне яманлау, аның мәгънәсен кечерәйтү хисабына авылны күкләргә чөеп мактый башласа, без авторның зирәклегенә шикләнеп карар идек. Юк, авыл белән шәһәрне кара-каршы куеп «сәешттерми» ул, тормышта һәрнәрсәнең үз матурлыгы, үз моңы булуы турында, сагыну-сагышларның көче һәм тирәнлеге хакында сөйли.

«Синдә калам». Шушы гап-гади сүзгә табигать баласының туган җиренә, туган авылына булган олы мәхәббәте сыйган да беткән. Җыентыкның исемен билгеләүче ул сүзләрне шагыйрьнең тугрылык анты, шигъри вәгъдәсе рәвешендә кабул итәсең.

Утыз еллык иҗат. Р. Гәрәйнең бу китабы әнә шул вакытны колачлый. Шактый зур ара булганлыктан, андагы шигырьләр шагыйрь иҗатындагы биеклекләрне, табыш һәм югалтуларны ачыкларга, кайбер нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә.

Мәгълүм ки, моннан ун-унбиш ел элек поэзиябезгә яңа бер агым килеп керде. Аның вәкилләре традицион алымнарны үзгәрттеләр, тормышка тирән үтеп кергән фән һәм техника яңалыгын рухи ихтыяҗлар, бүгенге көн яссылыгына куеп тикшерделәр. Нәтиҗәдә форма, хис һәм фикер ягыннан үзенчәлекле әсәрләр мәйданга чыкты. Омтылышлы, актив позицияле һәм фәлсәфи рухтагы бу шигырьләр шунда ук җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итте, кайнар бәхәсләр китереп чыгарды. Ни хикмәттер, Р. Гәрәйгә әлеге үзгәрешләр җиле кагылмады. Нәрсә бу: үз-үзеңә, шигъри сукмагыңа тугрылык, яхшы мәгънәсендәге үҗәтлекме, әллә инде чикләнгәнлекме? Икесе дә бардыр, ахры. Ни генә булмасын Р. Гәрәй «мөгез чыгарып» тормады, үзенчә генә итеп һаман үзенекен — авылны, аның гади кешеләрен җырлый бирде. Туган җиреннән беркайчан да бизми торган тургай

[1] Рәшит Гәрәй. Синдә калам. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1981.

шикелле, кырларына һәм болыннарына «ябышып» ятты.

Җыентык дүрт бүлектән тора: «Туып-үскән җирләрем», «Яшьлегем-мәхәббәтем», «Җырлы вагоннар», «Кояш чыгышларында». Дүрт бүлек, дүрт бәйләм. Бу — тематик яктан гына бүленеш, асылда алар бер-берсен тулыландырып, бер үк хисләрнең дәвамы булып киләләр. Мина калса, «Туган-үскән җирем» дип аталган беренче бүлек — үзенең колачы, шигъри нәфислеге, идея-эстетик кыйммәте белән арада иң уңышлысы, иң отышлысы. Биредә шагыйрьнең характеры, рухи яшәеше, мәсләге тулырак, тирәнрәк ачыла.

Нинди соң ул — шагыйрьнең туып-үскән җире? Бу сорауга җавапны шигырьләрнең үзләреннән, андагы конкрет хисләрдән, конкрет образлардан эзләргә кирәк.

**Әй, сине соң ничек яратмыйсың!**
**Күңелемә яшьли кергән җир;**
**Әткәм — кияү, әнкәй — килен булган,**
**Үзем гашыйк тотып йөргән җир.**

Бу юлларда буыннар бәйләнеше дә, тормышның мәңгелек хәрәкәте дә аермачык ярылып ята. Тумышы белән Минзәлә ягыннан булган шагыйрь халыкның «Барам әле Минзәләгә» дигән җырын «кайтам» диеп үзгәртеп җырлый. Чөнки «туган җиргә бармыйлар, аңа кайталар гына» икән ич! Менә шундый нәни генә поэтик ачышлар туган илне яратуның зурлыгын, аның бик тә кадерле хис булуын аңлатып бирәләр.

Авыл. Аның гади кешеләре... Шушы җирлектә шигъри хисләр бөреләнә. Ул — басу туфрагын, уҗымнарны сагыну, игенчене олылау, икмәкнең кадерен раслау. Кая гына бармасын — кояш чыгышындамы, кояш баешындамы — лирик геройны игенче рухы озата килә. Тауга менсә дә аны барыбер «кырлары, буразналары дәшеп төшерә».

Авылны ярату, сагыну турында күп язылды бездә. Аларның барысын бергә җыеп укысаң, бу шагыйрьләр әллә һәммәсе дә бер үк авылдан микән, дип елмаясы булыр иде, мөгаен. Дөресен әйтик, яхшылары белән бергә, тема инерциясе белән язылган йомшак шигырьләр дә байтак әле бу «кишәрлектә». Бәхеткә каршы, Р. Гәрәй гадилеге, табигыйлеге, ихласлыгы, сабыйларча сафлыгы белән алдыра. Хәтта вакыт-вакыт арттырыбрак та җибәргәли: кайчак табигый дигәнең натурага тартым була башлый. Сүзләрнең тәмене, поэзиянең серлелегенә хилафлык килә. Шагыйрь ни булганы белән генә чикләнеп кала, чынбарлыкның тагын да тирәнрәк катламнарына үтеп керергә омтылмый да шикелле. Фантазия каядыр читтә йөри яки йокы «симертә». Андый чакларда шагыйрьне уңышсызлык сагалап тора.

**Иркен сулыш алган чагы**
**Кырларның, болыннарның,**
яки:
**Сине уйлап күңелем моңсулана**
**Җәйге кичтә җилләр искәндә,**

— кебек юлларны укыганда күңел үзеннән-үзе поэтик ачышларны, шигъри яңалык белән өретелгән хакыйкатьләрне сагына башлый. Ә бит бүгенге көн укучысының рухи ихтыяҗы нык үсте, аны очкынсыз сүзләр белән генә шаккатырып булмый.

Сабыр шигырьләр дигән идек. Иҗатындагы сабырлык, тыйнаклык төсмерләре Рәшит Гәрәйнең үзеннән килә. Бу аңлашыла да, чөнки шигырьләр бит җанындагы рухи тәҗрибә, күңел байлыгы, әхлакый хәзинәләр җирлегендә туа. Тормышта күп нәрсәләрдән качып буладыр, әмма үз-үзеңнән берничек тә кача алмыйсың. Ак кәгазь каршына утырып күңелеңдәге уй-хисләреңә ирек бирүче шагыйрь өчен бу бигрәк тә шулай. Мохитына карап, төрле кыяфәткә, төрле рольләргә керүчеләр дә бардыр-барын, ләкин маскалар — вакытлы күренеш. Һәрхәлдә, безнең өчен кешенең чын йөзе, табигый халәте кыйммәтлерәк. Р. Гәрәй башкаларга үз характерын, күңел тирбәлешләрен ачып бирүдән куркып, тартынып тормый:

**Табигать иртәнгә кадәр**
**Ял итә эреп.**
**Аның серен тыңлап тору**
**Килешми кебек.**

Бүгенге көндә — хисләрен, уйларын, йөзләрен яшерә белүчеләр арта барган заманда — мондый ихласлыкны хупларга гына кирәктер, минемчә.

Сабырлык димәктән, аның тамырларын еракта эзлисе юк. Р. Гәрәйләр буынының балачагы дәһшәтле сугыш елларына туры килә. Ул яшьлек малай әтисенең батырларча һәлак булуын ансат кичергәндер дисеңме? Әтиләре урынына сабан сөреп үскән бу малайларның язмышы меңнәр язмышына охшаш:

**Кирәк чакта көмеш дагалардан**
**Тубал-тубал утлар чыгардык.**
**Булды көннәр... качып ят күзләрдән**
**Ат яларын сыйпап еладык.**

«Басу туфрагының бераз тозлы булуы» да аларның маңгай тире тамганнан икән ләбаса! Сугыш темасы әнә шулай биографик вакыйгалардан саркып чыга. Бүгенге

кояшлы июньнең чыклары шагыйрьгә сабыйлар һәм аналарның күз яшен хәтерләтә икән, моңа сугыш, фәкать сугыш гаепле. Р. Гәрәйнең «Елмаюлы таңнар хакына» дигән шигырендә шушы буынның фаҗигасе һәм шатлыгы аеруча калку күрсәтелә:

**Кайчак, бәлки, боек күренәбездер,**
**Гаепләргә кемнең ни хакы?**
**Уйнап-көлеп кенә яшәр өчен**
**Киләмени җиргә ир заты?!**

**Елмаябыз... безнең елмаюдан**
**Иң караңгы көннәр яктыра.**
**Боексак та бары боегабыз**
**Елмаюлы таңнар хакына!**

Сугышны тынычлык җиңәргә тиеш! Бу — миллионнар теләге. Ләкин дошман бүген дә йокламый: яңгырдан соң үскән гөмбә шикелле, җир шарының әле бер, әле икенче почмагында фашизм баш калкыта. Шуңа күрә илебез тынычлыгын саклаучы совет солдаты әле хәзер дә — маршта, маневрда, хәрби өйрәнүләрдә. Китаптагы «Җырлы вагоннар» дигән бүлек сугыш һәм тынычлык темасының дәвамы булып тора. Р. Гәрәйнең солдаты — шинель кигән шул ук игенче, кырлар хуҗасы. Аның «маршка» дигән сүзе дә «арышка» сүзе белән рифмалаша!

Р. Гәрәй иҗатының күп кенә үрнәкләре халык җырларына аваздаш. Бу бигрәк тә мәхәббәт шигырьләренә карый. «Кайгы кичермәгән кеше шатлык та кичермидер» кебек халыкчан тәгъбирләр, «Кыр казлары киткәндә» исемле җырның халык арасында популярлашып китүе шулай дип әйтергә нигез бирә.

Тагын бер сыйфат күзгә ташлана: автор шигырьләренең исемен текст эченнән «суырып» алган юллар белән билгеләргә ярата. Мисал өчен берничәсен күрсәтеп тә китик: «Урак очы, штык очы белән», «Басуларны күреп сөендем», «Рәнҗеп ята төсле бабамнар» һ. б. Исем кушудагы мондый алым — телисеңме, теләмисеңме — ярлылыкка, чикләнгәнлеккә илтерә, тәэсир көчен киметә. Р. Гәрәй иҗатында бертөрлелек (монотонлык) барлыгын да әйтер чак җитте шикелле. Мотивларны үзгәрткәләп алудан курыкмаска кирәктер. Оста гармунчы да бит, әнә, бер үк көйне уйнаганда хикмәтле борылышлар ясап ала, төрле төймәләрне төрлечә сайратып карый. Шундый борылышлар, төрле авазларның чиратлашуы безгә тормышның җанлы һәм хәрәкәтчән агымын тулырак аңларга ярдәм итә.

Бүгенге көндә авылның социаль йөзен үзгәртү, аның табигатен саклау мәсьәләсе бөтен кискенлеге белән каршыбызга басты. Авылны, аның кешеләрен чын-чынлап яратучы шагыйрь киләчәктә бу проблемаларны да читләтеп узмас дип ышанасы килә.

«Рәшит Гәрәйнең иҗаты асылда үзенчәлекле, матур иҗат, һәм аның шигърияте-без мәйданында кабатланмас урыны бар». Китапка сүз башы язган шагыйрь Ренат Харисның шушы фикерләренә кушылып тагын шуны әйтәсе килә: җырла, шагыйрь, яңа офыкларга омтыл, киләчәктә дә үз кырларыңның тугрылыклы тургае бул!

**Рашат НИЗАМИЕВ.**

# КЕШЕЛЕК ТАВЫНА КҮТӘРЕЛГӘНДӘ

Язучы һәр баланы үзенеке шикелле яратырга тиеш. Әнә шул тәкъдирдә генә аның әсәрләре балалар арасында да, өлкәннәр арасында да бертигез уңыш казана ала. Чыңгыз Айтматовның «Ак пароход»ы, В. Быковның «Бүре өере», «Кругляп күпере», М. Шолоховның «Кеше язмышы», Ш. Шамодиның «Нихәл, яшь иптәш» әсәрләре әнә шундыйлар.

Чит кеше баласын ярату дигәндә, сүз, әлбәттә, язучының рухи тәҗрибәсе белән тормыш тәҗрибәсе кушылу нәтиҗәсендә туачак әдәби герой турында бара.

РСФСР Язучыларының V съездында А. Барто: «Рухи башлангычтан мәхрүм ителгән балалар, үсеп җиткәч, үзләреннән соң килгән балаларны да балачакларыннан мәхрүм итәләр»,— диде. Әгәр язучы кечкенә геройларын үз баласы кебек ярата икән, ул рухи башлангыч турында, ягъни икенче төрле әйткәндә, балаларны кешеләр арасында кеше булып яшәргә өйрәтү турында беркайчан да онытмаска тиеш.

Без батыр малайлар турында язарга яратабыз, тик еш кына әнә шул күркәм сыйфатны кешелек төшенчәсеннән чыгып

бәяләмибез. Шунлыктан кайбер геройларыбыз батырлыкны робот сыман — уйсызнисез генә эшли. Ә мондый батырлык беркемне дә ышандырмый.

Батырлар турында сөйләгәндә, аларның эчке дөньяларын, җаннарын укучыга ачып күрсәтә алсак иде бөз һәм шулай ук кечкенә геройларның да зур җанлы булырга сәләтле икәнлекләрен онытмасак иде. Бу җәһәттән Ләбибә Ихсанованың яңа повесте «Наил һәм Фаил» гыйбрәтле генә. Кечкенә геройларның эчке дөньяларын, җаннарын шактый тулы ачып бирүгә ирешкән автор. Әсәрдә барысы да ал да гөл дип әйтергә җыенмыйм. Әмма автор балаларны яратып, аларның җанын аңлап язган. Ул балаларны кеше булырга өйрәткәндә үгет бирүдән качарга тырыша. Үзе иҗат иткән вакыйгалар эчендә балалар белән бергә кайный. Язучы әсәрнең башыннан азагына кадәр балаларның дусты, сердәше, киңәшчесе булып кала.

Повестьның төп герое — тискәре персонаж. Аны күпләр яратмыйлар, үзенең алла каргаган холкы аркасында байтак кына кыенлыклар күрергә туры килә малайга. Әмма аның күңел тәрәзәсен классташларына да, әти-әнисенә дә күренми торган якты нур балкытып йөри. Бөтен бәла дә шунда шул: тирә-юньдәгеләр күрмиләр, дөресрәге, күрергә теләмиләр малайның күңел тәрәзәсендәге яктылыкны. Хәер, малай күңел тәрәзәсен һәркемгә ачарга үзе дә ашыкмый. Чөнки аның алган тәрбиясе, холкы-фигыле шундый. Тик үзенең күңел тәрәзәсендәге яктылыкның зурая барачагына, шул яктылык төшкән җирдә кайчан да булса шифалы үсентеләр шытачагына ышана ул. Шул ышаныч — малайның рухи башлангычы.

Бала кешелек тавына күтәрелгәндә һәр җирдән мажара эзли. Аңа табигатьнең һәр күренеше кызык, һәр үләне, һәр бөҗәге серле булып тоела, серле күренә. Хыялсыз бала — чәчәксез гөл, канатсыз кош. Ләкин җир тормышыннан, реаль чынбарлыктан аерылмаган очракта гына хыял үз бурычын үти ала, гадәттән юлыннан килячәккә бару өчен балага канат була ала.

Адлер Тимергалинның «Таш алиһә» повесте — мажаралы әсәр. Ләкин аның хикмәте мажаралы булуында түгел. Язучының эрудициясендә һәм бай фантазиясендә генә дә түгел хикмәт. Иң мөһиме — А. Тимергалин геройларының хыяллары туган җирдән, ата-баба туфрагыннан, көндәлек эшләрдән аерылмый. Гап-гади вакыйгаларны, көндәлек эш-шөгыльләрне хыял канатларында йөздерә ала, гадәти бер мәктәп, гадәти бер авыл, гадәти бер колхоз тормышыннан мажара ясый ала язучы. А. Тимергалин мажарасы — бүгенге тормыш мажарасы, романтик рух белән сугарылган реаль мажара.

Без бүгенге көн турында язылган әсәр укысак, заман сулышы белән өретелгән, дип әйтергә яратабыз. А. Тимергалин повесте дә бүгенге көн турында. Анда колхоз тормышы да, табигатьне саклау проблемасы да, пионер дружинасы эше дә, авыл тарихын өйрәнү мәсьәләләре дә күтәрелә. Әмма Тимергалин, нәрсә турында гына язса да, сюжет сызыкларын кеше җаны аша үткәрергә тырыша. Нәтиҗәдә, әсәрдәге вакыйгалар тагын да реальләшә, мажара дигәнең чынбарлыкка тагын да якынрак килә, ә кайчакта хәтта чынбарлык белән бер бөтен булып тоташып та китә.

«Күп кеше асылда романтик һәм гомер буе бәләкәй генә булса да бер могҗиза көтеп яши... Тик еллар үтә, могҗизаның зурысы булмый, ә көндәлек бәләкәй могҗизаларны маңгай күзе күрми... Хыял сүнә, бәндәләр көндәлек тормыш мәшәкатьләре астында басылып кала. Ә бит могҗизаны көтеп ятмыйлар, аны эзләргә кирәк». А. Тимергалин үзенең яңа әсәрендә балаларны шул рәвешчә көндәлек тормыштан могҗиза эзләргә, көндәлек тормыштан могҗиза табарга чакыра.

Бала күңелендә кешелекле хисләр тәрбияләүдә табигатьнең роле искиткеч зур. Табигатькә мәрхәмәтле булырга, аны яратырга, аның байлыкларын күз карасыдай сакларга өйрәтә торган әсәрләр күп язылла бездә. Билгеле, һәр ялтыраган алтын булмый. Әмма ике тамчы су кебек бербереенә охшатып язылган әсәрләрне укыйукый ялыккан күңел кайчагында алтын да тели. Алтын дигәнем — табигать дулкыннарын кеше күңелендәге кичереш, хис ташкыннары белән кушып, уйсызны уйлы итәргә, гамьсезне гамьле итәргә сәләтле әсәр. Әлбәттә, балаларга натуралист язмалары да кирәк, аларны да кире кагып булмый. Ләкин Г. Троепольскийның «Акбай караколак» повесте шикелле чын художник кулы белән, чын мәгънәсендә кешелекле итеп иҗат ителгән әсәрләрдән дә баш тартмаслар иде безнең балалар. Натуралист язмалары баланың аң-белем дәрәҗәсен арттырса, хайваннар, кош-кортлар ту-

рындагы төшенчәсен киңәйтсә, соңгылары исә аны кеше булырга өйрәтә бит.

Әнисә Ибраһимованың «Аулак урманда» дигән повесте унөч яшьлек Ильясның яраланган поши бозавын тәрбияләп үстерүе һәм ахырда, үз гомерен куркыныч астына куеп, аны браконьерлар кулыннан йолып алуы турында. Максаты изге авторның. Кечкенә герое да бик инсафлы, изге күңелле малай. Тик менә шундый әйбәт малай катнашкан вакыйгаларның бераз өстенрәк тасвирлануы гына эчне пошыра. Табигате белән шактый куркак Ильяс, канга батып яткан пошины күргәч, кинәт кенә батырая һәм браконьер кулындагы пычакка карый-карый, үз-үзе белән шундый фәлсәфә куертып җибәрә: «Тукта, нигә бөтенләй җебеп төште соң әле ул? Бәлкем, бу куркынычтан берәр ничек котыла алыр? Кайсы урында соң әле алар хәзер? Ә теге чокыр, тирән куркыныч чокыр еракмы? Кайчандыр аннан шаулап, күбекләнеп дәрья аккан. Хәзер аңардан әнә шул куркыныч упкын гына калган. Салтый курыкмыйдыр ул чокырдан. Үскәч, Ильяс та курыкмаячак. Бернәрсәдән дә курыкмаячак ул.»

Кулына пычак тоткан башкисәр браконьер өстенә килгәндә, чокырның үткәне һәм хәзергесе турында кем генә шулай иркенләп әңгәмә куертып тора алыр икән? Ә бит әсәрнең бу иң югары ноктасы, сурәтобразларның кылычка-кылыч бәрелгәндәй очкыннар чәчрәтергә тиешле урыны... Кызык инде сәнгать әсәре, аз гына фальшьны да күтәрми. Матур гына укып килгәндә, әнә шундыйрак ясалма эпизодларга килеп сөрлегәсең дә, әсәр турындагы якты уйларың кинәт кенә тоныклана да китә...

Ярдәмгә мохтаҗ булган табигать иркәләре һәм аларга кешелекле мөнәсәбәт. Альберт Хәсәновның «Тугрылык» дигән китабына тупланган хикәяләр әнә шул темага багышланганнар. Альбертның хикәяләре җиңел укыла, истә кала. Ләкин художество эшләнеше ягыннан барысы да бертигез түгел. Арада «Ана кадере» кебек укучы күңелен дулкынландырырдайлары да, гап-гади натуралист язмаларыннан узмаганнары да бар. Хәлбуки, табигатьне танып-белү, кош-кортлар тормышын өйрәнү нисбәтеннән караганда, нәниләргә әйбәт бүләк әзерләгән Альберт Хәсәнов.

Баланың эстетик зәвыгын камилләштерүдә, аны матурлыкка өйрәтүдә, шигъри күңелле итеп тәрбияләүдә поэзиядән дә көчлерәк корал юктыр, мөгаен. Бу сүзләрне сөйләгәндә мин Равил Фәйзуллинның «Паласны кем кагар?», Роберт Миңнуллинның «Җиде абый тай җигә», Мөдәррис Әгъләмовның «Без, без, без идек» җыентыкларын күздә тотам. Өч төрле шагыйрь, өч төрле шигърият.

Равил Фәйзуллин шигырь юллары белән аеруча сак эш итә. Фикер кыска, ачык, аңлаешлы булсын! Шигырь бала күңеленә мәгънәсе, эчтәлеге белән генә түгел, музыкаль аһәңе белән дә тәэсир итсен! Балалар өчен яңа китап әзерләгәндә Р. Фәйзуллин үз алдына әнә шундый бурыч куйган һәм бу бурычны, нигездә, уңышлы үтәп чыккан.

Р. Фәйзуллин яңа китабы белән үзен балалар поэзиясендә байтак тәҗрибә туплаган шагыйрь итеп танытты. Җитди шаянлык, лирик фәлсәфә — Равилнең күп кенә шигырьләре өчен әнә шул сыйфатлар хас. Менә туган көн турында бер шигырь:

**Өлгеләр тулы — кояш,**
**Көзгеләр тулы — кояш,**
**Әби күзлегендә кояш,**
**Песи күзендә дә кояш...**
**Җиргә төшкән мең кояш!**
**Күктәгесен дә санасаң,**
**Бүген мең дә бер кояш.**

Роберт Миңнуллин балаларның характерларын, теге яки бу ситуациядә аларның үзләрен ничек тотачакларын алдан ук сизеп, чамалап тора һәм үзе дә бала ролендә бик оста уйный белә. «Җиде абый тай җигә» җыентыгына тупланган барлык шигырьләрдә дә диярлек, югарыда телгә алынган сыйфатлардан тыш, нәкъ менә балалар характерына, балалар сөйләменә генә хас юмор өстенлек итә. Ә кайчагында йомшак юмор гөнаһсыз иroниягә дә әйләнеп киткәли.

**Мине беләсеңдер инде,**
**Мәрдиев мин, Марат мин.**
**Мактарлык малай булсам да,**
**Мактанырга яратмыйм.**
**Миннән дә шәп укучы юк,**
**Бишле алдым бүген дә.**
**Шуңа мактанып торырга,**
**Мин мактанчык түгел лә.**

Р. Миңнуллин шигърияте үзенең музыкальлеге, шигъри аһәңе, ритмикасы ягыннан караганда, бу өлкәдә инде бөтен мактауларның чиген узган икенче бер мөхтә-

рәм шагыйребез Шәукәт Галиев поэзиясе белән янәшә бара. Янәшә баруы начар түгелдер. Мин бер генә нәрсәдән куркам: тора-бара Шәукәт Галиев салган эзгә ук килеп төшмәс микән Роберт Миңнуллин?

Мөдәррис Әгъләмовның табигать симфониясе хезмәт романтикасы белән бергә кушылып яңгырый. Монда көзге сары яфракларга кадәр балаларга аңлаешлы телдә киләчәк турында, яшь бөреләр турында дәртле җыр җырлый:

**Ул бөре, сезне сагынып,**
**Яз җиткәч йөгереп чыгар.**
**Таң калыр мине яңадан**
**Кайтмас, дип уйлаучылар.**

Монда Ватан азатлыгын яклап яуга керген яшь солдатның сүзләре өмет утына әверелеп дөрли:

**Көтә мине яр астында инеш,**
**Суы көмеш,**
**Илгә кайтыр өчен исән килеш**
**Мин җиңәргә тиеш!**

«Без, без, без идек» китабына — форма ягыннан да, тематик яктан да төрле шигырьләр тупланган. Ләкин мине телгә шул кадәр сак Мөдәррисенең бер строфасы сискәндерде.

**Иске мәктәп карап калды,**
**Теләп калды яхшылык.**
**Карт чаганнар ботагының**
**Арасыннан яктырып.**

Соңгы ике юл «әбиенең әбисенең әбие» сыманрак килеп чыккан.

Әйе, бер караганда балалар әдәбияты өлкәсендәге уңышларыбыз шактый кебек, әмма эшлисе эшләр дә аз түгел әле. Мәсәлән, безнең балалар «Маугли» һәм «Чипполино», «Винни Пух» һәм «Буратино» кебек монументаль әсәрләргә мохтаҗ.

Язган әсәрләребездә еш кына ана белән бала арасындагы мөнәсәбәтләр шактый калку гәүдәләнә. Ә менә ата белән бала проблемасы һәрвакыт кулагадәрәк калып килә. Хәзер инде сугыштан соң кырык елга якын вакыт узды, шуңа күрә бездә этисез гаиләләр бар икән, моңа инде сугыш гаепле түгел. Дөрес, безнең илдә этисез гаиләләр дә материаль яктан кытлык кичерми. Әтиле балаларга караганда тәмлерәк ашап, матуррак киенеп йөрүчеләр дә бар. Әмма бала күп очракта этисез үсүнең фаҗигасен бары тик балигъ булып, мескәкыйльлек юлына аяк баскач кына аңлый башлый. Кызганычка каршы, бу хакта язган әсәрләребез юк дәрәҗәсендә аз безнең.

Иптәш Л. И. Брежнев партиябезнең XXVI съездында ясаган докладында совет кешесенең белемле, культуралы кеше булуын, аның белән җансыз телдә сөйләшергә ярамавын, гомуми фразаларның беркайчан да уңышка китермәячәген басым ясап әйтте. Бу фикер турыдан-туры язучыларга, ә бигрәк тә балалар язучыларына кагыла. Шуны без беркайчан да истән чыгармасак иде.

**Фаил ШӘФИГУЛЛИН.**

# ДӘРДМӘНД ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ЯҢА БАСМАСЫ

XX йөз башы татар поэзиясенең үзенчәлекле күренеше булган Дәрдмәнд иҗаты шигърият сөючеләрнең игътибарын һәрвакыт җәлеп итеп килде. Башта ук шуны әйтергә кирәк, «Исә җилләр» исеме астында[1] дөнья күргән яңа басма элгәреләре белән чагыштырганда аеруча камил эшләнүе белән күзгә ташлана. Моның сәбәбе, әлбәттә, шагыйрь иҗатына үтә игътибарлы һәм сак, шул ук вакытта гаять таләпчән якын килүдә. Татар поэзиясе классикларын бастырып чыгаруда тупланган тәҗрибә һәм текс-

[1] Дәрдмәнд. Исә җилләр. Шигырьләр. Казан, 1980.

тологик культура да моңа ярдәм иткән. Җыентыкны Тукай томнарының соңгы басмасын чыгаруда күп көч куйган Рәис Даутов төзегән. Искәрмәләр дә анык. Тәҗрибәле редакторның нык уйлап эш итүе, пөхтә кулы Дәрдмәнд шигырьләрен тәркемләүдә үк күренә. Биредә моңарчы бер басмада да сыналмаган яңа принцип кулланылган. Нигезгә хронологик-тематик һәм калып-жанр принцибы салынган. Әйтик, I һәм II бүлектә Дәрдмәнднең иҗтимагыйэстетик йөзен ачыграк чагылдырган зуррак шигырьләре, өченче бүлеккә — дүртьюллыклары, дүртенче бүлеккә — икеюллыклары, бишенче бүлеккә — истәлек-парчалары, этюдлары һәм тәрҗемә прозасы кертелгән.

Китапның мөһим бер үзенчәлеге итеп Сибгат ага Хәким язган кереш мәкаләне күрсәтергә кирәк. Ул галимнәрчә тирән уйланылып язылган. Поэзиясенең идеяфәлсәфи ягы белән дә, шигъри синтаксисы, сүзлеге ягыннан да әле тиешле дәрәҗәдә тикшерелеп, ачылып җитмәгән шагыйрьне төшенү һәм аңлату юлында һәр адым, һәр чара безнең өчен кыйммәт. С. Хәким исә шушы өлкәдә әһәмиятле күзәтүләр ясый, шигъри осталык серенә төшенгән шагыйрь Дәрдмәнд иҗатында бүтәннәр әле күреп җитә алмаган якларны ача.

Инде җыентыкның үзенә кайтыйк. Дәрдмәнд әсәрләрен чыгарганда, бигрәк тә аларның калып-күләм ягыннан үтә кыска һәм җыйнаклыгын искә алсак, төгәл яңгыраш мәсьәләсе аеруча җаваплы булып баса. Яңа китапны хәзерләгәндә төзүче нәкъ шундый сак һәм игътибарлы текстолог буларак эш иткән, моңарчы яшәп килгән төгәлсезлекләрне, хаталарны төзәтә барган. Мәсәлән, төрле басмаларда, бигрәк тә аерым мәкаләләрдә мисал итеп китерелгән очракларда Дәрдмәнднең аерым сүзләрен шагыйрь язганча түгел, бәлки хәзер үзебез аңлый алганча бирү очраклары бар. Шундыйлардан берничә шигырьдә рифма буларак кулланылган «йөрәдер» фигылен күрсәтергә мөмкин. «Кораб» шигырендә:

**Төн вә көндез**
**Ул й ө р ә д е р:**
**Юл бара ят ил карап...**

«Кыш көннәре» шигырендә:

**Һәм күктә й ө р ә д е р,**
**Бәс белән томан!**

Һәр ике очракта фигыль «йөрәдер» сүзенә рифма булып килә. Аны «йөзәдер» дип төзәттекме — Дәрдмәнд поэтикасына хилафлык кылабыз. Китапны төзүче биредә тарихи төгәллек юлыннан бара. Элеккеге «васлат», «мазлум» дип язу урынына бу басмада «васләт», «мәзлум» дип алыну да дөресрәк һәм нәфисрәк яңгыраш бирә. Элекке әдәби телебездә киң таралган фарсы изафәсен чагылдыруны да (әйтик, нәкъ хәзергечә «исем шәрифең» түгел, ә тарихи «исме шәрифең» рәвешендә язу — 192 бит), «үз исмене» кебек шигъри ритмга буйсындырган «сыгылма» орфографиядән файдалануны да уңышлы һәм дөрес дип бәяләргә кирәк. Ниһаять, Р. Даутов элекке төзүчеләр җибәргән, хәзерге поэзия теленә дә ялгыш яңгырашта кереп китә язган сүзләрне төзәтеп бара: «бүзәрдем, шуңкар, тулпар» дип түгел, бәлки «бузардым, шоңкар, толпар» рәвешендә (49, 94, 161 һ. б. битләр).

Р. Даутовның соңгы елларда редактор буларак татар әдәбияты текстологиясенә керткән практик өлешенең берсе сыйфатында классик шигъри мирасыбызның дөрес яңгырашын, тарихи һәм фәнни төгәл ритмикасын саклауга омтылуын күрсәтергә кирәк. Аның орфографик формализм богауларыннан котылырга, поэтик орфоэпиягә якынлашырга тырышуы шуңа бер мисал. Һәм мондый омтылышны баш-баштаклык галәмәте дип түгел, бәлки элеккеге әдәби, шигъри фактларны фәнни дөрес, тарихи гадел яктыртырга тырышу дип бәяләргә кирәк. Чөнки һәр чорның поэзиясендә аның үзенә генә хас ритмика, вәзен-үлчәү барлыгын танысак, шул хосусый сыйфатларны дөрес, төгәл чагылдыруга омтылуның да хокукка ия икәнлеген икърар итәргә тиешбез. Мәсьәләгә шушы позициядән якын килгәндә «Исәҗилләр» китабының фәннилек юлында алга таба зур адым икәнлеген махсус билгеләп үтәргә кирәк. Дәрдмәнд шигырьләренең зур өлеше хәзер төгәлрәк яңгырауга ирешкән.

Дөрес, китапта бу юнәлештә дә төгәл эшкәртелеп җитмәгән аерым юллар оч-

раштырғалый әле. *Мәсәлән*, «гыйшык» сүзенең элеккеге әйтелешен эзлекле рәвештә исәпкә алмау нәтиҗәсендә кайбер юллар тәгәл яңгырамый (иҗек саны артып китә, яисә ритмик буын калыбы бозыла): «Гыйшык илә моңлы күңел тулган иде» (22 бит), яисә «Дәрде гыйшык — нирване шәмгы,— Дәрдмәнд пәрванәсе» (46 бит). Әгәр һәр ике очракта да «гыйшк» сүзен элекке кагыйдәчә шулай кыскартып укысак, юллар ритмик кысалардан чыкмыйлар. Соңгы юлны исә болайрак төзәтеп уку дөресрәк булыр иде: «Дәрде гыйшк нирване шәмгы,— Дәрдемәнд пәрванәсе» — ритмика бөтенләй төгәлләнә.

Җыентыкта хәзерге укучы өчен аңлаешсыз сүзләргә, гыйбарә һәм вакыйгаларга кирәкле аңлатмалар бирелгән. Элгәрге басмалар белән чагыштырганда, бу өлкәдә дә алга таба зур адым ясалган: әгәр бит итәгендәге аңлатмаларга кыскалык хас булса, гомум искәрмәләр фәнни-библиографик төгәллеккә ирешә, тарихи гаделлеккә якынлаша. Һәр әсәрнең кайчан, кайда һәм ничек басылуы яисә табылуы эзлекле рәвештә күрсәтелеп бик дөрес эшләнгән. Бу яктан караганда, яңа китап академик басмага якынлаша. Искәрмәләрдә кайбер шигырьләрнең вариантлары тәкъдим ителүне дә файдалы дип бәяләргә кирәк.

Әмма бу китапта аңлау һәм аңлату эшен тәмам төгәлләнгән дип әйтеп булмый әле.

Аерым шигырьләрне уңышсызрак аңлатулар да очрый.

**Ни кәбаирдер мисакъта рухым**
**иткән иртикяб,**
**Кем гадәм зәукыннан әүвәл хөкем**
**ителгән янасы,—**

— шигыре «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге» чигезендә болай аңлатылган: «Нинди зур гөнаһ — яратылышта ук рухым әшәкелек иткән; һәм яхшыны яманнан аермаган вакытта ук янарга хөкем ителгән» (159 б.). Сүзлекне төзүчеләр гарәп сүзләрен, әлбәттә, дөрес тәрҗемә иткәннәр, мәгәр Дәрдмәнднең шигъри синтаксисы һәм шигырьнең мәгънәсе тәрҗемәдә төгәл үк бирелмәгән. Аңлатма шулай дөресрәк булыр иде: «Яратылышта ук рухым эшләгән гаеп нинди зур: әле зәвыгы да юк көе янарга хөкем ителгән!..»

«Синең ялгашыңа тимим, күрәсең» дигән юл элекке басмаларда шулай дөрес басылган иде. «Исә җилләр»дә исә ялгашкан — «Дин вә мәгыйшәт» әһелләренә карата кулланылган үтергеч кинаяле образдан — гадәти «ялгышка», ягъни кеше хатасына әверелгән. Нәтиҗәдә «Чәбә!» дип әйткәнем юк, ник өрәсең» дигән икенче юлдагы җирәнүнең, нәфрәтнең рухына каршырак мәгънә барлыкка килгән.

Образлы сүзнең төп текстта да, искәрмәдә дә бер рәвештә хата язылуы (153 һәм 243 битләр) безне гаҗәпләнергә мәҗбүр итте — әллә корректорлар шулай нык эзлеклелек күрсәткәннәр микән? Мондый шиккә дә урын бар. Әйтик, «сыгыла» һәм «сыгъна» (25 бит), «нәрәдә» урынына «нәрдә» (226 б.), үзбәкчә «буйи» урынына «буйлы» (228 б.), «вәлякин» диясе җирдә «валәкин» (210 б.), шулай ук «вирдекеңезгә»не «видеңезгә»гә алмаштырып басуларны типографик хата дип бәяләү дөресрәк булыр иде — күпкә катлаулы башка текстларны дөрес аңлаган һәм укучыга да аңлаткан төзүчегә хас ялгышлар түгел болар.

«Тупас та булса тел илнең колагы» дигән шигъри юлда «та» кисәкчәсенең элгәрге сүзгә ялгап бирелүен (101 бит), нәтиҗәдә синтаксик чарадан («тупас булса да» мәгънәсендә) грамматик категориягә, ягъни килеш кушымчасына әверелүен, шулай ук «Диярмен — Сез, газиз илләр» урынына «диярменсез» басылуын (133 бит) һәм «та әзәлдән» гыйбарәсенең бергә язылуын (136 бит) да башкача аңлавы читен.

Укылышы дөрес булган кайбер гыйбарәләр дә, әсәр мәгънәсен тирәнрәк ачар өчен, махсус аңлатма бирүне сорый. Әйтик, «Кыйтга» шигырендәге («Чәчеп сүз дөрләрен...» дип башланган) гадәти булып күренгән «шәм-чырак» тәгъбире шундыйлардан (47 бит).

**Караңгы төн исә якын-ераклар,**
**Хәзин кальбемне вакла — як**
**ч ы р а к л а р:**
**Гарибләр, ш ә м - ч ы р а к күргәндә юлда,**
**Дисеннәр: бер заман бар булган ул да...**

Әгәр биредә сүз гадәти балавыз шәм, яисә шунар кушып чыра яндыру хакында гына булса, ягъни шулай аңлашылса, шагыйрь әйтергә теләгән олы теләк төгәл ачылмыйча калыр иде. Хикмәт шунда, әсәрдә сүз гади шәм хакында түгел, бәлки башкаларга, дөресрәге олы тормыш юлында гел гизүче «гарибләргә», ягъни гомер юлында иза чигүгә мәҗбүр ителгән гади кешеләргә үз йөрәк-күңеленең (уй-теләкләренең!) юл күрсәткеч якты факел булып януын өмет итүдә. Ягъни шәм-чырак — биредә факел мәгънәсендә.

Китапта киңрәк аңлатма сораган, лакин

ачылып җитмәгән образлы сүзләр дә бар. Әйтик, «һома» — бөркет түгел (85 бит), бәлки, икенче урында дөрес күрсәтелгәнчә, «бәхет кошы» (137 бит).

«Ил катар» гыйбарәсен «ил буйлап» дип (48 бит) түгел, бәлки «ил рәтендә» (тәгълрәге: кеше рәтендә) дип аңларга кирәк. Казакъ теле тәэсирен татыган Оренбург татарлары сөйләшенә хас бер күренеш бу. Шулай ук «дөньяви дүнән» тәгъбире (72 бит) «дөнья дигән дүрт яшәр атның» (ияргә һәм камытка күнекмәгән, холкы шомармаган яшь атның!) образын бирә. «Конан бил» гыйбарәсе дә гадәти «нәзек»не түгел (138 бит), ә катлаулы образны гәүдәләндерә: «конан» — өч яшьлек ат ул, «конан бил» исә шулай ук тайлык чорыннан чыгып җитмәгән, ягъни тупасланмаган яшь елкының нәфис, сыгылмалы биле дигән мәгънәне аңлата.

Кыскасы, Дәрдмәнд шигырьләрендәге шактый гыйбарәләр, образлар тәфсилләп аңлатуны сорыйлар әле.

Рецензиябез башында алга таба бер зур адым рәвешендә бәяләгән яңа китаптагы эреле-ваклы мондый төгәлсезлекләргә озак тукталуга гаҗәпләнмик: максатыбыз инде ирешелгән уңыш һәм казанышларны икърар кылу, бу олы хезмәтне ихлас күңелдән тәкъдир итү һәм аерым төгәлсезлекләрне махсус теркәп калдыру. «Исә җилләр» китабы булмаса, Дәрдмәнд мирасының текстологиясе хакында да болай иркенләп, төпченеп фикер йөртергә җирлек туа алмас иде әле.

Ниһаять, катлаулы текстологик мәсьәләләр буенча фикерне «Исә җилләр» китабы тирәсенә оештыру да очраклы түгел: иҗаты текстуаль җәһәттән катлаулы, әмма бер үк вакытта җыйнак Дәрдмәнд мирасы тәҗрибә туплар өчен дә, фикер алышу өчен дә бик уңайлы объект. Шундый конкрет иҗатлар һәм сыйфатлы басмалар өстендә фикер чарлау гына татар әдәби текстологиясенә яңа мөмкинлекләр ачачак.

Шулай итеп, безнең кулыбызда Дәрдмәнднең шактый тулы һәм җентекле эшләнгән яңа җыентыгы.

Миркасыйм **ГОСМАНОВ**,
Нурмөхәммәт **ХИСАМОВ**.

# БЕРЕНЧЕ КАРЛЫГАЧЛАР

Әдәбиятыбызда һәм әдәби тел тарихыбызда якты эз калдырган шагыйрь Габделҗаббар Кандалыйның лирик һәм сатирик шигырьләре хәзерге көндә дә яратып укыла, ул калдырган мирас галимнәр тарафыннан өйрәнелә.

Билгеле ки, бер генә иҗат та буш җирдә, үзлегеннән генә барлыкка килми. Аның туып-үсүе һәм чәчәк атуы өчен күп кенә факторларның булуы шарт. Шундый факторларның берсе — әдәбиятта һәм телдә традицияләр мәсьәләсе. Г. Кандалый иҗатында реалистик рухлы классик әдәбият традицияләренең дәвам иттерелүе һәм үстерелүе хакында беренчеләрдән булып профессор Х. Госман язып чыкты[1]. Хәлбуки бу уңай традицияләр шагыйрь әсәрләренең идея эчтәлегендә генә түгел, телендә дә ачык чагылыш тапты. Әдәбияттагы реалистик юнәлеш халыкның җанлы сөйләм теленә нигезләнгән милли әдәби тел туу процессы белән бәйле. Кандалый әсәрләрендәге тел халыкчанлыгының бер нигез ташы реалистик иҗат булса, икенчесе — шагыйрьнең поэзия телендәге уңай традицияләрдән һәм борынгы поэтик калыплардан файдаланып, аларны яңа шартларда үстерүендә.

Кандалый теленә кыпчак чыгышлы, халыкның җанлы сөйләм теленә нигезләнеп язылган матур әдәбият әсәрләренең тәэсире аеруча көчле булган. Мондый поэтик традицияләрнең «чишмә башы» исә Кол Галинең XIII гасыр башында иҗат ителгән «Кыйссаи Йосыф» поэмасына ук барып тоташа. Мәсәлән, Кандалыйның «Кыйссаи Йосыф» үлчәме белән, аңа охшатып язылган «Назме Йосыф» шигырендә бу бигрәк тә ачык күренә.

Кол Галидә:

**Һилалә биңзәр сәнең кашларың вар,**
**Энҗүя биңзәр сәнең дешләрең вар,**
**Гаҗәп зиба мишек йопар сачларың вар,**
**Кәнду әлен үрмәгә лаек имди.**

Кандалыйда:

**Һилалә охшар сәнең кашларың бар,**
**Энҗүя биңзәр сәнең дешләрең бар,**
**Гаҗәп зифа кара ефәк сачларың бар,**
**Һич кемсәнә саңа тиңдәш булмас имди.**

Харәзминең «Мәхәббәтнамә» (1353 ел) әсәре белән Кандалый шигырьләре арасында шулай ук кайбер охшашлыклар, параллельләр табарга була. Мәсәлән, Харәзмидә шундый юллар бар:

**Яраткан кем тән эчрә җан яратты,**
**Сәне күреклеләр үзрә хан яратты.**

Кандалыйда исә без мондый юлларны укыйбыз:

**Сәне сәрбаг эчрә гөл яратты,**
**Бәне сайрамага былбыл яратты.**

[1] Кандалый Г. Шигырьләр. Казан, 1960. Төзүчеләре: Х. Госман һәм Ж. Алмаз, 28—31 битләр.

Кандалый әсәрләрендә Хисам Кятибның «Җөмҗөмә солтан» (1370 ел) әсәре, С. Сараиның «Гөлстан бит-төрки» (1391 ел) китабы белән дә кайбер охшаш тел-сурәтләү чараларын мисалга китереп булыр иде. Бу поэтик сурәтләү чараларында тел һәм эчтәлек ягыннан зур охшашлык ачык чагыла. Билгеле, Кандалый иҗаты белән аңа кадәр яшәгән төрки шагыйрьләр иҗатында мондый параллельләр тагын да бар. Әмма телгә алынган кадәресе дә Кандалый үзенең әсәрләрендә борынгы төрки классик поэзиясенең иң күренекле традицияләрен һәм эчтәлек, һәм тел ягыннан дәвам иткән дигән фикерне куәтли. «Бәдига» әсәрендәге түбәндәге юллар шагыйрьнең Көнчыгыш поэзиясен дә бик яхшы белгәнлеген аңлата:

**...Мисыр шаһ углы Сәйфелмөлек тә**
**Ничә ел йөрде хәсрәттә, көектә.**
**Дир ирде: «Ник ишетмисең сәригам,**
**Бәдигам лә, Бәдигам лә, Бәдигам!»**

**... Дәхи Мәҗнүн тотып күп гыйшкы-мәйле,**
**Дәюр ирде: «И Ләйле лә! И Ләйле!»**
**Дәхи борын заманда үтте Фәрһад,**
**Ки Ширин атлы кыз чөн итте фөрьяд.**

**... Ки мән дәхи бу арага тезелдем,**
**«Бәдигам»,— дип, өзелдем лә өзелдем.**

Кандалый теле традицияләре аннан соң яшәгән һәм иҗат иткән татар шагыйрьләре телендә, конкрет алганда, Г. Тукай телендә ничек чагыла соң? Бу чагыштыруның сәбәбе шунда: Кандалый да, Тукай да, беренчеләрдән булып, иске әдәби тел традицияләрен җимереп, халыкның җанлы сөйләм теленә нигезләнеп язганнар, әсәрләренең төп лексик составын төрки-татар сүзләре, гомумхалык теле тәшкил итә.

Билгеле булганча, К. Насыйри тарафыннан төзелгән «Фәвакиһелҗөласа фил-әдәбият» җыентыгының азагында Г. Кандалыйның «Сәхипҗамал», «Фәрхисорур» һәм «Бәдига» әсәрләре бирелгән. Г. Тукайның «Исемдә калганнар» дигән автобиографик хикәясендә исә шундый юллар бар: «Кич белән китаплар актарганда кулыма «Фәвакиһелҗөласа» китабы төшеп, шуны укырга тотындым. Актыктагы шигырьләрен бик яратып укыйм һәм аңларга тырышам...». Димәк, Тукай Кандалый әсәрләре белән яхшы таныш булган һәм аларга һич тә битараф калмаган. Чөнки Тукайга кадәрге һәм ул яшәгән чорда да әле иске әдәби тел нормалары хөкем сөреп, халыкның җанлы сөйләм телендә язылган әсәрләр юк диярлек. Кандалый әсәрләре Тукай теленә нинди юнәлешләрдә тәэсир иткән соң?

Гомумхалык телендә яза башлауның бер нәтиҗәсе буларак, Кандалый үз әсәрләренә шул чорда бары тик көнкүрештә генә актив кулланылган гади сөйләм сүзләрен дә шактый күп кертә. Мәсәлән: ырылдау — ачуланып әйтү мәгънәсендә («йөремә,— ди-ди ырылдап...»); улау — кычкырып елау («ки әнчек эт тик уларсың»); кәлҗемә — бәрәңге кәлҗемәсе кебек йомшак, юаш кеше мәгънәсендә («юаш дигәнгә рәнҗемә, кесәл дә булма, кәлҗемә») һ. б.

Тукай әсәрләрендә дә без т и п т е р ү, к ә л җ е м ә, а ң г ы - м и ң г е, к а д а л г ы р ы, п ы ч а к к е р г е р е һ. б. шундый гади сөйләм теленә хас сүзләрне очратабыз. Тик аерма шунда: Кандалый гади сөйләм сүзләрен бик сайлап тормыйча, артык таләпчәнлек күрсәтмичә генә кулланса, Тукайда инде әдәби зәвыкны рәнҗетерлек сүзләр очрамый. Бу мәсьәләдә Тукайның фикере ачык һәм эзлекле. Мәсәлән, «Ялт-йолт» журналы редакторы Әхмәт Урманчиевка язган хатларында ул үз мәкаләләрен дөрес бастыруны һәм журналда сүзгә сак булуны таләп итә: «Бу номерда да әдәпсез сүзләр бар, шундый сүзләргә юл киселсен иде» [1].

Лексик диалектизмнарны әдәби телдә куллануга килгәндә исә, Кандалый телендә мишәр диалектына гына хас булган кайбер сүзләр очрый (инәлү — ялыну, көстәнү —

[1] Тукай Г. Әсәрләр, т. 1. Казан, 1977, 253 бит.

авыр сулау, сыктану — сулкылдап елау, тудык, тумачи — туганлык терминнары һ. б.) Кайвакыт Кандалый лексик диалектизмнарны стилистик максатлардан чыгып та кулланa. Мәсәлән:

**Сылу чабың — матур атың**
**Кала сөйләргә телләрдә,**

— дигән юллардагы ч а б һәм а т параллельләре шуны күрсәтә. Кайбер диалекталь сүзләрнең әдәби телдәге вариантлары белән бергә кулланылуы (чаб — ат, ирегү — сагыну, инәлү — ялвару, багу — карау һ. б.) шагыйрьнең аларны әдәби телгә аңлы рәвештә кертеп җибәрүен ачык күрсәтә. Г. Тукай исә диалектизмнарны куллану мәсьәләсендә бик сак эш итә.

Кандалый да, Тукай да, әсәрләрен халыкның җанлы сөйләм теленә нигезләп язу белән берләттән, үзләренең поэзиясендә иске язма тел традицияләреннән дә оста файдаланганнар. Бу аларның борынгы төрки-татар сүзләрен, шулай ук гарәп һәм фарсы алымнарын үзенчәлекле куллануларында бик ачык күренә.

Кандалый әсәрләрендәге архаик сүзләрнең күпчелеге әдәби тел традицияләре тәэсирендә кулланылган. Мәсәлән, шундыйлардан к и ч ә — т ө н, ә л — к у л; с а ч — ч ә ч, д е ш — т е ш, д и л — т е л, у г ы л — у л, у г л а н — о л а н һ. б. ларны санап китәргә була. Ритм һәм рифма таләпләре белән дә, шулай ук стилистик максаттан чыгып кулланышка алынганнары да очрый. Тукай телендәге архаизмнар исә стилистик катлау рәвешендә (тәкый, юк торыр, шәһит ирер, аглаю, аглыйдыр һ. б.), әдәби традиция рәвешендә (бер мән, кемсә, дәхи, ярлыкагыл һ. б.) яки ритм һәм рифма таләбеннән чыгып та кулланылган. Ике шагыйрь өчен дә хас булган тагын бер үзенчәлекне әйтеп китәргә кирәк: алар архаизмнарның күбесен хәзерге телдә актив йөргән вариантлары белән бергә кулланганнар. Мәсәлән, Кандалыйда да, Тукайда да без е г ъ л а у — е л а у, у г ы л — у л, у й к у — й о к ы, а н л а р — а л а р, б ә н — м и н, с ә н — с и н кебек синонимик рәтләр күрәбез. Димәк, иске сүзләрнең төшеп калып, яңаларының кулланышка керә баруы процессын Кандалый да, Тукай да бер үк дәрәҗәдә дөрес аңлап, үз әсәрләрендә ачык чагылдырганнар.

Кандалый һәм Тукай поэзиясе лексикасының бер өлешен гарәп һәм фарсы алынмалары алып тора. Һәр ике шагыйрьдә дә, китап теле өчен генә хас гарәп һәм фарсы алынмаларына караганда, гомумхалык теленә кереп киткән, андагы төрки-татар сүзләре белән бер дәрәҗәдә аңлаешлы булган алынмалар күбрәк. Бу исә, төрки-татар лексикасы кебек үк, аларның үз әсәрләрен халык теленә нигезләп язуларын исбатлаучы бер факт.

Китап алынмаларына килгәндә исә, Кандалый әсәрләрендә аларның күбесе рифма таләпләре буенча кулланылган — чөнки күпчелеге шигырь юлының азагында килүе дә шуны раслый. Менә «Сәхипҗамал»дан бер мисал:

**Дигел: «Кандалда бер х ә з р ә т,**
**Сәңа гыйшкы төшеп к ә с р ә т,**
**Кичә-көндез чигеп хәсрәт,**
**Янып-көядер, ай-вай ла».**

Китап теленә хас к ә с р ә т (күп) сүзе гомумхалык алынмасы булып киткән х ә з р ә т һәм х ә с р ә т сүзләренә рифмалаштыру өчен кулланылган. Сирәк очракларда Кандалый китап алынмаларыннан стилистик максатлардан чыгып файдалана:

**Көчәйтте дәрт белә хәстәм**
**Нинчә к ә р р ә, нинчә к а т л а р.**

Биредә к ә р р ә (кат) алынмасын аның татарча варианты к а т сүзе белән параллель кулланып мәгънәне көчәйтеп бирүгә ирешелгән.

Тагын да сирәгрәк очракларда Кандалый төрле мәгънә төсмерләрен белдерү өчен татар телендә тиңдәше булмаган сүзләрне сайлый: к и т а н — ак мамыктан эшләнгән

полотно («китан кебек тәнемгә кул саласы булса да соң ул»), сәйран итү — күңел ачып, тамаша кылып йөрү («ки сәйран иттем оҗмахта») һ. б.

Китап теленә хас гарәп һәм фарсы алынмаларын стилистик максатлардан чыгып куллану Тукайда да күренә. Мәсәлән, аның «Мәхәббәт шәрхе» дигән шигырендә мондый юллар бар:

Шундый хәкарәттә, хурлыкта мәхәббәт йолдызы... Һичшиксез, монда хәкарәт — хурлык синонимнары стиль чарасы итеп файдаланылган. Тукайда ритм-мелодия һәм рифма таләпләре буенча кулланылган китап алынмалары да шактый:

**Нечкәләп баксаң бу күлнең бар бугай шигърияте,**
**Бар кеби милләт хыялында аның сиррияте.**

Биредә сиррияте (серлелеге) алынмасы рифма өчен кулланылган.

Димәк, китапча гарәп һәм фарсы алынмаларын кулланганда Кандалый да, Тукай да бер үк принципларга таянып эш иткәннәр. Иске татар әдәби телендә язган шагыйрьләрдән аермалы буларак, аларда гарәп һәм фарсы алынмаларын урынлы-урынсызга куллану юк дип әйтерлек. Татар поэзиясендә Тукайга кадәр гарәп һәм фарсы алынмаларын шушы принциптан чыгып кулланган шагыйрь Кандалый гына булганга күрә, бу мәсьәләдә Тукай, һичшиксез, Кандалый традициясен дәвам итә дип кистереп әйтә алабыз. Ике шагыйрь иҗатындагы кайбер параллельләр дә шул турыда сөйли. Мәсәлән, «Сәхипҗамал»да мондый юллар бар:

**Я сурәтең ясатырга**
**Барыйм микән лә нәккашка!**
**Я үзеңне алыйм микән**
**Тотарга күз белән кашка!**

Мәгънә төсмере белән бу юлларга күбрәк туры килә торган рәссам (рәсем ясаучы, художник) сүзе булуга да карамастан, аның нәккаш (төрле сурәтләр төшерүче, бизәкче, буяучы) дигән варианты, һичшиксез, каш сүзенә рифма өчен генә файдаланылган булырга тиеш. Тукайда да шуны ук күрәбез:

**Бик матур бит, бакчы бу кызның күзенә, кашына,**
**Мең вә мильюн афәрин бу сурәтең нәккашына.**

Гомумән алганда, Тукай мондый тулысынча бер-берсенә туры килеп тора торган параллельләр, нәзирәчелек белән мавыкмый. Аның традицияләргә һәм, шул исәптән, Кандалый теле традицияләренә мөнәсәбәте башкарак аспектта. Тукай прогрессив идеяләр, фикерләр дәвамчысы, традицион формаларга да ул яңа, кабатланмаган эчтәлек салырга тырышкан. Мәсәлән, Сак белән Сок образлары элек-электән берберсе белән кушылырга зар булып та, һичкайчан моңа ирешә алмаячак кешеләрне сурәтләү өчен кулланыла. Кандалыйда да ул шулай:

**Бере Сок та, бере Сак та**
**Икесе дә ике якта**
**Моңаеп егълаган чакта,**
**Еламый һич түзеп булмай.**

Ә Тукай исә бу форманы һич көтмәгәндә сатирада куллана:

**Сак белән Сок кыяматтә берсен-берсе очрата;**
**Биш талчокчы, өч фахишә театрны пычрата.**

Татар телендә рус алынмалары да иҗтимагый шартлар таләбе белән туган объектив процесс булып тора. XIX гасыр башында беренче булып алар Кандалый телендә күренә башлыйлар. Мәсәлән: чашка, купец, мажик (мужик), пунәтәйләр,

анвалит (инвалид), дура, начальник, гурнича (горница) һ. б. Кандалыйда рус сүзләренең күбесе халык сөйләм теленнән килеп кергән булса һәм бу бары Кандалыйның җанлы сөйләм телендә язарга омтылышын чагылдырса, Тукайда инде иҗтимагый тормышта кулланылышка кереп тә, әлегә тәрҗемә ителмәгән һәм татарча адекваты табылмаган төшенчәләр, төрле терминнар өстенлек итә. Шундыйлардан дума, депутат, выставка, закон, юрист, адвокат, театр, пальто, колония, автономия һ. б. сүзләрне атап китәргә була. Шулай итеп, рус алынмаларын куллануның Кандалый башлаган тәҗрибәсе Тукай телендә югарырак баскычка күтәрелә.

Г. Кандалыйның төрле фразеологик әйләнмәләр, мәкаль һәм әйтемнәр, афоризмнар куллануд агы осталыгына да Тукай битараф калмаган. Һәр ике шагыйрьнең дә телендә халык теленнән алынган фразеологик әйләнмәләр, шулай ук төрле афористик тәгъбирләр искиткеч күп. Икесе өчен дә уртак булган фразеологизмнар да шактый гына: сафа сөрү, рәхәт сөрү, канлы яшь түгү, җан фида булу, җан ату һ. б.

Кандалый иҗаты һәм әдәби тел традицияләре — билгеле, катлаулы һәм зур мәсьәлә. Әмма гомуми күзәтүләр генә ясаганда да, Г. Кандалый татар поэтик теленең үз заманына якын, шул заман таләп иткән традицион формаларын терелтеп, аларны тагын да үстереп җибәргән дигән фикергә киләсең. Соңрак бу уңай традицияләр Тукай иҗатында тагын үстерелә төшә һәм бу үрнәк башка шагыйрьләр теленә дә зур йогынты ясый. Шуңа күрә дә, әгәр без Тукайны милли әдәби телебезнең нигезен салучы дип атасак, Кандалый әсәрләрен саф татарча шигырьнең «беренче карлыгачлары» диярге тулы нигез бар.

**Айсылу ЮСУПОВА,**
Казан дәүләт университетының
татар теле кафедрасы аспиранты.

## Укучының күңел дәфтәренә

**Гарәп мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Тел — акыл хезмәтчесе.*
*Озын гәп юл кыскарта.*
*Ябык авызга чебен дә керми.*
*Күп сөйләгән тиледән, телсез акыллы яхшы.*
*Бер-беренә булышсалар, кешеләр көчле була.*
*Ямау сала белүче һичкайчан шәрә булмый.*
*Сарыкка ярдәмгә килсәң, бәрәнне бүре урламый.*
*Ут якмасаң җылынып булмый.*
*Басуын сугарган кеше бодаен да тарттыра.*
*Синең турыда мин курай уйныйм, ә минем хакта син барабан как.*
*Зур тишеккә кечкенә ямау.*
*Ашыгып җавап бирүче уйлап тормыйча сөйли.*
*Әйткән сүз — акыл үлчәве.*
*Тулы савытның суы чайпалмый.*
*Улыңа сакал чыкса, үз сакалыңны алдыр.*
*Үзен тәлгәш итеп саный, ә үзе сыңар җимеш.*
*Бер дөя дә муены кәкре икәнен белми.*

# КҮҢЕЛ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

*Бакый Урманченың иҗат портретына эскизлар*

Сәнгать күгендә күп исемнәр балкып кабына, ләкин аларның бик азы гына җәмгыять тормышы белән, заман белән аваздаш әсәрләр иҗат итеп, күңел җәүһәрләрен тулысынча ачып салу бәхетенә ирешә. Мәдәниятебез үсешенә зур иҗади өлеш керткән, аны рухи тәҗрибәсе белән баеткан, матур ачышлардан торган образлар дөньясы тудырган Бакый ага Урманче әнә шундый бәхетле язмышка ия булган шәхесләрнең берсе.

Сәнгать бишеге янында торучыларга хас универсальлек, зур мәгълүматлылык һәм карашлар киңлеге Б. Урманчега үзен тулы һәм тирән хосусият белән чагылдырырга мөмкинлек биргән. Аның иҗаты милли сәнгатьнең йөрәк түрендә туу, уртак казанышларга таянып үсү өстенә, күңел сизгерлеге, талант куәте белән дә күп милләтле совет культурасының аерылгысыз бер өлешенә әверелде.

Бакый Урманче иҗаты революцион үзгәрешләр белән кайнап торган 20 нче елларда башлана. Заман художникка гаять зур йогынты ясый, аңа гомере буе иҗат итәргә җитәрлек куәт бирә.

20 нче еллар... Сәнгатьтә яңа эчтәлек, яңа сурәтләү алымнары эзләү нәтиҗәсендә, бер-берләренә охшамаган төрле юнәлешләр, агымнар янәшә яшәгән, аралашкан һәм тарткалашкан вакыт. Иҗади шәхесләрнең яңа дулкыннарын, баш әйләнгеч уңышларны һәм түбән тәгәрәүләрне күргән, бәһа биргесез ачышларга юлыктырган заман. Шушы гаҗәеп күп төрле агымнар, чәрексез «изм»нар һәм формалистик катламнар аша, кайчагында кискен һәм күзгә ташланырлык итеп, ә кайчагында ашыкмыйча гына, әмма җиңелмәс көч белән, барлык каршылыкларны туздырып, Октябрьның бөек идеяләре белән рухланган реалистик сәнгать үзенә юл яра.

Урманче әнә шул кайнап торган тормышка чума, яңа заманның яшәрткеч һавасын йотлыгып сулый. Революция әйтерсең лә аның күзен ача, рухи богауларын салдыра. Яңа заманны шулай стихияле рәвештә, күңел белән тою ул еллар рәсем сәнгатенең үзенә бер төрле эмоциональ-рухи күтәренкелегендә, фикер һәм хис хөрлегендә чагыла. Буяулар юмарт түгелә. Полотноларга саф җил бөркелә. Үтә күренмәле нәфис акварель төсләр яңача балкып китә. Картиналар якты нур белән өртелә («Җилкәнле көймәләр», «Сары күлмәкле хатын»).

Ләкин заман һәм уңга-сулга карамыйча иҗат итү өчен ачылган мөмкинлекләр белән хозурлану гасырлар буена килгән дини тыюлардан котылган татар халкы һәм республика интеллигенциясе алдында торган гаять мөһим бурычларны — профессиональ сынлы сәнгать, милли социалистик культура булдыруга бәйле бурычларны оныттыра алмый. Күп кенә рәссамнар революциядән соң ачылган яңа иҗат мөмкинлекләрен тоеп, милли тематиканы гәүдәләндерү, кабатланмас үзенчәлекле сәнгать тудыру эшенә зур фидакарьлек белән керешәләр. «Милли хасият»не эзләү төрле юнәлешләр буенча бара. Еллар узу белән борынгылык һәм этнографизмны керту, көнкүреш һәм милли психология үзенчәлекләренә күмелү аша гына ясалган күпчелек ачышларның, абстракт-геометрик сәнгатькә йөз тоту тенденциясе кебек үк, вакытлы табышлар булып чыгуы ачыкланды. Беренче эшләре үк чорның кыйммәтле документлары сыйфатында гына түгел, ә бәлки әле дә тәэсир көчен җуймаган сәнгать әсәрләре буларак безгә килеп ирешкән икән, бу Урманче эзләнүләренең дөрес юлда торганлыгы турында сөйли.

Ул еллардагы шанлы вакыйгалар үзәгендә кайнаган, иҗатын яңа культура төзү белән табигый рәвештә кушкан рәссам өчен «милли сәнгать» төшенчәсе хөр, азат, һәртөрле (дини һәм башка) чикләүләрдән һәм кимсетүләрдән арынган иҗат, ирекле яңа кеше турында сөйләүче иҗат синонимы була. Миллилекне чагылдыру бурычын ул ниндидер архаик шәкелләргә һәм борынгы символларга күмелүдә дә, монументаль «куфи», арабеска һәм мозаикаларда да түгел, ә бәлки азат кешенең рухи яңарышын чагылдыруда күрә, аны бөтен совет сәнгате алдында тора торган гомуми идея-эстетик бурычлар белән бәйләнештә карый.

Алсу-зәңгәр нурлар уйнаган, кояшлы төсләргә манылган, нәфис бизәкле киндерләреннән дә өрфиядәй җиңел яктылык бөркелгән «Кичүдә», «Сепаратор янында» картиналары Урманчега хас иркенлек, тыелгысыз илһам белән, пумалага тулы ирек биреп язылган. Картиналарның сафлыгы һәм инандыргыч чынлыгы, алардагы төс күчешләренең гаҗәеп җиңеллеге, тылсымлы нәфислеге шулкадәр табигый, аларда яңача милли колорит тудыруга, яңа социалистик эчтәлеккә лаеклы композиция-ритмика, пластик һәм тирән мәгънәле сурәтләү чараларына омтылышлы, гаять катлаулы иҗади мәсьәләләр чишү эзләре сизелми дә диярлек.

Урманче татар фигуратив сәнгатенең юл башында тора. Гомумән, пумала яисә кискеч белән иҗат итәме ул — күп кенә әсәрләре ачыш дип кабул ителергә хаклы. Әзер рецептлар, формалар алыр җире булмаган рәссамның. Аннан, кемнедер кабатлау аның табигатенә дә туры килми. Сәнгатьтә бердәнбер намуслы юл дип ул эзләнү һәм новаторлык юлын гына таный. Яңалыкларны тормыш үзе әзерли, аларны бары искәрә, төсмерли белергә генә кирәк. Әмма моның өчен бииһая сизгерлек һәм зур рухи әзерлек булу таләп ителә шул.

Тормышны бөтен киңлегендә һәм тирәнлегендә аңларга омтылу Урманчены күпкырлы, киң колачлы рәссам итә. Халык тормышын яхшы белү, милли әдәбиятка һәм культурага, язма һәм авыз иҗаты аша буыннан-буынга күчеп килгән традицияләргә якын тору, белемгә һәм яңалыкка омтылу, үз-үзеңне аямыйча эшли белү һәм табигый сәләтен шомарткан әйбәт профессиональ мәктәп — Бакый Урманче иҗатының нигез ташлары менә шулар.

Аның сәнгать дөньясындагы беренче адымнары А. Шевченко, С. Герасимов һ. б. кебек сәнгать осталарының иҗади эзләнүләре белән бергә үрелә.

Беренче адымнарын ясаганда ук Б. Урманче традицияләрнең эстетик-әхлакый кыйммәтен аңлый һәм аларны профессиональ сәнгатьтә иҗади куллану мөмкинлеген эзли. Әйтик, ул ачыш итеп кабул иткән импрессионистик язу алымы белән халыкның бизәк төшерү формалары арасында охшашлыклар бар икән. Шулай булгач, әлеге алым халыкның авыз иҗатында, җырларында; бизәк-нәкыш формаларында чагылган хикмәтле үзгәрүчән төсмерләргә бай, бөтенлекле һәм шул ук вакытта гаҗәеп хәрәкәтчән милли уй сөрешен тапшыру өчен бик уңай булырга тиеш бит!.. Чыннан да, бу манера, татар декоратив-гамәли сәнгатенең кабатланмас колоритын һәм ритм үзенчәлекләрен тапшырып, милли характерны сурәтләүдә иң кулай, иң ятышлы форма буларак үзен аклый.

Урманче иҗатында эчке тоемлауга өстенлек бирелүе ачык сизелә. Монда, күрәсең, күңел дөньясы гаять нык үскән шәхес турында сүз алып барырга буладыр.

Урманченың иҗат алымына тормыштан күчермә ясап, гадиләштереп сурәтләү ят нәрсә. Тормышны ул эчке параметрлар аша, кешеләр аша күрсәтә. Революциягә кадәр, мәсәлән, татар көнкүрешендә хатын-кыз — табигатьнең иң гүзәл, иң нәфис заты — «җанлы курчак» хәленә төшерелгән, җәберләнгән, рухи тормыштан мәхрүм ителгән җан иясе була. Яңа дөнья таңында татар тормышында барган гаять зур үзгәрешләрне гәүдәләндерүгә Урманче шушы контрастлар аша килә.

... Әнә ул, күбәләктәй, җиңел, тыйнак, горур, үз дәрәҗәсен тоючы, инде яңа үзгәрешләр рухын татып өлгергән татар кызы безгә «Сөт аертканда» картинасыннан карап тора. Тирәсендәге көнкүреш әйберләрендә — халык талантының хисапсыз иҗат җимешләрендә — аның җаны яктырып тора сыман, киндернең күз явын алырлык матурлыгы да аның рухи күтәрелүенә ишарә булып аңлашыла.

«Кичүдә» картинасындагы хатын-кызның инде яңа тормыш иркенлегенә чыкканлыгы сизелә, аның йөзенә саф җил бәрелә.

Рәссамга хас дулкынлану, күрү сизгерлеге шунда да чагыла: ул мөрәҗәгать ит-

кән образлар хәрәкәттә, үсештә, ачылу мизгелен көткән хәлендә алынганнар. Чынбарлык җирлегендә торып ул, әйтерсең лә, киләчәкнең асылын аңлауга ирешкән һәм бу чагылган нур аның образларын яңача балкыткан, аларны хәрәкәтчән, җитез иткән, аларның бәхетле үзгәреш кичерү мөмкинлегенә ышаныч уяткан. Урманченың моннан берничә ел элек иҗат иткән образларына әнә шундый күп мәгънәлелек, тормыш талпынуы һәм кичерешләр байлыгы характерлы. Аларда мәңгелек хәят сулышы, тормыш ялкыны сизелә.

Урманченың соңгырак чор иҗаты башка яктан үзенчәлекле: ул художник күзаллавын тирәнәйтү, осталыкны арттыру һәм чынбарлык белән, андагы реаль процесслар белән күбрәк кушылу юлыннан бара.

Рәссамның музей залларында торган әсәрләрен карагач, аның иҗатында берникадәр тынычлану, үз дөньясында бикләнү өстенлек алган кебек тәэсир туарга мөмкин. Чыннан да, ул язган полотноларда, сынлы портретларда, рәсемнәрдә һәм акварельләрдә, кагыйдә буларак, динамикалы сызыклар, кискен каршылыклар, гармония бозылулар, тышкы экспрессия һәм «яктылык белән караңгылык көрәше» дигән нәрсәләрне күрмибез. Сәнгать мул сулы, салмак агышлы елга кебек, иң әйбәт, иң матур нәрсәләрне кочагына алып, очраклы, узгынчы нәрсәләрне юдырып ага да ага бирә. Тышкы салмаклык исә фани дөнья шау-шуыннан азат булу, социаль проблемалардан читләшкәнлек иллюзиясе тудырырга мөмкин. Ләкин бу алдавыч тәэсир генә. Тирәндә яткан эчке агымнарны, кайнап чыккан чишмәләрне күрми мөмкин түгел.

Урманче әсәрләре бөтен ил буйлап чәчелгән. Алар, истәлекле тамгалар кебек, кайда яңа тормыш төзелә, икмәк, чуен, кеше өчен көрәш бара, шунда бөтенләйгә калалар... Без аларны Урта Азия һәм Казагыстанның яңа шәһәрләрендә, Караганда шахтерларында һәм Балхаш металлургларында, Үзбәкстан мамык үстерүчеләрендә очратабыз. Ул иҗат иткән һәр нәрсәдә — портретмы ул, пейзажмы, керамика яки монументаль сынмы — тормышны яратучы зур останың кайнар кичерешләре гәүдәләнә. Чынбарлыкта героик, җиңүчән башлангычлар өстенлек алу белән, аның осталыгы арта, кыюлана, иҗат алымы камилләшә.

40 нчы — 50 нче елларда рәссам иҗатында яңа сыйфатлар чалымлана. Төп басым зәвык белән язылган мохиттан кешегә күчә. Мәсәлән, иҗатының башлангыч чорындагы типлар конкрет кешеләр түгел, хәзер исә геройлар — таныш йөзләр: артистлар, язучылар, композиторлар, галимнәр, ягъни шул образлар аша ачыла торган тормышның иҗади башлангычлары. Бу еллардагы композицияләр тотрыклырак, саллырак була бара. Яңалык сафлыгына, нәфислеккә, бер мизгелдән илһам алып язуга алмашка саллы, төпле, төгәл башкарылган тыгыз рәсем килә. Рәссам яшәгән Урта Азиянең бай сурәтләре, кызган күк гөмбәзе, мең яшәр культура һәйкәлләре аның иҗатына сизелерлек эз сала.

Портрет жанры өстенлек ала. Аны рәссам буларак кешедәге иҗат башлангычы, хәтергә уелырдай бай, динамикалы характерлар гүзәллеге характерлый. Казакъ җырчысы һәм биючесе Шара портреты 40 нчы — 50 нче елларда иҗат ителгән портретларның иң шәпләреннән санала, монда төс чишелеше буяулар контрасты (сары, күе зәңгәр), колоритның сызыклы композиция белән нисбәте аша хәл ителә. Язучы Сабит Моканов, композитор Брусиловский, җырчы Мөнирә Булатова портретларында характерлар төрлелеге, индивидуаль чалымнар аркылы «сәнгать тормышын» күрсәтергә омтылыш сизелә. Урманченың портрет язудагы осталыгы кирәкле детальләрне кабарынкы итеп бирә белүдә, игътибарны иң мөһим нәрсәгә юнәлтә алуда чагыла («Жамбулда кунакта», «Бану» һ. б.). Бу эшләрдә тормыш белән хозурлану тулылыгы, соклandыргыч самимилек, хаклыкны тою хисе, җиргә, кешегә мәхәббәт әсир итә. Бакый Урманченың бу еллардагы рәсем сәнгате тормыш сулышы, нечкә бизәклелек белән сугарыла. Элеккедән бары нур һәм төсләр җемелдәве, буяулар балкышы гына кала.

Шулай итеп, чор үзе, аның ихтыяҗлары Урманчега талантын бөтен тулылыгы белән ачарга мөмкинлек бирә, аны күп кырлы художник итеп формалаштыра. Эшчәнлегенең киңлеге һәм төрлелеге, үз чиратында, әсәрләренә дә уңай йогынты ясый, иҗат юнәлешләрен ачыклауда ярдәм итә.

Урманченың графикага мөрәҗәгать итүе үзеннән-үзе килеп чыга. Белем сандыгы һәм рухны баету чыганагы буларак китапка хөрмәт белән карау традицияләрендә

тәрбияләнгәнгә күрә, китап сәнгате өлкәсендә ул аеруча яратып һәм теләп эшли. 20 нче еллардагы графикасында («Шүрәле» поэмасына, журналларга иллюстрацияләрдә) рәссам татар китапларын бизәү осталары нигез салып калдырган традицияләрне дәвам итә. Карандашны кәгазьгә тидерер-тидермәс ясалган җиңел, нәфис рәсемнәр; каләмне карага манып кыю сызыклар белән, нык басып, төсләрне йөгертеп, яктылык күләгәләрен уйнатып язылган, сызыклары бер калынаеп, бер нәзегәеп киткән рәсемнәр (Габдулла Тукайның «Пар ат» шигыренә сокландыргыч иллюстрация әнә шул алым белән башкарылган)... — Урманче рәсемнәре шулай күп төрле. Китапны күчереп язучы һәм бизәүче останың кул җылысын саклаучы, китап белән бер тарихны кичергән, бер җан, бер тән хасил итүче рәсем — аның иң яраткан жанры. Тукай шигърияте мотивларына язылган соңгы еллардагы акварельләрендә без инде төсләр купшылыгын очратмыйбыз, ул палитрасындагы кабатланмас төсләрне кара тушь белән чиратлаштырып, әйтерсең лә китап культурасына тагын да якыная төшә.

Әкренләп Урманче энциклопедик белемле кеше булып җитлегә. Бу процесста педагоглык һәм җәмәгать эшчәнлеге дә, ил гизеп йөрү, илебездә яшәүче төрле халыклар тормышы һәм культурасы белән танышу да, күп уку, фәнни белемнәр туплау да гаять зур роль уйный. Болар аның иҗатында яңача яңгыраш таба. Рухи культурасының байлыгы, зәвыгының нечкәлеге, фәнни дәлилләренең тирәнлеге һәм эрудициясе кеше күңеленә тирән үтеп керүне, европача аналитизмны, психологизмны Көнчыгыш сәнгатенең илаһилыгы белән кушарга мөмкинлек бирә. Бу эштә татар әдәбияты зур роль уйный. Аның йогынтысы Урманче иҗатының тематикасын киңәйтүдә генә түгел (Тукай поэзиясе генә дә рәссамга бер кочак тема һәм образлар бирә). Скульптор Урманче татар язучылары, шагыйрьләре һәм фикер ияләре образларын затлы Урал мәрмәрендә мәңгеләштерә. Сүз сәнгате, «сүз белән бизәк төшерү» алымы аның иҗат поэтикасына үтеп кереп, әсәрләрен күпкырлырак, образлырак, үзенчәлеклерәк итә.

50 нче еллар азагына Урманченың рухи тәҗрибәсе һәм профессиональ осталыгы шундый дәрәҗәгә ирешә,— ул инде пластикага, кешене сыннарда гәүдәләндерүгә мөрәҗәгать итә башлый.

Урманче иҗатының шушы чорында Казанга кайта. Туган туфрак аның иҗатына яңа көч бирә. Конкрет кешеләрнең, күбесенчә сәнгать әһелләренең портретларын иҗат итеп, ул тулы камиллеккә ирешә.

Урманче скульптуралары Казанда 50 нче елларда күренде һәм шунда ук сынлы сәнгатьнең бу жанрында көтелмәгән алга китеш буларак бәяләнде. Бу сокландыргыч күренешне халык күңелендә гасырлар дәвамында оеткы хәлендә яткан иҗади көчләрнең бер талант йөрәгеннән ургылып чыгуы дип кенә аңлатырга була. Ул үз сәнгатендә татар халкының, Урта Азиянең культура мирасында, рус һәм Көнбатыш классик сәнгать традицияләрендә булган асылташларны бер хаситәгә тезә. (Чагыштыру рәвешендә, даһи сынчы Эрьзя иҗаты хакында да шуны ук әйтергә була).

Кешене өзлексез, армый-талмый өйрәнүләре нәтиҗәсендә Урманче скульптурага мөрәҗәгать итә. Һәм ул бу жанрда әйтерсең лә яңадан туа, психолог талантын — кешене таный, аның хасиятен төшенә белү сәләтен сыннарда гәүдәләндерүгә ирешә. Моның да үз логикасы бар. Ул сәнгатькә китаптан килгән кеше. Шуңа күрә башлангыч адымнар бик хаклы рәвештә графика, китап бизәү өлкәсендә ясала. Тормышны һәр тарафтан күрә белү, күргәнен буяулар ярдәмендә төкми-чәчми сурәтләргә омтылу башта рәсем сәнгатенә алып килә. Рәссам алдында кеше яшәп торган мохитны сурәтләү бурычы килеп баса. Аннары кеше үзе өстенлек ала башлый. Урманче иҗатында портрет жанры тантана итүе дә шуннан. Аннан килеп, кеше белән, аның нечкә табигате белән кызыксыну, аны тагын да тирәнрәк аңларга, күбрәк күрергә омтылу Урманчены скульптура юлына этәрә. Хәзер инде иң мөһиме — кешенең йөз үзгәрешләре, пластикасы.

Урманченың 50 нче — 60 нчы еллардагы күп кенә пластик образлары һәркайсы ачыш дип бәяләнә ала. Бу чорда татар профессиональ скульптура сәнгате тәүге адымнарын атлый. Дөрес, аның нигезе 30 нчы елларда ук салына. Беренче татар сынчысы, монументаль һәм скульптура әсәрләре авторы Садри Ахун ул заман пластика тарихында сизелерлек эз калдыра.

Хәзерге татар скульптурасында яңа проблематика, яңа стиль урнашу Урманче

иселе белән бәйле. Аның сурәтле фикерләү көчлеге, талантын үзе теләгән якка юнәлтә белүе татар халкының тарихи язмышына һәм рухи дөньясына тирән үтеп керү рәвешендә ачылды. Татар әдәбияты, сәнгате әһелләре һәм галимнәр портретларында ул халыкның рухи көчләре баш калкыту, үсү процессының өзлексез дәвам итү идеясен үткәрә. Һәм аларның һәркайсы — халыкның мәдәни үсеш юлындагы мөһим маяк.

Шигъри көче, рухи ныклыгы белән язмыш фаҗигасен җиңгән хәр күңелле, баш имәс Җәлил безнең алда халыктагы патриотик хисләрнең югары чагылышы буларак гәүдәләнә. Антик скульптура үрнәкләре белән аваздашлык художник тудырган образның җуелмас кыйммәтен раслый. С. Ахун язган портретта герой шагыйрь документаль, публицистик рухта сурәтләнсә, Урманчеда инде ул — илаһи һәм шигъри образ, эчке омтылышлы һәм хәрәкәткә омтылучы Җәлил.

Эчке асылы белән сынландыру чараларының табигый бөтенлеге Г. Ибраһимов образына ышандыргыч дөреслек бирә. Нигезнең кытыршы формалары йөз шомалыгындагы төсмерләр өчен отышлы фон булган. Сын образның хисси байлыгын ачуга булышучы сәнгать әсәре буларак кабул ителә.

Үз дөньясына бикләнгән, уйчан Мәрҗани гаҗәп иркен, колачлы итеп, эпик киңлектә аңлатыла. Һәм янәшәдә үк — поэтик биеклекләргә омтылган, фани дөньядан ваз кичкән Дәрдмәнд. Ә шулай да Урманче талантының иң югары очышы — Тукай сыны. Шагыйрь образы борынгы Римдагы скульптура портреты традицияләрендәгечә, охшашлыкны төгәл саклап сурәтләнә, аның эчке дөньясының бөтен тирәнлеге тыенкы гына сурәтләү чаралары ярдәмендә чагылдырыла. Тукайның халыкка кадерле чалымнары уелган ак мәрмәр аның күңел серләрен, газапларын һәм өзелгән өметләрен саклый сыман. Портретның композициясе дә үзенчәлекле: шагыйрь халкы өчен сызланып, аның язмышы хакындагы уйлар авырлыгыннан сыгылып төшкәндәй сурәтләнгән, әмма без шагыйрь йөзендә халыкның якты язмышына ышану нурын да күрәбез.

Кол Гали, Насыйри, Әмирхан, Бабич портретлары... Төрле заманнарда яшәгән бу шәхесләрнең образларын художник гаделлек өчен көрәш, хакыйкать эзләү идеясе җирлегендә берләштерә алган.

Бөек скульптор Роден узган гасырда «Кале шәһәре гражданнары» дигән композициясен иҗат итә. Анда холыклары, байлык дәрәҗәләре, зәвыклары үзгә булган, әмма Ватан хакына үз-үзенне корбан итү кебек уртак идея белән бәйләнгән кешеләр тезмәсен күрәбез. Бу скульптура ничек бербөтен булса, Урманченың гражданлык, патриотизм хисләре белән сугарылган пластик образлары да Ватанга мәхәббәт, халыкка хезмәт итү идеясен гәүдәләндергән бердәм композиция буларак кабул ителә.

Урманче скульптуралары зур рухи көчкә ия. Аның кайбер әсәрләрен караганда ирексездән Леонардоның: «Рәсем сәнгате турында трактат»ындагы: «Әгәр синңа тән тезелеше гаҗәеп сәнгать әсәре булып тоелса, шул хакта уйлан: бу тәндә яшәгән җан белән чагыштырганда ул бер ни дә түгел»,— дигән сүзләре хәтергә килә. Урманченың төрле материалда — Урал мәрмәрендә, груша, чинар, зирек агачында иҗат итүе дә образларның мөкаммәллеге тәэсирен арттыра төшә.

Кешелек бәхете өчен көрәш идеаллары белән рухланган художник, ниһаять, В. И. Ленин образын гәүдәләндерә. Аның хезмәте әле дә бу бетмәс-төкәнмәс бай образны ачуда, аңларга тырышуда кыйммәтле тәҗрибә булып кала бирә. Юлбашчы портретын иҗат итү — яшәвенең бөтен мәгънәсе кешеләр бәхете һәм тормышны үзгәртеп кору өчен көрәш булган шәхеснең рухи дөньясын эчке сиземләү юлы булды. Зур монументаль яңгыраш алган бу эшендә Урманче монументалист буларак ачылды. Ленинның ак мәрмәрдә уелган йөзендә гаять зур рухи активлык һәм илһамлану чагыла, юлбашчы рухи дөньясының иң катлаулы, үтә нечкә төсмерләре ачыла. Урманченың соңрак яшь Ульянов образына мөрәҗәгать итүе очраклы түгел, ул Ленин шәхесенең тылсымлы йогынтысын туктаусыз тоеп тора. Ленин образында эчке хасият белән пластик гәүдәләндерү алымнарының табигый бөтенлеге иң югары ноктага җитә. Скульптураның күркәле, ашкынулы иркен формасы әйтерсең модельнең эчке кичерешләреннән үк туа. «В. И. Ульянов сөргендә» композициясендә гәүдә сызыклары, кием ритмнары, яшь егетнең иркен хәрәкәтләре аның чыраендагы самимилек, сафлык белән бик оста үрелә. Болар бар да яшь революционерның уй-хыяллары бөеклеген тоярга ярдәм итә.

Урманче — образлы, тасвирлы детальләр остасы. Яшь Ульянов иңенә салган студент курткасы канатлар булып та кабул ителә ала, ул символ көченә ия.

Соңгы елларда Урманче мөһим һәм кыйммәтле күренешләрне чагылдыручы әсәрләр иҗат итәргә, синтезга омтылды, бер әсәр эчендә үк гомуми, глобаль, универсаль мәсьәләләрне чишәргә тырышты. Гомумиләштерүләр юлы аны фәлсәфи-метафорик образлар иҗат итүгә алып килде. Мәсәлән, кеше кичерешләренең тирәнлеге, гомер елгасының тиз агышлы булуы һәм гел яңарып торуы, һич тә саекмавы турындагы уйланулар җимеше булып безнең алга «Сагыш» дип аталган скульптурадагы Картның дулкынландыргыч драматик образы калка. Төгәлләнгән образ тудыру өчен ул агачның сырлы, уентыклы урыннарыннан бик оста файдалана. Композициянең нигезе киңәеп җир катламына кереп китә, шушы символ аша кешенең туган туфрагы белән гомерлек бәйләнешы раслана.

Мәңге гүзәл, гел үзгәреп торучан, берничек тә юкка чыкмый торган, үзен бары яңадан-яңа рәвешләрдә раслый торган хәят турындагы уйлануларын Урманче безгә курай тоткан ялангач кыз рәвешендә иҗат ителгән «Яз көйләре»нең сихри музыкасы аша җиткерә. Скульптура агач кәүсәсеннән эшләнгән. Ул шундый бер хыялый күңел очышы, самими яшьлек сафлыгы белән тулы ки, әйтерсең лә, аны язгы җилнең бер йомшак, сак кагылышы тудырган. Үзенең салмак «агышы», мөлаем-йомшак борылышлары белән скульптура курай моңын хәтерләтә.

Шулай да останың соңгы еллардагы иң гүзәл иҗат җимеше «Сөембикә» бугай. Гомумән, Урманче кайчан да булса җан өргән образларның иң шигъри, иң илһамлыларыннан ул. Бу — халкыбызның хатын-кыз матурлыгы турындагы хыялының сынга әверелүе. Сөембикәнең түбән караган күзләрендә оялчанлык, сафлык, гыйффәтлелек һәм мәңгелек тылсым-наз, ә кыз үзе — әйтелмәгән сер... Бу әллә хатын-кыз, әллә агачның җаны, әллә мәңгелек Табигать үзе.

Агач бөтенләй эшкәртелмәгән диярлек. Кай урыннарда гына оста кулы калдырган поэтик чигешләр күзгә ташлана. Агач кәүсәсеннән сирпелгән серле нур җиһанның, кеше матурлыгының акыл ирешмәслек табышмагы булып хәтердә кала.

Ул елларда Урманченың тагын да үсә барган осталыгы күп төрле юнәлешләрдә ачыла. Бизәү скульптурасы өлкәсендәге эзләнүләре кызыклы гына. 20 нче елларда ук ул Казан художество училищесында керамика остаханәсе булдыра, анда халык традицияләренә таянып, чүлмәктән скульптуралар һәм бизәкле савыт-саба ясау белән шөгыльләнә. Эче куыш агачлардан ясалган һәм Тукайның «Шүрәле»се темасына композицияләр белән бизәлгән 70 нче еллар вазаларын әнә шул иҗат сызыгын дәвам итү дип санарга була. Әмма хәзер материал бөтен (агач) булу эшкәртү техникасының да, форманың да үзгәрүенә китерә. Вазаларның тыштан уеп бизәлгән үтә күренмәле рельефы һәм дулкынлы фоны «Шүрәле»не дә бүтәнчә күз алдына китерә.

Тукай мотивлары оста күңелен еллар буена биләп, илһамландырып тора. Урманче шагыйрьнең төрле шигырьләренә, поэмаларына, әкиятләренә дистәләрчә иллюстрация ясый. «Шүрәле»гә төрле композицион вариантлардагы акварельләр сериясенең язылу тарихы гаять кызыклы. Егерме ел буена ике процесс бергә бара: рәссам, бердән, акварель техникасын камилләштерсә, аны йомшаграк, табигыйрәк, йөзмәрәк итә барса, шул ук вакытта артык тәфсилле тасвирлаудан качарга, җыйнаклыкка, кыскалыкка ирешергә омтыла.

Кытай карасы белән язылып, кайбер җирдә генә төс өстәлгән бу җиңел, үтә күренмәле акварельләр, әйтерсең лә тере. Һәрбер сызыгында — мәгънә тулы. Ак җирлек ара-тирә кызгылт-сары, шәмәхә һәм яшел төсләр белән балкып китә — бусы да композициянең актив өлеше. Урманче үзенең образларын киңлектә күрергә өйрәнгән. Шуңа күрә кәгазь бите көзгесеннән әкияти карурман, көмеш ай урагы балкыган күк, Былтыр, Шүрәле һәм башка «урман халкы» карап торган төсле...

Тукайның әлеге поэмасына ясалган иллюстрацияләрнең исәбе-хисабы юк. «Шагыйрәнә ялган» Шүрәле образын рәссамнар төрлечә күз алдына китерәләр. Кайбер иллюстрацияләрдә Шүрәле явыз зат итеп тасвирланса, икенче берләрендә табигатьнең хыял ярдәмендә генә җанландырыла торган бер кисәге итеп күрсәтелә. Урманче бу образны табигать белән дә, кеше белән дә бәйләп, әлеге дисгармонияне бетерә.

Кешегә охшамаган урман пәрие аныңча җанлы табигатьнең бер өлеше. Ул кешенең үз-үзе белән эчке көрәше башлангычын, табигать белән бердәмлек идеясен гәүдәләндерә. Аны аңлаcalled, кеше үзен дә аңлый. Урманченың Шүрәле турындагы әсәрләрендәге бөтен шигърият әнә шуңа буйсындырылган.

70 нче еллар — совет сәнгатендә зур гомумиләштерүләр һәм аллегорияләр чоры. Дөньяның катлаулылыгы һәм каршылыклары, аны танып-белүнең читенлекләре сынландыру чараларының синтезына, сәнгать төрләренең бер-берсенең казанышлары исәбенә байый баруына китерә. Графика һәм рәсем сәнгатенең үзара йогынтысы күзәтелә: рәсем сәнгате графикага хас шартлылык, күп мәгънәлелек исәбенә катлаулылана, ә графика төсләр байлыгы, штрих һәм сызык төсмерләре арту исәбенә символик эчтәлекне бирү мөмкинлеге ала. Бу мөһим үзгәрешләр совет сынлы сәнгатенең гомумиләштерү көче артуына китерә. Синтезга омтылу, төрле вакытта, төрле җирдә булган вакыйгаларны бер композициядә тасвирлау Урманче иҗатында да чагылыш тапты.

Дүрт полотнолы «Истә калганнар» циклы үзенчәлекле аллегорияләрдән, гыйбрәтле хикәяләр, үткән һәм бүгенге көн турында уйлануллардан гыйбарәт. Художник тормышка яңадан яшь күзләр белән карый кебек. Төрле заманнарга хас күзаллаулар бер мәгънә төенена — тормыш тәгәрмәченең мәңгелек хәрәкәтен раслауга кайтып кала. Чабылмаган болыннар, милли кием кигән, көянтә-чиләк аскан яшь хатыннар — болар хәзерге көнне шигъриятләштереп күрсәтү дә, балачак хатирәләре дә булырга мөмкин. Түргә үк алып кереп китә һәм яңадан алгы планга кайтара торган бормалы-сыгылмалы пластика үк үткәннең һәм бүгенгенең бердәмлеге турында сөйли кебек... Урманченың «Истә калганнар»ы — Татарстан рәсем сәнгатендәге беренче аллегорик әсәрләрдән. Яшьләр — И. Зарипов, А. Абзгельдин һәм башкалар белән бергә ул республикабыз сәнгате тарихында яңа сәхифәне ача. Бу хәл аның иҗатын гаҗәеп яшь, заманча итә.

Бу полотноларда күктә йөзгән ак болытлар, яшел иңкүлекләр, бәйрәмчә киенгән хатын-кызлар акрынайтылган кадрдагыча күренә сыман. Рәссам тамашачының карашын һәрбер детальдә, сында, сызыкта туктата, тормышның һәрбер мизгеле тиңсез кадерле булуын һәм аны күреп, тоеп һәм хәтерләп калырга кирәклеген кисәтә.

«Истә калганнар» циклы техник алымнарга бай. Көнчыгыш китап миниатюрасының йогынтысы да беркадәр сизелә. Төс, колорит — бар да бергә тупланган. Композициянең бөтенлеге дә, киеренкелеге дә әнә шунда инде. Хәрәкәтнең, вакыт агышының салмакланган булуы авторның уйлану халәтен чагылдыра. Бу — үзенә күрә поэтик йомгак, нәтиҗә. Үткән белән саубуллашу һәм киләчәккә үрелеп карау. Аларда рәссамның бөтен иҗатын сугарып торган төп сыйфат — оптимизм яңа төсмерләре белән чагыла.

Урманче иҗаты икеләнүләр, уңышсызлыклар, материал каршылыгы, тормыш кыенлыклары белән көрәштән башка гына барган дип әйтү дөрес булмас. Әмма ул, сәнгатькә һәм тормышка мәхәббәте көчле булганга бөтен киртәләрне дә җиңеп үтте. Ул гомере буе өйрәнде, инде җитлеккән оста килеш тә, армый-талмый яңалыкка омтылды. Зирәк һәм саекмас талант иясенең бөтен гомере, бөтен иҗаты — сәнгатькә һәм халыкка хезмәт итүнең матур үрнәге.

Даһи япон рәссамы Хокусайның (XVIII гасыр) түбәндәге сүзләре аның иҗади омтылышларына да туры килә сыман: «Җитмеш яшькә кадәр кылган эшләремне хисапка алып тормаска да була,— ди ул.— 73 яшемдә генә мин табигатьнең чын асылын якынча аңлый башладым. Сиксән яшькә җиткәндә, тагын да зуррак уңышка ирешәчәкмен. Туксанда җисемнәрнең серен аңлаячакмын. Йөзгә җиткәндә могҗизага әверелермен, ә йөз дә ун яшь тулгач, минем һәр сызыгым, һәр ноктам — барысы да мөкәммәл булачак».

**ДИНӘ ВӘЛИЕВА,**
сәнгать фәннәре кандидаты.
**РОЗАЛИНА ШАҺИЕВА,**
сәнгать белгече.

## МАНСУР МОЗАФФАРОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

# УЛ ТОРМЫШКА ГАШЫЙК ИДЕ

Композитор Мансур Мозаффаров иҗаты профессиональ музыкабыз тарихында иң якты сәхифәләрнең берсе булып тора. Аның дөньяга карашы 1905—1907 еллардагы революцион азатлык хәрәкәте тәэсирендә формалаша башлый. Үз чорының күренекле шагыйрәсе Маһруй Мозаффария улы буларак, Мансур кече яшьтән үк татар әдәбияты һәм сәнгатенең күренекле вәкилләре даирәсенә керә. Бөек Октябрь революциясе казанышларын исә аңа хәтта кулына винтовка алып якларга туры килә. Революция тәмам җиңгәннән соң ул үзенең бөтен гомерен иҗади эзләнүләргә, Татарстанның яшь музыкантларын тәрбияләүгә багышлый.

Мансур Мозаффаров үз иҗатын татар музыка сәнгатенең партиячел һәм халыкчан, интернациональ һәм демократик, тормышчан һәм кешелеклелек рухында үсүенә булышлык итүгә юнәлтте. Моның өчен ул рус классик сәнгате үрнәкләрен өйрәнү кирәклеген тирәннән аңлый иде.

Композитор гаять катлаулы, җитди һәм әһәмиятле темаларны күтәрә. Ул татар халкының үткәндәге авыр тормышы турында да («Галиябану», «Зөлхәбирә» опералары), социалистик революция дулкыннары күтәргән вакыйгалар турында да («Мулланур Вахитов истәлегенә» исемле симфоник поэма), бүгенге матур тормыш турында да (күпсанлы җырлар һәм кантаталар) уйлана, нәтиҗәле иҗат итә. Аның әсәрләрендә тарихи мәсьәләләр дә, көнкүрешнең гади генә күренешләре дә сурәтләнә. Музыканың яңгырашы исә куелган бурычка карата үзгәреп тора: ифрат тантаналы яки йомшак, җитди яки бик нәзакәтле, кырыс яки шаян. Әмма, яңгырашы нинди генә булуга карамастан, Мозаффаров иҗат иткән әсәр һәрчак тирән мәгънәле, уйландыручан һәм зур максатлы булып калды.

М. Мозаффаровның бай мирасы жанрларның күплеге ягыннан да аерылып тора. Автор күп кенә жанрларга безнең композиторлар арасында беренче башлап мөрәҗәгать итә.

Аның симфоник поэмалар өлкәсендәге хезмәтләре аеруча игътибарны тарта. Культурабыз тарихында якты йолдыз булып балкучы шагыйрь Габдулла Тукай образына мөрәҗәгать итеп, аны музыкаль образда тасвирлап, композитор зур уңышка ирешә. Алга куелган максатының ачыклыгы авторга дөрес интонацион образ тудырырга мөмкинлек биргән. «Мулланур Вахитов истәлегенә» дип исемләнгән икенче симфоник поэмасында да М. Мозаффаров халыкның киң катламнары өчен яхшы таныш булган, дулкынландыргыч тарихи вакыйгаларны төп материал итеп ала. Шушындый зур күләмле һәм киң масштаблы әсәрләрендә ул үзен профессиональ яктан оста, милли хисләрне тирәннән аңлаучан талант иясе итеп танытты. Бу күркәм сыйфат, ягъни милли яңгыраш белән дөнья музыкасындагы прогрессив алымнарның табигый үрелеше композитор иҗатында әсәрдән-әсәргә көчәя килде. Мансур Мозаффаров — татар музыкасында лирик-драматик рухта язылган программ-симфоник поэмаларның беренче үрнәген биргән композитор.

Ул милли симфонияләрне дә беренче башлап язды. Дөрес, бу өлкәдә М. Мозаффаров әллә ни мавыгып эшләмәде, әмма аның бу юлга беренче эз салуы симфония жанрында А. Ключарев, А. Вәлиуллин, А. Монасыйпов кебек композиторларга җиң сызганып эшләргә ярдәм итте, маяк ролен уйнады.

Мозаффаровның скрипка өчен язган әсәрләре дә татар музыкасында яңалык иде. Аның бу жанрда биргән үрнәк әсәрләре тыңлаучыны әсир итәрлек моңы, тирән әһәмиятлелеге ягыннан хәйран калдыра.

Мансур Мозаффаровның җырларын, романсларын тыңлап кем генә сокланмаган?! Әле 30 елларда ук ул, А. С. Пушкинның «Җырлама син, иркәм, минем алда» исемле шигыренә (Ә. Ерикәй тәрҗемәсе) уңышлы романс язып, Рөстәм Яхин иҗатына ышанычлы җирлек әзерләде, дип әйтергә мөмкин. Мозаффаров иҗатында җыр белән романс сыйфатларының синтетик берләшүен һәм шуның нәтиҗәсендә уйландыргыч җырлар тууын күзәтергә була. Гражданлык лирикасы бөркелеп торган «Менәргә иде Урал тауларына» (Г. Зәйнашева сүзләре) җырын гына алыйк. Мондагы милли моң яңгырашы һәм тирән фәлсәфи фикер шулкадәр табигый бәйләнгән ки, музыкадагы бу бердәмлекне бары тик авторның зур талант иясе булуы белән генә аңлата аласың.

Мансур Мозаффаров опера жанрында эшләгәндә тыңлаучыларга яхшы таныш һәм алар тарафыннан яратып кабул ителә торган халыкчан сюжетларны сайлый. Эчтәлекне ачуда ул иң популяр халык җырларына таяна. Композиторның беренче операсыннан саналган «Галиябану» моңа ачык мисал була ала. «Зөлхәбирә» исемле икенче операсын язганда исә Мозаффаров фольклордан турыдан-туры файдаланмый, халык җырларының аерым бизәкләрен генә «чүпли» һәм оригиналь музыка иҗат итә. Операның сюжеты өчен дә беренче очрактагы кебек халык җыры эчтәлеге түгел, ә күпләргә яхшы таныш булган бәет сайлап алына. Опера белән халык бәетенең музыкаль-поэтик бәйләнешен булдыру Мозаффаров иҗатының ифрат кызыклы бер үзенчәлеген тәшкил итә. Гомумән, Мансур Мозаффаровның опера өлкәсендәге эшчәнлеге татар операсының үз сыйфатын, үзенә генә хас якларын тудырырга ярдәм итте. Ә сәнгатебездә көнкүрешне сурәтләүчән лирик операның барлыкка килүе исә турыдан-туры М. Мозаффаров исеменә бәйле.

Профессиональ осталыкка, идея-эстетик яктан өлгергәнлеккә ирешүдә композиторга туган халкының фольклорын җентекләп өйрәнү нык ярдәм иткән. Аның иҗатына һәрчак халык җырлары тәэсирен тоеп тору, әсәрләренә милли аһәңне иңдерергә омтылу хас. Бу олы иҗатның юл башында ук халык музыкасына гашыйклык, аны аңларга, өйрәнергә һәм сакларга омтылыш сизелә. М. Мозаффаров тарафыннан эшкәртелгән йөзләрчә җырлар композиторның халык җырларына никадәр соклангалыгына, аннан күпме өйрәнгәнлегенә дәлил була ала. Халык җырларын эшкәртүгә ул зур әһәмият бирә һәм иҗатның бу тармагына да мөстәкыйль хезмәт итеп карый иде. Аның бу өлкәдәге эзләнүләре матур нәтиҗәләр бирде. Татар халык җырларын җыю, эшкәртү аның үз стилен халыкчан, демократик, аңлаешлы итте.

М. Мозаффаровның профессиональ музыкабыз үсешендәге ролен тәгәлрәк күрсәтү өчен, мөгаен, аның белән бергә иҗат иткән башка композиторлар иҗатын да күздән кичерергә кирәктер. Бу җәһәттән иң алда аның якын дусты һәм хезмәттәше Салих Сәйдәшев тора. Композиторлар Нәҗип Җиһанов, Фәрит Яруллин, Заһит Хәбибуллин, Җәүдәт Фәйзи белән бергә Мансур Мозаффаров Татарстан музыка сәнгатен үстерүдә армый-талмый иҗат итә.

Композиторларыбызның яңа буыны да М. Мозаффаров үрнәгеннән киң файдалана. Әсәрләрендәге музыкаль фикернең талгынлыгы, көй үсешендәге табигыйлек, лирик образның гаҗәеп якты булуы күп композиторларны сокландыра. Бүген уңышлы иҗат итүче А. Монасыйпов, Р. Еникеев лирикасының беренче этәргече Мозаффаров тудырган лирик образлар икәнен чамалау һич тә кыен түгел. Әлбәттә, яшь авторлар бу башлангычны яңача үстерәләр, яңа төсмерләргә баеталар һәм үз стильләрен барлыкка китерәләр. Җыр жанрында индивидуаль башлангычның көчәеп китүендә дә, һичшиксез, Мансур Мозаффаров иҗатының роле зур. Р. Еникеев, А. Монасыйпов, И. Якубов, Р. Яхин әсәрләре бу фикерне ышандырырлык дәлилли. Халык җырларын сәнгатьчә эшкәртүдә М. Яруллин, Р. Белялов игътибарны җәлеп итә. Р. Белялов, мәсәлән, М. Мозаффаров кебек үк, халык көйләреннән иҗади файдаланып, күп кенә инструменталь әсәрләр дә язды. Ф. Әхмәтовның һәм А. Монасыйповның Ф. Яруллинга, М. Җәлилгә багышланган симфоник поэмаларын тыңлаганда да, ихтыярсыздан, хәтергә М. Мозаффаровның хезмәтләре килә. Р. Еникеевның Х. Ямашев истәлегенә багышлап язган сонатасы исә Мозаффаровның лирик-

драматик симфонизмын искә төшерә. Ә аның опера жанрындагы эшчәнлеге композиторларыбыз Х. Вәлиуллин, Р. Гобәйдуллин, Б. Мөлеков иҗатларында дәвам итә.

Кыскасы, музыкабызда композитор Мансур Мозаффаров башлап җибәргән һәм якты үрнәк итеп калдырган традицияләр тулылана, үсә, ныгый бара.

**КЛАРА ТАҖИЕВА,**
музыка белгече.

**Түбәндә Татарстан әдәбияты һәм сәнгате эшлеклеләренең композитор Мансур Мозаффаров турындагы истәлекләреннән өзекләр тәкъдим ителә.**

Мин әтиемне белмим. Ата назы, ата тәрбиясе ничек була торгандыр — миңа мәгълүм түгел. Әмма Казаннан еракта гастрольләрдә йөргәндә Мансур ага Мозаффаровның вафат булу хәбәрен ишеткәч, күңелдә туган ятимлек хисе, җанны тетрәткеч югалту тойгысы — болар барысы да атаны югалту да шулайрак була торгандыр инде, дигән уйлар тудырды. Ни өчен шулай соң? Моның, әлбәттә, сәбәпләре бар.

Тел ачылганда ук Мансур аганың җырлары белән ачылу, балалык һәм үсмер елларда аның җырларын җырлап үсү, музыка училищесына Мозаффаров җырын җырлап керү, консерваториядә инде ул үзе укытучы һәм иптәш, иҗатташ һәм сердәш булу, аннан соңгы елларда да бергәләп киңәшеп эшләү һәм, ниһаять, аның җырларын бар булган гомереңә юлдаш итеп алу — күрәсең, бу шәхеснең күңелгә никадәр якын һәм мокатдәс булуына сәбәпләр аз түгел...

1954 елның ахырына таба училищеда кышкы зачетлар, имтиханнар башланды. Имтихан комиссиясенең председателе М. Мозаффаров иде. Ул сирәк чәчле, уйчан моңсу йөзле, уртачадан тәбәнәгрәк тулы гәүдәле, салмак хәрәкәтле кеше иде, бераз аксабрак йөри. Бер күрүдә үк кеше турында ниндидер фикер туа бит. М. Мозаффаров хакында иң беренче туган тәэсир шул булды: бу кеше бер вакытта да берәүгә дә яманлык кыла алмый торгандыр. Шуннан соң байтак еллар танышлык чорында моның шулай икәненә һәр көн, һәр адымда ышана барырга туры килде...

М. Мозаффаров җырларны искиткеч тиз яза иде. Аннан соң иҗат кешесенә гаять кирәкле булган гүзәл сыйфатка ия иде ул: дусларының киңәшенә бик игътибарлы, колак салучан, башкаручының теләген искә алырга һәрвакыт әзер. Бу уңайдан Ә. Ерикәй сүзләренә «Хәерле иртә» җырының язылуын искә төшереп үтәсе килә. Бер көнне Мансур ага консерватория коридорында мине туктатып, яңа җыр язып алып килгәнлеген әйтте. Гадәтенчә, кесәсеннән бөгәрләнгән нота кәгазен чыгарып, шунда, коридорда ук әкрен генә җырлап та бирде. Бу вакытта инде Мансур ага белән шактый кыю сөйләшә башлаган идем. Күземне дә йоммыйча фикеремне әйтеп салдым. Беренчедән, бу текстка вальс характерындагы көй ишетәсе килә. Икенчедән, көйнең беренче фразасы белән дәвамы арасында бәйләнеш юк кебек, әнә шул беренче фраза логик рәвештә үссен иде. Мансур абый берсүзсез кәгазьне кире йомарлап тыкты да: «Ярый, иртәгә яңадан язып алып килермен»,— дип китеп барды. Икенче көнне, чыннан да, җырның яңа вариантын алып килде. Бу юлы инде көйнең кушымтасы вальс характерында иде. Тагын утырып киңәштек, тагын төзәтмәләр кирәк дип таптык, нота кәгазе тагын бөкләнеп кесәгә салынды. Кыскасы җыр тәмам әзер булганчы әнә шулай өр-яңадан язулар, үзгәртүләр күп мәртәбә кабатланды. Соңгы вариантын тыңлаганда язучы Риза ага Ишморат та бар иде. Ул гаҗәпләнеп, кулларын җәеп болай диде: «Бәрәкалла, мондый көйләр дә язып була мени? Мин инде бөтен көйләре дә язылып беткәндер, башка язып булмыйдыр дип уйлаган идем». Әйе, әйбәт көй туды. Темасы ягыннан кирәкле, музыкаль яктан бик оригиналь һәм матур җыр иҗат ителде.

**ИЛҺАМ ШАКИРОВ,**
РСФСРның атказанган артисты.

Мансур Мозаффаровны мин бик кечкенә бала вакытыннан ук белә идем. Мансурның атасы Хуҗәхмәт мулла һәм анасы Маһруй апаны минем әти бик яхшы белгән булса кирәк. Маһруй апа әле шул чорда ук хәр фикерле, алдынгы карашлы кеше булган. Бик иртә хәреф тануым аркасында 5—6 яшьтән үк әтием мине әнә шул апага укытырга илтеп тапшырган. Әле дә хәтеремдә: мәктәп Маһруй апаның үз йортында иде. Дәрестән соң әти килеп алганчы мин мәктәп бүлмәсендә утырып тора идем. Ул вакытта Мансур шул минем яшьтәрәк бик шаян малай иде. Дәресләр беткәнне белсә ул минем янга килеп керә иде. Артык шуклыгы белән кайчак мине рәнҗетә, хәтта елата иде. Бу хәлне ишетеп Маһруй апа керер иде һәм мине үз бүлмәсенә алып чыгып прәннек, конфетлар белән сыйлый иде. Шул вакытлардан алып алар гаиләсен шактый якыннан белеп калдым...

Мансурның беренче әсәрләрен — «Җиләк җыйганда», «Яшь егетләр, яшь кызлар» һәм ул эшкәрткән татар халык көйләрен җырларга туры килде. Мозаффаровның әсәрләрен мин һәрвакыт бик яратып башкара идем. Аның иҗатында ниндидер үзенчәлек, яңалык бар. Ул башкалардан аерылып тора торган интонацияләр таба белә. Бер сүз белән әйткәндә, мин М. Мозаффаровны музыка сәнгатендә үзенә генә хас иҗади тел, аерым бер яңа аһәң тапкан, шуның белән безнең татар музыка сәнгатен бизәгән композитор дип саныйм....

Мозаффаров татар көйләрен һәм җырларын Мәскәүдә граммофон тәлинкәләренә язу эшен оештырды. Бик катлаулы һәм зур эш булса да, композитор аны бик матур башкарып чыкты. Ул вакытта бик күп татар көйләре һәм җырчылары пластинка аша бөтен илгә танылып өлгерде. Язма өчен җырчыларны һәм көйләрне сайлаганда һәм язмага хәзерлек вакытында Мозаффаров зур җаваплылык күрсәтте, күп хезмәт куйды. Әлеге язмалар тарихка бер хәзинә булып калдылар.

**МӘРЬЯМ РАХМАНКУЛОВА,**
РСФСРның халык артисткасы.

Бергәләп иҗат иткән соңгы җырларыбызның берсе «Мин тормышка гашыйк» булды. Мансур абый, чынлап та, тормышка гашыйк кеше иде. Гомеренең соңгы елларында аның сәламәтлеге шактый какшады. Хәл алып, ныгып китү теләге белән ул көн саен диярлек Идел буйлап саф һава сулап кайта. Без ул елларда Иделдән ерак тормый идек, юл уңае туры килгәндә Мансур абый безгә дә керә. Бер көнне шагыйрь Мостафа Ногман белән икәү килеп керделәр. Кояшта янган, ничектер күңеле бик күтәренке... Чәй янында күңелле генә сөйләшеп утырдык, шунда Мансур абый, Идел буйларының матурлыгы, тормышның, яшәүнең, гомернең кадерле булуы турында җыр язасы иде, дип куйды. Мин аның бу сүзләрен күңелемә беркетеп, уйланып йөри башладым. Һәм, ниһаять, мондый юллар табылды:

**Озак яшәрмен дип тибә йөрәк,**
**Ашкына күңелем һәр эшкә...**

«Бу фикер миңа ошый, язып бетер, тиз язып бетер, шушындый язгы матур көннәрдә музыка язасы килә, кулда сүзләре булса, тиз генә эшләр идем»,— диде Мансур абый. Мин берничә көннән сүзләрне язып бетереп Мансур абыйга китердем. Ул шул көнне үк кич белән миңа шалтыратты: «Җырны яздым, ничек булгандыр, иртәгә килеп тыңла»,— диде.

Икенче көнне йөгерә-йөгерә Мансур абыйларга киттем. Пианино янында утыра, тирә-ягы ноталар, китаплар белән тулган. Үзе уйнап, әлеге яңа җырны җырлап күрсәтте. Дөресен әйтим, «Мин тормышка гашыйк» дигән бу җырыбыз миңа башта бер дә ошамады. Музыкасы ничектер ярлы кебек, моңы юк кебек тоелды. Мансур абыйның зәгыйфь кенә тавышы белән җырлап күрсәтүе дә матур тәэсир калдырмады бугай. Ошамады дип әйтеп булмый, шундый олы, хөрмәтле кеше язган музыкага каршы сүз әйтергә кыймадым. Рәхмәт әйтеп кайтып киттем. Бераз вакыттан соң ул җырны җырчы Х. Гыйниятова башкаруында радио аша ишеттем һәм гаҗәпкә калдым: шундый матур, бай музыка, шундый тирән мәгънәле музыка агыла! Миңа

оят булып китте. Ничек ул музыканы ошатмыйча кайтып киттем икән дип үз-үземне тиргим. Илһам Шакировка бу турыда сөйләгән идем, ул: «Мансур абыйның бер дә тавышы юк шул, җырлый алмый. Шул җырлый алмаган килеш җырлап күрсәтә дә үз әсәрләрен аңлата алмый»,— диде.

**ГӨЛШАТ ЗӘЙНАШЕВА.**

Мансур абый дигәч, уйлар бик еракка алып китә. Ул бик яхшы кеше иде. Шул кадәрле йомшак, киң күңелле, һәркемгә рәхимле кулын сузып, һәркемгә ярдәм итә торган кеше иде ул.

Композитор буларак Мансур абый берәүне дә кабатламый: мелодик яктан да, гармониясе белән дә.

Соңгы елларны аның белән бергә бер йортта торырга туры килде. Ял итәргә чыкканда ул: «Нәрсә эшлисең, Заһид, ничегрәк бара эшең?» — дип хәлгә керә, кайгырта иде. Мансур абый һәрвакыт үзенең яхшы киңәше белән иҗатыма ярдәм итте.

**ЗАҺИД ХӘБИБУЛЛИН,**
композитор, ТАССРның халык артисты.

Мансур Мозаффаров музыка сәнгатен изге, сихри, бер көч итеп таный иде. Моны мин үз күзәтүләремнән чыгып әйтәм. «Галиябану» операсының режиссеры буларак, миңа композиторны шактый якыннан белергә, аның ничек иҗат итүен өйрәнергә туры килде.

Операны сәхнәләштерү чорында Мансур Мозаффаров, мәктәп укучыларыныкыдай беркатлылык белән, театр сәнгатен, аның кануннарын аңларга, аның серләренә төшенергә тырышып йөрде. Театрны аз белүен бездән һич яшерми иде ул.

«Галиябану»га әзерлек барган көннәрдә спектакльгә кагылышлы һәр нәрсәгә ул бик игътибарлы булды. Репетицияләр вакытында мин аның я сабый балаларча сөенүен, я юк кына уңышсызлыкка да тирәннән борчылуын, я җитди киңәшләр бирүен ишетеп гаҗәпләнә идем. Операда аны, әлбәттә, героиня образы барыннан да ныграк кызыксындырды. Саф образ иде ул, шагыйранә образ, күкләргә ашардай романтик канатлы образ! Мин тоеп тордым: Галиябану образы композиторны гомеренең соңгы көннәренә кадәр дәртләндереп, рухландырып торды. Ул үзенең бу операсына кат-кат кайтты, аның берничә вариантын эшләде.

Мансур Мозаффаров зур күләмле икенче әсәрен дә татар кызының революциягә кадәр кичергән аянычлы язмышына багышлады. Бөек Ватан сугышы башлангач та, ул Әхмәт Фәйзи либреттосы буенча «Зөлхәбирә» операсын язарга тотынды. Либретто турында фикер алышканда, аның әле өлгереп җитмәгәнлеген, аңа багышлап зур күләмле музыкаль әсәр язарга әле иртәрәк икәнен әйттеләр. Шул чагында Мансур Мозаффаровның ни дәрәҗәдә кайгырып йөргәнен күрсәгез иде! Бу борчылуны аңларга бик мөмкин: чөнки композиторны либреттода сурәтләнгән кызның картада оттырылган булуы тирәннән дулкынландырып өлгергән иде инде. «Зөлхәбирә» композиторның «Галиябану» операсын язганда ачыла башлаган фикерләрен йомгаклау өчен дә бик кирәк булгандыр, ихтимал...

**ШИРИЯЗДАН САРЫМСАКОВ,**
РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе.

Соңга калып таныштык, гомеренең ахырында гына, бары ике генә җыр иҗат итеп калдык. Шул ике җыр өчен дә аңа чиксез рәхмәт, шул ике җыр белән дә үземне бәхетле саныйм. Шагыйрьнең гомер буе күңелендә йөрткән үзенә бик кадерле хисләре була, алар туып үскән җирең-туфрагың белән бәйле хисләр. Күңелне алар һәрвакыт җирсетеп тора, бигрәк тә туган якта, бигрәк тә июнь печәннәре

җиткән вакытларда ул хисләр җирси, болын чәчәкләре өстеннән йөгергән дулкыннар әз генә кагылу белән күңел ташый... Сине туктаусыз газаплаган, интектергән хисләр. Аларга шул кырлар кирәк, шул болыннар кирәк. Алар бары тик кешесе туры килмәгәнгә күрә генә җыр-көй булып яңгырамый торалар, кешесен эзлиләр... Мәңгелек җир, мәңгелек дулкыннар, мәңгелек сагыш. Минем шундый җырларның берсе — «Башка берни дә кирәкми». Ул хисләргә юлны Мансур ага Мозаффаров ачты.

Ансат кына тумады ул җыр. Җырның үз сукмаклары, үз борылмалары бар. Гади борылмалар түгел, тормышның, тарихның кискен чатын искә төшергән драматик борылмалар. Җырдагы хисләрнең зурлыгын шуның белән генә аңлатып буладыр. Халык күңеленнән китми торган, төшми торган җырларны халыкның «Кара урман»нары, тарихы, язмышы, җире-туфрагы тудыра торгандыр, җыр — зур хисләрнең җимеше. Борылмалар....

**Туып-үскән шушы җирнең ямен**
**Алыштырмый икән һичнәрсәң.**
**Башка берни дә кирәкми,**
**Үзем чапкан печәннәрне**
**Бер туйганчы иснәсәм...**

Шул бер юл: «Башка берни дә кирәкми»... Хисләрнең агышын, юк, әйтерсең узып барган гомереңнең агышын кинәт туктата. Туктата, уйланырга мәҗбүр итә. Җырның бөтен сихерле көче дә шул бер юлда. Мансур абыйның көе дә хисләрнең тәмам төйнәлеп җиткән шул төшендә, кадерле, газаплы, татлы хисләрнең нәкъ шул төшендә кискен борылыш ясый, аннан тагын туган җир болыннары буйлап салмак кына агыла башлый...

Икенче җыр — «Кайда да йөрәктә». Кырлай, Тукай. Бу җырны да Мансур ага белән бергә язуыма шатланам. Ул бала чакта Тукайны күрү бәхетенә ирешкән, мин Тукайның якташы һәм кулга каләм алган көннән башлап аның турында җыр тудырырга хыялланган кеше.

Шулай туры килә бит. Мин Мансур Мозаффаров белән очраштым. Куанып бетә алмыйм. Мансур ага бала чакта, ун-унбер яшьлек вакытта Тукай белән очрашуына бөтен гомере буена куанып яшәгәндер. Очрашкан, һичшиксез, рухланып яшәгән. Андый бәхет сирәк эләгә. Мин дә шат, Тукайга лаек икенче бер кешенең туры килүенә шат.

Ун-унбер яшьлек Мансур «Болгар»да яшәгән Тукайга газеталар китерә, бөек шагыйрьнең: «Малай, мин бүген фәрештәләр белән сөйләштем»,— дигән тылсымлы сүзләре әйтерсең, Мансурның кайчан да булса бер сәнгатькә хезмәт итәсен белеп әйтеләләр. Иҗатта, сәнгатьтә изгелек кирәк, җанда, күңел түрендә шул саф, керсез изге хис ятарга тиеш.

**Ятса күңелдә чымырдап,**
**Оеп изгелек,**
**Табыла үзеннән-үзе**
**Кирәк сүз элек...**

Кем белә, бәлки ул «Туган тел» яки «Тәфтиләү», «Зиләйлүк»нең дөньяга килгән чагы булгандыр? Минем өчен ул гаҗәп кызык очрашу. Тормышта була бит шундый изге минутлар! Туры килә бит шулай. Мансур Мозаффаровның тора торган йорты нәкъ Тукай һәйкәле каршында, аның белән ул сөйләшеп яши, киңәшеп яши. Язганнарын башта Тукайдан тыңлата, аның фатихасын ала, аннан — халыкка. Тукай белән башланып, Тукай белән очланган олы гомер, зур иҗат.

**СИБГАТ ХӘКИМ,**
РСФСРның М. Горький, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты.

# ИЛ БАТЫРЫ

*Генерал-лейтенант Якуб Чанышевка — 90 яшь*

Алдан сөйләшкәнчә, Мәскәүгә килеп төшү белән башкалабыз үзәгенә, «Россия» кунак йортыннан ерак булмаган Серов урамына юл тоттым. Мин Якуб ага Чанышевка Казанда чыккан берничә китап кертеп чыгарга тиеш идем. Ул һәрвакыттагы кебек туры, каһарман гәүдәле, горур кыяфәтле һәм ачык йөзле.

Аның Татарстан китап нәшрияты бастырган «Казанда 1917 ел» (Казан, 1968), «Үткән походларны искә алып» (Казан, 1973) дигән китаплары күпләргә таныш. Алар турында искә төшереп, өстәлендәге кульъязмасы турында сорагач, ул берникадәр уйланып: «Хәзер мин, туган, Бөек Ватан сугышы турындагы хезмәтемне тәмамладым. Менә ул,— дип миңа ике йөз биттән артык кульъязмасын сузды,— «Кызыл байраклы укчы Брест корпусының хәрби юлы». Генерал бу легендар корпусны үзе төзегән, аның командиры булып, дәһшәтле юллар аша Берлинга кадәр барып җиткән.

— Менә бу хезмәтемне нәшриятка тапшыргач, хәрби тормышым, бөек Ленин партиясендә тәрбияләнүем турында яшьләр өчен зур мемуар язасым килә әле тагы...

Якуб ага Чанышевның язарлык хатирәләре дөнья кадәр. Аңа 90 яшь! Әйтергә генә җиңел. Ул 65 ел буена бөек Ленин партиясенең алгы сафында, үз гомерен хәрби эшкә багышлаган, солдат хезмәтеннән генерал дәрәҗәсенә кадәр күтәрелгән. Яшьтән ятим калып, тормышның әчесен-төчесен татыган авыл малае, элекке батрак...

1892 елның февраль аенда элекке Уфа губернасындагы Стәрлетамак өязенең Тукай авылында туган Якубка яшьтән үк Габов, Сладков, Рәҗәпов, Алкин кебек алпавытлар утарларында бил бөгәргә туры килгән. Тормыш бигрәк тә атасы дөнья куйгач авырая. Олы абыйлары эре сәүдәгәр Яушевларга яллангач, хәлләр тагын да начарая. Якубны сеңелесе белән Уфадагы ятимнәр йортына озаталар. Әнисе кечкенә энеләре белән авылда кала. Гаилә өчкә бүленеп, әни тәрбиясеннән мәхрүм кала, ятимлек башлана.

Якубның укуга сәләте игътибарсыз калмый. Аны татар укытучылар мәктәбенә мөгаллим булып кайту шарты белән өяз хисабына Казанга укырга җибәрәләр. Биредә ул Г. Тукай, М. Гафури, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимовлар белән таныша, аралашып яши.

— Әдәбият, сәнгатьне сөюем шуннан калды,— ди Якуб ага.— Минем иллегә якын дәфтәремдә язучылар, композиторлар, рәссамнарның әсәрләре турындагы фикерләрем язып куелган. Хәрби кеше үзендә кешелек хисләрен уяу саклыйсы килсә, әдәбият, сәнгать, музыкадан аерылырга тиеш түгел.

Аның сүзендә безнең Совет кораллы көчләребезнең йөзе, Совет солдатының эчке дөньясы турында гади, тик шул ук вакытта философик мәгънә ята.

Үз гомерен укытучылыкка багышларга, татар крестьян балаларына аң-белем бирергә теләгән Якубны тормыш дулкыннары бөтен юнәлешкә алып китә. 1913 елда аңа солдат шинеле кияртәләр. Ул Варшавада артиллериягә өйрәнү командасын тәмамлап, фейерверкер дигән кече командир чины ала. Аннан өч ел буена беренче Бөтендөнья империалистик сугышында катнаша, батырлыгы өчен Георгий кресты белән бүләкләнә.

1917 ел башында унтер офицер Чанышевны Казан юнкерлар училищесына укырга юллыйлар.

Элек Казанда укыганда һәм фронтта ул Маркс, Ленин турында ишетә, аларның кайбер әсәрләре белән таныша. Сугыш кырында В. И. Ленинның «Империалистик сугышны гражданнар сугышына әверелдерергә!» дигән лозунгысы белән танышып, аны хуп күрә, большевиклар белән аралаша. Юнкерлар училищесында революцион карашлы Казан университеты студентлары, фронттан кайткан кешеләр белән якыная, фәкать Ленин җитәкчелегендәге большевиклар партиясе генә чын халык бәхете өчен көрәшүче икән дигән нәтиҗәгә килә. Шуның өчен дә 1917 елның 15 мартында Я. Җ. Чанышев икеләнмичә большевиклар партиясе сафына баса, Февраль буржуаз-демократик революциясеннән соң Казан большевикларының 26 мартта университетта уздырылган беренче оештыру җыелышында катнаша. РСДРП(б)ның Казан комитеты һәм Мулланур Вахитов җитәкчегендәге Мөселман социалистлар комитеты кушуы буенча ул Камил Якуп, Һади Маликов белән татар солдатлары, эшчеләре арасында зур агитация-пропаганда эше җәелдерә, митингларда, җыелышларда чыгыш ясый, татар милләтчеләрен, Вакытлы хөкүмәтне, меньшевикларны һәм уң эсерларны фаш итә.

Казанда, иң зур хәрби округ үзәкләренең берсе буларак, зур гаскәр тупланган. Шуның өчен большевиклар солдатларны Советлар ягына тартуга аеруча зур игътибар итәләр. 1917 елның сентябрендә Үзәк Комитет кушуы буенча Казан партия комитеты каршында большевикларның хәрби оешмасы төзелә. Оешма җитәкчеләре итеп Н. Ершов, Н. Ежов, К. Грасис, Я. Чанышев, П. Шумилов, Л. Милх сайлана. Татар солдатлары большевикларны яклап чыга, Хәрби шура яклы Мөселман хәрби комитетын яңадан сайлауны таләп итә. Гарнизон мөселман хәрби комитет председателе итеп ефрейтор Әбдрәшитов, урынбасары — Чанышев һәм членнары итеп Биккинин, Сәйфельмөлеков, Шмаков һ. б. сайлана. Якуб Чанышев солдатларны һәм эшчеләрне Вакытлы хөкүмәткә каршы коралы восстаниегә хәзерләүдә иң актив катнашучыларның берсе була. Ул восстание белән җитәкчелек итү өчен Революцион штаб составына кертелә. Восстание башлангач, аның җитәкчелегендәге отряд юнкерларны Казанка елгасы яныннан Кремльгә чигенергә мәҗбүр итә. Восстание җитәкчеләренең берсе Н. Ежов: «Прапорщик Чанышев Якуб һәм башкалар җитәкчелегендәге милли роталар гаять кыю хәрәкәт иттеләр»,— дип язды.

— Владимир Ильич восстаниегә сәнгатькә караган кебек карарга өйрәткән иде. Казанда Совет власте Петроград белән бер көндә урнашты,— дип искә ала ул көннәрне Якуб ага.

Коралы восстание революциянең иң югары ноктасы булса, җиңгәннән соң властьны кулда тоту аның төп максаты. 26 октябрьда тантаналы рәвештә Казанда Совет власте игълан ителә. Революцион тәртип урнаштыру һәм революцияне саклау өчен беренче пролетар диктатура органы — Революцион комитет төзелә. Аңа татар милләте вәкилләре дә, аерым алганда, Мулланур Вахитов, Камил Якуп, Якуб Чанышев, Вәли Шәфигуллин сайлануын басым ясап әйтергә кирәк.

В. И. Ленинның һәр революция үзен-үзе саклый белгәндә генә берәр төрле әһәмияткә ия була, дигән күрсәтмәләреннән чыгып, Казан большевиклары хәрби округка, аның эшенә аеруча зур игътибар иттеләр. Округтагы миллионга якын солдатның кем ягында булуы революциянең язмышына турыдан-туры бәйле. Кичекмәстән Солдат советы депутатларының II округ съезды чакыртыла, аңа 98 гарнизоннан 200 гә якын вәкил җыела. Делегатлар арасында легендар В. И. Чапаев та була. Съезд Казан хәрби округы белән идарә итү, Совет властеның коралы көчләрен оештыру, округта революцион тәртип урнаштыру өчен биш кешедән торган Комиссарлар Советы сайлый. Советка Якуб ага Чанышев та сайлана. Аңа татар хәрби частьлары төзү, хәрби училищеларны яптыру, фронттан кайткан офицерларны Совет хәрби частьларында файдалану мөмкинлекләрен карау кебек җаваплы вазифа йөкләтелә, ул татар буржуазиясенең контрреволюцион үзәге булган Хәрби шура һәм «Болак арты республикасы»н тар-мар итүдә дә катнаша.

Гражданнар сугышы елларында Я. Чанышевның хәрби сәләте тагын да ачылып китә. Атаман Дутовны һәм ак чехословакларны җиңгәннән соң бөтен көч адмирал Колчакны тар-мар итүгә юнәлдерелә. Казан һәм Идел буе шәһәрләрендә Беренче Идел буе татар укчы бригадасы төзелә. Шунда Я. Чанышев батарея командиры итеп билгеләнә, соңыннан бригада комиссары була.

Бригада Оренбург, казакъ далалары аркылы Фирганә, Бохара, Тянь-Шань тауларына кадәр барып житә. Урта Азиядә басмачыларны тар-мар итүдә, урыннарда Совет власте урнаштыруда бригаданың роле аеруча зур. Төркестан фронты командующие М. В. Фрунзе басмачыларга каршы батырларча көрәшкән һәм Бохара әмирен тар-мар итүдә катнашкан татар кызылармеецларына күп тапкырлар рәхмәт белдерә.

Якуб Чанышев бригада комиссары буларак та, үзенең шәхси батырлыгы белән дә кызылармеецлар һәм җирле халык арасында зур абруй казана. Басмачыларның иң явыз җитәкчеләреннән берсе булган Хол-Хуҗаның өненә курыкмыйча үзе юнәлә һәм аның белән сөйләшүләр алып бара, ленинчыл милли, эчке һәм тышкы политиканың фәкать эшче һәм ярлы крестьяннар яклы икәнлеген бәйнә-бәйнә аңлата, советларның декретлары белән таныштыра. Нәтиҗәдә басмачыларның бу отряды Советлар ягына күчә.

Якуб ага Андижанның почетлы гражданины. 1926 елда Андижан хезмәт ияләре Я. Чанышевны Бакуда III Коммунистик Интернационалның II конгрессы инициативасы белән чакырылган Көнчыгыш халыклары съездына делегат итеп җибәрәләр. Бирегә ул инглиз интервентлары һәм эсерлар тарафыннан ерткычларча үтерелгән 26 Баку комиссарын күмүдә катнаша. Комиссарлар арасында безнең якташыбыз, Лаеш егете, элеккеге Крестовниковлар заводы (хәзерге Вахитов исемендәге химкомбинат) эшчесе И. Я. Габишев та була.

— Без комиссарлар белән бик тирән кайгы кичереп саубуллаштык,— ди Я. Чанышев.— Ләкин төшенкелеккә бирелмәдек. Аларның изге эшен дәвам итәргә ант иттек. Әле дә күз алдымда: зур мәйдан халык белән шыгрым тулы. Без инглиз һәм башка империалистларга революцион нәфрәт белән Черчелль, Чемберлиннарның карачкыларын да җиргә күмдек.

1921 ел — Якуб ага өчен иң истәлекле елларның берсе. Төркестан коммунистлары аны партиянең X съездына делегат итеп сайлап, зур хөрмәт һәм ышаныч белдерәләр. Ул бөек юлбашчыны тагын күрәчәк, аны тыңлаячак! Ә беренче мәртәбә В. И. Ленинны 1919 елның 19 январенда Мәскәүдә Карл Либкнехт һәм Роза Люксембургның ерткычларча үтерелүенә багышланган кайгылы митингта күргән һәм ялкынлы речен тыңлаган иде.

Ерак, ләкин күңел өчен якын булган Мәскәүгә юл тотканда Якуб агага һәм аның юлдашларына тормыш ничектер икенчерәк төстә күренеп алды. Йомшак купе, тыныч, борчу юк кебек... Әйтерсең лә поход тормышы, басмачылар белән үлем сугышы, ат өстендә үткән йокысыз, арыткыч төнге походлар бөтенләй булмаган, юк...

Ниһаять, Мәскәү. X съезд. Делегатлар, шулар арасында Я. Җ. Чанышев та Ильичны зур дикъкать белән тыңлый, аны тулысынча яклый.

— Бер үкенечем бар,— ди Якуб ага X съезд турында сүз барганда.— Буйлы-буйлы халатлардагы безнең делегацияне күргәч, Владимир Ильич янәбызга килде дә ничек урнашуыбызны, хәлләребезне сорашты. Шунда мин бер фотографны күреп алдым да Ленинга делегациябез белән рәсемгә төшәргә тәкъдим иттем. Ул берсүзсез риза булган иде. Менә шул фотокарточка миндә юк. Эзләтеп тә карадым, бер кайда да табылмады. Өметемне өзмим, берәр архивта, я кемдә дә булса сакланадыр әле.

Гражданнар сугышында күрсәткән шәхси батырлыгы һәм ленинчыл милли политиканы тормышка ашыруда күрсәткән хезмәтләре өчен Якуб ага Чанышев Хәрби Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. Ул шулай ук Төркестан республикасының Кызыл Байрак орденына да лаек була.

Урта Азияне контрреволюция көчләреннән, басмачылардан азат итүдә бригада комиссары Я. Җ. Чанышев, шулай ук Ю. Ибраһимов, Х. Мәүлетов, Б. Белоусов, Г. Касыймов, А. Маматказин, Н. Енекеев, Ш. Усманов һәм башкалар җитәкчелегендәге Беренче Идел буе татар укчы бригадасы данлыклы юл үтте, искиткеч батырлыклар күрсәтте. Кызганычка каршы, бу бригада турында әле күпләр, шул исәптән Урта Азиядә дә белеп җиткермиләр. Бригада турында нәфис фильм булдырырга иде дигән фикерне Якуб ага бик хуп күрде. Бригада членнарының күпләре Совет һәм Төркестан хөкүмәтенең югары орденнары белән бүләкләнгән. Шулар арасында апалы-сеңелле Мәрьям һәм Гайшә Саиновалар да бар. Алар — хатын-кызлар ара-

сында беренчеләрдән булып Хәрби Кызыл Байрак орденына лаек булган шәфкать туташлары. Якуб аганың тормыш иптәше Мәрьям ханым гражданнар сугышында алган югары бүләкне изге истәлек итеп саклый. Генерал белән бергә тормышның ачысын-төчесен татыган чын-чынлап шәфкатьле Мәрьям ханым — татар халкының мактауга лаеклы горур кызы ул.

Туплар шартлавы тынып, тыныч тормышка күчкәч, Я. Чанышев Мәскәүдәге Хәрби академиягә укырга җибәрелә. Аны уңышлы тәмамлаганнан соң ул хәрби берләшмәләр белән командалык итә. 1925—1932 елларда укчы дивизиянең командиры һәм комиссары булып хезмәт итә. Атаклы композитор Салих Сәйдәшев бу дивизия өчен махсус марш яза, ул хәзер «Совет Армиясе маршы» дип йөртелә.

Якуб ага Чанышев ул елларда СССР һәм ТАССР башкарма комитетлары, Татарстан өлкә комитеты бюросы члены буларак, республика тормышында актив катнаша, яшьләргә патриотик тәрбия бирүгә, Кызыл Армия сафларын идея һәм политик яктан ныгытуга зур игътибар бирә. Ул Татарстан делегациясе белән партиянең XIV һәм XVI съездларында катнаша.

Бөек Ватан сугышын Я. Чанышев Фрунзе исемендәге академия курслары начальнигы буларак каршы ала, беренче туплар шартлаганда курсантлар белән чик буенда Гродно шәһәре янында хәрби өйрәнүләрдә була, чигенү авырлыкларын татый. Аннары Мәскәү өчен барган сугышларда, Харьков операциясендә катнаша. Сталинградтагы көчле бәрелешләрдә дивизия командиры Я. Чанышев каты яралана, сәламәтләнгәннән соң 68 нче армия командующие Толбухинның урынбасары итеп билгеләнә, төньяк-көнбатыш фронтны ныгытуда үзенең хәрби талантын, белемен киң куллана. Дошманның Демянск группировкасын юк итүдә, Новгород, Великие Луки, Ст. Русса операцияләрендә катнаша.

1943 елда Я. Чанышевка корпус төзү бурычы тапшырыла. Икенче Белоруссия фронты составында корпус данлы юл үтә, бигрәк тә Брестны дошманнан азат итүдә дан казана. Герой Брест крепосте барлык кешеләргә билгеле, аны саклауда күрсәткән батырлыгы өчен татар егете Михаил Гаврилов исеме тарих битләренә алтын хәрефләр белән язылды. Якуб Чанышев Брестны дошманнан азат итү операциясен искиткеч осталык белән башкарып чыкты. Мәскәү бу җиңүне котлап салют бирде, корпус Брест дигән данлыклы исем ала. Ә корпусның командиры Беренче дәрәҗә Кутузов орденына лаек була.

Генерал Чанышев корпусы Польшаны азат итүдә (ул Польшаның өч ордены белән бүләкләнгән), Одер елгасын кичеп, беренчеләрдән плацдарм алуда, Берлин операциясендә катнаша. Данлыклы корпус Эльбаны кичә һәм Шверензееда АКШ һәм Англия гаскәрләре белән очраша. Америка хөкүмәте легендар генералны АКШның иң югары ордены белән бүләкли.

Сугыштан соң Якуб ага ун елдан артык Хәрби академиядә курслар начальнигы булып эшли һәм алмашка хәрби кадрлар хәзерли.

Ул хәзер яшь солдатлар, үсмерләр арасында чыгышлар ясый, аларны патриотизм рухында тәрбияләүдә зур эш башкара.

**МАРАТ МӨЛЕКОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

## Клара Булатова

### Хәзерге Дон-Жуанның яңа кыйссасы

Күрештек тә ошатыштык,
Анда кемнең ни эше?
Миңа бары утыз өч яшь,
Унбиш яшькә ул кече.

Аулак бүлмә, өстәлендә
Тулы бәллүр чәркәсе.
Кызый үзе эшләми дә,
Шәп урында эткәсе.

Ашаганы татлы ризык,
Кигәннәре импортный,
Шундый гүзәл яр янында
Кем хатынын онытмый?

Кочкан чакта эштә-нидә
Ватылмаган гәүдәсен,
Әйтергә соң «хатын бар», дип,
Ничек телең әйләнсен.

Аңа әйбәт, миңа җәннәт,
Юкка башны йөдәтмим,
Хатын, бала барын-югын
Ул сорамый, мин әйтмим.

Ул яратты — мин аныкы,
Мин сөйдем — ул минеке,
Нигә безгә никах-мазар?
Безнең сөю ирекле.

Оҗмах кичтек, шәраб эчтек,
Миләр, каннар кайнады.
Үбешү дә, кочышу да,
Башкасы да калмады.

Шуннан димсең? Алты айдан
Нәтиҗәнең кәттәсе:
Алиментка судка биргән
Урындагы эткәсе.

Башларыңа бу хәл килгәч,
Тулы йөзең сулыгыр...
Әле өйдә хатын белгәч,
Бала белгәч ни булыр?!

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ИЛ БЕЛӘН БЕРГӘ

ТАССР Художниклар союзының күргәзмә залында КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе Л. И. Брежневка 75 яшь тулуга багышланган республика күргәзмәсе ачылды. Әлеге экспозиция ТАССР Культура министрлыгы, ТАССР Художниклар союзы һәм ТАССР Сынлы сәнгать музее тарафыннан оештырылды.

Юбилей күргәзмәсендә Татарстанның танылган сынлы сәнгать осталары — СССРның халык художнигы Х. Якупов, РСФСРның халык художнигы Л. Фәттахов, РСФСРның атказанган художниклары Б. Урманче, В. Куделькин, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Н. Кузнецов, ТАССРның халык художниклары Ә. Тумашев, С. Лывин, М. Хәйретдинов һ. б. әсәрләре урын алган.

«Л. И. Брежнев чирәм җирдә», «Л. И. Брежнев портреты», «Тынычлык Маршалы»... Юбилей күргәзмәсе Р. Имашев, И. Әхмәдиев һәм В. Куделькин тарафыннан иҗат ителгән әнә шундый әсәрләр белән ачыла.

## ИҖАТ ИНТЕЛЛИГЕНЦИЯСЕ УКУЫ

Казанда иҗат интеллигенциясенең КПСС өлкә комитеты каршында эшли торган семинарының чираттагы занятиесе уздырылды. Язучылар, художниклар, композиторлар, театр һәм кино эшлеклеләре, уку йортлары, культура учреждениеләре житәкчеләре алдында КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Р. М. Мусин чыгыш ясады. Ул КПСС Үзәк Комитетының ноябрь (1981 ел) Пленумы карарлары яктылыгында республика үсешенең социаль-экономик проблемаларына, партиябезнең XXVI съезды карарларын тормышка ашыруда иҗат интеллигенциясе алдында торган бурычларга тукталды. КПСС Үзәк Комитетының Халыкара бүлек секторы мөдире Н. В. Мостовец хәзерге чорда Совет—Америка мөнәсәбәтләре турында лекция укыды.

## АКМУЛЛАНЫҢ 150 ЕЛЛЫГЫ

Күренекле мәгърифәтче һәм шагыйрь Мифтахетдин Акмулла тарихка халык уйларын һәм теләкләрен чагылдыручы булып кереп калды. Узган елның 14 декабрендә башкалабыз Мәскәүдә, Союзлар йортының Колонналы залында үткәрелгән тантаналы кичә аның тууына 150 ел тулуга багышланды. Анда әдәбиятчылар, җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты.

Кичәне ачканда РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе С. В. Михалков Акмулла поэзиясенең күпмилләтле әдәбиятыбыз тарихына күркәм сәхифә булып керүен билгеләп үтте. Кичәдә тугандаш республикалар җәмәгатьчелеге вәкилләре совет халкының рухи культурасының аерылгысыз өлешенә әйләнгән татар, казакъ һәм башкорт шагыйре иҗатының зур әһәмияте турында сөйләделәр. Тантанада Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов та чыгыш ясады.

## СИБГАТ ХӘКИМНЕҢ ЮБИЛЕЙ КИЧӘСЕ

Күренекле шагыйрь, РСФСРның М. Горький, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Сибгат Хәкимгә 70 яшь тулу уңае белән, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында юбилей кичәсе булды. Кичәне кереш сүз белән ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. А. Ахунов ачты.

Совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм 70 яшь тулу уңаеннан шагыйрь, СССР Верховный Советы Президиумы Указы нигезендә, Октябрь Революциясе ордены белән бүләкләнгән иде. Татарстан өлкә комитеты, ТАССР Верховный Советы Президиумы, ТАССР Министрлар Советы исеменнән ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Г. Батыев Сибгат Хәкимне кайнар котлады һәм аңа Октябрь Революциясе ордены тапшырды.

С. Хәкимнең иҗаты турында филология фәннәре кандидаты, Татарстан Язучылар союзының партия оешмасы секретаре Р. С. Мөхәммәдиев сөйләде.

Юбилярны республикабызның хезмәт коллективлары, партия, совет һәм профсоюз оешмалары, культура учреждениеләре вәкилләре, Мәскәүдән һәм Башкортстаннан килгән кунаклар котлады, күп санлы телеграммалар укылды.

Кичәдә КПСС өлкә комитеты секретарьлары М. Ф. Вәлиев, Ф. А. Садыйков, ТАССР Министрлар Советы председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов катнаштылар.

Соңыннан Татарстан сәнгать осталары катнашында зур концерт булды.

* * *

Чаллы шәһәренең «Энергетик» культура сараенда шагыйрь Сибгат Хәкимнең юбилеена багышланган әдәби кичә үткәрелде. Кичәдә шагыйрь үзе дә катнашты. Аның

тормышы һәм иҗаты турында тәнкыйтьче Р. Мөхәммәдиев сөйләде. Шагыйрьләр Р. Гатауллин, Р. Миңнуллин, язучыларның Чаллы оешмасы секретаре Р. Вәлиев, Түбән Камадан язучы Р. Хисмәтуллин шигъриятебезнең аксакалын олы юбилее белән ихлас котладылар, зур иҗат уңышлары теләделәр. Шагыйрьне шәһәр җәмәгатьчелеге исеменнән партия, совет һәм профсоюз оешмалары вәкилләре котлады.

Кичәдә Түбән Кама үзешчәннәре концерты күрсәтелде. Халык талантлары шагыйрь сүзләренә язылган көйләрне башкардылар, шигырьләр яңгырады.

Соңыннан Сибгат Хәким әдәбият сөючеләрнең сорауларына җаваплар бирде, үзенең иҗаты белән таныштырды, шигырьләрен укыды.

Шушындый ук әдәби кичәләр Алабуга педагогия институтында, Түбән Кама шәһәренең Техниклар йортында, шәһәрнең профессиональ-техник училищеларында да уздырылды.

* *
*

Сибгат Хәкимнең туган җирендә — Арча районының Күлле Киме авылында да юбилей тантаналары булып узды. Анда шагыйрь үзе, язучы М. Мәһдиев, тәнкыйтьче Р. Мөхәммәдиев, шагыйрьләр И. Юзеев, Р. Гатауллин, Р. Миңнуллин, Л. Шакирҗанова, җырчылар Вафирә Гыйззәтуллина һәм Шамил Әхмәтҗанов катнашты. Башта кунаклар шагыйрь укыган мәктәптә чыгыш ясадылар, Сибгат Хәкимнең тормыш юлына һәм иҗатына багышланган музей-бүлмә белән таныштылар. Кич белән авыл клубына шагыйрьне котларга авылдашлары җыелды. Кичәдә «Сибгат Хәким межасы» дигән документаль фильм күрсәтелде, шагыйрь иҗаты турында каләмдәшләре сөйләде, соңыннан авыл үзешчәннәре концерты булды.

## ЗӘКИ НУРИГА 60 ЯШЬ

Күренекле шагыйрь Зәки Нурига 60 яшь тулды. Ул, совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен, СССР Верховный Советы Президиумы Указы нигезендә, Халыклар Дуслыгы ордены белән бүләкләнде.

Казанның Төзүчеләр сараенда шагыйрьнең юбилее хөрмәтенә тантаналы кичә уздырылды. Аны язучы В. Н. Нуруллин ачып җибәрде.

КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, юбилярны КПССның Татарстан өлкә комитеты, ТАССР Верховный Советы Президиумы, ТАССР Министрлар Советы исеменнән котлап, аңа Халыклар Дуслыгы орденын тапшырды.

Зәки Нуриның тормыш һәм иҗат юлы турында филология фәннәре кандидаты Н. Ш. Хисамов сөйләде.

Юбиляр шагыйрьне республикабызның хезмәт коллективлары, партия, совет һәм профсоюз оешмалары, иҗат союзлары, культура учреждениеләре вәкилләре, Йошкар-Оладан, Чабаксардан килгән кунаклар котлады, шулай ук бик күп санлы тәбрикләү телеграммалары укылды.

Кичәдә КПСС өлкә комитеты секретаре Л. М. Смагин, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

Соңыннан Татарстан сәнгать осталары катнашында Зәки Нури әсәрләреннән файдаланып төзелгән концерт бирелде.

* *
*

Шагыйрь Зәки Нури Зеленодольск шәһәренең М. Горький исемендәге культура сараенда әдәбият сөючеләр белән очрашты. Ул укучыларны үзенең иҗат планнары белән таныштырды, шигырьләрен укыды, күп санлы сорауларга җавап бирде.

Кичәдә шулай ук тәнкыйтьче Ринат Мөхәммәдиев, шагыйрь Рәдиф Гатауллин, Роберт Миңнуллин, Зеленодольскида яшәүче язучы Мәхмүт Хәсәнов та катнашты.

## ҖЫРЧЫ ЮБИЛЕЕ

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Фәхри Насретдиновның тууына 70 ел, эшчәнлегенә 50 ел тулуга багышланган юбилей кичәсе булды.

Юбилей кичәсен ТАССР Культура министры урынбасары Р. М. Харисов ачты. Ф. Насретдиновның тормыш юлы һәм иҗаты турында сәнгать фәннәре кандидаты Ч. Н. Бәхтиярова сөйләде.

Юбилярны республикабыздагы хезмәт коллективлары, партия, совет һәм җәмәгать оешмалары, иҗат союзлары, культура учреждениеләре, югары уку йортлары вәкилләре котлады.

Кичәдә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

Соңыннан опера һәм балет театры сәнгать осталары һәм юбилярның үзе катнашында зур концерт булды.

## ТЕАТРГА БҮЛӘК

Татар дәүләт драма һәм комедия театры коллективы бер ай буена Ташкент, Алмалык, Чирчик, Ангрен, Яңа юл сәхнәләрендә чыгыш ясады. Татар әдәбияты классиклары, бүгенге драматурглар Г. Ахунов, Н. Исәнбәт, И. Юзеев әсәрләре буенча иҗат ителгән спектакльләрне тамашачылар җылы кабул итте.

Татар дәүләт драма һәм комедия театры коллективына Үзбәкстан ССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы тапшырылды. Ул бу бүләккә тугандаш культураларны пропагандалауда һәм үзара баетуда, республика хезмәт ияләренә художество-эстетик тәрбия бирүдә актив булышкан өчен лаек булды.

## БӨТЕНСОЮЗ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Калининград шәһәрендә «Укучыларны идея-әхлакый һәм эстетик яктан тәрбияләүдә матур әдәбиятның роле» дигән темага Бөтенсоюз фәнни-практик конференция уздырылды. Әлеге форумда Казаннан педа-

гогия фәннәре кандидаты Фәнис Исламов та катнашты һәм «Укучыларга әхлакый һәм эстетик тәрбия бирүдә татар халык авыз иҗатының роле» дигән темага доклад ясады.

### БӨТЕНРОССИЯ СЕМИНАРЫНДА

Латвиядәге Ян Райнис исемендәге иҗат йортында яшь тәнкыйтьчеләрнең Бөтенроссия семинары булып узды. Ул КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарының ун еллыгына багышлап үткәрелде.

Бу семинарларда Татарстаннан «Казан утлары» журналының сәнгать бүлеге редакторы Мәдәррис Вәлиев (Салих Маннапов) катнашты. Яшь тәнкыйтьченең иҗаты РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре В. В. Дементьев һәм «Яшь гвардия» нәшриятының баш редакторы Н. П. Машовец җитәкчелегендәге семинар группасында тикшерелде һәм уңай бәя алды.

### ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕНДӘ

Әстерханда М. Луконин көннәре булып узды. Мәгълүм булганча, ике тапкыр СССР Дәүләт премиясе лауреаты, күренекле рус шагыйре Михаил Луконин Әстерхан өлкәсенең Киленче исемле татар авылында туган. 1976 елдан бирле бирегә ел саен шигырь бәйрәме уздырыла. Быелгы бәйрәмдә Мәскәү, Ленинград, Мурманск, Саратов, Куйбышев, Волгоград һәм Әстерхан шәһәрләреннән килгән кунаклар катнашты, Татарстаннан шагыйрь Равил Фәйзуллин да килгән иде.

Киленче авылында 1933 елда М. Җәлил дә яшәп киткән. Мәктәп музеенда Җәлилгә багышланган махсус почмак оештырылган.

### «ӘДӘБИ ҖОМГА»ЛАР

Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында яңа сезон узган елның октябрь аенда башланып китте. Аны әдәбиятыбызның аксакалы Гомәр Бәширов ачып җибәрде. Ул истәлекле вакыйгалар, күренекле әдипләр турында сөйләде. Тамашачылар Н. Исәнбәт, Н. Дәүли, Р. Фәйзуллин, Р. Батулла, Рәшит Әхмәтҗанов, Зөлфәт, Р. Хәлиуллина, Э. Гыйрфанова белән очраштылар, Ф. Сөләйманова, Р. Дәминов, И. Биктаһиров кебек талантлы җырчыларның җырларын тыңладылар.

* *
*

Чираттагы «әдәби җомга» шагыйрә Флера Гыйззәтуллина иҗатына багышланды. Аның иҗаты турында язучы Кояш Тимбикова сөйләде. Республикабыз җәмәгатьчелеге котлауларыннан соң юбиляр әсәрләреннән төзелгән концерт күрсәтелде. Соңыннан Ф. Гыйззәтуллина үзенең гражданлык һәм патриотизм хисләре белән сугарылган шигырьләрен укыды.

* *
*

«Әдәби җомга»ларның берсендә күренекле татар совет драматургы Мирхәйдәр Фәйзинең 90 еллыгы билгеләп узылды. Кичәдә язучы Барлас Камалов драматургның иҗаты һәм тормыш юлы турында сөйләде, Татарстанның халык артисты Х. Сәлимҗанов, Татарстанның халык артисткалары С. Садыйкова, Г. Кайбицкая, М. Миңлебаева, М. Фәйзинең туганнары И. Фәйзуллин, С. Фәйзуллина үзләренең истәлекләре белән уртаклаштылар.

Кичәнең концерт өлеше атаклы «Галиябану» җыры белән башланды. Җырчылар Ш. Әхмәтҗанов, М. Зәкиева, Ф. Низамова башкарган җырларны тамашачылар яратып кабул иттеләр.

### СТУДЕНТЛАР ЯНЫНДА

Шагыйрь Илдар Юзеев Казанның культура институтында режиссерлар әзерләүче факультет студентлары белән очрашты. Башта студентлар шагыйрьнең «Таш диварлар авазы» поэмасын сәхнәләштереп күрсәттеләр, «Язылмаган поэма»дан, «Өзелмәс кыллар» поэмасыннан өзекләр укыдылар. Аннары театр, поэзия һәм драматургия турында әңгәмә булды.

### ДУСЛЫК КИЧӘСЕ

Украина башкаласындагы Композиторлар йорты, Киевның 1500 еллыгына багышлап, концертлар циклы оештырды. Яңа циклдагы беренче концерт РСФСРның халык артисты Рөстәм Яхин әсәрләреннән төзелгән иде. Музыка белгече Елена Таранченко тыңлаучыларны композиторның иҗат юлы, аның иң яхшы әсәрләре белән таныштырды. Концертта катнашучылар арасында СССРның халык артисткасы Галина Туфтина, Татарстанның атказанган артисты Геннадий Васько, Татарстанның халык артисткасы Вафирә Гыйззәтулина бар иде.

### ЧАЛЛЫ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА


Тукай районы хуҗалыкларында Чаллы язучылар оешмасы, аның әдәбиятны пропагандалау бюросы оештырган «Хезмәтебезне һәм илһамыбызны КПССның XXVI съезды карарларын тормышка ашыруга багышлыйбыз» дигән әдәбият-сәнгать айлыгы булып үтте.

Районның «Гигант», «Новотроицкий», «Ильбухтинский», «Татарстан», «Бүләк», «Чулпан», «Ворошилов» совхозлары, «Коммунизмга», Чкалов исемендәге, М. Җәлил исемендәге, Калинин исемендәге колхоз хезмәтчәннәре язучылар Разил Вәлиев, Эдуард Касыймов, Газиз Кашапов, Нәҗип Мадъяров, Равил Вәлиев, Кадыйр Сибгатуллин, Рәшит Бәшәров, Ямаш Игәнәй, рус шагыйрьләре Николай Алешков, Валентина Алешкова, Павел Юлаев, Евгений Кувайцев, шәһәрнең танылган үзешчәннәре Фәнүсә Кадыйрова, Азат Хәсәенов, Гөлсинә Сабирова, Илгизәр Закиров, Ренат Гобәйдуллин, Сания Мәҗитова һәм башкалар чыгышларын көтеп алдылар, яратып тыңладылар.

# Күзләреңә әллә күз тидеме?..

**САРА САДЫЙКОВА**
музыкасы

**ФЛЕРА ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА**
сүзләре




2
Чулпан йолдыз күздән җуйды мәллә
Зәңгәр төннең челтәр кашларын?..
Мин барыбер йолдыз-челтәремне
Синнән башка бәйли башламыйм.

3
Мин барыбер бүген килам сиңа
Төн күгемнән йолдыз балкытып...
Учларыңда йолдыз биетер булсаң,
Үрнәкләрен күктән ал отып.

Бәясе 90 тиен.
Цена коп.

Индекс 7321

## КИЛӘСЕ САНДА:

*Проза*

Нурихан Фәттах. **Сызгыра торган уклар.** *Роман.*
Афзал Шамов. **Кире беткән кыз.** *Хәрби корреспондент язмасы.*
Равил Мирхәйдәров. **Безне онытмагыз.** *Повесть.*

*Поэзия*

Равил Фәйзуллин, Роберт Әхмәтҗанов, Рашат Низамиев, Рәфикъ Юнысов. *Шигырьләр.*

*Очерк һәм публицистика*

Рәис Сабиров. **Ульяновлар.**

*Әдәби тәнкыйть*

Ибраһим Нуруллин. **Әдәбиятта шартлылык турында.**

**КАЗАН УТЛАРЫ**
**(ОГНИ КАЗАНИ)** ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал, орган Союза писателей Татарии